Эльмира Шәрифуллина

# МӘХӘББӘТНЕҢ ҖИДЕ ТӨСЕ

Повестьлар, эсселар, хикәяләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ш95

**Шәрифуллина Э.М.**

Мәхәббәтнең җиде төсе: повестьлар, эсселар, хикәяләр / Эльмира Шәрифуллина. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 255 б. — 3000 д. — ISBN 978–5–298–01505–9

Бишек һәм ләхет, яшәү һәм үлем...

Шушы аралыкка сыйган хатирәләр: Ата-Ана кадере, Туган җир бөеклеге, салават күперенең җиде төсен сеңдергән Мәхәббәт газаплары мәкерле дә, ләззәтле дә гомер сукмагын бизәгән галиҗәнап вакыт бизмәнендә бер мизгелгә тиң. Әмма күз ачып йомган аралыктагы бу яшәешебезнең бәрәкәте, кыйммәте нәрсәдә? Язучы Эльмира Шәрифуллинаның психологик кичерешләр белән иҗат ителгән проза әсәрләре укучыны шул хакта уйланырга чакыра.

ISBN 978-5-298-01505-9
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Шәрифуллина Э.М., 2007

Повестьлар

## ***Әтием***

Динә күзен ачканда, ул яткан хастаханә бүлмәсенә бер мизгелгә генә кереп чыга торган кояш инде киткән иде. Алай гына да түгел, көн әллә нинди көлсу томан белән капланган. Күк йөзенең кара пәрдәләре әнә теге ертыла башлаган җиреннән умырылып төшәр дә аның бүлмә тәрәзәсен бөтенләе белән томалап куяр һәм кояш нурын түгел, көн яктысын да кертмәс шикелле тоела. Кыз баланың тәне калтырый башлый, ябынган юрганы астында теше тешкә тиеп өши. Ул гүя бөтен дөньясында берьялгызы калган. Таянырга, ышыкланырга һичбер кеме юк... Чү, томан артында әтисенең гәүдәсе шәйләнә түгелме соң? Тик ул кулын суза башладымы, пыр тузып әллә каян әнисе килеп чыга. Килеп чыга да: «Сөйләшеп кенә кара, мин синеме! — дип яный башлый. — Мин сине туган өеңнән, мәктәбеңнән аерып, әнә шул яткан урыныңнан каерып алып, япан кырга — буар еланнар, ерткыч җанварлар арасына илтеп ташлаячакмын. Син башка бервакытта да миңа «әни» дип эндәшә алмассың. Аңладыңмы?.. Аңладыңмы?.. Аңладыңмы?..» — дип, изүеннән тотып, бар көченә җилтерәтә.

«Аңладым, әни, — ди Динә, әкрен генә. — Аңладым».

«Әни түгел, әнием!» — ди ул, тагын да ныграк җилтерәтеп. Үзе, халат кесәсеннән әзер торсынга салып куйган яулыгын алып, тиз генә башын бәйләп куя.

«Гафу ит, әнием, сине борчыганым өчен, — ди Динә, ашыгып, күптән өйрәтелгән сүзләрне кабатлап, — гафу ит! Мин аңа башка бервакытта да «әти» дип эндәшмәм. Син генә авырма, әнием. Син безне туйдыручы! Син безне киендерүче! Син, син, син...» Әнисе тынычлана. Хәйләкәр генә көлә. «Менә шулай... — ди ләззәтләнеп. Аннары: — Шулай итәләр синең кебек аңгыра сарык бәрәнен», — ди дә яулыгын чишеп алып, халат кесәсенә сала һәм күздән югала.

Әнисе ераклашкач, Динә курка-курка гына томан артында, еракта-еракта басып торган әтисенә карый. Ул тагын да ныграк моңсуланган, тагын да ныграк ябыккан шикелле тоела. Яшьле зәңгәр күзләрен Динәгә төбәгән. Динәгә әкрен генә кулларын да суза. «Кызым, син бит арада иң миһербанлысы. Ник син дә кире кагасың мине? Сагынам бит мин сезне! Яратам бит мин сезне!» — ди ул. «Әтием, мин дә сине бик-бик яратам, — дип пышылдый Динә. — Яратам, бик сагынам. Әмма минем үземне дә һаман кыерсытып, һаман җәберләп торалар бит. Мин бит әни алдында сиңа охшаган булуым өчен дә гаепле. Карашларымның синеке кебек моңсу, чәчләремнең синеке кебек дулкынланып торуы өчен дә күралмыйлар алар мине. Күпме әшәке сүз ишетәм, күпме мыскыллау күрәм мин шуның аркасында. Алар мине өебездән синең белән бергә куган булырлар иде дә, ашагач табак-савытларын юарга, кысталып өйдә йомышын үтәгән этебезнең астын чистартырга кеше кирәк. Кол кирәк аларга, артларыннан җыештырып йөрүче кол. Хәер, син чын мәгънәсендәге кол идең дә бит, тик син дә ярамадың...»

Шәүлә чигенә. Күзләре — Динәдә. Кулы да аңа сузылган. Шул хәлендә әкрен-әкрен артка таба атлый, ерагая бара, үзәкләргә үткәреп соңгы сүзләрен әйтә: «Сау булыгыз! Мин яраттым сезне! Үсеп җиткәч, үзегез әти, үзегез әни булгач аңларсыз әле... Аңларсыз... Аңларсыз...»

*** * ***

Динә саташа иде. Менә ул, шабыр тиргә батып, күзләрен ачты. Ярасы төзәлсә дә, тәне әллә нинди сәер сызлау белән калтырана. «Ашыгыч ярдәм» машинасы белән алып килеп, сукыр эчәгесен кисеп алдылар аның. Тән ярасы болай уңышлы үтте, тик менә күңел ярасы гына...

Ул тагын туңа башлады. Тирә-юньдә аны җылытырлык бер генә әйбер дә, бер генә кеше дә юктыр сыман тоелды. Ә менә әтисе булса? Әтисе ничек тә җылытыр иде. Һичшиксез җылытыр иде. Әтисе кешелекле, намуслы, бик тә чиста күңелле аның. Ничек тә әтисенә хәбәр җибәрәсе, әнисе күрмәгәндә генә аның белән сөйләшәсе, әтисенең киң җилкәсенә сыенасы, иркәләнәсе килде Динәнең. Әнисенә: «Ник сез миңа әтиемне җәлләгән өчен каныгасыз?» — дип каршы әйтәсе килде. Ләкин андый әйтүләрнең ни белән тәмамланганын яхшы белә ул. Шуңа күрә күпчелек очракта Динә дә әтисе күк эндәшми башлады хәзер. Чөнки барыбер аларның сүзе сүз булып кала. Апасы Динара белән бергә аны елатканчы көләләр генә. Аннан ләззәтләнеп, үз-үзләреннән канәгать калып, түгәрәкләнеп утырып чәй эчәләр. Эчеп туйганда гына:

— Чык чәй эчәргә, әтиең кызы! — дип, аны да чакыра әнисе. Әнисенең шул түбәнсетеп әйткән чакыруына чыкмасаң, чәйнекнең суына кадәр түгеп, бөтен ризыкны җыеп куялар. Аннан инде дилбегәне апасы үз кулына ала. «Иртәгә ванна бүлмәсенә бикләп куегыз, көн буена бер кабымлык ипи, бер минутка да яктылык бирмәгез», — дип боера. Әнисе әйтелгәннәргә тулысынча риза була һәм шулай эшли дә. Чөнки ул олы кызыннан үзе дә курка. Ниндидер мәсьәләдә каршылык күрсәтсә, нәрсәдер сорап алмасамы, апа: «Мафиядән морданы җимертергәме?» — дип кенә кычкыра. Кулларын

бөеренә куеп, гәүдәсен тирбәлдереп, арт санын боргалап тора. Әни үзе дә әтием алдына нәкъ шулай итеп килеп баса торган иде. Басар иде дә баштанаяк пычрак сүз белән керендерер иде. Әтием исә соңгы вакытта бу хәлләргә сәерсенеп карамый башлады, элеккеге кебек һич югы бер сүз белән булса да җавап та кайтарып тормый, бары тик әкрен генә атлап өч бүлмәнең иң кечкенәсенә кереп китә торган иде. Керә дә как тимер караватка сузылып ята. Чөнки тора-бара ул кечкенә бүлмәдә бернәрсә дә калдырмады әни. Якын әбием биргән зур-зур йомшак мендәрләр, каз мамыгыннан сырылган юрган, ятак өчен әзерләнгән юка түшәкләр — барысы да безнең урын-җирләргә күчеп бетте.

«Ябынырга берәр нәрсә бир әле», — дигәч, «Балаларымның сәламәтлеге сиңа караганда кыйммәтрәк!» — дип кенә җикерә иде аңа әни. Апа исә, кеше кергәндә шыксыз булып тормасын дип, каплап куйган иске япманы да әтием кулыннан тартып алды беркөнне.

— Әни сатып алды аны, — диде япманы төрми-нитми караңгы бүлмәгә атып бәргәндә.

— Ә нинди акчага сатып алды? — диде әтием, сабыр гына.

Синең тиеннәреңә түгел, билгеле, — диде апа, русчалап, әтием алдында кулларын бутап. — Әниемә өч бала тапкан өчен бирелгән пособиегә алдык!

— Ул йөз сум бик күпкә җиткән булып чыга түгелме соң? Киемнәрегез дә шул пособиегә алынган... — диде әтием, сүзләрен сузыбрак һәм көлемсерәп.

Апа анда да аптырап калмады.

— Әнием кебек акча тота белсәң җитә ул! — диде.

Әтием эндәшмәде. Шул вакытта мин, ник дип әтием апаның яңагына берне чалтыратып җибәрми икән, ул да әллә аның мафиясеннән курка микән, дип уйладым. Мафия малайлары юкса әтиемнең бот төбеннән генә бит инде. Теләсә өч-дүртен бергә болгап ыргыта ала. Ә ул эндәшми. Идәндәге якын әбием сугып биргән җәймәне урамга алып чыгып селки дә, шуны астына салып, курткасын ябынып төн куна.

Әтием без торганчы әллә кайчан эшкә киткән була. Мин моны без торганда урыны суынып, иртән барып кергәндә йоклаган бүлмәсендә хәтта исе дә бетүеннән беләм.

Исе дә калмаган була дигәннән, соңгы вакытта әни ни өчендер этне ишек төбеннән алып, әтием яткан бүлмәгә кертеп, ул ята торган караватның башына бәйләп куя башлады. Әтиемнең исен шул эт йотып бетереп бара кебек тоела миңа. Шуңа күрә эчемнән генә аңа да ачуым чыга. Ләкин эт белән эт була аламмы соң? Әнинең нинди максат белән этебезне әтием яткан бүлмәгә кертүен дә белмим. Сорасаң, тагын бөтен өйне аякка бастырып сүгә башлаячак. Тагын апа белән энемне куенына алып, миңа яңадан-яңа мыскыллау сүзләре әйттерәчәк. Шуңа күрә мин дә эндәшмим. Иң яхшысы дәшми калу дип уйлыйм. Мин дә әтием кебек аз сөйләшергә мәҗбүр була башлармын, ахры. Этебез белән дә күңелемнән генә ачуланышам. Ник ачуланышаммы? Чөнки беркөнне әтиемне идән җәймәсеннән дә мәхрүм итте ул. Ничек икәне мәгълүм инде, алда әйткәнемчә, кысталып.

Әтиемнең эше шундый. Ул әнинең: «Акча җитми. Очын очка ялгап, тиеннәр санап утырырлык булгач, ник өч бала таптырдың миңа, хәерчелек арттырып?!» — дип кычкыруыннан гарык булдымы, әллә күзләрем аз булса да бу мәхшәрне күрми торсын дипме, Себергә эшкә ялланды. Хәзер ул айның яртысын гына өйдә тора. Унбиш көнен Себердә, кырык градуслы эче суыкта безнең өчен «озын берлекләр суга». Әнигә эшләмәскә, балаларны, ягъни безне карарга куша. Әни исә бик теләп безнең белән бергә йокы симертә. Аннан торып киерелә-сузыла да апаны кибеткә җибәрмәкче була. Апа гадәттәгечә, киреләнә. «Динә барсын», — ди. Әни: «Ул әле акча саный белми, аны алдыйлар кибетчеләр, мин синең копилкаңа зәп-зәңгәр бер матур әйбер салырмын», — дип кызыктыра. Апа, зәп-зәңгәр матур әйбернең биш сум акча икәнлеген шунда ук аңлый, киенеп кибеткә чыгып китә. Әни кушканча, ун пирожный алып керә. Олы булганнары өчен апа белән әнигә өчәр, энем белән миңа икешәр тия. Минем урындык турындагы тәлинкәгә пирожныйларның һәрвакыттагыча җимерелгәннәре салынган була. Моны күргәч, юри апа урынына утырмакчы булып карыйм. Апа каравыл кычкыра. Ә әни: «Динә, син үз урыныңны белмисеңме әллә? Хәзер үк үз урыныңа күч!» — дип кычкыра. Минем күңелем тула. Утырмас идем — ашыйсым килә. Мин әкрен генә, эндәшми генә үз урыныма утырам. Сөйләшми генә ашыйм. Эчтән елый-елый ашыйм. Әтиемне исемә төшерәм. Әни җикереп-җикереп кычкырганда, ул да шулай эчтән елап ашый торган булгандыр. Ашаганын йөрәгенә яткыра алмыйча гына. Биредәге өебездән пропискадан төшеп, авылга теркәлгәндә бабам аңа: «Гаилә җылысыннан аерылып, Себер суыкларында катып-өшеп, сәламәтлегеңне бетереп йөрмисеңме әллә, улым?» — дигән иде дә, әтием:

— Монда бигрәк әз түлиләр бит, әткәй, — диде.

Минем уемча, Себер суыгы түгел, безнең гаилә суыгы куркытты аны. Шул кадерсез мөнәсәбәтләрне аз булса да күрми торыр өчен китте ул Котып ягына.

Әмма әтиемнең төянеп кайтып кергән сәгатьләре барыбер ниндидер бәйрәм төсен ала иде. Ике метрга якын озын буйлы әтиемнең аркасына күтәреп кайткан рюкзагы үзеннән дә озынрак була торган иде. Нәрсәләр генә юк анда! Күршеләребезнең төшенә дә кермәгән әллә нинди тәмле әйберләр, матур-матур тартмаларга салынган уенчыклар, төрле төстәге колготкилар, җылы эчле йомшак киемнәр...

Күршеләребезнең төшенә дә кермәгән дип әйтүем шуңа, чөнки ул елларда кибетләрдә мин санаганнарның берсе дә юк иде. Булганнарына да озын-озын чират. Көн буе шундый чиратларда торганда хәтта, «чираты килеп җиткәндә генә башы әйләнеп егылган икән», йә булмаса «чиратта торганда кысып кабыргасын сындырганнар икән, хәтта таптап үтергәннәр» кебек сүзләр дә сөйлиләр иде. Ул яктан чыгып караганда да минем әни бу мәшәкатьләрнең барыннан да азат булды. Әни никадәр генә танырга теләмәсә дә, әтием бик юмарт куллы, мәгънәле кеше иде. Ул, мәсәлән, үзе кабып та карамый торган шоколадларны берәрләп, унарлап та түгел, йөзәрләп, тартмасы белән алып кайтты. Әллә нинди фасоннарга кертеп, кырлап, сырлап дигәндәй эшләнгән матур банкаларга салынган, капкачы борып ачыла торган соклар, компотлар дисеңме, әллә нинди кыйммәтле балык консервылары, ит ризыклары, бизәкле пакетлардагы печенье, конфет ише нәрсәләр дисеңме, хәлвә, варенье кебек тәм-томнар — рюкзактан чыгып, тау кебек булып идәнгә өелә иде. Әле шуның өстенә бер-берсеннән икешәр-өчәр чиләк чыга торган кәгазь тартмаларга салынган мүк җиләге, нарат җиләкләре. Әтием аларны эштән соң Себернең сазлы, шомлы урманнарыннан, караңгы төшкәч, кесә фонарьлары яндыра-яндыра җыя торган булган. Арып-талып эштән кайткач та, җилекләреңә үтеп керерлек шул суыкта берәмтекләп чиләк-чиләк җиләк җыеп кара әле син! Ул да кеше. Эш сәгате беткәч, аның да җылы урынында ял итәргә хакы булгандыр. Әмма аның безнең янга бай итеп, мул итеп кайтасы килгән, күрәсең... Һай, без бала-чагалар ул вакытта бу җиләкләрнең нинди зур дәвалау көченә ия булган гаҗәеп кыйммәтле нигъмәтләр икәнен башыбызга да китерми идек шул. Шуңа күрә әтиебез хезмәтенең олылыгын, аның кайгыртучанлыгын, тырышлыгын да күрмәгәнбез. Ә әни күрергә теләмәгән. Һәм бездә әтиебезгә карата тырнак очы кадәр дә рәхмәт хисе тәрбияләмәгән...

Әтием алып кайткан әйберләр әле болар гына да түгел бит. Менә әрбет чикләвеге. Анысы тагы нинди хәзинә?! Мин аны берәр уч, берәр уч итеп классташларыма да бирә идем. Якынракларына, ягъни дус кызларыма, чикләвекле күркәләрне бүләк итәм. Күркәләр дәрәҗәлерәк. Беренчедән, карап торырга матур, икенчедән, чикләвеге дә өч-дүрт уч чыга. Иптәш кызларыма чәчәкле сурәтле буш савытлар, укалы шоколад кәгазьләрен биреп тә абруемны күтәрә идем әле. Ә инде конфет, хәлвәләрне әз-әз генә каптырып та каратсам — мине сырып алалар, мин һәрвакыт игътибар үзәгендә. Чөнки сабакташларымның кайберләренең мондый ризыкларны хәтта бәйрәм вакытларында да ашаганнары юк икән. Шуңа күрә алар миңа һәрвакыт кызыгып, сокланып карый иде. Ә безнең өчен алар, әйткәнемчә, артык кадерле әйберләр дә түгел. Алай дисәң, әнием, ни өчендер, әтиемнең туганнары килсә, андый әйберләрне бик еракка яшерә. Бервакыт якын әбием авылдан: «Яңа суйган итне сезгә дә авыз иттерәсем килде», — дип, иңсәсенә аллы-артлы зур сумкалар асып килеп керде. Үзе әйткәндәй, таш кебек авыр сумкаларын бушаткач, чәй куйдык. Шунда әни әбиемә авыз иттерергә дип алып чыга башлаган ассорти компотымны кулымнан тартып алды.

— Ни өчен шулкадәр дә юләр син, ә? Ничек бәләкәй генә булса да башыңны уйлата белмисең? Гел шундый компотлар ашап яталар икән дип сорап әтиеңне җәфалаячаклар бит, — диде минем әтиемне кызгану хисемә басым ясагандай итеп.

Телемнән тартып әйттергәндәй:

— Ә без сорамыйча да бирик. Әтиемне тудырган бит ул, син безне тудырган кебек, — дидем.

Әмма бу «батырлыгым» өчен әбием киткәч ничек каһәрләнгәнемне үзем генә беләм...

Бер начарның бер яхшысы була, диләр бит. Нәкъ шушы сөйләшү, әнинең нәкъ шушы кыланмышы икенче яклап та күзләремне ачты. Шул көннән башлап безнең гаиләдә әтием ягы туганнарының әнием ягы туганнарыннан нинди зур аерма белән кабул ителүенә игътибар итә башладым.

— Үз туганнарыма никадәр бирсәм, шуның кадәр үк күчтәнәч алам, — дип мактана торган гадәте бар әнинең әтиемнең күргән-белгәннәре каршында. Ләкин әни алдаша. Хәтта нык итеп алдаша иде. Әтиемнең әнисе килсә (нигездә, әтием ягыннан ул гына килә дә), икешәр ай ашарлык ит күтәреп китерә. Казы, үрдәге, күркәсе, тавык-чебеше янына сөтен, каймагын, эремчеген алып килә һәм күп булса икене кунып, бабагыз берүзе, маллар күп бит, дип кайтып та китә. Әле шул кунган кичләрендә дә үзе җегерләп алып килгән җептән кайсыбызга оекбаш, кайсыбызга бияләй бәйләп калдыра. «Бик җылы булыр, Алла боерса, бик мамыклы бәрән җонынnan бәйләдем», — дип сөйләнә. Ә без аның бу сөйләнүләренә артык әһәмият тә бирмибез. Әни дә, туйдырдың инде дигәндәй илтифатсыз гына:

— Ярар, ярар, рәхмәт, — дип куя. — Барыбыздан да ныграк малаең тишә оекбашларны, шуңа күбрәк бәйлә! — ди.

— Йөрүе күптер, — ди әбием. — Ул киемнәрен бик сак, бик чиста кия иде үзе, — дип өсти.

Ә чынлыкта әни әтиемә дип бәйләнгән оекбашларны апасының иренә, малайларына биреп җибәрә дә алардан әйләнеп килгән тишекләрне, малаең туздырды дип, авылга озата. Дөрес, әбием: «Кая, килен, балаларның нинди баш сабасы, ямыйсы әйберләре бар», — дип, үзе үк сорап ала аларны. Һәм, этиләре бәрәңгегә кайткач алып китәр, дип, үзе үк күтәреп алып та китә. Әмма минем шулкадәр тырышып, безгә ихлас күңеленнән булышып йөргән әбиемне алдаганы, аннан астыртын гына көлгәне өчен әнигә ачуым килә. Кыскасы, әтиемне генә түгел, аның әти-әнисен, туганнарын да яратмый минем әни.

Бервакыт этиемнең сеңлесе, Бакуга барган җиреннән мохер җеп алып кайтып, үз кулы белән энигә косынка бәйләп биргән иде. Аның да бу изгелеге үзенә явызлык булып әйләнеп кайтты.

— Җебен кыйбатка саткан! — диде эни, әбием бер килгәндә, косынкасын диванга ыргытып.

Әбием башта аңышмый торды. Аннан:

— Булмас, килен. Арттырасы килсә, чит кешегә саткан булыр иде, — диде. — Үз туганына арттырып сата димени?

— Оятсызлар шулай эшли, — диде эни.

— Тавыш чыгарма, килен. Күпмегә арттырган, әйт, үзем түлим, — диде әбием, кулъяулыгына төйнәлгән акчасын кесәсеннән алып.

— Кирәкми, синнән алмыйм мин аны. Тезләндереп, гафу үтендереп, үзеннән түләттерәм, — диде эни, бөеренә таянып. Халатының ике генә төймәсе эләктерелгәнлектән, ул шәрә юан ботларын аерып, әбием алдында бик ямьсез итеп басып тора иде. Әбием хәтта, йөзен яулык чите белән каплап, башын читкә борды.

— Хаталанма, килен, балаларымның андый гадәтләре юк, — диде әбием, бирешәсе килмичә. — Өч бала үстергәнегезне беләләр, сездән алырга түгел, җай чыккан саен үзләре бирергә тырышалар, — диде.

— Балаларыңны фәрештә дип уйлыйсыңмы әллә? Мин бала тапмагач, гел минем гайбәтне сөйләдегез. Менә исбатладым мин сезгә үземнең кысыр түгеллегемне. Алардан да уздырдым, өчне таптым! — диде эни, әбием алдында тагын да кыяфәтсезрәк хәрәкәтләр ясап.

— Исән булсыннар, килен! Бик рәхмәт табуың өчен! Баланы табу гына түгел, тәрбия итәргә, үстерергә дә кирәк әле аны, Алла ярдәменнән ташламасын! — диде әбием, йомшак кына итеп. — Шикләнмә, килен, балаларымның берсе дә синең белән булышмады, кайда нинди яхшы табиб барлыгын белешеп, дәваларга гына тырыштылар үзеңне. Кая, китим мин булмаса, килен. Болай тарткалашып утырырга дип килмәдем, — диде ул, кузгалып.

— Ак юл! — диде эни русчалап һәм туалетка кереп китте. Әбием артыннан ишекне мин бикләп калдым.

Ә энинең туганнары килсә, безнең өйдә хәмерле табын кору, җир җимертеп сөйләшү, шау-шу, ыгы-зыгы башлана. Андый «бәйрәмнәр» атна-ун көн буена дәвам итә.

Салмыш вакытта этинең дә теле ачыла. Бервакыт шулай баҗасы табын янында, энигә ярарга тырышып булса кирәк:

— Булдырды минем балдыз, бөтен өшкерүче-төкерүче әбиләрне әйләнеп чыкса чыкты, барыбер үзенекен итте, тапты бит бала. Җиде елдан соң булса да тапты, — диде. Аннан соң, этигә карап: — Йә, баҗай, моннан болай активрак инде, давай. Бушка узган елларны куып җитәргә кирәк, — дип өстәде.

Әнием шунда:

— Ул үшән үгезгә карап ятсаң гел баласыз калырга мөмкин иде, — димәсенме!

Әтием сикереп торды да:

— Нәрсә, Динара минеке түгелмени? — дип сорады.

Әни кызарды. Ялгыш җавап биргәнен аңлады булса кирәк. Ләкин сүз инде авызыннан ычкынган иде.

Әтием артыннан баҗасы торып басты.

— Утыр әле, әйдә, тынычлан әле, әйдә, берне тотып куйыйк...

Ул арада энинең апасы чәчрәп чыгып иренә ташланды.

— Кирәк-кирәкмәгәнне кузгатып син утырасың, тәпәч. Авызыңа керсә, ни сөйләгәнеңне белмисең, тавык мие ашаган нәрсә, — дип тузынды.

«Тавык мие» — аның яраткан сүзе. Димәк, тавыкныкы кадәр дә башың юк, дип әйтәсе килә аның иренә.

Әтием, кабатлап:

— Әйт син, әйт, нигә ярты юлда калдырасың. Димәк, минеке түгел, әйеме? — дип, басым ясап сорады.

Әни бераз уш җыйган иде булса кирәк — үзе этигә ташланды.

— Менә, ишеттегезме, Динараны минеке түгел, ди. Оятсыз. Җирбит! Син ажгырып торган ир булсаң, мин җиде ел балага узмый йөрми идем, — дип тезде. Һәм үкереп елап йокы бүлмәсенә кереп китте. Күңелсез ыгы-зыгы башланды.

Әтием тагын эчте дә үзалдына сөйләнеп утыра башлады: —

Һе, ажгырып торган ир? Әнә коляскадагы ирдән дә табалар, маясы урынында булса, — диде. Баҗасы ватык магнитофон кебек: «Баҗай, зурга җибәрмә, баҗай, зурга җибәрмә!» — дип, һаман бер сүзне кабатлады. Энинең апасы, йокы бүлмәсеннән чыгып, этиемнең энидән гафу үтенүен таләп итәргә тотынды.

Әтием, башын өстәлгә иеп утырган хәлдә:

— Нәрсә, үшән үгездән көтеп ятсаң булмый иде, диме? Менә сиңа иске авыздан яңа сүз. Кырын-кырын йөргәнен сизештерә идем инде мин аның. Тик яратам, сине генә яратам, аерылмыйк, дип, алдыма тезләнеп елагач кызгандым шул. Аерылышырга биргән гаризамны кире барып алдым. Иртәгә суд була дигән көнне. Ышандым шул. Ә ул менә башка күсәк белән орды... — дип, үзалдына сөйләнде дә сөйләнде әтием.

Әниемнең апасы, әтиемнең җилкәсенә таянып, хәйләкәр тавыш белән:

— Ул алай дип әйтмәде. Син үзең: «Динара минеке түгел», — дидең, бар, кереп гафу үтен хәзер үк хатыныңнан! — дип өндәде.

Әтием, торып, әни янына кереп китте. Әни караватка капланып елаган булып ята иде. Әнинең апасы сару кайнаткыч кирәкмәгән сүзләр белән мәсьәләне һаман катлауландыра торды.

— Сеңлем, тор, ирең тезләнеп гафу үтенергә керде яныңа, — диде.

Әтием, аңа каерылып:

— Нишләп әле мин тезләнеп гафу үтенергә тиеш? Мин, кемнән мөгез куйдырттың, дип сорарга кердем, — диде.

Әни кинәт кенә торып утырды да, бөтен көченә кычкырып:

— Мин синең белән сөйләшергә дә теләмим. Бар, күземә күренмә, ычкын моннан! — диде һәм тагын да үкеребрәк елый башлады.

Әти:

— Рәхмәт! Рәхмәт, күрергә дә теләмәгәч, — дип, әкрен генә атлап йокы бүлмәсеннән чыкты, өстәлдән алып бер стакан су эчте дә диван почмагына барып утырды. Һәм бераз телевизор караганнан соң, башын кыңгыр салып йоклап та китте.

Шушы вакыйгадан соң мин аларның кабат бу темага әйләнеп кайтканнарын белмим. Әмма әлеге сөйләшү минем күңелемдә тирән шик уятты. Ни дисәң дә, энем белән мин әтиемә охшаганбыз, ә менә апам — холкы белән дә, йөз чалымнары белән дә башкарак. Шуның өстенә ул әллә нинди үзенә бертөрле усал да, тиз кызып китүчән дә. Мин аның бу сыйфатын әтине чын мәгънәсендә яратмавыннан чыгып та әйтәм. Әтием нинди дә булса киңәш яки үгет кебек сүз әйтсә, апа, урам малайларына кычкырган кебек итеп:

— Саруымны кайнатма! — ди.

Әни исә, апаның җавабыннан бик канәгать булып, бер кырыйда көлеп басып тора. Әтием эндәшми, тәмәкесен ала да ишек артына чыгып китә.

Русчалап сөйләшү безнең өйдә гадәти хәл санала. Бу әтиемне тагын бер кат түбәнсетү өчен дә кирәк, күрәсең. Чөнки әтием авыл егете. Русчасы аралашырга җитсә дә, әни белән апаның явыз теленә җавап кайтарырга җитми. Аннан соң, әйткәнемчә, соңгы вакытта, гомумән, сөйләшмәскә әйләнеп бара ул.

Шушы вакыйгадан соң әнинең туганнары әтием өйдә юк чагында килә башладылар. «Бәйрәмнәре» эти югында үтсә дә, бурычын ул кайткач түләргә туры килә иде. Йә акчалата, йә аракылата. Әни аны әтиемә, баҗаң эчте, дип аңлата, чынлыкта исә баҗа белән бергә апасы да, апасына ияреп әни дә бертигез чөмерә. Үзләре ялыкканчы торганнан соң, әни аларны балконда яткан мүк, нарат җиләкләрен күтәртеп, эрбет чикләвеге, авылдан әбием алып килгән итләрне, оекбашларны биреп озата.

— Ярый әле килдегез, унбиш көн буена нишләр идем берүзем, — ди әни, рәхмәт әйтеп. — Балалар бакчасындагы тәрбияче кебек шушыларны саклап, беркая бара алмыйча яшьлегем үтә.

— Соң, чыккалап йөр, — ди апасы, сеңлесенең хәленә керергә теләгәндәй. — Унбиш көн буена алар да тик кенә йөрмиләрдер әле. Хәзерге ирләргә ышансаң?! — дип өсти кырын күзе белән үз иренә карап. — Әллә сине генә уйлап, сине генә сагынып ята дип уйлыйсыңмы? Алар җыенысы бер чыбыктан сөрелгән. Әйбәт дип йөргән җизнәң дә әнә бертуган абыебызның хатыны белән...

— Беркем дә себерелмәгән, — ди җизни тиешле кеше, аның сүзен бүлдереп. — Хатын-кыз белән елмаеп исәнләшергә дә ярамый алдыгызда. Үз туганыгыздан көнләшеп теңкәгә тиясез...

Әнинең апасы исә, иренең сүзенә һич илтифат итмичә, сеңлесенә карап җыр суза.

Сары сандугач ник булдың,
Сайрамагач ник кундың?
Янымдагы яр булмагач,
Җан көйдереп ник тудың?

Сандугачым, гүзәлем,
Тибрәтмә тал үзәген.
Ятларны «гүзәлем» диеп,
Үзәгеңне өзәрмен!.. —

дип, берничә такмак та җырлап бирә. Апасы бик күп җыр белә, кирәк кешесенә мәҗлесләрдә такмак белән генә төрттерә иде.

— Ул безне түгел, әнисен сагынып кайта. Кайтып бер атна тора да тизрәк авылларына йөгерә, — ди әни, җырга бөтенләй дә илтифат бирмичә.

Якын бабам белән якын әбием үстергән бозау итен күтәреп китеп баручы кунакларыбыз эндәшми. Соң, сеңлем, ул малларга печәне, саламы кирәктер бит. Бәрәңгесе дә карамыйча үсми. Бөтен ашаганыгыз авылдан лабаса, дип берсе дә әйтми. Хәер, берсе дә диюем урынсыз. Чөнки ул да иренең телен күптән тешләткән булса кирәк. Аның ире дә эти кебек эчеп алса гына азрак сүзгә катнаша. Һәр ике гаиләдә алар үзләре баш, үзләре түш. Гадел булсалар, баш булсалар да ярар иде дә... Әнә бит апасы һаман кирегә сукалый:

— Монысы аларның үги баласы булды инде. Эшләргә дисәң ул, ә бөтен тапкан-табынганнарын төпчекләренә агызып торалар, — дип, утка керосин сибә.

— Акчасын да шуларга кайтара дип уйлыйм әле мин аның. Юкса бирерләр сиңа бушка шулкадәр ит! — ди әни, нindидер уйчанлык белән.

— Билгеле шулай, — ди апасы.

Һәм, ниһаять, алар утырган автобус кузгалып китә.

* * *

Минем әтием белән әни бик соң өйләнешкәннәр. Әтиемә утыз тулып үткәндә, әни утыз яшенә якынлашканда. Әтием минем тышкы табигате белән юаш булса да, эчке дөньясы белән үзенә бертөрле тирән кеше. Туен да кеше төсле итеп кенә үткәрмәгән. Әнинең эти-әнисе өлкәнрәк яшьтә булып, «авылга кайтып йөри алмыйбыз» дигәч, төпчек кызларының туен күрми калмасыннар дип, әтием мәҗлесне алар ягында, Казанда ясаган. Ипподромга барып туй атлары сөйләшкән. Чуклы-чачаклы итеп бизәлгән, биеп торган юртаклар, укалы кашёвкалар гадәти таксилардан ун бәягә артык торса да, гомер юлын матур итеп башларга тырышкан. Язылышуын да шәһәрнең үзәк — иң дәрәҗәле загсында теркәлгәннәр. Ул кадәресен оештырырга әтиемнең апасы ярдәм иткән. Туй фотоларына карасам, минем хәзер дә күзләремә яшь килә башлый. Әтием озын буйлы, киң җилкәле, пөхтә итеп киенгән соклангыч ир кеше. Әнә, әнине кулларына күтәреп, баскычтан менеп бара... Алга китеп әйтим, энемне тапкан елны да, бозлавыкта аягын сындыргач, дүртенче катка гел күтәреп кенә йөртте ул әнине. Шуның өстенә әтием бик басынкы, бик ипле холыклы. Кеше белән эләгешеп, үч саклап та йөрми. Тик әтием беркатлы, бик тиз ышанучан. Менә шул гадәте, үзе гадел булгач, башкалар да гаделлек белән җавап бирергә тиеш дигән сабыйларча берьяклы хөкем йөртүе харап итте кебек аны.

Әни, әйткәнемчә, шәһәр кызы. Һәрвакыт эти-әнисеннән узып сөйләшә торган, кияүгә чыкканчы әнисе әзерләгәнне ашап, әзергә-бәзер булып яшәгән бер иркә зат. Инде утырып калу куркынычы янаган сазаган кыз булганлыктан, ерак әбием белән ерак бабам, үз тиңен тапмасмы дигән уй белән булса кирәк, аны төрле поход, экскурсияләргә барулардан, аулак өйләргә йөрүләрдән тыймый башлаганнар. Чынлап та, шундый сәяхәтләренең берсендә — Казаннан Таллы Күл шәһәренә иптәш кызының туена килгәч этине очрата ул. Очрата да каптырып та ала. Шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатиры барлыгын да белгәч, тиз генә кочагына да сала... Шулай итеп, үзенең өлгерлеге, үткенлеге аркасында әни менә дигән кирпеч йортта, балконлы ике бүлмәле фатирда, моңарчы күрмәгән яхшы шартларда яши башлый. Ни өчен моңарчы күрмәгән дип әйтәм, чөнки ул, башкалабызда торса да, шәһәр читендә, уңайлыклары булмаган иске агач йортта яшәгән була. Ә биредә өй иркен, бала-чага юк. Ирне кая теләсәң шунда борып була, ашарга әзерләргә яратмый торган әнине эти бик еш ресторанга алып бара. Өстәвенә комачау итәр каенанасы, каенатасы, туганнары да күренми, барысы да читтә, һәммәсе үз тормышы белән яши. Ә эти-әнисе, фатир алсын өчен улларына пропискага кереп торсалар да, авылда үз хуҗалыклары белән көн итә. Менә шулай итеп җәннәт эченә чума минем әни.

Каената белән каенанасының тормышлары иркен. Бакчасы, бакчасында мунчасы дигәндәй, абзар тулы мал-туары тагын. Кайтканда әтием белән әнине дә зурлап кунак итәләр. Алар кайтуга туганнарын ашка җыеп алалар. Бәйрәм ашы — кара каршы, аннан соң үзләрен дә бер-бер артлы йә чәйгә, йә ашка чакыралар. Ә инде кара күзле, кыска чәчле, күп сүзен русчалатып сөйләшә торган килен авыл кызлары янында чит планетадан килгән канатсыз фәрештә кебек күренә. Якын әбием үзе дә өрмәгән урындыкка да утыртмый аны. Соңарып өйләнгән улына килене гаилә рәхәте күрсәтсен дип тели.

Ләкин икесе ике мохиттә тәрбияләнгән кешеләрнең тормышка карашлары төрлечә була икән шул. Әни эшләмичә тәмле ашарга яратса, әтием, сыгылып төшеп, борыны белән җир сөрә. Хәтта шундый хәлдә дә әни аны үзенең зеңләп торган көчле тавышы белән бик тиз бастыра, үзе әйтмешли, минут эчендә авызын яба иде. Болай да йомшак кына, әкрен генә сөйләшүче әтием сәерсенеп, бөтенләй югалып кала, әмма күтәрелеп бәрелми. Шул чагында чәчрәп апам килеп җитә һәм һичбер кирәкмәгәндә әнигә «ярдәмгә» ташлана.

Әтием күзгә күренеп бөрешә, иңнәре түбән салына, һәм әнигә:

— Син нәрсәгә өйрәтәсең балаларны? — ди.

Әни исә, тагы да гайрәтләнеп:

— Мин өйрәтмим аларны, хәзер алар зур. Кемнең кем икәнен үзләре күрә, — ди. — Белдеңме инде, минә синең беркемең дә юк. Ә минем өч балам бар! — дип күкрәк кага.

Әнинең безнең адреска әйтелгән «алар хәзер зур үсте» дигән сүзе бигрәк тә апаны канатландыра.

— Каян туган соң ул балалар? Кем ашаткан, кем туйдырган аларны? — ди әтием, гаҗиз калып.

— Син Себердә йөргәндә үзем ашаттым, үзем тәрбияләдем. Аннан кайткач та тизрәк анаңнар янына ашыга идең, синең бала караганың булмады, — диде әни.

— Син яхшылыкны аңламыйсың. Ашка таш ату — иң түбән сыйфат! — ди әтием, өзгәләнеп. Һәм башкача, әни күпме генә кычкырса да, җавап кайтармый. Тагын тәмәкесен ала да ишек төбенә чыгып китә.

Бервакыт шулай кышкы суыкта әтием бер арыш капчыгын аркасына асып, икенчесен кулына күтәреп, тирләп-пешеп килеп керде.

— Урмандагы аю кебек син, куркып качарлык, — диде әни ишек төбендә торган әтиемә.

— Капчыклары авыр булды. Арыдым әле, — диде әтием, иплэп кенә.

— Арысаң йөрмә, — диде әни. — Кайтуыңа берәр хатын табып торалар, ахрысы. Бетмәгән авыл булды.

— Башта исәнләшер идең, — диде әтием, бүрегендәге карын кага-кага.

— Бездә килеп кергән кеше исәнләшә, кадерлем! Ул турыда күптән белергә вакыт, — диде әни ирония белән.

Дөрестән дә... бернинди культурасы юк.

— Авыл-авыл инде, әйеме, әнием! — дип чәрелдәп апам килеп чыкты. Аннан, әнигә сыенып: — Мин дә куркып киттем, капчыкларын тегендә дә, монда да аскан, нәкъ аю инде менә.

— Телегезгә салынмагыз. Алып килгән әйберләрне урнаштырыгыз. Сөт-каймаклары түгелмәсен, итләрен балконга чыгарыгыз, — диде әтием.

Мондый вакытларда әтиемне яклап чыгу файдасыз икәнлеген мин инде күптәннән аңладым. Әни белән апа икесе бергә өстемә очып куналар да әллә нинди җәзалар уйлап табалар. Шуның өчен бу юлы өйдә апам белән икәүдән икәү калгач кына сүз башларга булдым.

— Апам, әтиемнең арыш капчыклары күтәреп йөрүенең сәбәбе — әбиемнең мондагы сумкаларын җыеп җибәрмәүдән бит, — дидем.

Апам бераз гына уйланып торды да, теле телгә йокмыйча:

— Әйт, нинди сумка аларныкы? Теге, миңа балконнан ыргытканда агач башына эленеп калганымы? Аны инде кояш ашап бетергән. Әллә автобуста әшәке малайлар кискәнен әйтәсеңме? — дип, мыскыллы тавыш белән тезеп китте.

Мин, аңа карамастан:

— Барысы да әбием теккән, авыл белән ике арада йөри торган сумкалар алар, — дидем.

— Моны сиңа ул санап күрсәттеме? — диде апа, әтиебез исеменә ишарә ясап. — Аннан, йөзен чытып: Нинди вакчыл, — дип өстәде.

— Әти бу хакта белми дә. Моны сиңа мин санап күрсәтәм, — дидем мин апама. — Үзегез көләсез, үзегез әти күтәреп ташыганны ашыйсыз.

— Билгеле, көләбез, — диде апам, кулларын җәеп. — Чөнки без аяк өсте йоклап йөрмибез сезнең кебек. Тере мәетләр!

— Димәк, мин дә тере мәет? — дидем мин, апама бик нык ачуым килеп. — Әтине сез тере мәет иттегез. Ул башта бөтенләй дә андый түгел иде. Сезнең чамасыз оятсызлыгыгыз телсез итте аны! Бөтен дусларыннан, туганнарыннан аерып җанын үтердегез. Шәүләсе генә йөри аның хәзер безнең арада.

Апам миннән мондый каршылыкны көтмәгән иде. Ул үзенең бирешә башлаганын сизде. Сүзсез калып ике-өч секунд чамасы басып торды да кинәт, нәрсәдер исенә төшкәндәй, йөгереп күрше бүлмәгә кереп китте һәм әнинең укол ясый торган шприцын күтәреп чыкты.

— Беләсеңме, син тагы шул ахмакны яклап талашсаң, мин сиңа йоклата торган дару җибәрәм, — диде.

Апамның бу сүзләре мине шиккә салды. Мин чынлап та уколдан куркам. Аның шулай янавы тагы да куркынычрак иде. Әтием кебек, мин дә телемне тешләп өнсез калдым.

Апам өстен чыкты. Андагы җиңүче кыяфәте үзен тагын да иркенрәк, батыррак тотарга юл ачты. Соңгы вакытта болай да апамның җиткән кыз булуына басым ясала иде һәм аны киендерү беренче максат итеп куела башлады. Ә беркөнне әни тездән дә югарырак менеп торган мех эчле, кыйммәтле итекләр, күн куртка, әллә ниткән матур бүрек алып кигерде аңа. Ял көннәрендә эшләр өчен, базардагы танышы янына эшкә дә урнаштырды. Бу эштә апам үзенең бик «кирәкле кишер яфрагы» икәнлеген тиз үк күрсәтә дә башлады. Әйтми-нитми югала торганга әйләнде. Тик барыбер әнинең сер бирәсе килмәде. Ике сүзнең берендә: «Динара хәзер үзен-үзе киендерә», — дип әйтә иде.

— Базар яшь кыз баланы юньлегә өйрәтми. Яхшы вакытта туктасын, ач та, ялангач та түгел бит ул! — диде әтием беркөнне, шактый таләпчән итеп.

— Нәрсәсе бар соң? Кеше арасына киеп чыгарга, йә, нәрсәсе бар? — дип кызып китте әни.

— Акча синдә бит, нишләп алмыйсың, нишләп киендермисең?

— Үзе эшли башлагач ялангач түгел инде, — дип, әтиемнең канына тоз салды әни. — Көн саен йөз сум ала хәзер, Аллага шөкер, иптәш хатыныма булыша.

— Ә укуы? — диде әтием, һаман да төп мәсьәләне кайгыртып.

— Укый да, эшли дә. Минем балаларым барысына да җитешә. Сиңа ялынычыбыз бетте хәзер, — диде ул, шактый дорфа итеп. Әтием эндәшмәде.

Көннәр шулай үтте. Дәрес калдырганы өчен апама кисәтү ясый башладылар. Ә беркөнне, әти-әнине директорга чакырып, минем арттан хат җибәрделәр. Әтинең Себердә чагы иде.

Татар теленнән мине дә, апамны да бер үк укытучы укыта — Рәхимә Шаимовна. Җитмәсә, ул апамның класс җитәкчесе дә. Иртән турыбыздан үтеп барганда, әни аны эндәшеп туктатты. Туктатты да:

— Динараның мәктәптән күңеле кайтуына син гаепле, — дип тавыш күтәрде. — Син укытучы түгел, әләкче, — диде. — Эшнең директорга барып җитүенә син гаепле. Җүнле укытучы башта баланың анасы белән сөйләшә ул!

Укытучым нәрсәләр дип җавап биргәндер, кычкырып сөйләшмәгәч, мин аның сүзләрен ишетмәдем, әмма әнинең әче тавышы бөтен ишегалдын яңгыратты.

— Бала-чага артыннан кәгазь җибәрә, имеш. Шушыннан үтеп-сүтеп йөрисең бит. Кер дә сөйләш идең, шуның өчен көрәп акча аласың бит. — Ул кызуы белән тагын әлләниләр дип кычкырды. Тик минем аңым аның башка бер генә сүзен дә кабул итмәде. Бары тик күз алдымда бертуктаусыз ачылып ябылган авызы гына торып калды. Һәм бу ямьсез күренеш бик озак тынгы бирмәде. Укытучымнан әни өчен

тезләнеп гафу үтенәсем, шул кечтә үк торган җирен эзләп китәсем килде. Ләкин уемны тормышка ашыру өчен үземдә һичбер төрле көч таба алмадым. Алай гына да түгел, икенче, өченче көннәрдә дә мөгаллимем каршына барып сүз башламадым. Ә ул исә мине гүя күрми иде. Дәресләрдә атна буе минем фамилиямне атамады. Кыяр-кыймас кына кул күтәрсәм дә, сорамады. Аның миңа карата мондый битараф мөнәсәбәте тәмам хәлемне алды. Татар теле дәресләре үтүгә, юынырга кергән булып, елап күңелемне бушатып чыга башладым. Өйгә кайткач исә әллә ничә тапкыр укытучым үткәргән матур дәресләр турында сөйләп әнине сокландырасым, мөгаллимәмә карата мәхәббәт уятасым килде. Аның Рәхимә Шаимовна белән бик яхшы мөнәсәбәттә булуын теләдем. Тик сүз башлап җибәрә алмадым. Беренчедән, әни алдында дәрәҗәм юклыгын белү мине бу эштән тыеп торгандыр дип уйлыйм. Икенчедән, башын кисмәгә бирсә дә, сүзен бирмәс әни, минем бу тырышлыгымнан кабынып китеп, яңа җәнҗал гына куптарыр дип курыктым. Тик шушы вакыйгадан соң мин өйдә аз сөйләшә торган булып калдым, әтием кебек, үз эчемә бикләндем. Нәтиҗәдә тагын бер яңа кушаматка ия булдым. «Тешләк!» «Атасы кебек тешләк!»

Хәер, мине инде мондый кушаматлар борчымый. Мине фәкать бер әйбер, укытучымның калган хәтере генә борчый иде. Аның белән элекке кебек рәхәтләнеп сөйләшеп утыру, элекке кебек шатлана-шатлана җавап бирүләр, бишле билгесе алу теләкләре уянмавы борчый. Якын әбиемнең: «Калган хәтер белән үткән гомер кайтмый шу-ул», — дип, үзалдына сөйләнеп йөрүләре искә төшә дә, күңелем тула. Шулай ук мин аның рәнҗүен гомерем буе иңнәремдә йөртермен микәнни дип уйлыйм.

Тик апамның чираттагы «югалуы» минем бу авыр уйларымның икенче төрлесен тудырды. Уку елы тәмамланырга санаулы көннәр генә калган иде. Укытучымны бер-ике мәртәбә күрү мөмкинлегем булса да, аның авырып хастаханәгә кереп ятуы сәбәпле, очраша алмадык. Икенче уку елында исә ул инде мин укыган класста укытмый иде. Шулай итеп, минем йөрәгемдә авыр яра, күңелемдә бертуктамый тырнап торган газаплы уй калды. Яраткан укытучымның нахакка рәнҗетелгән җаны, мәсхәрәләнгән хезмәте миңа күтәрелеп тә карамаска теләгән күзләреннән ниндидер утлы агым булып киләдер кебек тоелды. Утлы агым гына түгел, мин ул караштa хәтта елан кыяфәтендәге афәт сурәтен дә күргән шикелле булдым. Куркынып, әмма андый афәтнең килмәвен теләп көттем. Һәм бу куркыну минем бик күп нәрсәгә дәртемне сүндерде. Әйтик, китап уку. Бер кичтә бер повесть-романны эһ тә итмичә укып чыгып, апа, мине сөйләтегез әле, апа, мин җавап бирим әле, дип атлыгып кул күтәреп утырулар бетте. Стена газетасы чыгару өчен редактор һәм хәбәрчеләр билгеләгәндә, эчтән генә: «Укытучым мине атаса икән», — дип, эчке бер омтылыш белән көтеп, теләп утырулар да бетте. Класс данын яклау өчен үткәрелгән смотр-конкурсларга үзем теләп төрле сюжетлар, темалар тәкъдим итү дә бетте. Һәм башкалар, һәм башкалар да. Миндә сүлпәнлек, үз эчемә бикләнү тойгысы тамыр җәйде.

Ләкин, вакытлар үтү белән, йөрәкнең берьюлы йөзләгән кылын авырттырып чирткән вакыйгалар ничектер тоныклана, икенче планга күчә икән. Беренчесенә ерта-ерта яңалары килеп керә.

Җәй үтте. Укулар башланырга берничә көн калгач кына, апамның, әнинең туганнарына күчеп китеп, укуын Казанда дәвам итәчәген белдем. Бөтенесен дә астыртын эшләгәннәр. Юкса Казанга бергә бардык, бергә кунак булып йөрдек. Әтиемә әйтер дип курыкканнардыр. Димәк, әтием генә түгел, бу гаиләдә мин дә артык кеше була барам.

Юк, курыкканнардыр дип әйтүем һич дөрес түгел. Бу аларның куркулары түгел, әтиемне санламаулары, кешегә исәпләргә теләмәүләре...

Шулай итеп, әтием Динара апамның укуын Казанда дәвам иткәнен бары тик сентябрь урталарында, Себердән кайткач кына белде. Ләкин аңа хәтта ул вакытта да, әни әйтмешли, «отчет бирергә җыенып торучы» күренмәде.

Әтием:

— Нишләп минем белән киңәшмәдегез? — дигәч, әни:

— Синең белән нигә киңәшергә? Син бала үстерәсеңмени? Сиңа балалар кирәкми бит. Аларны мин үстерәм. Көне-төне мин карыйм. Шуңа күрә кайда укытасым килә, шунда укытам, — диде. Аннан, бу гына җитмәде әле моңа дигәндәй: — Синең бит кайткач та өйдә торганың юк. Ике-өч көн үтүгә, анаң янына йөгерәсең, — дип ярсыды.

— Мин йөрмәсәм кем китереп бирә соң? Авылга кайтсам, төяп әйберен дә алып киләм бит, — диде әтием, тәмам аптырадым инде мин сезгә дигәндәй.

— Төяп акчасын алып кайткач, төяп бәрәңгесен алып киләсең инде, — диде әни, чын мәгънәсендә әтиемнең кешелеген таптап.

Әтием башын селкеп торды да:

— Оят юк синдә, — диде һәм, тагын тәмәкесен алып, ишек төбенә чыгып китте.

Әни тагын әллә нәрсәләр дип кычкыруын, әтиемне гаепләвен дәвам итте. Әмма әтием, үзе әйтмешли, әнинең атлыҗәяүле җитешеп булмаслык теленә башкача җавап кайтармады. Шулай итеп, апа мәсьәләсендә башланган сөйләшү тагын әнинең чираттагы җиңүе белән тәмамланды.

*** * ***

Әни Динараны өч бала арасында барыбыздан да аерып ярата. Хәтта күзенә генә карап тора. Аңа ни эшләсә дә рөхсәт ителгән. Ни эшләсә дә сүз әйтү юк. Алай гына да түгел, һәммә эш аның белән киңәшеп, ул дигәнчә эшләнә... Мин моның серенә озак вакытлар җавап таба алмыйча йөрдем. Соңрак якын әбиемнең бер сөйләшеп утырган чагында әтиемә көрсенеп әйткән сүзләрен ишеттем.

— Динара бик көтеп алынган бала бит, улым. Утызы узып өмете өзелгәндә тудырган баласы, шуңа бик якын, шуңа бик тәмле инде ул! — диде.

— Шулай шул. Ә калган икесен Динара үлмәсен дип кенә тапты инде ул, — диде әтием.

— Алай түгел инде, улым. Нәзерен үтәп тапты ул калганнарын. Дөрес, Динарны бик яратты, бик шатланды. Аны тапканчы әйткән булган, балага уза башласаммы, уза башласам, бер-бер артлы өчне табар идем, дигән. Җиде ел балага узмый йөрү бик күп бит инде ул. Бер ел узмасаң да, ырудан калдым микән әллә, дип хафаланып йөри башлыйсың бит ул! — диде әбием.

— Өч бала да минеке булса, тигез яратырга тиеш ул аларны. Ә ул һаман, Динара да, Динара, ди. Гаиләдән аерып читкә җибәрде.

Әтием бераз салып алган иде, күрәсең.

— Алай уйлама, улым! Балалар синеке! Бар, ят, йокла, арыдың син бүген, бик күп эшләдең, рәхмәт яугыры. Урының җәелгән, улым, ят! — диде әбием, йомшак итеп.

Тәнемнән йөз аяклы кортлар йөгереп үтте. Димәк, мин дә, энем дә кирәксенеп табылган балалар түгелбез. Әйткән нәзере тотмасын, Динара үлеп китмәсен өчен генә тапкан икән бит ул безне. Минем, йөгереп чыгып, әбиемә дә, әтиемә дә күп-күп сораулар бирәсем килде. Тик алар минем бу әңгәмәне ишетеп торуымны белмиләр иде. Шуңа күрә мин, йоклаган булып, күрше бүлмәдә ятуымны дәвам иттем.

Әбиемнең олы җанлылыгына ушларым китә минем. Әтиемнең гаиләдә кадере бик чамалы булуын сизсә дә, безнең алда әнигә тел тигереп сүз башлаганын белмим. Киресенчә, шул әллә нигә бер килеп киткән арада да безнең күңелләребезгә бик тә иман нуры салырга тырышты ул. Әлхәм, Колхуалла кебек догаларны ятлатып карады. «Табын янына утырганда, кулларыгызны юып, бисмиллагызны әйтеп килеп утырыгыз, кузгалыр алдыннан амин тотыгыз, — ди торган иде. — Амин токкач та тота-каба торып китмәгез, мул, тәмле ризыклар биргәнe өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтегез! Аннан килеп, карап үстергән әнкәемә, эткәемә рәхмәт! дип әйтегез. Табып үстерүче әниемә сәламәтлек, озын гомер бир; туйдыручы әтиемә сәламәтлек, озын гомер бир, дип теләк теләгез!» — дип әйтә торган иде. Ләкин аның сүзләре һавада эленеп кала бирде. Чөнки әни әбиемә дә көлү чыганагы итеп карарга өйрәткән иде инде безне.

Бервакыт шулай әбием:

— Балалар, ипиегезне уң кулыгызга тотып ашагыз! — диде.

— Кашыкны сул кул белән тотыйкмыни? — диде апам, әбиемнең тәкъдимен бигүк килештермичә.

— Кашыкны да уң кулга тотыгыз. Ашны кабасыз да кашыкны куеп, шул кул белән ипине тешләп аласыз. Шулай итсәң, аш та тәмле була, тамак та тиз туя. Ә сул кул белән ашаган ризыкны шайтан йотып бара, — диде әбием.

— Менә инде! — диде әни, әбиемнең сүзләрен бөтенләй дә ошатмыйча. — Сулагайлар бөтенләй үзләре ашамый буламыни синең сүз буенча? — Әнием кычкырып көлеп җибәрде. Аңа ияреп без дә көлдек.

— Сулагайның да уң кулы бар бит. Эшен сулы белән эшләсә, ашын уңы белән ашарга тиеш, — диде әбием.

— Әби, бу сүзләреңне кайткач тавыкларыңа сөйлә, яме. Ә безне балалар бакчасында кашыкны — уң кулга, ипине сул кулга тотарга өйрәттеләр, — диде апа.

Без тагын көлдек.

Әни, йомгак ясагандай итеп, чигәсен бораулап:

— Авылча инде, — диде.

Безгә шул җитә калды. Ул көнне беребез дә амин тотмадык. Бары тик ашык-пошык:

— Рәхмәт! — дидек тә утырган урындыкларыбызны да алып куймыйча, төрлебез төрле якка таралды.

Әбием генә өстәл артында озак кына догаларын укып утырды. Аннан: «Рәхмәт, килен, аш-суың тәмле булды, аягың-кулың сызлаусыз булсын!» — дип, әкрен генә урыныннан торды һәм һәркайсыбызның буш чынаягын җыеп юа башлады.

Апам соңгы елларда әнинең үзен дә санга сукмый башлаган иде. Бервакыт «симез дуңгыз» дип кычкырды ул аңа. Шулай итеп, безнең өйдә хәзер апа баш. Соңгы сүз аныкы. Нишләп соңгысы гына? Беренчесе үк аныкы. Әйтик, бүлмәдәге җиһазларның кайсын кая кую, кайсы бүлмәгә нинди обой алу. Кем кайда йоклый, кайсыбызга нинди кием килешә, нәрсәне алырга да, нәрсәне юк — барысын да апа хәл итә. Әни аны узып бернәрсә дә эшли алмый. Кыскасы, өйдә шуңа охшашлы мәсьәләләрдә сүз чыкса яки әтием белән минем тәртибем турында гайбәт китсә — әни апаның күзенә генә карап тора. Апа ни дип нокта куйса, шул була.

Бервакыт шулай әтием Себердә вакытта безгә апамның сабакташ кызлары килде. Бөтен бүлмәләребезне дә карап чыккач:

— Ай-яй фатирыгыз зур икән, әтиегез алдымы? — дип сорадылар.

— Әти алды, — дидек без.

— Ә шулкадәр күп шоколадны кем алып кайта?

— Әти.

Безнең бу сөйләшүләрне әни ишетеп торган икән. Кунак кызлары киткәч, өйдә җитди сөйләшү булды.

— Беркайчан да онытасы булмагыз: боларның барысы да минем аркада! — диде әни, һәр сүзенә мәгънә салып. — Фатиры да, башкасы да!

Апам аңа сәерсенеп карады:

— Ничек инде?

— Минем аркада! — дип кабатлады әни, тагын да катгыйрак итеп! — Мин ирдән тиешлесен таләп итә белгәнгә шулай!

— Бик беләсегез килсә, — дип уйнаклатты әни үзенең җилкә-күкрәкләрен, — миңа кадәр бер марҗа белән типтерә иде атагыз. Туйда күреп алдым да әйбәтләп кенә үзем килеп йөри башладым. — Авылдагы мокытларының да татар кызы кирәк дип малайларының колак итен ашавы минем файдага булды... Кыскасы, белеп торыгыз — болар барысы да әниегезнең хезмәте!

Апа нигәдер уйчан иде.

— Себер шартларында эшләргә бөтен кеше дә атлыгып тормый. Анда озак яшәүчеләрнең чәчләре коела, тешләре төшеп бетә, ди бит классташымның әнисе, — диде апа, әллә әтиемнең хезмәтен күрергә теләп, әллә иптәш кызына биргән җавапларының хаклыгына басым ясарга тырышып.

— Бр-р, карачкы белән торасы көннәр бар икән әле, — дип шаярткан булды әни, апаның җитди йөзенә текәлеп. Аны, күрәсең, курку биләп алды. Ул чыбыкны йомшак чагында бөгәргә уйлады булса кирәк: — Динара, минем моңа кадәр сиңа әйткәнем юк иде әле. Беләсеңме, атаң синең турыда нәрсә әйтә?..

— Нәрсә? — Апа җанланып китте.

— Ә син?.. Күрәм аның өчен нишләргә белми торасың!.. — Әнинең күзләрендәге агулы ук апаның йөрәгенә кадалды.

— Ә син әйт! Әйт, нигә куркып торасың? Нәрсә ди минем турыда?

— Динара минем кызым түгел, ди, бик ишетәсең килсә.

Апа кызарынды. Эчтән дә, тыштан да давыллап кайный башлады.

— Нәрсә?! Ул шулай диме?! — Апа аптыравыннан, көтелмәгән яңалыктан кая бәрелергә, ни әйтергә белми торды.

— Күз алдыңа китер әле, — ди әни, эчпошыргыч тыныч тавыш белән сүзен дәвам итеп. — Синең хәлең әле ярый, менә минем турыда уйлап кара син! Җиде ел балага узмагач, нинди генә газаплар кичермәдем! Нинди генә хастаханәләрдә ятмадым! Нинди генә профессорларга күренмәдем! Нинди

генә ар, мукшы, чуаш әбиләренең сасы мунчаларында аунамадым! Тирә-юньдәге бөтен өшкерүче-күрәзәче, чүлмәк салучы әбиләрне йөреп чыктым һәм үз дигәнемне иттем, барыбер сине таптым. Ә ул, рәхмәт урынына, минем тырышлыгымны күрү, күккә чөеп учында гына йөртү урынына, менә шундый сүз әйтә. Динара минеке түгел, ди.

— Турыдан-туры Динара минеке түгел диме? — дип кабатлап сорый апа, ышанасы килмичә.

Аның бу ышанасы килмәвендә дә — этиемнең әлеге сүзне әйтүенә икеләнү тойгысы түгел, бәлки кемдәдер аңа карата авыр сүз әйтә алу батырлыгы булуы гаҗәпләндерә. Ничек инде Динара тикле Динара турында, гаиләнең төп фигурасы хакында, «минеке түгел» дигән игълан булырга мөмкин?

— Турыдан-туры әйтте, димәк?

— Турыдан-туры.

Әни диванга сузылып ята да, песиебезне кочаклап үбә-үбә, телевизор кабыза. Ул һәрвакыт шулай безне кыздыра да аннан, иңеннән таш төшкәндәй, иркенләп җиңел сулап куя. Йөгәнен дәвам итүчеләре кулына тапшырдым дип уйлый, күрәсең. Аның каравы апа чыгырыннан чыкты. Этиемнең өйдә чагы булса, белмим, нинди мәхшәр булыр иде? Озын тырнаклары белән, мөгаен, йөзен ертып төшерергә дә күп сорамас иде ул. Яхшы әле этиемнең Себердә чагы туры килде. Әмма апаның тузынуы бик озакка барды. Өйдә сүз көн саен шул хакта дәвам итте. Этиемне ничек кенә сүкмәде дә аңа нинди генә яңа кушаматлар такмады. Ахырдан һәрвакыт, кайтсын әле, күрсәтәм мин аңа кыслалар кайда кышлаганны, дип йомгаклап куя башлады. Мин алдан ук этиемнең моңсу карашын, чарасызлыктан иелгән башын күз алдыма китереп, кызганып, аның өчен куркып тора башладым. Чөнки этиемнең абруе өйдә көннән-көн кими, ул көннән-көн кадерсезгә әйләнә бара иде. Әни исә, Пушкинның «Алтын балык» әкиятендәге балыкчы хатыны кебек, көннән-көн ныграк тузына, көннән-көн ныграк комсызлана, безне этиебезгә эткә өстергән кебек өстерә, үзе шуннан ләззәт ала иде. Хәзер мин, күпмедер үскәч, ул вакытларны искә төшереп, үземчә бәя биреп карыйм.

Этием, күп сөйләшмәсә дә, бик нечкә, шигъри күңелле кеше булган икән. Аның сабырлыгы шәһәрдәге бакчада көннәр буе онытылып эшләвендә дә чагыла. Алмага груша агачын ялгап, таш кабакка кыяр сабагын күчереп утыртып нинди генә тәҗрибәләр үткәреп карамый иде. Ул үстергән затлы-купшы чәчәкләр җәй буе бөтен тирә-юньне ямьләп тора... Ә әни ул бакчага барып та карамады бугай. Аның өчен көнбагыш ярып, ишек төбендәге эшсезләр белән гайбәт сатып утыру күпкә рәхәтрәк иде. Әйе, хәтта ул бу гадәтен дә безнең алда бер өстенлек итеп күрсәтә белде. Чөнки күрше-күлән турында өйгә тау-тау яңалык җыеп керә. Аларны үзе күргән кебек итеп тәмләп сөйли. Соңгы яңалыклар белән без дә кызыксынабыз, төрле сораулар бирәбез. Безгә күңелле. Җитмәсә, нәрсәдер пешерергә инде вакыты калмаган әни торт күтәреп керә — без шау-гөр килеп, һәр күршебезгә аерым-аерым тукталып, сөйләшә-көлешә чәй эчәбез.

Этием исә бу мәсьәләдә дә «ачык авыз». Бер генә күршебез турында да бер генә яңалык та белми. Бу темага аның белән сөйләшү бөтенләй күңелсез. Алай гына да түгел, аның белән табын янына утыру да кызыктырмый безне. Ул әнә шулай бакчасыннан арып-талып кайта да, газ плитәсе өстендәге буш кәстрүлләрне күргәч, берсендә бәрәңге пешереп ашый. Ашый да, тәмәкесен алып, тагын тартырга чыгып китә.

Әйткәнемчә, мин ул вакытларны искә төшереп, хәзер күп уйланам. Татар ирләренең гаиләдә кадерсез булып яшәвендә, күбесенең тәмәкегә, аракыга тартылуында заман сәясәтенең дә гаебе зурдыр дип уйлыйм. Безнең этиебез дә шул хәлдә сыман. Мәсәлән, ул берәр русча сүзне дөрес әйтмәсә дә, берәр тел сынмалы катлаулы атаманы исендә калдыра алмаса да шаркылдап көлә идек. Ә ул йөз сүзгә бер сүз белән дә җавап кайтаралмый кала. Бу, билгеле, аның тел белмәвеннән генә дә түгел, бәлки чын татар авылында, әби-баба кулында инсафлы тәрбия алу нәтиҗәсе дә. Хәзер шуларны күз алдыма китерәм дә уйлыйм, безнең кыланмышларыбыз аны, мөгаен, соң чиккә китереп җиткергәндер. Игелеккә тоташтан начарлык белән җавап бирү, күпме генә тырышса, ни генә эшләп караса да һаман рәхмәтсез булып калу этиемне көннән-көн үзенә ныграк бикләнергә мәҗбүр иткәндер.

Ә теге алда сөйләгән вакыйга апамның, әни фамилиясенә күчәм, дип тузынып йөрүе белән тәмамланды. Әмма ни өчендер, әни туктаткандырмы, анысын тәгаен генә белмим, бу ярсып башлаган эшен тормышка ашырмады. Тик ахыр чиктә этиемнең безнең яныбыздан китеп баруына бу вакыйганың да йогынтысы зур булгандыр дип исәплим.

Этием безнең яннан китте дисәм дә, аңа кадәр башка сыймаслык, күз яшьләремне түкмичә искә алмаслык күп мәсхәрәләр кичерде әле ул.

Моңа безнең вак, соңарып табылган балалар булуыбыз, шунлыктан бик күп нәрсәне акыл белән бәяли белмәвебез дә тәэсир иткәндер. Әбием әйтмешли, бәләкәй, җил кайсы якка иссә, шунда ава торган чагыбыз иде шул. Әни бөтен көченә җикерә, димәк — көчле. Эти эндәшми, димәк — гаепле. Этидән акча сорыйсың — әниегездә, ди. Әнидән сорыйсың — акчасы зур сумка белән! Бала-чага кемгә кызыга? Һәрвакыт өстен калган акчалы кешегә, билгеле. Гап-гади тормыш фәлсәфәсе.

Моңа тагын икенче бер сәбәп, этием тоташ унбишәр көн Себердә эшләгән чагында әнинең бик еш туганнан туган тиешле сеңелләренә кунакка йөрүендә булмады микән?

Соңгы вакытта әтием белән әнинең аралары күзгә күренеп суына барды. Әмма әле шул килеш тә әтием һаман түзде, һаман дәшмәде. Хәер, инде муенына менеп атланган хатынын сүз белән генә җиңә алмаячагын аңлаганга күрә дәшмәгәндер ул.

Илле яшен тутырган көннәрдә Себергә йөрүеннән туктады әтием. Бу вакытта аның куе, дулкынланып торган матур чәчләре шактый сирәкләнгән, йөзе үз яшеннән күпкә иртә җыерчыкланган иде.

Зур хезмәт хакы алып эшләргә өйрәнгән әтием монда да акчалы урын эзләде. Авыр тимер эшен сайлады. Кара таңнан китә, сулып-суырылып кич кенә кайта. Кайтуына хәтта чәй куеп торган кеше дә юк. Гомумән, мин әтиебезне тәмле ашлар әзерләп, табынга утырмыйча көтеп алганыбызны хәтерләмим. Әтебезгә сан булса да, әтиебезне санга сугу булмады.

Ул елларда илдә зур буталчыклык, тәртипсезлек заманы иде. Эшләгән кеше еллар буе хезмәт хакын ала алмый тилмерде. Бу хәл әтием эшләгән оешмага да килеп кергән, күрәсең. Әмма әтием анда да акчасызлыктан чыгу юлларын эзләде. Ял көннәрендә әче таңнан җилем көймәсен, озын җилем итекләрен күтәреп балыкка китә, кичкә Чулман балыгы төяп кайта иде. Әни, авызын ерып, балык сатарга чыгып чаба. Башта күршеләргә әйтеп чыга, аннан подъезддагыларга, туганнарына, танышларына шылтырата. Үзе әйтмешли, бер ванна балыкны «ә» дигәнче акчага да әйләндерә. Әмма үзе эшләмичә, Себер акчасы белән «фарсить итеп» яшәргә өйрәнгән әнигә мондый керемнәр төкерек кенә. Ул һаман, тиресенә сыеша алмас дәрәҗәгә җитеп, әтиемнән акча таләп итә. Гомере буе пычагы май өстендә булганлыктан, авырлыкка бер көн түгел, бер генә минут та түзәсе килми.

— Бирмәгәч, нишләтим соң мин аларны? — дип нәүмизләнә әтием беркөнне хезмәт хакы сорап каршысына килеп баскан әнигә.

— Алдалыйсың! — ди әни. — Иваннарга биргәннәр, нишләп сиңа юк?

— Безнең сменада Иван исемле кеше эшләми. Бәлки, башка сменаларга биргәннәрдер, мин анысын белмим.

— Белмисең? Бик яхшы беләсең! Бер оешмада берсенә биреп, икенчесенә бирми калдырмыйлар. Мине үзең кебек надан, үзең кебек ахмак дип уйлыйсыңмы? Анаңа биргәнсең син ул хезмәт хакыңны...

— Күрәлмәгәнең әнкәй булды инде. Алар үзләре безгә бирергә әзер. Мохтаҗлыклары юк. Әткәйгә сугыш пенсиясен ай саен үз вакытында биреп торалар. Акчаң бетсә, сорап тор, — ди әтием, һаман да тыныч калырга тырышып.

— Әйе, сорадым ди! Аларга кул сузып акча сорап бардым ди! Син бир, мин теләнеп йөрим, имеш...

— Акча сорамасаң, хәлләрен белергә бар. Әнкәй авырып ята анда, — ди әтием, сүзне йомгакларга тырышып.

— Хәзер... Өч бала өстенә тиен дә акча бирмәгән ирнең анасын да карыйм икән. Таптылар йомшак агач. Мин сезне болай гына калдырмыйм әле. Өйрәтәм әле мин сезне. Әле кем белән эш иткәнегезне белмисез сез!.. — дип яный әни. Әтием кухняга кичке ашны ашарга дип чыккан җиреннән эндәшмичә, хәтта су да эчмичә, кире борылып кечкенә бүлмәгә кереп китә. Әни, һаман тыела алмыйча: — Авырган кешедә яңа җиһаз алу кайгысы булмый анда. Мине бер диванага саныйсыз, ахры, — дип кычкыра.

Йомшак җиһаз дигәннән, якын бабамнар картаеп еш авырый башлагач, авылда мал-туарларын бетереп, без торган шәһәрдән фатир алганнар иде. Әнинең белмәгән кешесе, кермәгән тишеге юк бит аның. Бабамнар фатир алган йортта да бер чыбык очы туганы пәйда булды. Әлеге яңалыкны — әбиемнәрнең яңа диван сатып алу хәбәрен дә — телефоннан әнигә ул хәбәр иткән иде.

Чынлап та, әни бу хәлне болай гына калдырмады. Икенче көнне эштән кайтып чәй эчеп утырган әтинең кулыннан стаканын тартып алды да:

— Бүгеннән башлап өйдәге бер ризыкка да кагылмыйсың. Син әрәмтамакны ашатып, балаларымны ач тота алмыйм! — диде.

Шунда да кул күтәрү түгел, авыз ачып авыр сүз дә әйтмәгән әтиемдә нинди сабырлыклар булды икән дип уйлыйм хәзер.

Ул, тәмәкесен алып, тагын ишек төбенә чыгып китте. Аннан тагын кечкенә бүлмәгә кереп китте.

Ә инде бер ай чамасы вакыт үтүгә, ягъни соңарып бирелгән хезмәт хакын алганда, әтием үзенең алиментка бирелгәнлеген белгән. Эштән кайтканда ул бераз салган һәм ике сумкага тутырып ризык күтәреп алып кайткан иде. Кайтып чишенде дә әнигә:

— Син миңа тагын бер мөгез куйдың, әйеме? — диде. — Нишләп мин синең алиментка биргәнеңне хезмәт хакы алганда гына белергә тиеш? Минем сиңа эшләгән акчамны кайчан бирми калганым бар?..

— Синең кебек әйтеп аңламаганнар белән нишләргә тагы? — диде әни, ниндидер бер зәһәрлек белән. — Закон балаларны ач тотарга ирек бирми. Закон минем якта!

— Синең якта булмаса да буйсындырасың син аны! — диде әтием, авыр сулап. Аннан, безгә карап: — Балалар, сыйланыгыз, менә сезгә, төрлесеннән алдым шунда, — дип, сумкаларны алдыбызга китереп куйды. Үзе тәмәкесен алды да тагын ишек төбенә юнәлде. Көлешә-көлешә сумкаларны бушаттык, кылкынганчы ашадык. Һәм шул кичтә үк, әтиебез йокларга ятуга, кесәсендә калган акчаларын да «чистарттык».

Икенче көнне ул кесәләрен карап тормыйча гына киткәндер эшенә. Хәер, хәтта караса да ул безне йокыбыздан уятып тавыш чыгармас иде. Аның тәрбиясе моңа юл куймаганын без инде төшенгән идек. Тавыш чыгару дигәннән, гомумән, мин әтиемнең үзе башлап гауга кузгатуын белмим. Әллә нинди авыр очракларда да ул фәкать сакланырга гына тырыша. Дөресрәге, гаделлекне яклап бер-ике сүз генә әйтеп куя. Ләкин гаделлек дигән әйбер безнең өйдән чыгып ук качкан, ахры.

Шулай итеп, әтием безгә алимент түләп, безнең белән яшәвен дәвам итте. Бик авыр, бик хурлыклы булгандыр аңа бу яшәү. Әмма ул түзде. Кесәсеннән соңгы акчаларын алып бетерү генә түгел, икенче көнне эшкә — әбәткә дип алып кайтып куйган катык, күмәчләрен дә иртән торуына «юк итә» башладык. Ә бит ул эшкә кибетләр ачылганчы кузгала, эшләгән җирендә ашханә дә юк. Тимер эшендә көне буе ач килеш түзеп кара әле син?..

Хәлләрен белү өчен дә, бәлки, тамак туйдыру нияте беләндер дә, эштән кайтышлый әтием якын әбиемнәргә кагыла башлады. Ә эштән вакытында кайтмаган кешегә бездә тәртип каты. Йозакның эчке келәсен эләктерәбез дә ишекне ачмыйбыз. Әтием исә ишек төбендә, үз өенә керә алмыйча, сәгатьләр буе басып тора. Шулай итеп, берничә тапкыр «акылга утырткач», әтием үзе ясаган тимер ишекнең тыштан ачып булмый торган йозагын алыштырып куйды. Һәм әбиемнәргә дә эштән соң түгел, ял көннәрендә генә бара башлады. Ә бер баруында ул якын әбиемнең бик нык авырый башлавын әйтеп, телефоннан шылтыратты. Әнидән: «Килеп, юындырып кит әле», — дип үтенде.

— Баралмыйм, — диде әни, бер сүз белән генә.

— Алайса, мин бүген кайтмам, — диде әтием.

— Миңа дигәндә, бөтенләй кайтма! Безнең өчен тагын да әйбәтрәк булыр, — дип, телефон трубкасын ыргытты әни.

Ул вакытта әтием, чынлап та, бер атна чамасы әбием белән бабам янында торды. Бары тик табиб чакыртып, әбиемне хастаханәгә салгач кына өйгә кайтты. Ә бездә бернәрсә үзгәрмәгән. Һаман шул ук җикереп кычкыру, төрле ямьсез сүзләр белән түбәнсетү. Әтиемнең өрлек кебек төз буе чарасызлыктан тагын да ныграк чүккән, кечерәеп калган кебек тоелды миңа. Әтиемне кочаклап елыйсым, аны яклыйсым, пешкән әйберләрне яшереп булса да аңа алып каласым килә иде. Тик мин боларның берсен дә эшләмәдем. Хәтта алар күрмәгәндә әтием йоклаган бүлмәнең идәнен юып чыксам да мине тиргиләр иде. Тик вакытлар үтү белән батырая башлаган кебек идем инде мин. Әмма...

Әтием әбиемне хастаханәдән алып чыкты да тагын бер атна чамасы аларда яшәде. Бу хакта ул әнигә алдан ук әйтеп, аның рөхсәтен алып дигәнәй эшләгән иде дә... Тик әнинең әтиемне яратмавы шул чиккә җитте ки, хәтта безгә дә әйтеп тормыйча, әтием ясаган тимер ишеккә өстәмә яңа йозак куйдырды.

Әтием:

— Нигә алай эшләдең? — дигәч:

— Ирсез өй, эчтән бикләнми торган ышанычсыз йозак, ә мин шунда балаларымны йоклатырга тиеш. Юк инде, дускаем, алай булмый, — диде әни.

Әтием эндәшмәде. Ачкыч та сорамады. Тик шулай да әни аңлатуны кирәк тапты булса кирәк.

— Ачкычы өчәү генә иде, балаларга бирдем. Син барыбер йә кайтасың, йә юк, — диде.

Әтием тагын эндәшмәде.

Ул аны хәзер эштән туры өйгә кайтканда да еш кына ишек төбендә басып торырга мәҗбүр итә башлады.

Әтием яртышар сәгать кыңгырау шылтыратып торганнан соң:

— Ай, ваннада идем. Ай, телефоннан сөйләшә идем, телевизор тавышы белән ишетмәгәнмен, — дип, берни булмагандай барып ача да артын уйнаклатып залга, тагын телевизор каршына кереп китә иде.

Әтием әнә шулай түзде. Түзде-түзде дә беркөнне эшенә киткән җиреннән кайтмады. Өстенә нәрсә кисә шуның белән китеп, авыру әбием белән бабам янында тора башлады.

Китүенә берәр ай чамасы вакыт үткәч, көз кергәч, әтием курткасын сорап килде. Апаның кайткан вакыты иде. Апа аңа ишекне ачмады, курткасын да бирмәде. Тәрәзәдән без аның башын иеп автобус тукталышына таба китеп барганын карап калдык.

Мин шунда түзмәдем:

— Суык бит хәзер урамда. Нишләп курткасын бирмәдек инде? — дидем.

— Акчасы күп, базардан чыгар да алыр, без монда хәерче алимент акчасына яшибез, — диде апа.

Әни исә, миңа усал итеп карап:

— Ә ул куртка, бик беләсең килсә, минем апамнар биргән акчага алынган. Димәк, куртканы безнеке дип исәпләргә була, — диде.

— Алар әтине туган көне белән котлап бирде бит ул акчаны, — дидем мин.

— Дөрес, — диде апа, җөпләп. — Ә мин аны сатам да үз өстемә алам, яки базарга алып барып хатын-кыз курткасына алыштырам. Һәм ул икенче көнне үк шулай эшләде дә, әни каршы төшү түгел, киресенчә, «тормышчан син!» дип мактады гына.

Әтием, бер ай чамасы үткәч, тагын килде. Анысында да апаның өйдә чагы туры килде.

Бер-бер артлы кыңгырау шылтыраткан этигә:
— Малайларны чакырып, чыраеңны тигезләтергә кирәкме әллә? — дип кычкырды.
Әти, тавышын күтәрмичә генә:
— Кышкы киемнәремне бирегез әле, суык бит болай, — диде.
— Туйдырды тәки, — дип таптанды апа.
Әни караңгы бүлмәдән этиемнең кыршылып беткән пальтосын тартып чыгарды.
— Мә, ыргытып бәр, башка килеп йөрмәсен, — диде.
Апа күтәреп карады да:
— Үзең ыргыт, авыр, — диде.
Әни, ишекне ачып, пальтосын этиемнең йөзенә бәрде.
— Ал да ычкын.
Тик этием пальтосын алгач та китеп бармады. Ул тагын кыңгырау шылтыратты.
Апам, тагын куелган «күз»гә текәлде:
— Әни, алар икәү.
Әни барып карады да:
— Ә, кияүләре ул, — диде.
Әти тагын озын-озын итеп кыңгырау шылтыратты һәм ишек аша:
— Бүрек белән ботинканы да бирегез! — диде.
— Ботинкаңны исерек килеш бажаңа кигереп җибәрдең, оныттыңмыни? — диде әни, кеше барын белгәч бераз йомшап.
— Ботинканы түгел, кроссовканы кигердем мин аңа, бик яхшы хәтерлим, — диде этием.
Әни, көя ашап, йоны коелып беткән кыш көннәрендә кожан астыннан киеп балыкка, урманга бара торган куян бүреген алып ыргытты да, тиз генә ишекнең ике катын да ябып, бөтен йозакларын бикләп куйды.
Әтиемнең:
— Яңасын бирмәде инде болар, — дигән сүзе генә ярым-йорты булып ишетелеп калды.
— Нәрсә, һәр көнне килеп йөриме әллә ул? Кайттым исә ыржаеп ишек төбенә шул килеп баса, — диде апа, үз-үзенә урын тапмагандай ишекле-түрле йөреп.
— Ә син бүтән килмәслек ит! — диде әни. — Миңа күңелле дип беләсеңме әллә аның ишек артында мөгрәп торуы? Күршеләр болай да кырын карап йөри әнә!
— Каяле аның теге армиядән сөйрәп кайткан иске чемоданы? — диде апа, нindidер кискен карарга килеп.
— Караңгы бүлмәдә, — диде әни.
Апа тиз генә куе зәңгәр төстәге кечкенә чемодан тартып чыгарды. Эчендәге әйберләрен бушатты һәм:
— Кая, тагы нинди чүп-чары калды аның бездә? Җыегыз, кабат килеп йөрмәслек итәм мин аны хәзер, — диде.
Әни өстәл сөртергә дә ярамаслык тишек, ертык, саргаеп, сүтелеп, изрәп-тузып беткән майка, күлмәкләр; көя кисеп бетергән трусик, уртасы аерылып чыккан шарфлар тартып чыгарды.Шуларны чемоданга салдылар да апа миңа:
— Киен! — дип боерды.
Ерак бабамнарның ишек төбенә барып җиткәч, апа чемоданны минем кулымнан тартып алды да дык итеп идәнгә куйды һәм кыңгырауга басты.
Ишекне этием ачты. Аның мөлаем зәңгәр күзләре безгә текәлде. Безне күрү шатлыгыннан нур чәчеп өйгә дәште.
Тик апаның аягы белән чемоданга тибеп:
— Менә калган иске-москыларың. Моннан соң безнең өйдә эзең булмасын! — диюе башына күсәк белән орудан да яманрак булгандыр. Ул тораташ кебек катып калды. Безнең тек-тек басып баскычтан төшеп китүебезне карап, тагы бер сүз дә эндәшмәде.
Әтием белән шуннан соң байтак кына күрешмәдек. Ә инде акча кирәк булгач, без аны тагын барып таптык. Ул якын әбием белән якын бабамны бик кадерләп, тәрбияләп аларда тора иде. Сорап килгәдә безне бервакытта да буш кул белән борып чыгармады. Ә бер барганымда якын әбием мине үз янына дәшеп алып, әниемнең килүен үтенде.
— Бик авырыйм, кызым, озак тормам. Әниеңә әйт әле, кызым, килсен әле, үкенечтә калмасын, әйтәсе сүзләрем бар,—диде. — Син бит безнең якка тартканысың, кызым. Кечкенә чагыңда күңелең дә бик матур иде. Миһербан хисеңне югалтма, балам. Әтиеңне онытма! Гомере буе сез дип яшәде бит ул! Җан тирләрен чыгарып сезнең өчен тырышты! — диде.
Мин җавап кайтармадым. Аны тынычландырып җылы сүз әйтү түгел, озаклап утырасым да килмәде. Бу оялу хисе идеме, әллә, әни әйткәнчә, чир тия торган карчык түгел әле ул, юри ята дип

уйладыммы? Белмим. Ә бу сөйләшү минем әбием белән соңгы күрешүем, соңгы очрашуым булган икән.

Өйгә кайткач әбиемнең әйткәннәрен барысын да сүзен сүзгә җиткердем әнигә. Тик әни аларга бармады. Әбием исә шуннан соң озак та тормыйча вафат булды. Үлеп, аны җирләргә алып киткәч, алар күршесендәге әнинең теге чыбык очы туганы хәбәр биргәч кенә, әбиемнең, чынлап та, авырганлыгына ышанды булса кирәк әни. Фәкать шул вакытта гына барып, өй сакларга калган күршеләреннән: озак чирләдеме, кем карады, кызлары килдеме, дип сорашып, өйләрен айкап, төпченеп йөрде.

Якын әбием акыллы карчык иде. Әнинең көтеп-көтеп тә килмәслеген белгәч, әйтәсе сүзләрен язып калдырган булып чыкты. Әтием аны әнигә минем аркылы җибәрде.

*«Килен, яшь чагында улымны бик яраттың бит. Олыгая башлагач, нигә кирәкмәскә әйләнде соң ул? Син ана кеше. Өч балагыз бар. Баланы кем генә, кайчан гына кыерсытса да, ана күңеленә бик авыр. Адәм фәрештә түгел. Житешмәгән җирләре аныкы да бардыр, синеке дә бардыр. Улымны маңгай тирен түгеп корган үз оясына кертмичә, өстеңә гөнаһ аласың, килен. Ир хакы бик олы хак бит ул! Балаларны «әти» дигән тәмле сүзне әйтүдән мәхрүм итеп тә ялгышасың. Улым дөнья көтәргә ярамаслык кеше түгел. Кулыннан эш килә. Нәрсә тотса, шуны коеп куя. Акчасын таба. Хатын-кыз белән чуалып йөрми. Синең әти-әниеңә зур хөрмәт күрсәтеп соңгы юлга озатты, урыннары оҗмахта булсын! Алар исән булсалар да мин әйткән шушы сүзләрне әйтерләр иде. Бергә яшәгез! Балаларны ятим итмәгез, бергә тәрбия итегез, килен! Аларның бәхете сезнең татулыкта, сезнең бердәмлектә, бер сүздә булуыгызда, килен!»*

Ләкин әни яхшы сүзне аңлаудан һәм яхшылыкны бәяләүдән узган иде, ахры. Үзем кыз булып җитә барган саен, мин әнидәге үзгәрешләрнең, аның көннән-көн матуррак киенергә тырышып дәртләнеп йөрүләренең тикмәгә түгеллеген аңлый бардым. Хәзер ул ир «тоткынлыгыннан» тәмам азат. Аны хәзер бер генә нәрсә борчый: минем әтием ягында калуым. Шуңа күрә, апа киткәч, ул мине ныклап «эшкәртергә» тотына. Ә минем күңелемдә газаплы зилзилә...

* * *

Динә арып күзләрен йома. Үзе дә аңламый, әллә йоклый, әллә саташа ул. «Әтием, — дип кабатлый Динә, хәлсез иреннәрен көчкә кыймылдатып, — әтием!» Томан артында әтисенең гәүдәсе шәйләнә. Динә аны чакыра, чакыра, чакыра, тик әтисе ишетми.

«Сез... аның аңын томаладыгыз, шуңа ишетми ул сине, — ди бер әзмәвер, Динәнең колагына пышылдап. — Кадерен белмәдегез!..» «Өйләрен нигезләре белән күтәрик тә китик», — ди икенче әзмәвер. «Юк, верандаларын гына алыйк», — ди өченче бер ямьсезе. Динә алардан куркып кача башлый, үзе, күзләре белән әтисен эзли, табарга да аңа ышыкланырга уйлый. Тик нигәдер әтисенең инде мәһабәт шәүләсе дә күренми. Динә калтырый, дер-дер килә. Бераздан патшабикә камзулы кигән таза гәүдәле әнисе пәйда була. Кулындагы айбалтасын уңга-сулга болгап, куе томан эчендә исәнгерәп йөргән ирен табып ала. Бөтен көченә кычкырып: «Әнә, әнә ул, алып китегез, күз алдымнан юк итегез үзен! Айбалталарыгыз белән телем-телем итеп тураклагыз! Нәрсә катып калдыгыз, тиз булыгыз!» — дип боера. Әнинең әмерен генә көтеп торган теге ямьсез затлар әтиемне верандага бикләп, иңнәренә күтәрәләр дә ашыга-ашыга каядыр йөгерә башлыйлар...

Динә тагын да ныграк калтырана, бастырыла. Кычкырып теге әзмәверне туктатырга, әтисен коткарырга, үз янына чакырып алырга тели — тик тавышы чыкмый. Ул да булмый, авызыннан да, колакларыннан да, борын тишекләреннән дә эт йоны үсеп чыга. «Сукыр эчәгеңә дә эт йоны тулган иде, — ди аңа операция ясаган табиб. — Соң инде, мөселман кешесе өйдә эт асрыймы?» — дип башын чайкый...

Динә авырлык белән күзләрен ача. Куллары белән үзен капшап карый. Йокы күлмәге сыгып ташларлык булып чыланган, тәне һаман хәлсез. Күк йөзендә шул ук шыксыз болытлар йөзеп йөри. Аның өзелеп-өзелеп әтисен күрәсе килә. Бары ул гына көч бирә алыр, бары ул гафу итсә генә аягына басар, җаны савыкса гына тән ярасы төзәлер сыман тоела аңа!..

*1998, 2005*

## *Җанлыдан җан ялгач*

Сабый бала!

Гөнаһсыз җан иясе!

Йөзеңдә илаһи нур, сафлык, чисталык. Синең янда гайбәтләргә һич урын юк. Кодрәтең шундый киң, газиз әниеңнең генә түгел, җиде ят игенченең дә, шагыйрьнең дә йөрәген яулый, буйсындыра

аласың. Сабыйлыгың, садәлегең белән бөек галимнәрне дә, президентларны да сөендерә, бәхетле итә аласың. Әмма сөендерү генә түгел, көендерү дә көчеңнән килә синең!..

* * *

Җәй. Җылы яңгыр ява. Рәхәт. Күрше авылдан кайтып барыш. Ак борчак төшкән зәңгәр күлмәгем тәнгә сыланган. Чәч дулкыннарым юешләнеп, тагы да ныграк бөдрәләнгән. Басу буендагы йомшак чирәмнән әкрен генә атлыйм. Шулчак олы юлдан велосипедлы бер егет үтеп китте. Үтеп китте дә, ике-өч метр ара узуга, туктап, миңа каерылып карады. Берәр танышына охшаткандыр, мөгаен. Ә аннары, бер туктагач, кыз баланы ялгызын калдырып китәргә уңайсызлангандыр, күрәсең, велосипедын җитәкләп, янәшәмнән атлый башлады.

— Әй, кызый, кая барасың?

— Бармыйм, кайтам, — дидем мин, «әй» дип эндәшүне өнәп бетермичә.

— Биш Куык кызымыни әле син?

Безнең авылны мыскыллап шулай Биш Куык дип йөртәләр. Бервакыт ике туган тарантаска утырып сабантуйга барганнар, имеш. Алда басу капкасы очраган. Төшеп, капканы ачарга кирәк бит инде. Кем төшә? Туганнар бер-берсенә карап аптырашта калганнар. Чөнки тарантастан чыгып торган аякларында яхшы күн итек, икенче аякларында чабата икән боларның. Нишлисең, төшеп капканы ачмыйча да булмый бит. Капка ачар өчен генә аяк киемнәрен дә алыштырып торып булмый. Төшкәннәр, ачканнар капканы, әмма басу капкасы төбендә үтеп-сүтеп йөрүчеләр дә булган шул... Шулай итеп, хан заманында бирелгән кушамат хәзерге көндә дә яшәп килә. Аның каравы бөтен районда беләләр безнең авылны, аның кешеләрен. Биш Куыкныкы, дип кенә җибәрәләр.

Без сөйләшеп кайттык. Аерылышканда:

— Бүген клубка чык, Гөлмәрьям, — диде миңа юлдашым.

Аңа карап елмайдым гына, җавап бирмәдем. Ә эчемнән: «Чыгам, һичшиксез чыгам», — дип кабатладым.

Өйгә кош тоткандай йөгереп кайттым. Кайттым да, баскыч башында торган комганнан су агызып, ялан аякларымны юдым. Йөгереп кереп көзге алдына бастым. Маңгаема, яңакларыма ябышкан чәчләремне, юеш күлмәгем аша кәгазьгә сызып ясагандай үтәли күренеп торган сынымны карадым. Үз гомеремдә беренче мәртәбә күзләремә игътибар иттем. Күзләремдә кабынып китәргә торган очкын иде. Шулчак кулларымны җилпеп каядыр очасым, кара чәчләремне җилфердәтеп яшел болын буйлап йөгерәсем килде...

Хисләремнән бүленмәс өчен, аулак урын эзләп, мунчага киттем. Каләм очын чәйни-чәйни әллә никадәр шигырь яздым. Хәтта шул шигырьләрне үзем үк көйгә дә салдым бугай әле.

Шулай, сабыем...

Бүген менә синең белән сөйләшеп утырам. Синең белән юанып яшим. Ләкин син минем җанымнан яралган бала түгел. Шулай ук җиде ят та түгелсең... Тыңла! Әнә шулай якты итеп елмаеп тыңла!

...Кызык инде. Бер белмәгән кеше белән дуслашып киттек без. Бик тә моңлы егет булып чыкты Илдар. Өздереп гармун уйный, бии, җырлый. Ә иң күңеллесе — шаяртырга, көтмәгәндә килеп чыгып шаккатырырга маһир.

Беркөнне, язгы чәчүдән соң, кызлар-егетләр җыелып, Качкын очы яланына уенга төштек. Биедек, җырладык. «Сигезле», «Чылбырлы» уйнадык. «Яр эзләү»гә бастык. Карасам, ялт итеп алдыма Илдар килеп чыкмасынмы.

Алмы синең яулыгың,
Гөлме синең яулыгың?
Очраганда эндәшмисең,
Юкмы синең саулыгың? —

дип җырлыйбыз. Ә ул ике-өч дистә кыз арасыннан мине эзләп таба. Җитәкләшеп артка чыгып басабыз.

— Киттек, — ди Илдар.

— Бу уен бетсен инде, — дисәм дә, үзенекен итә, көчле куллары белән читкә тарта.

Без тыкрыкка, безнең өй янында гына үсеп утырган, әтиемнең әтисе утырткан өянкеләр ягына юл алабыз.

— Ничек килдең? Ык суы ташыган, урман-болынга су җәелгән, диделәр ич. — дип сорыйм, үзем юл өзегендә дә килә алуына сөенәм.

Ә ул:

— Җир өстеннән юл бетсә, җир астыннан юл салып киләчәкмен, Гөлмәрьям, — ди.

Без инде бер-беребезгә хәтсез ияләшкәнбез. Көн саен очрашмасак та, елга якын вакыт эчендә күп мәртәбә күрешеп сөйләштек. Илдар җебеп төшкәннәрдән түгел, килгән саен күкрәгенә ныграк кыса, матур сүзләрне күбрәк әйтә. Менә хәзер дә:

— Яратам бит мин сине, әйдә өйләнешик, — ди.

Илдарның кайнар куеныннан чыгып, күзләренә карыйм. Аннан — зәңгәр күккә. Икесендә дә саф зәңгәрлек. Күк йөзе — гүя Илдар күзләренең дәвамы. Анда йолдызлар яна. Никадәр йолдыз, никадәр сер! Әлегә минем өчен бер генә йолдызның сере ачылды. Әлегә минем белән бер генә йолдыз сөйләште. Ул миңа үзенең сөюен, мәхәббәтен әйтте. Ә Илдар күзендә миллионлаган йолдыз. Димәк, шуның кадәр үк сер укыйсым бар әле минем. Ул йолдызларның серен ачып бетереп булыр микән? Гомер юлыбыз озын микән безнең, Илдар?

Илдар минем күзләремнән үбә. Кайнар сулышы муенымны кытыклый, тәнем буйлап йөгерә.

— Гөлмәрьям, — дип пышылдый ул. — Мин әниләр белән сөйләштем. Синекеләрне килештерик тә өйләнешик, — дип кабатлый.

Сәер ләззәттән хәлем китә. Буыннарымның көчсезләнүен тоям. Әкрен генә чәчләреннән сыйпыйм.

— Тагы иркәлә, тагы, тагы... Хатын-кызның кулы нәкъ шулай, таң җиледәй сизелер-сизелмәс кенә кагылырга тиеш, — дип пышылдаганын ишетәм. — Мин сине берәүгә дә бирмим. Син бары тик минеке генә. Әгәр этиләрең карышып торсалар, күз алларында урлап качам, — ди.

Мин вакытны бераз сузарга уйласам да, Илдарның һаман үҗәтләнеп кыставы, үзе килә алмаган көннәрдә хатлар язып җибәрүе мине тәмам иләсләндерә. Яварга җыенган яңгырны туктату беркемнең дә кодрәтеннән килмәгән кебек, эти-әниемнең дә: «Кызым, сабыр итик әле», — диюе мине тыеп кала алмый. Без өйләнешәбез, шәһәргә күчеп китәбез.

*** * ***

Бала тудыру йорты...

Ак халатлы шәфкать туташлары һәм көмәннәре борыннарына җиткән хатыннар. Кайсы ыңгырашып ята, кайсы әкрен генә йөренеп тора.

Минем дә үз хәлем хәл. Ләкин, бирешмәскә теләп, Бөек Ватан сугышыннан әллә никадәр тән ярасы алып кайткан әткәемне, алты бала тапкан әнкәемне искә төшерәм. Түзгәннәр бит! Бөтен авырлыкка да түзгәннәр! Ә нишләп мин сыгылып төшәргә тиеш? Юк... Озакламый мин үзем дә Җир йөзенә Кеше тудырачакмын!..

Тирән итеп сулыйм. «Йа Алла, котылуым шушы микән?» — дип уйлыйм. Хәлсез кулларым белән маңгаема бәреп чыккан салкын тирне сөртәм. Шытырдап кипкән иреннәремә бармакларым белән кагылам. Барысы да үз урынында. Тик тау кадәр булып яткан эчем урынында гына үзгәреш бар. Кабыргаларым биек булып күтәрелеп тора, ә эчем кинәт кенә аска төшеп киткән. Җитмәсә, тактага кыскандай, юкарып калган...

Якты дөньяга килүгә, тирә-юньне яңгыратып аваз салган сабыемның кендеген кисеп, миңа күрсәтәләр. Ир-бала икән. Солдат. Ил терәге!

Тышта таң беленеп килә. Тәрәзәдән агачларның ябалдашлары, зәңгәр күк йөзе күренә. Тоташ зәңгәрлектә очкын чәчеп йолдыз яна — таң йолдызы. Гомерем юлында — Илдарым күзендә янә бер йолдыз. Ул шундый яктырып, нурланып яна! Мин аны иремнең ир бала табуыма куануы дип юрыйм. Ни әйтсәң дә, ир-атка ир бала якын бит. Беркөнне, кан буенча кыз бала исәпләделәр, дигәч тә, авызын турсайтып, егет кирәк, дип куйган иде. Ә минем өчен ир бала ни дә, кыз бала ни! Исән-сау гына тусын.

Бала табу хатын-кызның үзен дә яңарта, яшәртә икән. Гүя үзем дә яңадан тудым. Үзем генә түгел, хәтта дөньясы да менә-менә туып кына киләдер сыман тоелды. Күзләрем моңа кадәр гомер күрмәгән матурлыкларны абайлады. Колак яфракларыма гомер ишетелмәгән нәфис моңнар килеп кагылды. Шундый рәхәт. Дөнья шундый матур, тәндәге яраларны шытырдатып теккән табиб та шундый әйбәт, йомшак куллы булып тоелды.

— Гафу итегез, бер генә телем ипиегез юкмы? — дип сорыйм мин янымнан узып баручы җыештыручы ападан.

Ул каяндыр бер телем ипи алып килә.

— Мә, тик бераз кибеп киткән. Ипләп аша, аңкавыңны ертмасын, — ди калын итеп киселгән икмәкне миңа сузып.

Ипекәй!

Шул чакта ул бер телем ипинең нинди тәмле булуын белсә икән кеше! Гүя ел буе тәгам җыймаганмын. Гүя ел буе авызыма валчык та капмаганмын. Гүя ипи дигән ризыкның тәмен үз гомеремдә беренче тапкыр татыйм. Шул бер телем ипекәйнең тәме бүген дә тел төбемдә тора кебек!..

Йөрәк ялгануга, изрәп йоклап кителгән. Йокымнан торганда, безнең палатага тагы бер хатынны кертеп салганнар иде. Хәзер без өчәү. Светлана исемлебез инде күптән ята. Икенче баласын тапкан. Ярып алганнар. Инде Светлананың да хәле рәтләнеп килә. Ул безнең бүлмәдә горурлык символы. Хәер,

бүлмәдә генә түгел, бөтен хастаханәдә. Лекцияләр вакытында, коридорда, юынган җирдә һаман Светланага сокланып сөйлиләр. Кирәк бит, операция белән икенче баласын табарга килгән. Табиблар кат-кат кисәткәннәр үзен. Беренче баласы ярып алынган хатын-кыз икенчесен дә, өченчесен дә фәкать шул юл — ярып алу юлы белән генә дөньяга китерә ала, дигәннәр. Ә Светлана өченчесен табарга да теләге булуын әйтеп тора.

— Йөрәк тә бар икән үзеңдә! Белә торып пычак астына килгәнсең. Ә бит операциянең төрлечә чыгуы ихтимал, — дим.

— Мин аның уңышлы булачагына ышандым, кызлар, — ди ул.

Светлананың тавышында горурлык хисе дә, эшләгән батырлыгының дәрәҗәсен белү дә, беркадәр тәкәбберлек тә бар.

— Ирем бик тә балалар ярата минем. Бала өчен җанын фида кылырга риза. Өлкән кызым да кечкенә бәби сорый. Аларны шатландыру, кадерле кешеләремне бәхетле итү кулымнан килә икән, нигә әле мин булдыра алганны эшләмәскә тиеш? — дип өсти.

Хак әйтә. Әмма бүген бер, күп дигәндә ике бала китерә хатыннар. Заманасы шундый. Танцылар, кинолар, сәяхәтләр, чит илгә чыгулар кызыктыра аларны. Итәк тулы бала белән кая барасың?! Ә соңрак — соң була. Дөньяның кызыгы китә, дәрт сүрелә.

— Их, мөмкинлегем булсамы, дистә итеп түгәрәкләнгәнче табар идем үзләрен. Белмисез, тулгак белән бала табуның кадерен белмисез, — ди Светлана, безне шелтәләп.

Тулгак тоту — бөтен эч-бавырларыңны кузгатып баланың юлга чыгуы ул. Тәмуг газабы белән тиңлиләр аны. Ничек итеп шул газап рәхәт булмак кирәк, Светлана, димәкче булам. Ләкин, операция белән чагыштырганда, хатын-кызның баланы үзе таба алуы бәхеттер шул, дип, эчтән генә аның белән килешәм.

— Баланы табу белән генә түгел бит әле, Светлана. Тапкач үстерәсе дә бар аларны. Ә әйбәтләп үстерү, балага яхшы тәрбия бирү өчен пар канат, ярты юлда ташлап калдырмастай ышанычлы яр кирәк, — дим мин, сүзне икенчегә борып.

— Рөхсәттер бит? — Ишекне киереп ачып, Настя түти килеп керә. — Алла, җаным! — ди ул, еш-еш тын алып. — Ничә ел эшләп, хатынын бу кадәрле дә яраткан ирне күргәнем юк иде. Гел дә шулаймы ул, әллә кеше алдында гынамы? Көненә бишәр килә бит, билләһи...

Светлана «таш»ның кем бакчасына ыргытылуын яхшы аңлый. Аның күзләренә бәхет тулган. Алай гына да түгел, һәрбер күзәнәгендә, һәрбер кан тамырында шатлык ага Светлананың. Шул шатлык тулышып, тыгызланып килеп күзләреннән бәреп чыга. Һәр хәрәкәте, һәр адымы үз тормышыннан канәгать булуын сиздерә, һәр сулышы, һәр карашы зар-интизар булып хәләл җефетен көтеп утырган хатыннарга: «И мескен, кызганыч җан ияләре, бәндә бәндәләре! Сез өйләнешкәч тә иң мөһим минутны, ирегезне кулга алу мөмкинлеген ычкындыргансыз. Аның өчен кайберегездә наз, кайберегездә хәйлә, ә кайберегездә усаллык җитмәгән. Әйе, әйе, өйләнешкәч тә бүлегә җибәргәнсез сез ирегезне. Кесәсендә күпләп акча калдыргансыз, сансызлыкка өйрәткәнсез. Шуңа күрә хәзер авызыгызны чөйгә элеп утырасыз да. Ә ирләрегез сезгә иң кирәкле вакытта күзгә дә күренми», — ди кебек.

Табигый хәл. Светлана кебек кадерле хатыннар янында бик һаваланып булмый. Ниндидер гаебең, кыек эшең бар сыман, кырыйдарак торасың. Чәчрәп чыга, артыгын сөйләшә алмыйсың.

— Сезгә, җаным, үзегезгә бер почтальон кирәк, — ди Настя түти, һаман үзенекен тукып. — Кара син аны, кишеренә, чөгендеренә кадәр угычтан чыгарган. Бәби тапкан хатыннарга иң кирәге кишер белән чөгендер икәнен каян белгән? — Настя түти кызык итеп көлә. Күзләре тәмам кысыла, икенче ияге сакал кебек селкенә башлый. Гәүдәсе туңып өлгермәгән дерелдәвек кебек калтыранып тора.

— Ул, апа, безгә ни кирәген миннән күбрәк белә, — ди Светлана, ире тутырып җибәргән пакетны кулына алып. — Чынлап та, кеше өчен кишер бәк файдалы ул, Начтя түти. Күзнең күрү сәләтен, йөзнең нәфислеген саклый торган витаминнар күп анда. Ә менә азрак шикәр комы салып, өстенә кайнаган су коелган кызыл чөгендер төнәтмәсе йөрәк авыруыннан саклый, ди. Саный китсәң, бәк күп чөгендер белән кишернең файдасы.

— Әллә табибмы син, җаным? — ди Настя түти, күзен зур итеп ачарга тырышып.

— Табиб түгел мин. Әмма кайбер игътибарсыз табиблардан күбрәк беләм. Профессорларның, доцентларның халык медицинасы һәм дару үләннәре турындагы бәк күп хезмәтләрен укыдым, язып алдым.

— Ә, юк, самолечение опасно, җанкисәгем, — ди Настя түти, башын чайкап.

— Нәрсәсе куркыныч булсын икән аның! Мәсәлән, йоклый алмый башлыйм икән, бер стакан җылы суга бик әйбәтләп бер аш кашыгы балны болгатам да йокларга ике-өч сәгать кала эчеп җибәрәм. Атна-ун көн шулай эчсәң, күзләрең үзеннән-үзе йомыла башлый. Файдасы тимәсә дә, балның зыяны юк, Начтя түти. Балны аны җитмеш төрле авыруга дәва, таң сызылганда йолдызларның чәчәкләргә кунган нуры ул, ди торганые безнең әби.

— Әллә ниләр беләсең син, Светлана, — дим, мин дә сүзгә кушылып.

Светлана, шуны гына көткәндәй, тагын да тәфсилләбрәк сөйли башлый.

— Юк, бик каты авырмаганда кеше кебек тора салып хастаханәгә йөгермибез без. Иремне дә, баламны да хәзинәдә булганы белән үзем дәвалыйм. Әйтик, ютәлли башлады, ди. Сарымсакны бик әйбәтләп угычтан чыгарам. Аягын сабынлап юып, сарымсак белән табанын ышкыйм, йон оекбаш кидереп куям. Тагын шулай ук бер стакан суга бер аш кашыгы балны болгатып бирәм дә төреп урынга салам. Менә шуларның нәрсәсе начар инде, йә? — ди ул, әле беребезгә, әле икенчебезгә карап. — Барысы да үзебез ашап-эчә торган әйберләр. Ә дәвасы тисен өчен, билгеле бер тәртипкә салып, кирәк вакытында кулланырга гына кирәк.

Ул да булмый, кучтәнәчләрен тумбочка өстенә таратып:

— Сүз бетмәс ул, әйдәгез, хатыннар, сыйланыгыз, — дип безне кыстый. — Начтя түтекәчем, монысы сиңа! — Почтальонның кесәсенә бер төргәк сала, чупылдатып битеннән үбә.

Настя түтинең дәррәү авызы ерылып китә.

— Рәхмәт, Светочка, — ди ул. — Ирең нәрсә әйтим? Тагы килсенме?

— Тагы килсен. Син никадәр күбрәк килсәң, хатының шулкадәр тизрәк савыгачак, диген, Начтя түтекәчем!

Авыр адымнар белән көчкә хәрәкәтләнеп, уфылдап килеп кергән Настя түти, тәмам җиңеләеп, балкып бүлмәдән чыгып китә. Аның таза гәүдәсе дә ничектер җыйнакланып калган кебек тоела.

«Менә бит, — дип уйлыйм мин эчемнән, — җылы сүз нишләтә кешене. Димәк, Светлана өйдә дә шундый ук тере, җылы һәм таләпчән, һәрберебезгә үрнәк алырга кирәк. Хатын-кызга бик тә кирәк гадәтләр бу...»

Үрнәк алырга дип, Гөлмәрьямнең тормышыннан зарланганы юк әле. Илдарыннан һәрвакыт канәгать булып, янында ныклы терәк тоеп яши ул. Бераз гына корырак булса да, игътибарлы, ышанычлы кеше аның ире. Иртән-иртүк шулпасын кайнатып, сөтен алып, базар кучтәнәчләре күтәреп хастаханәгә бер тапкыр килеп киткән икән, нигә дип тагы-тагы чакырсын әле аны Гөлмәрьям? Якын итеп язылган хатын укыгач, тәрәзәдән иренең килешле буй-сынын карап калгач, өстәп ни кирәк бәби тапкан хатынга? Ә Светланаларга килгәндә, үзләренә шулай ошый икән, ул мәсьәләдә икесенең дә холык-фигыле пар килгән икән, яши бирсеннәр. Ничек яшәү — һәркемнең үз эше ләбаса.

— Әниләр! Йөрәк җимешләрегезне кабул итәргә әзерләнегез! — ди очып кына йөрүче очкын күзле шәфкать туташы. Үзе, эскәк очына эләктереп, бор кислотасы эремәсендә чылатылган мамык өләшә. Бүлмәдә җанлылык башлана. Без җылы су белән сабынлап кулларны, күкрәкләрне юабыз. Авыз-борынга ак япма, башыбызга ак яулык бәйлибез. Имеп туйгач, баланы салып торырга ятакка клеенка җәеп, урын хәстәрлибез. (Акыллы хатыннар, күкрәкләренә массаж ясап, сөтенең сыек өлешен банкага савып куя.)

Ана сөте — изге сөт. Дөньяда аны бернинди ризык та алыштыра алмый. Ана сөте аша нарасый җанына игелек күчә. Ана сөте баланың җелегенә егәр бирә. Ана сөтен озак имгән бала сәламәт, таза бәдәнле, озын гомерле була.

Ни газизрәк — бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!
Ул мөкатдәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр! —

дип кабатлыйм мин эчемнән генә Дәрдмәнд шигырен.

Уйлап карасаң, менә шушы шигырь генә дә ана сөтенең хикмәте түгелмени? Юкса алтын промышленносте хуҗасы, миллионер Закир Рәмиевне ил-ватан турында уйланып, нечкә лиризм белән сугарылган шигырьләр язарга кем мәҗбүр иткән? Акча кирәк булганмы аңа? Юк. Изге сөт — ана сөте эше бу!

Без сабыйларны күтәбез. Җанда, тәндә ниндидер үзенә бертөрле түземсезлек, талпыну. Тән буйлап кайнар кан акканы, күкрәкләргә сызлатып җылы сөт тулганы сизелә. Баштанаяк акка киенеп, дөньяда иң кадерле, иң асыл җан иярен күтәбез. Менә алар. Таш курчактай тыгыз итеп төрелгән нарасыйлар. Кулга алгач, югары күтәреп: «И газизем, йөрәк парәм, алтын алмам! — дип дәшәсе килә. — Күр, нинди якты дөньяга тудырдым мин сине! Беләкләремә күчәр егәремне, битләремә кунар аллыгымны бирдем. Ләкин мин генә түгел, син дә чиксез ләззәт китердең. Син миңа мәшәкатьле һәм мәгънәле тормыш бирдең, көч бирдең! Чынлап та, мин хәзер шундый дәрманлы, бер генә җил дә, бер генә давыл да аяктан ега алмас кебек. Һәм бернинди дәрья дулкыны да җир йөзеннән юып төшерә, агызып алып китә алмастыр сыман. Кайчагында кысып-кысып кочасы, рәхәтләндереп сөясе килә үзеңне. Юк шул, синең әле ныклап тотарлыгың да юк. Син шундый нәни, кечкенә, сине бары караш белән генә, җан белән генә иркәләргә-назларга ярый. Синең белән сак һәм иплә эш итәргә кирәк. Чак кына җайсызрак тотсаң да, очанлап, уалып китәрсең сыман!»

Улымны күкрәгемә якын китерәм. Әбәү лә инде, иренен турсайтып, борчылгандай итә. Нинди ачы әйбер бу? Минем эммәтәемә кем нәрсә сөрткән, янәсе... Нарасыем кагылган күкрәктән үзеннән-үзе сөт

тама башлый. Улымның алсу иреннәрен сөткә тидерәм. «Ай, менә икән ич ул тәмле әйбер!» Бала имә. Тәмләп, рәхәт итеп имә.

Дөньяда кеше шуны белеп калсын: хатын-кызның бала имгәндә алган ләззәтен башка бернинди рәхәтлек тә алыштыра алмый. Ул ләззәт тәнгә сихәт бирә. Тормышның иң матур якларын искә төшереп исертә. Ул рәхәтлек сине бөтен дөнья мәшәкатьләреннән арындыра, онытылдыра, оета. Гүя татлы йокыга талдырып, җәннәткә илтә...

Чү!

Үз күзләремә, үз колакларыма ышаныргамы, юкмы дигәндәй, кинәт әсәренеп калам. Кинәт чалт аяз көндә күк күкрәп, яшен яшьнәгәндәй тоела. Тымызык көндә җил-давыл уйный башлый. Көн яктысы томалана. Кеше күңелендә зилзилә куба...

— Алмыйм мин аны. Имезергә дә алмыйм, хастаханәдә калдырам...

Нарасыем белән мавыгып китеп, тирә-юньдәгене бөтенләй искәрмәгәнмен, ахры. Тимер караватта тимер кебек салкын, тимер кебек каты бәгырьле ана ята икән. Янында, аннан туган баланы күтәреп, шәфкать туташы басып тора.

— Күз генә салыгыз. Кызыгыз арада бер тере, әйбәт бала. Керфекләренең озынлыгын күрсәгез икән. Үсеп җиткәч, егетләрне аяктан егар дәрәҗәдә чибәр кыз булачак... — ди ул, гасабиланып.

Ана эндәшми. Урынга китереп салганнан бирле, беркем белән сөйләшми, беркем белән аралашмый, аркасын куеп ята ул. Аның җавапсыз калуын килешүгә исәпләпме, кыз тагын:

— Кулларыгызны юыгыз, көтеп торам, — ди. Үзе читкәрәк китеп баса да бала булып сөйләшә башлый: — Син нәрсә, әнием. Минем карыным ачканны белмисеңме әллә? Минем бит дәү үсәсем, синең белән чәбәк-чәбәк уйныйсым, тәпи басасым бар...

Ләкин ананың һаман да кымшанмыйча ятуын күреп:

— Бәй, сез әллә чынлап та тормаска уйладыгызмы? — ди ул. — Нәрсә булды сезгә? Авырмыйсыздыр ич?

— Янымда җан көеге булып тормагызсана. Алмыйм дигәч алмыйм...

— Эчегездә җаныгыз бармы соң сезнең? Шушындый томрап торган баланы ни йөрәгегез белән калдырып китәргә уйлыйсыз?

— Шул шул, җаным булганга йөрәгемне бозасым килми. Бер имезсәң, калдыру авыр, диделәр...

— Аһ, нәләт! Аһ, хәсис! — дип чәчрәп чыга моңа кадәр көчкә түзеп торган Светлана. — Йодрык кадәр сабыйның бәләкәй йөрәгeн түгел, үзенең туң йөрәген кайгырта бит әле. Оялмыйча хастаханәдә хөкүмәт ипиен ашап ята. Кадер-хөрмәттән бер дә баш тартмый, ә баладан...

— Си-ин! Артык кызма. Җөйләрең шартламасын!

— Шартлатырмын мин сиңа. Бик каты шартлатырмын. Зинһар өчен, алыгыз аны безнең бүлмәдән. Андый хәсисләр сасыткан һаваны сулыйсыбыз килми, — ди Светлана шәфкать туташына.

— Юк инде, ярык корсак. Боерык биреп ятарга «Әпипә»гә биеп йөрүче ирең юк монда. Хастаханәдә син дә бер, мин дә бер. Менә хәзер одеялымны ачам да ботымны күтәреп ятам...

— Тфү, нәләт! — ди Светлана, икенче якка борылып. — Җир дә йотмый бит шундыйларны. Кара аны, мин сине болай гына калдырмаячакмын! — дип яный.

Светланага, туктарга кушып, ишарә ясыйм. Чөнки мондый сөйләшүнең уңай нәтиҗә бирмәячәге көн кебек ачык. Аулакта калып, кешеләрчә аңлашып карарга кирәктер. Бәлки...

Шәфкать туташы, өметен өзеп, тынгысызлана башлаган сабый белән ишеккә юнәлә.

— Сеңлем, бир әле монда, — дим мин, әллә кайчан туеп, кулымда йокыга киткән улымны урынга салып. Кулларымны, күкрәкләремне кабат юып, ят баланы кулыма алам. Текәлеп-текәлеп күзләренә карыйм. «Сабыкай, — дим эчемнән генә. — Сиңа шушы якты дөньяга туарга җиде ят ярдәм итте, җиде ят ап-ак биләүгә биләде. Ә тудырган анаң баш тартты... Юк, юк, ташламас ул сине, дөресрәге, ташлап китә алмас. Кайнар күкрәгендә кайнар сөте ташып торганда, ризыгыңны кисмәс. Ул да кеше ләбаса. Әйбәтләп сөйләшкәнне аңлар, шәт...»

Уемны белгәндәй, безне аулакта калдырып, Светлана чыгып китә.

— Кәримә, — дип эндәшәм мин куенымдагы баланың әнисенә, — хастаханәдән бергә чыксагыз, бәлки, әтиегез дә килер?..

— Килми, — ди Кәримә, кырт кисеп.

— Кәримә, — дим мин тагын, бераз тын торганнан соң, — хастаханәдән чыккач, ирең янына, бәлки, мин барып сөйләшеп карармын?

— Эт белән юллап табалсаң...

— Э-э-э, кайда икәне дә билгеле түгелмени? Сабый кызганыч бит, Кәримә. Тере әнисе, тере әтисе була торып... ятим яшәсенмени?

— Тотындылар нотык укырга! — дип мыгырдана Кәримә. — Берни булмас, үлмәс. Совет хөкүмәте үтерми ул, — дип тә өсти.

— Үлүен үлмәс. Бәлки, синнән яхшырак киендерерләр дә, яхшырак карарлар да. Ләкин гомере буе ана назы, ана җылысы җитмәячәк аңа, Кәримә! Биләүдән дә чыгар, тәпи дә баса башлар. Әнә шул

беренче адымын ясаганда кулын сузып кемгә килер ул? Беренче уңышына, беренче һөнәренә кем сокланыр аның? Үз итеп кем яратыр, кем иркәләр? Урынсызга кыерсытылганда, яклау эзләп, кемнең итәк арасына шомырт башын яшерер?

— Яшермичә үсүчеләр дә бик күп, ул да үсәр, — ди Кәримә.

«Ала-ай, димәк, игә килергә исәбе юк моның», — дип уйлыйм мин.

— Соң, шулай булгач, үзең шул ятимнәрне күреп тә торгач, нигә балаңа да усал язмыш калдырасың?

— Дөньяда андыйлар да кирәк. Мин бу эшне эшләмәсәм, телеңнең кычытуын кем белән басар идең әле менә? — ди бу миңа.

Булмый икән моның белән сөйләшеп. Юк, булмый икән. Анасыннан тәмам өметемне өзеп, йотлыгып-йотлыгып имгән сабыйга карыйм. Күзләремә яшь килә. Бүген үк ятимлеге башланды ич инде бу нарасыйның, бүген үк... Бер атна да үтмәс, аның белән бергә туган балаларның әтиләре, якыннары килер. Ефәк юрганга төреп, җиңел машинага утыртып, чәчәк бәйләмнәре белән өйләренә алып китәрләр. Ә сине, гөнаһсыз сабый, хастаханәнең кыршылып, төсе уңып беткән одеялына төрерләр дә балалар йортына озатырлар, ташландык исеме тагарлар...

Тәки үзенекен иткән икән. Бүлмәгә өлкән шәфкать туташын ияртеп Светлана килеп керде. Шәфкать туташының Кәримәгә «әни кеше» дип мөрәҗәгать итүенә үк кабынып китте:

— Нинди ана булсын ди ул! Хәтта хайваннар да үзләренең балаларын яламыйча, иркәләмичә, тамакларын туйдырмыйча ташлап китмиләр... Интим хисләрен тыя алмаганнан гына бала табарга мәҗбүр булган хатын нинди ана булсын ди? Ана исеменә лаек түгел ул...

— Тынычланыгыз, сезгә борчылырга ярамый, — диде шәфкать туташы һәм Светлананы караватына илтеп куйды. — Ә сезнең белән баш табиб янына кереп сөйләшик.

Алар чыгып киттеләр. Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Бөтен тән ватылып, авыраеп калган иде. Сабыйларны озатуга, икебез дә, кисеп ташланган агачтай, урыннарыбызга аудык. Гүя безне эт итеп кыйнап ыргытканнар иде. Юк, тән түгел, җаннар кыйналган иде безнең, җаннар!..

Соңыннан баш табиб белән әңгәмәгә Кәримәнең карт әнисе дә килүен белдек без. Ул инде кызының бер баласын тәрбияли икән. Әлеге сабыйны да хәлсез куллары белән төреп куенына алган. Әмма йөрәгендәге җылысы бетмәсә дә, җитмеш яшьлек карчыкның беләгендә нинди җегәр калсын соң? Кулына алган баланы чак кына төшереп җибәрмәгән. Шул көнне баланың язмышы анык хәл ителгән: ай дигәндә, балалар йортына озатылачак ул...

* * *

«Ашыгыч ярдәм» машинасы бик тә ашыгып йогышлы авырулар хастаханәсенә килеп туктады. Әмма анда тиз генә кабул итәргә ашыкмадылар безне. Хәер, өйгә килгәч ясалган уколдан соң баланың хәле бераз аруланган иде арулануын. Тик барыбер тәне кайнар, төргән чүпрәге аша кулларны пешерә. Табиблар китереп җиткерүләре турында документ тутырып кул куйдырдылар да кире борылдылар. Ашыгалар. Чакырылган урыннары күптер, мөгаен. Бераздан безне дә, карап-тыңлап дигәндәй, коридорга салдылар. Улыма укол ясадылар. Ул йоклап китте. Мин дә бераз гына булса да тынычландым. Табиблар кулына килеп эләккәч, шәт, ничек тә ярдәм итәрләр, үләргә ирек бирмәсләр дип уйладым. Әмма... Атна-ун көн үтүгә, безнең авыруыбызның монда түгел, бәлки икенче хастаханәдә дәваланырга тиешлеге беленде. Күчеп, яңа җирдә яңа дәва ала башладык. Яңа дуслар, яңа язмышлар белән очраштык. Ләкин хастаханәнең монысында да терелеп чыгарга язмаган икән безгә. Кабаттан да «ашыгыч ярдәм» машинасы белән ашыгыч рәвештә өченче хастаханәнең хирургия бүлегенә озаттылар. Баланың тәне яңадан ут кебек кызышты, яңадан тыны кысылды. Кабул итүче табиблар, тиз генә температурасын төшереп, үпкә сурәтен ясаттылар, анализлар алдылар, боларның йөгерешүенә карап, күңелемне нindидер шом биләде. Икенче яктан караганда, сабыем язмышы өчен дистәләгән белгечнең җаваплы булуы бераз гына тынычландырды да. Шул көнне үк, улымның умрау сөяге турысындагы венасын табып, кан һәм дарулар җибәрү өчен махсус җайланма куйдылар. Шул көнне үк даруны кан юлына тамызып торучы система көйләделәр. Озын төн буе керфек тә какмыйча, системаның төгәллеген күзәтеп утырдым. Миңа калса, табиблар мөмкин булганны эшләделәр, ә организмга даруның тигез һәм дөрес баруын тәэмин итү минем бурычтыр сыман тоелды. Шушы минутларны, шушы көннәрне исән-имин кичерсәк, улым савыгыр кебек иде...

Юк шул, эшнең башы гына булган икән әле бу. Икенче көнне иртән обход булды. Безнең бүлмә авыруларын дәвалаучы табиб үзе белән таныштырды. Ул миңа улымның үпкәсендә яман да усал, эшәке авыру — стафилококк ялкынсынуы башлануын әйтте, һич кичекмичә пункция ясарга кирәклеген, башка чара булмавын аңлатты. Риза булмый хәлем юк: балакаемны үз кулым белән процедура бүлмәсенә озаттым.

Уйласам, хәзер дә шаккатам. Сабыемның инәлеп-инәлеп елавына ничек түздем икән шул чагында? Һәртөрле пункция-операцияләрнең яшь балага бернинди наркозсыз, өшетүсез — тере тәнгә ясалуын

мин соңыннан гына белдем. Тере тәнгә! Кайчагында кулга шырпы гына керә. Кайчагында бармакны гына кисәбез. Шул нәни генә яра да ничек әрни бит... Операцияне үз тәнемә ясасалар, җаным ул кадәр үк авыртмас, йөрәгем ул кадәр үк сыкрамас иде... Көткән кешегә озак тоела бит ул. Кулымда сәгатем юк. Әллә кайчан төш авышкан, әллә кайчан төн җиткән кебек тоелды. Балакаемның да тавышы тынды. Тавышы килми башлагач, тагы эчем пошты. Хәлсезләнеп, еларлык та көче калмагандыр инде дип уйладым. Шулчак улымны чыгарып урынына салдылар. Бөтен күкрәк читлеген ак бинт белән чорнаганнар. Култык астыннан чәнти бармак юанлыгында резин көпшә күренеп тора. Шуңа банка беркеткәннәр. Эссе мунчада бик озак чабынгандай, изрәп, хәлсезләнеп калган сабыем. Агарынган, сулган, бәләкәйләнеп киткән...

— Алтын алмам, матур кешем, — дим мин, аның янына чүгәләп. — Бик тә авыр булгандыр шул. Яныңа кертсәләр, нәни бармакларыңнан тотып кына булса да торыр идем дә бит, ярамый... Син акыллы, улым, түздең. Ир-егетләрчә тоттың үзеңне. Әтиеңә мактап хат язармын менә...

Әти димәктән, бик тә борчыла Илдар улыбыз язмышы өчен. «Нинди дарулар кирәк?» — дип сорап кына тора. *«Ничек дәвалыйлар, алга китеш бармы? Баланың ныклыгы синең сөтеңә дә бәйләнгән. Борчылмаска тырыш, яхшылап аша»,* — дип хатлар яза. Бәясе белән исәпләшеп тормыйча, базардан җиләк-җимеш, яшелчә ташый. Шулай бервакытны, тавык шулпасына йорт токмачы килешә дип, токмачлы аш пешереп килгән. Килгәч, ашын пакеттан чыгарып, тагы бер карады. «Үземчә бик нечкә итеп кисәргә тырышкан идем, ашка салгач, әллә нишләп үсеп, калынаеп китте бу токмачлар», — ди. «Бәй, син камырны кайдагы оннан бастың?» — дип сорыйм мин, күзәнәкләнеп, эре булып пыяла банка аша күренеп торган токмачларга карап. «Яшел кәстрүлдән алып», — ди Илдар. Мин көлеп җибәрәм. Яратып чәчләрен тузгытам. Җилкәсенә сыенам. «Анда коймак оны иде бит», — дим. «Ишкәнмен икән ишәк чумарын», — ди Илдар да, елмаеп, һәм үзенең егет чагында ничек итеп крахмалдан коймак пешерергә азаплануын искә төшерә.

«Йә, ярар, табиблар күрсә ачуланырлар», — дим мин, ирем белән хушлашып. Битеннән үбеп, улым янына йөгерәм.

Әтиебез, чынлап та, әйбәт кеше безнең, улым. Синең дә зур зәңгәр күзләрең, киң маңгаең, сорау билгесе кебек озынча колак яфракларың нәкъ әтиеңнеке төсле. Әй, охшаудамыни хикмәт? Гел охшамасаң да, безнең балабыз инде син. Безгә синең тизрәк терелүең, сәламәтләнүең кирәк, улым. Тизрәк үсеп, балигъ булуың, кеше булуың кирәк!

Хәзергә син йоклыйсың! Син бик тә арыгансың. Күз кабагыңны күтәрерлек тә хәлең юк. Әмма әйтеп бетергесез матур син! Һәм шулкадәр дә якын, шулкадәр дә газиз, шулкадәр дә кадерле, йөрәгемнән өзелеп төшкән җимешем син, җанымны ярып яралган балам. Беркем, берни белән алыштыргысыз табышым. Әнә банкадагы фурацилинда нәни генә һава куыклары сикерешә. Димәк, син сулыйсың. Димәк, син исән! Син яшисең!

Стафилококк авыруы — яман да куркыныч чир, дип сөйли дәвалаучы табиб. XX гасыр чумасы икән аның исеме хәзер. Хәтта бик озак дәвалап, инде кеше сәламәтләнде дип торганда да микробларның икенче органга күчеп утыру ихтималы бар икән. Шуңа күрә, сизенүгә үк, тиз генә дәвалый башларга кирәк, ди табиб.

Андый очракта да тиз генә бирешә, тиз генә җиңелә торган авыру түгел икән әле ул.

Мин улымнан күземне алмыйм. Керфекләренең әз генә дерелдәп китүе дә минем өчен олы шатлык.

Безнең өйдә без җидәү дигәндәй, палатада җиде җан иясе без. Ике өлкән кеше, биш бала. Минем улымнан соң шундый ук пункцияне Азат исемле балага ясадылар. Аның инде бишенче яше. Әнисе Лидия ханым киткәндә, елый-елый: «Зинһар, улыма күз-колак булыгыз, русча бер авыз сүз дә белми», — диде. Азат тыныч, акыллы бала. Ләкин ак халатлы кешеләрдән уттан курыккандай курка. Мөмкинлеге булса, минем артка гына яшеренмәс, әллә кайларга чыгып качар иде, бичара. Әле хәзер дә, шәфкать туташы процедурныйга алып кермәкче булгач, бөтен көчен җыеп каршы торды. Каерылып-каерылып миңа карый, күзләре белән ярдәм сорый. Сикереп торып, Азатны күтәреп алам. Тынычландырып җибәрергә кирәк балакайны. «Азат, син бик әйбәт егет, тик авырыйсың. Әниең янына, әтиең янына, апаң янына тизрәк кайту өчен менә бу апаң белән кереп, даруланырга, укол ясатырга кирәк сиңа. Бераз гына авыртса да, еламаска, түзәргә кирәк», — дим. Азат минем белән килешә. Ак халатлы апаны җитәкләп, процедура бүлмәсенә юнәлә.

Әйткәнемчә, бүлмәдә олы кешеләр икәү без: Сабиратти белән мин. Һәм тагы төрле яшьтәге биш бала. Үзебезнекеләрдән тыш янә дә өч баланың астын алыштыру, юындыру, дарулар бирү, ашату-эчертү — безнең эш. Аның өстенә иртәнге якта кайсын рентгенга, кайсын кварцка, кайсын ингаляторга алып барырга кирәк.

Сабиратти бик тә гадел зат. Эштән чирканып, эшне бүлешеп тормый. Ләкин аның өчен биредә бер әйбер аңлашылмый. Ярый, бу эшләрне башкарырга шәфкать туташлары җитешмәде дә ди. Булышабыз, кулыбыз калмый. Ә нигә балалары белән яткан аналарга урын-җир көйләнмәгән монда, ди ул. Кара инде син, балаңа сиксән сантиметрлы бер тартма бирделәр дә, үзеңә ни урын-җир, ни койка-мазар юк. Көнен дә, төнен дә бер урындыкта булмый бит инде. Ул бит бер генә төн, бер генә көн түгел. Бала

имезгән, көне буе өч-дүрт сабыйны тәрбия кылган хатын кәкрәеп коры урындыкта йокларга тиеш микәнни?

— И Сабиратти, улым терелеп чыкса, урын димәс идем әле. Ничек тә түзәр идем.

— Без шулай инде, — ди Сабиратти. — Менә мин дә бер җылы сүзгә алданып, дару исенә исереп ятам. Киленемне әйтәм, әмма дә тәмле телле инде. «Әнкәй бәгърем, безнең өйдә баланы синнән дә оста, синнән дә әйбәт караучы юк, — ди. — Әнкәй бәгърем, син кирәк чагында әкиятен укыйсың, кирәк чагында өшкереп аласың», — дигән була. Ә мин, тиле дигән саен тигәнәк буе сикереп, менә айдан артык инде оныгым белән бүлнистә ятам, — ди. — Менә бу балага да күз тигән, — ди Сабиратти, өч яшьлек Катерина янына килеп, — күзләрен яртылаш ачып йоклый мескен сабый. — Һәм әкрен генә үзенекен укый:

Бисмиллаһи мар-мар,
Бисмиллаһи зар-зар,
Име-томы бар-бар.
Алтмыш алты ала күз,
Җитмеш җиде кара күз,
Әллә хатын, әллә кыз,
Тфү, тфү, тфү...

Бала йоклый. Сабираттинең сүзе моның белән генә бетмәгән икән әле:

— Әнкәй мәрхүмә әйтер иде: балага сокланмагыз, кинәт кычкырмагыз, дияр иде. Балага кинәт кычкырсаң, куркулы булып кала, дияр иде. Хәзерге яшьләрне карап-карап йөрим дә, — кая кычкырмаган! Өнен алалар сабыйларның. Бертуктаусыз кимчелекләрен әйтеп, бәгырьләренә төшәләр. Бер уйласаң, хатын-кыз да жәл! Нишләсен, чыдыйлар-чыдыйлар да, түземнәрен җуеп, исерек ирләренең ачуын сабыйларыннан алалар бит алар.

— Сабиратти, сезнең улыгыз эчми дә, тартмый да торгандыр, шулай бит? — дим мин.

— Әй, олан, эчмәгән кеше бармыни инде ул хәзер! Кайтып тавыш куптармаса, китереп сукмаса, салуына гына бик риза инде мескен хатын-кыз.

Икебез бергә авыр сулап куябыз.

— Хәзерге хатыннарны әйтәм, — дип дәвам итә Сабиратти, — карап кына торырлык, өрмәгән җиргә утыртмаслык матурлар бит. Күбесе исерек белән чиләнә шуның. Рәхәтләнеп ир кочагында сөеп-сөелә алмыйча, наз күрмичә тилмерә. Тәнендә дәрте ташып торганда, алпан-тилпән атлап өшәнгән ире кайтып кергәч, ачуы килми нишләсен соң? Ачуын аяк арасында уралып йөргән баласыннан алмый кемнән алсын? Менә шулай итеп, үзебез тапкан балаларны үзебез бозабыз без, Гөлмәрьям олан. Бернәрсә булса, күкерт кебек кабынырга әзер торган балаларны үзебез тәрбиялибез. Миңгерәтеп бетерәбез.

Мин тыңлыйм, гыйбрәт җыям, каршы әйтергә көчем дә, теләгем дә юк.

...Ә күпме бала аракы аркасында җитлекмичә яки гарип булып туа. Әнә Катерина шуның ачык мисалы. Аяк-куллары, ташка үлчим, туганнан бирле хәрәкәтләнми. Җитмәсә, аның үпкәсендә дә шул ук стафилококк чире башланган. Күзләренә күчкән. Озакламый сабыйның уң күзен алачаклар. Ничек ул түзәр дә, ничек без түзәрбез?

— Белмим, белмим, — ди Сабиратти. — Юк инде, бер булмаса, көтү көткән акчаңны да бирмәсләр, — дип өсти. — Катеринаның әнисен әйтәм әле, хәмер белән аңы томаланмаса, мондаен да авыр вакытта тудырган баласы янына килми калыр идемени? «Миңа авыру бала кирәкми. Үлсә, телеграмма бирерсез», — дип әйтеп әйткән ди бит!

Без сөйләшеп утырган арада, Азатыбызга операцияне ясап та бетергәннәр. Аны да шундый ук банка белән бүлмәгә чыгарып салдылар. Ул да тәмам хәлсезләнгән, шабыр тиргә төшкән иде. Иреннәрен көчкә тибрәтеп, еламсырап әнисен чакырды.

— Әниеңә бергәләп хат язарбыз, яме, Азат. Азат хәзер бик әйбәт дәвалана. Тиздән бер җире дә авыртмаячак, диярбез. Менә килегез әле, күрегез әле, Азат ничек дәү үсте, диярбез.

Азат тыңлый. Ул барысын да аңлап, уйланып ята. Йөзенә карап, мин аның ныграк булырга тырышканын тоям. Сөлгесен юешләп, маңгаен, муен тирәләрен сөртәм. Иренәнә мамык белән су тидерәм. Әкрен генә тагын шигырь укыйм.

*** * ***

Дөнья күп төрле көтелмәгән очрашулар белән тулы.

Менә без дә очраштык. Кем белән дисезме? Бала тудыру йортында үзем имезеп утырган ятимә кыз белән. Исеме чынлап та «ташландык» иде сабыйның. Без яткан бүлмәгә алтынчы бала итеп керттеләр аны. Сөтегез калса, имезерсез, диделәр. Ә мин якын бер дустымны, әллә күпме белгән танышымны очраткандай шатландым. Күтәреп улым янына алып килдем. Икесен сөйләштерәсе иттем.

— Улым, карале, кем килгән безнең янга? — дидем. — Исеме Кәримә атлы, ди, улым. Бәй, тукта, әнисе дә Кәримә иде ич. Кәримә кызы Кәримә була димени, язмаганны! Безнең татарда алай олы Иван да кече Иван юк ул, әйеме, улым? Әйдә, икенче исем эзлик. Матурны... Ләйләгөл ничек булыр?

Улым, сүзгә кушылып, раслагандай:

— Ыг-гы, гы-гы, — дип куя.

— Менә бит, сиңа да ошады, — дим мин, сөенеп... — Димәк, бүгеннән башлап исемең Ләйләгөл булыр, кызым, — дим мин күптәнге танышыма.

Ләйләгөл хәтсез үскән, тернәкләнгән. Авыруны җиңеп килә. Култык астындагы ярасы да нәни генә җөй калдырып төзәлеп беткән. Ә минем йөрәк парәмә шундый ук операцияне кабат ясадылар. Чөнки беренче пункция бер сантиметрга өскәрәк тишелгән икән...

Шулай ук бәхетсез йолдыз астында тудың микәнни соң син, минем бәгырь кисәгем? Ничек түздең икән син ул яраларга? Әгәр телең булса: «Бик тә авырта шул, әнием», — дияр идең дә бит, телең ачылмаган. Ә күзләрең белән телле кешеләрдән болайрак сөйләштек без синең белән, улым!..

Гомеремнең соңгы минутына кадәр онытасым юк синең күзләреңне. Шундый да акыллы, шундый да түзем күзләр булса да булыр икән... Сиңа авыр икәнен, кайбер минутларда хәл эчендә ятканыңны яхшы беләм. Шуңа күрә сине әз генә булса да юатырга исәпләп, уенчык кыңгыравыңны шалтыратам. Кулыңа ялтыравык шарлар биреп карыйм. Авызымны бөреп төрле авазлар чыгарам. Ә син зур, уйчан зәңгәр күзләрең белән текәлеп карап ятасың-ятасың да аскы иреңеңне дугаландырып елап җибәрәсең. Күзләрең белән: «И әни, мин ут эчендә ятам, ә син ничекләр көлә аласың?» — дисең кебек. Мин, бик олы гаеп өстендә тотылгандай, каушыйм, кыенсынам. Үземне «акылсыз» дип тиргим. Күңелем белән синнән гафу үтенәм. Күзләремне синең зур зәңгәр күзләреңнән яшерәм. Зинһар өчен, гафу итә күр, йөрәк парәм. Чөнки мин ул көннәрдә һаман өмет белән, синең терeлəчәгеңә олы ышаныч белән яшәдем. Мин ул вакытта синең култык астына ясалган пункция тишекләренең бергә кушылып зур ярага әверелүен белми идем әле...

Улым хирургия бүлегенең аеруча җитди авырулары исемлегендә. Еш кына төркем-төркем табиблар, студентлар кереп хәлен белешәләр. Авыруның ничек башлануы, үземнең һәм әтисенең нинди чирләр кичерүе белән кызыксыналар. Атнага бер мәртәбә профессор үзе бөтен авыруларга күзәтү ясый. Һәр бала янында озаклап туктала. Беренче һәм соңгы анализлар белән таныша. Ренгент сурәтләрен җентекләп карый, киңәш бирә.

— Үпкәсен көнбагыш маенда эретелгән прополис белән юдырып карарга. Начар имгән көннәрдә зонд аша тукландырырга, кан алыштыруны дәвам итәргә, — ди ул синең турыда.

Әгәр дә мәгәр җир йөзендә могҗиза булса, әгәр дә мәгәр җир йөзендә берәр профессор тудырганнан соң баласына әнисе җанын күчереп куя алса, бернинди икеләнүсез газиз җанымны сиңа бирер идем, улым! Ә хәзергә җанымны түгел, нибары канымны гына бирә алдым!

Процедурныйга икебезне бергә йөртә башладылар. Минем беләктән йөз илле грамм кан алалар да шунда ук сиңа җибәрәләр. Шифасы тия булыр, тими калмас. Бит очларыңа нәни генә алсулык йөгергән, йөзеңә нур кунган кебек тоела. Шулай тоелган гынадыр... Ә бәлки, чынлап та, шулай булгандыр. Син авыруны җиңә, терелә башлаган кебек идең инде югыйсә. Үлемең бөтенләй көтмәгәндә булды...

Күпме гомердән соң андый матур көнне беренче күрүем иде. Никтер бик иртә йокы ачылды. Торып, бүлмәнең идәнен юып чыгардым. Тузан сөрттем. Ләйләгөл белән синең күлмәк-ыштаннарыгызны юдым.

Кызык инде. Әйтерсең сез игезәк балалар. Икегез дә бер күкрәк сөтен имеп үскәнгә шулай якындыр, бәлки? Өс-башыгызга кидерергә дә икегезгә дә бертөрле кием-салым, башлык алам. Матурракларын, каралгач та кире бирмичә, үзем юып, үзем үтүклим. Кергәч, безнең бүлмәдәге чисталыкка, балаларның караулы булуына табиблар да игътибар итә. «Рәхмәт», «Яхшы», — дип, Сабиратти әйтмешли, салпы якка салам кыстыргалап куялар.

Соңгы көннәрдә синең уңайрак булуыңа сөенеп, тәмам очынып, шатланып йөри башлаган идем инде, улым. Син әнә йоклыйсың. Аякларыңны шундый кызык итеп чәлмәштергәнсең. Зурлар кебек, уң кулыңны баш очыңа куйгансың. Сул кулың һәрвакыттагыча күкрәктә. Култык астыңдагы яраң җибәрми булыр сул кулыңны. «Шундый да нәни, шундый да матур кеше бит син, минем алтын алмам», — дип уйлыйм. Тик шунда ук сискәнеп китәм. Як-ягыма төкерәм. Ахмак, балаңа күз тидер тагы, дип, үземне шелтәлим. Яшерен-батырын түгел, авыр вакытта әллә нинди ырым-шырымнар искә төшеп, күңелне шомландыра. Ныклабрак уйласаң, бәлки, ырым да түгелдер әле алар...

Күз тиюне, мәсәлән, Сабиратти фәнгә нигезләп аңлата. Киленем «Здоровье» журналыннан укыды: күз тию гипноздан килә, ди. Аннан соң меңәр чакрым еракта яшәүче әниең: «Кызым, төшемә кердең, әллә авырыйсыңмы?» — дип хат язамы? Әллә кайдагы якыныңны искә төшереп вакыт-вакыт эчең пошамы? Менә анысы кешедәге биотоклар эше була икән инде. Кешенең баш өстендә биологик кыр дип аталган хикмәт була икән әле. Ягъни баш өстендә салават күпере кебек төрле-төрле төсләр бар,

имеш. Кемнәргәдер ул төсләрне күрү һәм шуларга карап кешенең эчке халәтен аңлау сәләте бирелгән. Анысын үзем «Комсомольская правда» газетасыннан укыган идем, Сабираттигә шуны сөйләдем.

Сабиратти — укымышлы карчык. Искечедән дә, заманчадан да мәгълүматы зур аның. Чөнки, өлкән яшьтә булуына карамастан, күп укый. Бер генә көнне дә радиодан яңа хәбәрләрне тыңламыйча калмый. Матур әдәбият ярата. Тәмләп килене турында сөйли.

— Олан, — дип башлый ул сүзен. — Чит бавыр белән килешеп яшәү бик җайлы эш түгел. Кайчагында сукыр, кайвакытта саңгырау булырга кирәк. Әмма киленем тәмле телле булды минем, — ди. — Эштә генә бик арый. Өйгә кайткач, җеп өзәрлек тә хәле калмый мескенкәйнең. Ашый-эчә дә, әнкәй бәгърем, рәхмәт, гомереңне бирсен синең кебек матур теләкләр яудырып, диванга авып кына китә, — дип көлдерә.

Үзенең дә килен чакларын исенә төшерә, каенанасын «әнеки» дип атый.

— Әнекием үлгән чагында әйтте, — ди ул. — Йорт-җирем кала — йорт-җиремдә җитәрлек тордым, үкенмим; байлыгым кала — рәхәтен күреп яшәдем, уфтанмыйм; киленем кала — менә шунысы җәл. Кешесенә туры килгән идек тә бит, озаклап, чөкердәшеп гомер итә алмадык, дип әйтеп әйтте. Әнекиемә яхшы хезмәт иттем, Аллага шөкер. Тамагыннан үтми башлагач, тавык итенең майлы җирен бик вак итеп турап авызына каптырыр идем. Шуны суырды, мәрхүмәкәем, — дип искә ала Сабиратти. Каенанасына ялгап, ире Фәхрисламны да сөйләп китә.

— Фәхрислам? Кызык. Мөхәммәт Мәһдиев сезнең гаилә белән таныш булмагандыр бит? — дип сорыйм мин, сәерсенеп.

— Менә тагы, тора торгач бер амин. Нигә алай дип сорыйсың? — ди Сабиратти, үзе дә гаҗәпләнеп.

Без бергәләп «Ут чәчәге» исемле романнан Фәхрислам белән Сабира турындагы өзекне укыйбыз.

«Фәхрислам эчтән генә үзенең гомере гаилә җылысын тоймаган көе әрәмгә узганга ачынды. Хәер, Сабира белән бер кич кунгач та, ул үзенең ялгышканын аңлады: хатында наз юк иде. Дөньяда иң бәхетсез ир кем? Назны белмәгән хатынга өйләнгән ир. Туйлар ясалган, расходлар күп тотылган иде. Икенче көнне, тотылган акчаны кызганып түгел, болай гына, Фәхрислам сәке кырыена утырып әйтте:

— Да-а-а... Акчаны суга салдым...

Сабира бичара кинаяне аңламады. Самавырга чыра телеп яткан җиреннән олы якка чыкты да:

— Нигә суга саласың аны, миңа бир, — диде.

— Вәт, ту-ты шул, сиңа бирдем инде мин аны, — диде Фәхрислам, төксе итеп...»

Сабиратти көлә.

— Мәгәр оста да яза, — дип, Мөхәммәт Мәһдиевне мактый. — Тыңлыйсыңмы, Гөлмәрьям олан? Киленем «Татарстан яшьләре» газетасыннан укыды. Бервакыт шулай байтак башлы кешене редакциягә чакырып сорау биргәннәр. «Әгәр дә мәгәр яшьлегегез кире кайтса, ни кылыр идегез», — дип әйткәннәр. Ә Мөхәммәт агаң ни дип җавап биргән? «Әгәр дә мәгәр гомерне яңадан башларга туры килсә, хатыныма һичшиксез дүрт-биш бала үстерергә дигән шарт белән өйләнер идем», — дип әйтеп әйткән, рәхмәт яугыры...

Сабираттинең зиһене шәп. Кайчагында үзе яшь вакытта укыган китапларын искә төшерә. Кет-кет көлеп эчтәлеген сөйли:

— Ә бервакыт аракы белән тәмәкегә каршы көрәш башланды. Китап-журналлардан кызыграк шигырьләр эзләп табабыз да сәхнәгә менәбез. — Сабиратти үзен хәзер дә сәхнәдә хис иткәндәй, җилләнеп сөйли башлый. — Монысын егет кеше сөйли, — дип аңлатма бирә ул:

Бутылканың авызы тар,
Эчендә виносы бар.
Алып эчкәнчегә кадәр
Ахырын уйласы бар.

Эч тә бик пошып тора,
Исәп тә төшеп тора.
Арка-җилкәләр авыртып,
Исәнлек китеп тора.

Кая, хатын, ат җигим,
Хәзер базарга китим.
Бер ун потлап арышны
Төяп сатарга илтим.

Хәзер кыз дәвам итә:

Ярый, алай булгачтын,
Мин дә майны җибәрим.
Кирәк-яракка булыр дип
Әзерләгән идем мин.

Күлмәгем юк алмашка,
Яулыгым да юк башка.
Шулар өчен булыр инде
Бу майны саткан акча.

Ярый, бик озак йөрмә,
Эчеп кеше көлдермә.
Кеше көлү белән бетмәс,
Соңыннан булыр төрмә...

Мин кул чабам. Сабираттине мактап җибәрәм. Сабиратти, үсенеп китеп, тәмәке турында да өстәп куя:

Тәмәке үпкәне бетерә,
Айнымаслык ютәл китерә.
Кызулатып йөрәк тибешен,
Күп кешене яшьләй үтерә...

Мин бу юлы да кул чабам.
— Менә шулай, олан. Безнең дә бар иде ул яшь чаклар! Ай, тиз уза соң кеше гомере! — ди.
Кеше гомере!
Нигә шулай кыска, нигә шулай моңлы икән ул кеше гомере? Киләчәге өчен шатлык китерәм дип уйлаганда, баласы язмышына уралып, кайгы туганын нигә белми икән әни кеше? Үзеннән алда үлеп, туфрак булсын өчен тудырамыни соң ана баланы? Бала кайгысыннан җаны пәрә-пәрә телгәләнсен өчен табамыни ул аны?
Артта Азат караваты шыгырдый. Юри ишетмәмешкә салышып, яным белән утырам.
— Тук, тук, — ди Азат, нәни бармаклары белән әкрен генә аркама кагылып.
— Да-а-а.
— Хозяин дома?
— Дома.
— Гармонь готова?
— Готова.
Азат, гармун уйнагандай итеп, бармакларын минем кабыргаларымда йөртә. Мин бик каты кытыгым килгәндәй көлгән булам, урындыгымда кыеш-мыеш киләм. Аннан, кочагыма алып, кысып сөям үзен. Кемгә генә кирәкми соң ул җылы караш, наз?! Эчендә җаны булган кемнең генә сөелеп, иркәләнеп яшисе килми бу дөньяда? Әнисе килсә, ярты сәгатьләп концерт куяр чамасы бар хәзер Азатның. Килгәндә русча бер авыз сүз белмәгән егетнең әнә шундый такмаклар өйрәнүе үзе ни тора!
— Дәү үстең инде, Азат. Озакламый әтиең белән әниең килер. Сине өегезгә алып китәрләр, — дим мин.
Ә ул, бүген үк аерылышасы кешедәй күңеле нечкәреп, муенымнан кочып ала. Аннан:
— Апа, без сиңа хат язарбыз, яме, — ди.
Шуның кадәр дә ияләште ул миңа. Бер тотам артымнан калмый. Кулыннан килгән кадәр булышырга тырыша.
— Апа, кара әле, Ләйләгөл «балык тотып ята», — ди башы белән караватка ымлап.
Бергәләп кечкенәнең оеклы ыштанын алыштырабыз, астына коры чүпрәк җәябез. Ләйләгөл киерелеп куя.
— Әй, «үстерергә» онытканмын ич! — Ике кулын да баш очына җибәреп, күкрәктән аяк бармакларына кадәр йомшак кына итеп сыйпыйм. Ләйләгөлгә бик ошый «үстерү». Рәхәтләнеп ята. Үкчәсе белән тибеп, бәләкәй эчен пух итеп бүлтәйтеп куя. Мин тагын, тагын сыйпыйм. Бәби чиреннән котылгач та, ерак юлны якын итеп, әнкәемнең тизрәк килеп җитүен, үз йортлары белән торучы танышларыбызга бәби мунчасы ягып, мине дә шулай сыйпый-сыйпый юындыруын исемә төшерәм.
Бәби мунчасы.
Гадәттә өлкәнрәк апалар яга аны. Бик белеп, бик хасиятләп эшлиләр бу эшне. Кулны күтәргәч эсседән тырнак көймәслек булырга тиеш бәби мунчасында. Уртасына бөтнек, мәтрүшкә куеп бәйләнгән каен себеркесе пешерәләр. Бөтен мунчага хуш ис тарала. Якканнан соң ике-өч сәгать вакыт үтеп, мунча тәмам әзер булгач, тәмләнгәч, әйбәтләп парлангач кына бәби тапкан хатынны мунчага алып керәләр. Ап-ак җәймә җәеп ләүкәгә яткыралар.
— Бөтен әшәке чир тир белән чыга. Бераз тирләп ят, — ди әнкәй. Үзе кер сабыны белән бик әйбәтләп кулларын, беләкләрен, тәнен юа. Түшле ак алъяпкычын бәйли. Бисмилласын әйтеп, кер сабыны белән эчемә массаж ясый башлый. Нәкъ хастаханәдә шәфкать туташлары ясаган кебек, сулдан уңга түгәрәк буенча йөри-йөри дә кендек турыннан нык кына итеп эчкә баса. — Бозык каның җыелып

калмасын, — ди әнкәй. Күкрәкләрне, кулларны, аякларны сылый. Алай гына да түгел, һәр егерме бармакка, бармакның һәр буынына хасиятләп массаж ясый...

Миңа рәхәт. Мин әнкәемнең осталыгына, алҗымавына сокланып ятам. Ә бәлки, бик тә алҗыгандыр, миңа гына сиздермәгәндер.

— Бу һөнәр — күрше әбиеңнән калган мирас, — дип сөйли әнкәй. — Сылау серләрен бик яхшы белә иде. Кулының шифасы бик күпләрне аякка бастыра торган иде.

Бер уйласаң, шаккатарлык бит. Беркайда укымаган, кроликлар, этләр өстендә бернинди практика үтмәгән, рус телен белмәве аркасында томана дип аталган авыл карчыгы дөп-дөрес итеп кеше организмындагы кан йөреше юнәлешен белгән, кайсы уңайга сыларга кирәген өйрәнгән. Гыйлем, осталык үзләштергән...

Җәй җитте исә һаман аклы күлмәктән, кершән кебек ап-ак яулыктан йөрүче күрше Маму әбекәйне мин дә бик яхшы хәтерлим әле. Аны бөтен авыл халкы хөрмәт итә.

— Аш-суга оста. Пешергән ризыклары авызыңда гына тотып торырлык була торган иде, — дип өсти әнкәй.

— Маму дигән исемне син куштың бит аңа, кызым, — ди гаҗәп кызык вакыйганы искә төшергәндәй. — Синең матур булып телең ачылып килгән көннәр. Кабак бәлеше салдым да, авыз итсен дип, аңа да керттек. Ишекне ачуыбыз булды, мо-у, мо-у дигән тавыш ишетелде. Син гаҗәпләндең. Тавыш тагын кабатланды. Әбиең өйдә юк. Ә морҗа арасыннан карыны ачкан бозау кычкыра. Менә шуннан соң күршебез әйбәтләп кенә Маму әбигә әйләнде дә куйды. Башта кызык итеп, синең сүзеңне кабатлап, үзебез дә Маму әби дип эндәштек без аңа. Соңыннан бөтенләй гадәтләнеп киттек, — ди.

Беркавым авыл карчыкларын искә төшереп ятам. Үзенә бер пөхтәлек, үзенә бер аклык бар бит ул безнең татар карчыкларында!

Кояш шактый күтәрелгән, хәтта Ләйләгөлнең күзенә төшә башлаган икән. Үзе еламый тагы, әмма башын боргалап пошыргалана. Кызыкайны кулыма алып, әкрен генә үчтеки иттерәм. Ул иркәләнүдән бик тә канәгать булып көлә. Бит очлары чокырлана. Ияк очындагысы тирәнәеп китә.

— Үз балаңнан да ныграк карыйсың шул үксезләрне, — ди мине күзәтеп яткан Сабиратти.

— Сабиратти, — дим мин, аның баш очына чүгәләп. — Ирем дә балалар ярата, әллә, мин әйтәм, улым терелгәч, хастаханәдән икесен бергә алып чыгыйм микән? Бик ияләндем бит үзенә.

— Әйталмыйм, олан. Кеше белән киңәш, үзеңнекен тот, дигән борынгылар. Белмим...

Бүлмәдә тынлык урнаша.

Сабираттинең мәңге искерми торган үз темасы бар, ичмаса. Чак кына сүзгә сусап тордыңмы, бик тәмләп тагы киленен сөйли башлый. Бүген төшендә күргән икән.

— Аллага шөкер, киленем үз туфрагымнан яралган, теле белән эретә, — ди. Әйткән сүзләрен тезеп китә, ике сүзнең берендә «әни бәгърем» дип эндәшүенә басым ясый. — Башкаларны синең белән үлчим, синең белән чагыштырып карыйм. Син, әни бәгърем, безнең җәмгыятьтә яшәргә тиешле кешеләрнең өлгесе-үрнәге кебек. Хәзер, әни бәгърем, «дефицит доброты» заманы. Хәзер кеше бер-берсенә игелек эшләүдән курка, дигән була. Дөрес әйтә киленем, киленем акыллы минем, — дип сүзен очлый Сабиратти.

Әллә каян күренеп тора аларның тату яшәүләре. Дөньяны яратып, гаиләсеннән канәгать булып яши Сабиратти. Кеше күңеленнән гаеп-кыек түгел, матурлык эзли. Бер педагог та әйткән бит: кешедәге начар гадәтне күреп, аны һаман искә төшереп, төрттереп торырга ярамый. Киресенчә, кешенең яхшы ягын табып, шул гадәтен үстереп, үсендереп яшәргә кирәк, дигән.

Әбәү лә инде, улым да уянып, зур зәңгәр күзләре белән мине дәшеп-чакырып ята, имеш. Ләйләгөлне урынына яткырып, улым янына барам. Температурасын үлчим. Нәни кулына чәнти бармагымны тоттырам. Шулай ярата ул. Бармагымны кысып-кысып тота. Минем һәр хәрәкәтемне, һәр сулышымны күзәтә.

Ыгы-зыгылы хастаханә көне башлана. Балаларны күтәреп, бер-бер артлы яраларын бәйләтергә йөгерәбез, кварцка, ингаляторга алып барабыз.

Бүген улым гел куандырып тора әле мине. Башка көннәргә караганда имүе дә яхшырак, үзе дә хәллерәк күренә. Бергәләп коридорга чыгабыз. Аквариумдагы балыкларны, читлектәге кошларны карыйбыз, елмаябыз, талпынып куябыз.

— Кәефләрегез ничек? — ди дәвалаучы табибыбыз.

— Бүген күзгә күренеп әйбәтләнә башлады шикелле, — дим мин, шатлыгымны яшерә алмыйча.

— Күпмелек булды инде?

— Нәкъ йөз көн.

— О-һо, димәк, үсәбез. Ә Азат тиздән авылларына кайтыр, шулай бит? — ди ул, миннән бер тотам да калмый йөрүче егетемнең башыннан сыйпап. — Әмма кайтып киткәч менә бу матур бәбиләрне сагынырсың әле, — дип өсти.

Сагыну — йөрәге булган һәр җан иясенә хас сыйфат ул.

Мин үзем дә сагынырмын әле аларны. Сабиратти әйтмешли, ана каз кебек, бөтенесен канат астына җыеп йөреп, бик тә ияләштем үзләренә. Берсенә дә җил-яңгыр, кайгы-хәсрәт күрсәтәсем килми дә бит... Кодрәтемнән килсә, бер балага да чир тидермәс идем, бер балага да борчу китермәс идем.

Көн кичкә авышты. Тагын бер студент егет кереп, стафилококк авыруының улымда ничек башлануын бәйнә-бәйнә язып алды. Дәвалаучы табиб һәрвакыттагыча зур игътибар белән баланы күзәтеп, сулышын тыңлап чыгып китте. Шул көнне улыма бишенче мәртәбә кан күчерелде. Ампицилин, канамицин, стафилококк гамма-глобулины ише дарулар белән тулы бер курс дәвалау үткәрелгәннән соң иң көчле препарат— кефзол бирелде. Шул көнне...

Озын-озак көн булды ул көн. Китап укып та, Илдар белән хат аша сөйләшеп тә үткәреп бетереп булмады. Күңел ни өчендер тынычсызланды. Бер эштән икенче эшкә күчеп, мавыгу эзләде. Сабираттинең әйтүенә караганда, кичкә кергәч, балаларга сынап-сынап карап, моңсуланып йөргәнмен, имеш. Кеше эндәшкәнне дә ишетмәгәнмен.

— Гөлмәрьям ханым, улыгызны процедурныйга илтегез, — ди икән миңа шәфкать туташы.

Мин ишетмим. Кешедә шундый сәер бер халәт була икән. Үзем, мәсәлән, шәфкать туташының күзләренә карап, нәрсәдер әйтүен күреп торам. Үзем әйткән сүзнең мәгънәсен аңламыйм. Миемә барып җитми. Берничә минуттан, Азат килеп кагылгач кына айнып киттем мин. Сискәнеп сикереп тордым. Озак йоклап, яңа гына уянган кешедәй уңайсызландым. Үземә-үзем сәерсенеп киттем. Улымны чиста чүпрәккә төрдем... Ә Азат бөтерчек кебек минем култык астында йөри:

— Апа, апа, аякларын кара әле. Бәп-бәләкәй!

— Ә без дәү үсәчәкбез әле, Азат абый. Кулларым да, аякларым да, үзем дә дәү үсәчәкмен. Хәзергә дәваланырга, үпкәбезне юдырырга киттек, сау бул, — дип, улым булып җавап бирдем.

— Суы сарыксын, үзе калыксын, — дип, Сабиратти дә безгә хәерле сәгать теләде.

Ләкин... Ул сәгатьнең хәерсез буласын белгән булсам икән соң... Бер дә ашыкмыйча кысып-кысып кочаклар, баш очыма чөеп уйнатыр идем үзен. Зур зәңгәр күзләренә озаклап бер карап калыр идем! Юк, белгән булсам, мин аны, гомумән, кемнеңдер кулына бирер идем микән әле? Юк, белмәдем...

Гадәттә, баланы процедурныйга илтеп биргәч, ишек төбендә көтеп торырга кушылмый. Бүлмәгә кайтырга кирәк. Бу юлы да, кире палатага кереп, Ләйләгөл белән юандым. Сүзсез генә күзгә-күз карашып тордык. Бу бала әтисенә охшагандыр, ахры, дип уйладым мин. Чөнки әнисе төскә-биткә икенчерәк иде. Тәпи бастырып, күпертмә җиңле күлмәк кидереп, чәченә зур тасма бәйләтеп күз алдына китердем. Гаҗәп матур. Матурлыкка матур да бит, үзе дөм ятим. Кайдадыр тере әнисе була торып ятим. Йөрәгем өши. Ничектер туңып, калтыранып куям. Вакыт уздырыр өчен урын-җирне яңадан кабартып җәям. Азатка яңа шигырь ятлатам. Ләкин вакыт һаман бик әкрен уза.

Шулчак берничә табибның ашыгып процедурныйга үтеп киткәнен күрдем. Куркынып ишеккә ташландым.

Сабиратти тотып калды:

— Тыныч бул, олан. Син бүген көне буе бәргәләнеп йөрисең. Хәтта авырлык килсә дә, нык бул. Көчле хатын син, — дип юатты.

— Нәрсәдер булган, Сабиратти. Табиблар йөгерешә, — дим мин, пыяла ишектән күземне алмыйча.

— Ни генә булса да, безнең кулыбыздан ярдәм тия торган эш түгел. Тынычлан. Андый вакытта әнекиләребез башына килгән авырлыкларны уйла син, — дип киңәш итә Сабиратти. — Без күргәнне генә күргәнмени алар, без кичергәнне генә кичергәнмени? Ире, бишәр-унар баласы сугышта ятып калган аналар бар. Сезгә ул кайгыны бирмәсен Ходай, тфү, тфү!

Табиблар, башларын иеп, әкрен адымнар белән таралыша башладылар. Кайберләре гаепле кебек астан гына безнең бүлмә ягына карый. Миемне яндырып «үлгән» дигән уй үтә. Үлгән... Хәлем китеп, Сабираттинең җилкәсенә барып орынам, үксеп елап җибәрәм.

Их, улым, бәгырь кисәгем! Йөрәгемнән өзелеп төшкән нәни балам! Җанымны ярып чыккан асыл кошым! Мин сине шуның өчен, якты дөньяда нибары йөз көн яшәп калсын өчен тудырдыммыни? Шуның өчен, нибары йөз көнлек гомерең өчен җан газабы белән тартыштыммыни?..

Дәвалаучы табиб кереп өлкән табиб катына чакырганда, аның кайгылы йөзенә күтәрелеп карамыйча да барысын аңлаган идем инде. Буыннарымның хәле китеп, күз яшемә буылдым:

— Бетте, бар да бетте, Сабиратти. Сүнде, сүнде бәхет йолдызым, — дип пышылдадым.

...Яшенле түгел бу яңгыр,
Яшьле булып тоела.
Яңа кабер туфрагына
Коела да коела...

«...Нишлисең?
Тукта!!!» — дип, хәзер
Язмышларга дәшимме?
Керфекләремне көйдерә —
Яшемме бу?..

Яшенме?

Соңгы юллар үзеннән-үзе аңымда кабатлана: «Керфекләремне көйдерә — яшемме бу?.. Яшенме?..»
Улымның үлеме мине шигърияткә яңадан кайтарды. Күңелем кузгалды исә, кәгазь-каләмгә барып тотынам. Язам да томрап торган Ләйләгөлемә укып күрсәтәм. Ул авызын ерып тыңлап ята. Аннан соң, әллә нинди зур эш майтаргандай очынып килеп, Илдарга укыйм.
Ул:
— Шәп, — дип куя.
Аның шул бер сүзе мине күкнең җиденче катына күтәрә. Сабый бала кебек сабырсызланып, язган бөтен шигырьләремне рәттән укый башлыйм. Һәм... әкрен-әкрен үземнең очсызлана баруымны сизәм. Нәкъ кирәк вакытта туктап кала алмавымны, «шәп» дигән олы бәя алганнан соң, урта кул шигырьләр белән мавыгуымны аңлыйм. Беркатлыланып, Илдарга да әйтәм.
Ә ул:
— Һәр салган йомырка алтын булмый, — дип юата.
Илдар күп сөйләшми, эшне коры тота. Янында озаграк сырпаланып тора башласаң: — Булды. Бар, эшеңне кара, — ди.
Ә минем, киресенчә, аңа сыенып, озаклап утырасым, әллә ниләр сөйләшәсем, киңәшәсем килә. Әмма үземне тиз кулга алам. Китеп, алдагы көн өчен Илдарның киемнәрен әзерлим. Бер дә иренмичә, тәмләп, кичке аш хәстәрлим. Әнкәем каз мамыгыннан тутырып биргән ап-ак тышлы мендәрләремне күпертеп урын җәям. Ябынырга күбек кебек җиңел дөя юрганы куям. Шулчак ниндидер акыллы эш эшләп, Илдарымның игътибарын үземә юнәлтәсем, макталасым килә. Ул арада, йөгереп килгән җиреннән егылып, Ләйләгөл елый башлый. Илдарга исә шул җитә кала.
— Бөтен кеше дә җилдән туган бала алып кайтыр иде. Туйдым шуның тавышыннан, — ди.
— Илдар, киңәшмичә алмадым лабаса. Табибка да икебезне бергә чакырдылар, — димен хәтерем калып. Аннан соң: — Нишләп җилдән тусын ул? Әнисе яхшы хатын иде аның. Бик каты авыргач, баласын калдырырга табиблар үзләре киңәш итте... — дип алдашам.
— Хәзер кая йөри соң ул әйбәт хатын? Яхшы булгач, нигә ире белән тормаган? Терелгәч, нигә баласын юллап килми? Һаман авырмыйдыр, шәт? — дип тезеп китә Илдар. — Юньле хатын, бик беләсең килсә, ирennән аерылмый. Ир белән тора белү — үзе бер һөнәр. Ир тәрбияли белү — үзе бер сәнгать. Килде-китте хатыннар кулыннан килми ир белән тору! — ди.
Илдарның һәр сүзе миемә чүкеч белән суккандай тәэсир итә. Кайчагында: «Ләйләгөлне алып хаталандыкмы әллә? Үз баласы була алган ир кешенең җиде ятны тәрбияләп ятасы килмәс шул», — дип тә уйлыйм. Тик үзем берничек тә аны ят итә алмыйм: бик ияләндем мин аңа.
Биш яшькә кадәр итәк җиле дә ярамады Ләйләгөлгә. Көз җитсә, тын да кермәслек итеп тизрәк тәрәзәләрне сылыйм. Мамыктан сөнәкәй сырып кидерәм. Иске пальтомның якасыннан җылы оек әмәлләп бирәм. Шулай итеп, дөньяның ай-ваена карамыйча, үсеп килә безнең Ләйләгөлебез. Хәзер теле дә ачылды. Хәтере дә әйбәт. Тукай, Әминә Бикчәнтәева шигырьләрен өйрәтәм үзенә. Абдулла Алиш, Пушкин әкиятләрен укыйм. Ә ул, төз басып, ятлаган шигырьләрен кычкырып сөйләп җибәрә. Кайбер сүзләрен онытканда, кат-кат төкереген йоткан була. Үткен булыр бу, дим, шатланып. Үткен булсын. Әнкәй әйтмешли, минем кебек «сыек салмалар» заманы үтте хәзер.
Беркөнне шулай кунаклар килгән иде. Сөйләшеп утырдык та, кузгалып, коридорга чыктык. Ләйләгөлем кунакларны китә дип уйлады, ахры, кул изәмәкче булды. Аннан соң, алданганын бик тиз сизеп, күтәрелгән кулы белән чәчен төзәтеп куйды. Билгеле, бу кыланмышын миннән башка беркем сизмәде. Мин исә монысын да кызымның тапкырлыгына юрадым. Эчемнән сөенеп куйдым.
Әйткәнемчә, Ләйләгөл бик матурланды хәзер. Төсле тасмалар, төсле күлмәкләр ярата. Бик күп шигырьләр, җырлар белә. Әле бүген дә күрше кызларыннан яңа җыр отып кайткан:

Я маленькая девочка,
Я в садик не хожу.
Купите мне сандалики,
Я замуж выхожу.

Үскән саен матур гадәтләре дә ишәя кебек. Әтисе кайтып керүгә, йөгертеп, өйдә кия торган башмагын илтеп бирә дә, рәхмәт көтеп, күзләренә карап тора.
Бала — мәхәббәт җимеше, дибез. Сөю-сөелүнең иң югары ноктасыннан өзелеп төшкән җимеш ул. Ләкин, ничек кенә гаҗәп булмасын, ир белән хатынның мәхәббәтен закон белән ныгытканнан соң өзелеп төшсә генә кадерле һәм тәмле икән ул җимеш. Ә Кәримә ханым белән Ләйләгөлнең әтисе арасында булды микән ул сөелү? Мәхәббәт уты кабынган иде микән алар йөрәгендә? Әллә гадәти бер мавыгу, ялгышу, абыну гына иде микән? Белсәң иде, кайда икән ул Кәримә атлы хатын? Ләйләгөлдән котылгач, тормышын көйли алды микән? Үзенә тиң яр тапты микән? Исән булса, баласын эзләми түзмәс иде, мөгаен. Әллә?.. Сүзләремне җил алсын берүк. Исән була күрсен. Аның Гөлмәрьямгә нинди зыяны тия? Ә бәлки, эзләп тә йөргәндер әле кызын, таба гына алмагандыр. Бәлки, әйбәт кеше

очраткандыр да менә дигән итеп гаилә коргандыр. Яшь иргә яшьлек ялгышын күрсәтеп, нигә тормышын бозарга? Кем ялгышмый бу дөньяда? Рәхәтләнеп яратышып яши бирсеннәр. Дөнья иркен, барыбызга да урын җитәрлек...

Сөю, сөелү турындагы фикерләремне калдырып, еш кына үлгән улым турында уйлана башладым мин хәзер. Йөрәгем әллә нишли. Шуның кадәр газап күреп тә, шуның кадәр яшәргә тырышып та сабыемның яши алмавы җанны телгәли. Тәмам әйбәтләнә, тәмам тернәкләнә башлагач бит... Табибларны гаепләмим анысы. Алар үпкәсен яхшылап юдырыйк дип тырышканнардыр. Шул чагында артерия — кан тамыры зарарланган булырга тиеш. «Ничек кенә тырышсак та, кан килүен туктата алмадык», — диделәр бит. Нишлим? Уйлыйм-уйлыйм да, язмыштыр, дип куям. Дөньяга шулай берәмләп киләбез, берәмләп китәбез, дип, Сабиратти сүзләрен кабатлыйм. Ләкин үземне ничек кенә тынычландырмыйм, ничек кенә юатмыйм, сагышлы хисләрем мәйдан сорый. Аларны кәгазьгә төшерәм:

Ак ефәк канатың, күбәләк,
Битемә кагылды.
Очмый тор, күбәләк, карыймчы,
Күримче җаныңны.

Битемә синең күк сак кына
Кагыла иде ул.
Югалып торсам мин чак кына,
Сагына иде ул.

Учымда җилпенә, әйтерсең
Әнисен таныды.
Кем соң син, күбәләк, әллә соң
Улымның җанымы?..

Гомер дигәнең шулай икән. Хәзер мин сиртмәле арбада бөтенләй чит бала тирбәтеп утырам. Кем ул миңа? Оныкмы? Белмим. Анда минем каным юк. Анда...

Тормышыбыз әйбәт. Ләкин өзелеп-өзелеп туган авылымны сагынам. Бормаланып аккан Баҗана елгасын, Качкын очындагы яланнарны, Түбәтәй тауларын сагынам. Баҗана димәктән, хәзер бик тә саеккан, тубыктан гына калган, дип сөйлиләр аны. Хәтта каңгылдашып казлар чумарлык та суы юк, имеш. Әмма без үскәндә, билгә җиткән урыннары, чоңгыллары бар иде. Эссеме, җиләс көнме, буш вакыт булды исә, йөгерешеп шунда киләбез. Киләбез дә чишенеп суга чумабыз. Аяк астыннан, болганып, кып-кызыл ләм өскә күтәрелә. Иякләребезгә — «сакал», борын астыбызга «мыек» үсә. Чәчләребез пычрак белән бутала.

Өйгә кайткач, әнкәй:

— Тәүфигың арткыры, чәчеңә тарак та керерлек түгел бит, — дип орышкан кыланып, җитәкләп бакчага алып керә. Анадан тума чишендереп, кояшта җылынырга куйган су белән башымны, тәнемне юа. Комгандагысын агызып коендыра, чиста кием бирә.

Менә шулай. Мин дә кайчандыр нәни бала булган лабаса. Әнкәемнең күкрәк сөтен имгән. Җылы кулларында тирбәлгән, иркәләнгән, назланган. Әнкәем мине дә ак биләүгә биләгән, бәхетле булсын дип теләмәде микәнни соң? Ай, юк, ялгышам. Бәхетле минутларым санап бетергесез күп булды минем. Илдар белән яшәгән чакларны секундына кадәр сагынып искә алам хәзер.

Шулай үзләренең туган якларына алып китте бу мине. Әтисе белән туганнан туган абыйларына алып кайтты. Җиңги тиешле кешегә булышып, бик тиз үз булып киткәч, абыйсы сүзен җөпләп, үтә бер канәгатьләнү белән:

— Минем карчык авыл кызы, эштән чирканып тормый, ашка-суга да бик оста, — дигән иде.

Гомерем буе сагынып сөйләрлек, искә алырлык матур гадәте булган икән бу Илдарның. Пешергән ашларымны һәрвакыт яратып, мактап ашар иде. Сөйгән кешесе өчен тәмле итеп аш-су әзерләү — хатын-кызның зур бәхете булуын мин хәзер, аны югалткач кына аңладым. Шулай да авыз иттерергә өлгермәгән әллә никадәр тәмле ризыкларым калган икән. Күрсәтергә өлгермәгән әллә никадәр осталыгым калган. Хәзер менә пешерәм дә мөлдерәмә күзләрем белән мул табынга карап торам. Әллә нигә тәмен тапмыйм мин аларның. Җыйган тәгамем дә йөрәккә ятмый сыман, һай, кара-каршы утырып, чөкердәшеп, бер тапкыр чәй генә эчәргә иде дип уйлыйм. Бергәлекнең рәхәтен бөтен тирәнлеге белән аңламаганбыз икән ул чагында. Хәзер менә сагынып уйларга гына калды...

Мин сезнең авылыгыз турында сөйли башлаган идем бит әле, Илдар. Өйләнешкәч беренче кайтуыбыз гына түгел иде юкса. Әмма һәр кайтуымда син туган авылның сихри матурлыгын хәйран калып, сокланып кабул итә идем. Бу юлы да туганнар белән бер кат күрешеп, чәйләп алганнан соң, балачакта үзең тәгәрәп уйный торган тауларга алып менеп киттең. Биеккә басып, бөтен тирә-юньне күзәттек. Безнең күз алдында чиксез манзара ачылды. Офыкларга барып терәлгән арыш басулары, кояш нурында җем-җем килүче күлләр, тау итәгеннән агучы елга — барысы да бик якында, уч

төбендәге кебек җәйрәп яталар. Без карап тордык-тордык та җитәкләшеп түбән йөгердек. Җиләс җил чәч араларыма, куенга тулды. Төшеп җитәрәк, син кулларыңны ычкындырып алга йөгердең. Каршыма чүгәләп, килгән шәпкә күтәреп алдың. Мин зәңгәр күзләреңә текәлдем — иксез-чиксез галәм киңлегедәй чиста зәңгәр күзләреңә. Анда — бетәсе түгел якты йолдызлар. Безнең бәхетле минутларыбыз саен кабынган йолдызлар... Күзләремне йомдым. Илдар, битләремнән үбеп, сак кына җиргә бастырды, җитәр, тәмле әйбер күп булмый ул, диде. Мин, шул чагында гына айнып китеп, аның кадерләвенә каршы җавапсыз калуымны исемә төшердем. Кулларыннан җитәкләп, якында гына челтерәп аккан чишмә буена чаптым. Куш учларыма салкын суын алып, Илдарга суздым.

Ул эчте-эчте дә:

— Сыйлаганда су эч, — дип рәхәтләнеп көлде.

Без улактан улакка күчеп йөгерүче, кызлар толымыдай үрелеп-үрелеп агучы саф сулы чишмәгә шактый озак карап тордык. Борылып, әкрен генә күл буена киттек.

— Чишмәнең суы элекке шикелле салкын түгел, — диде Илдар. — Таулар да бераз иңгән дип әйтимме, әллә без үскәнбез шунда... — дип нәтиҗә ясады.

— Юк инде, Илдар, һәркайсы үз урынында, без үзебез хәзер дөньяга икенчерәк күз белән карыйбыз, — дидем мин.

— Бәлки, — диде ул, минем белән килешкәндәй итеп. Ә аннан, кырт кына миңа борылып: — Ә шулай да матур бит минем туган авылым, әйеме, Гөлмәрьям? — диде.

— Искиткеч, — дидем мин, шундый ук күтәренкелек белән. — Карале, Илдар, сезнең авылда Карашәм дигән тыкрык бар иде. Ни өчен шулай атаганнар аны? — дип сорадым.

Син каян беләсең аны дигәндәй, Илдар миңа гаҗәпсенеп карады.

— Күптән бит инде ул, хәзер ул урамны Якты Таң урамы дип йөртәләр, — диде. Һәм сөйләп китте: — Элек анда, бер бәләкәй генә йортта, хыялый Кәбип дигән бабай яшәгән. Көне буе эшләп арыганнан соң, кич буе чыра яндырып шәҗәрә төзи икән бу мескен карт. Кемнең кем улы, кем нәселе булуын терки, ягъни мәсәлән. Ә карчыгы тирги икән Кәбип картны: «Бөтен өйне каралтып бетердең. Өйне генә түгел, бөтен урамны кара сөрем иттең», — дип әйтә икән. Ләкин карчыгы ничек кенә ачуланмасын, тыкрыкларга ник әллә ничә Карашәм исеме бирмәсеннәр, төне буе чыра яндырып язуы язу булган Кәбип картның. Авыл халкының ике-өч йөз еллык тормышын өйрәнеп, һәр нәселнең берничә буынга кадәр ата-бабасын ачыклап калдырган. Аннан соң минем әти дәвам иткән бу эшне. Әтигә мин дә байтак кына булыштым әле, беләсең килсә, — диде Илдар, күкрәгенә суккан булып.

— Менә бит нинди кешеләр икән сез, — дидем мин. — Ә соң үзеңнең ата-бабаларың хәтереңдә калдымы? — дип сорадым.

— Ничек инде! Һәр аңлы кеше нәселен җиде бабасына кадәр белергә тиеш, — диде Илдар һәм бармагын бөгә-бөгә санап китте.

Шулчак мин үземнең олы бер кимчелегем булуын аңладым. Никадәрле генә тырышсам да, өч буыннан ары берәүне дә исемә төшерә алмадым. Нинди ваемсыз бәндә икәнмен, дип, үземне тиргәдем. Илдарның бу өлкәдә дә хәбәрдар булуына соклануымны белдердем.

Ул исә:

— «Тарихи истәлекләрне һәм башка культура байлыкларын саклау турында кайгырту — СССР гражданнарының бурычы һәм вазифасы», — дип, Совет иленең Төп Законында язылганча итеп, тәкәббер генә җавап бирде.

— Илдар, — дидем мин, иремнән бераз арткарак калып, мәһабәт буй-сынына сокланып барганнан соң.

— Тыңлап карыйк, тагын нинди сорау бирерсең икән? — диде Илдар, атлавыннан тукталмыйча гына.

— Ил-да-ар! — дип кабатладым мин, аның исемен ярым пышылдап.

— Нәр-сә-ә? — диде ул да, сузып кына.

— Мин сине я-ра-там, Ил-дар!

Ирем мине сабый баладай итеп югары күтәрде.

— Әй син, Биш Куык кызы, мин дә сине бик-бик яратам бит, — диде...

Менә шулай, сабый балам! Дәү әниемнең чәчләре ак, димә. Мин һаман бала чагымда, уйларым белән яшьнәп торган яшьлегемдә әле. Яшь барса да, йөрәкнең һаман җилпенеп-җилкенеп торган чагы! Егетләр кебек төз буйлы булса да, дәү әтиеңнең чәчләренә дә кунган иде ул ак кырау. Сәбәпчесе, билгеле, Ләйләгөл булды.

Көтмәгәндә-уйламаганда Хәмбәл атлы егет белән танышты синең әниең. Бигүк пөхтә йөрмәсә дә, болай үзе ярыйсы гына егет. Буйга-сынга, төскә-биткә дигәндәй, кеше арасында кимхур булырлык түгел. Хәтта кайчагында йөз чалымнарын Ләйләгөлгә дә охшатып җибәрәм. Башыма ир белән хатын күпчелек очракта охшаш булалар дигән уй килә. Аннан, и, яшь вакытта кем кем белән дуслашып йөрмәгән, дип уйлыйм. Чөнки Ләйләгөл үзе дә ул кадәр үк яратып, башын югалтып йөргән кебек түгел. Әлеге дә баягы, киенүен өнәп бетерми. «Кайсыбер чалбарының төбе тезенә кадәр төшеп тора, әйберне

киеп карап түгел, размер буенча гына ала, ахрысы», — ди. Ә хәзерге размерларга ышансаң, чынлап та шулай. Олы дигәнең кече, кече дигәнең олы булып чыга. Эш киемдә дә, буй-сында да түгел, билгеле. Хикмәт кешенең үзендә, йөрәгендә, алган тәрбиясендә. Баштагы мәлне бакчаларга килеп, бик булышкалап та йөргән иде Хәмбәл. Әмма Илдар тәртәне тиз борды.

— Йөрмәсен, безгә кулай кеше түгел, — диде.

Әмма «йөрмә» дигән сүзне егетнең йөзенә бәреп әйтергә беребезнең дә батырлыгы җитмәде. Ул һаман килә торды, Ләйләгөл белән очраша торды. Ләкин үзенең Илдарга ошамавын сизенә иде булса кирәк. Шуңа күрә гел этиебез юкта, аулак вакытларда килә башлады ул безгә. Мин дә Илдарның үзеннән, ни өчен кулай түгел, дип сорарга базмадым. Бары тик, этисез, җилдән туган бала булгангадыр, дип уйладым. Җитмәсә, әнисе дә авыру икән. Беркөнне аулак өй хөрмәтенә бик тәмле итеп камыр ризыклары пешердем дә Хәмбәлгә:

— Бар, әниеңне алып кил, — дидем.

Ул:

— Әни чыгып йөрми, — дип җавап бирде.

Күрешеп сөйләшәсе килә иде килүен. Үземнең барырга теләвемне әйткәч тә, Хәмбәлнең сикереп төшеп чакырмавын, ничектер кыенсынган кебек, сүзне икенчегә боруын сизгәч, кочләмәдем. Әнисе авыру булгач, өйләре дә җыюлы түгелдер, чәй әзерләве дә кыен ич чирле кешегә дип уйладым. Әмма Илдарның сүзләре күңелдән китмәде. Шуңа күрә соңгы вакытларда Хәмбәлгә карата саграк була башладым.

Шулай Илдарның йомыш белән күрше өлкәгә киткән чагы. Без өчәүләп бакчадан кайтып киләбез. Бер малай, әллә ялгыш, әллә шаяртып, Ләйләгөлнең аякларына су сиптерде. Атылган ук кебек, Хәмбәл теге малайны куа китмәсенме!

— Тотсам, башыңны өзәм! — ди бу моңа.

Хәмбәлнең шушы сүзеннән икебезнең дә йөрәкләребез алынып:

— Хәмбәл, Хәмбәл, борыл! — дип, артыннан йөгерә башладык.

Хәмбәл үзен тиз кулга алды. Борылып көлгән булды.

— Сез нәрсә, мин юри генә куркыттым аны. Икенче тәртип бозмас, — диде.

Мин:

— Юк өчен алай каты куарга кирәкмәс иде. Егылып башын яруы, куркуыннан машина юлына барып керүе бар, — дидем.

Хәмбәл дә, Ләйләгөл дә эндәшмәде. Яхшы сүзгә тау күчереп бирергә риза булган бу егетнең кечкенә генә начарлыкка шулай кабынып китүе, кешенең гомеренә бәйләнешле сүзләр әйтүе мине куркуга салды, уйландырды. Нәкъ шул көннәрдә, үч иткәндәй, йөрәк борчый башлады. Мине хастаханәгә салдылар...

Шулай, сабыем. Әниең — Ләйләгөл аркасында әллә нинди бәлаләргә юлыксам да, һаман җәллим үзен. Моннан соң бәхетле генә була күрсен иде дип телим.

Ә Илдар турында уйлый башласам, бөтенләй авыруга сабышам. Артык күп уйлап, зиһенемә зыян килмәгәе, дим. Әйбәт күңелле кеше. Сүзен өзеп сөйләшә, төчеләнүне, икейөзлелекне җене сөйми иде. Торам-торам да: «Чыгып китеп чит җирләрдә каңгырып йөрүендә үземнең дә гаебем бар бит», — дип куям. Кайчандыр биотоклар турында укыган мәкалә исемә төшә. Әллә соң Илдарда шул сиземләү булдымы? Куенызбызга килеп кергән үксезнең фаҗига китерәсен тоеп, күңел кылы шулай хәвефле зеңләде микән аның? Хәзер күз алдына китерсәм, тәнемнән ниндидер сәер бер сискәнү уза. Илдар җанындагы тынычсызлыкны күргәндәй булам. Вакыты-вакыты белән әшәке җаннар турында тешен кысып әйткән сүзләрен искә төшерәм.

— Начар кешеләрдән дә яхшылык эзлисең, — дип тәнкыйтьли иде ул мине. Әмма кайчагында каты бәрелүе өчен гафу үтенә. Бигрәк тә беренче елларда Ләйләгөлгә күрсәткән дорфалыгы өчен кыенсына иде булса кирәк. Соңгы вакытта Ләйләгөлгә бик тә ияләште, аталарча олы мәхәббәт белән яратты. Ә мин исә ятимлектән үз кулларыбыз белән йолып алган, күкрәк сөтемне имезеп үстергән сабыйның бәхеткә тиенүенә сөенеп бетә алмадым. Матур якларын Илдар алдында күпертебрәк күрсәтергә тырыштым, искә төшереп кат-кат сөйләдем.

Шулай җәйге эссе көн иде. Ләйләгөлне җитәкләп су буена төштек. Комда уйнадык, су коендык, ятып тордык. Бераздан балакайның ашыйсы килде, ахры. Имигә үрелде.

— Кызым, — мин әйтәм, — кеше күп бит, көләрләр үзеңнән, — дим дә этисе артына качам.

— Әйдә ятыйк алайса, әйдә ятыйк, — ди ул, еламсырап.

Янәсе, ятып имгәч, кеше күрми. Үзе белә башлаганчы имездем мин аны. Таза-сәламәт бала булсын дип теләдем. Әнкәй әйтмешли, көчле ризык ашатырга тырыштым. Ә дүрт-биш яшьләренә җиткәч, бәләкәй бәби сорый башламасынмы бу! Һич чарага куймыйча, иртә-кич бәби сорый. Төрлечә җавап биреп карыйбыз — алдап кына булмый бит.

Ахыр чиктә этисе:

— Кызым, син әлегә бәләкәй, үскәч бәбине үзең алып кайтырсың, — диде. — Аның өчен башта күп итеп ашарга, дәү булып үсәргә, эшләргә кирәк. Аннан соң эшләгән акчаны табибка илтәсең, табиб витамин бирә. Витаминны курчакка ашатасың да, ул бәләкәй бәби булып елый башлый.

— Э-э-э, алдыйсың. Бәләкәй бәби әниләрнең эчендә була, — димәсенме Ләйләгөл!

Илдар бөтен дөньяны яңгыратып рәхәтләнеп көлә.

— Онытып торам икән, витаминны әниләр ашый шул, — ди ул, көлүдән тирләп чыккан борын очын сөртеп.

— Ә эчтән ничек алалар?

Әти кешенең җиңелә баруын күреп, сүзгә мин кушылам.

— Кендектән. Төенен чишәләр дә, кендек ачылып китә. Менә шуннан иплән кенә бәбине алалар, — дип аңлатам.

Ләйләгөлнең күзләре очкынлана. Сикергәләп:

— Әни, беләсеңме, без аңа матур күлмәк, матур башлык кидерербез. Сиртмәле арбада үзем тирбәтермен, — ди.

Кичләрен еш кына Ләйләгөл белән китаплар укыйбыз. Шулай бервакыт:

— Әни, Шүрәле мәктәптә укыганмы? — дип сорау бирә бу.

Аптырап киттем. Үземә дә кызык тоелды.

— Укымаган, — дип җавап бирдем.

Ләйләгөл исә:

— Юк, укыган, мәктәптә укыган. Дәрестә кызларны көлдереп утырган ул, — ди.

Шулай итеп, Тукайның Шүрәлесеннән укучы ясадык без. Үзебезчә хәтсез кызык әкият килеп чыкты. Әмма нинди генә шигырь, нинди генә әкият булмасын, аларның кайгы белән төгәлләнүе Ләйләгөлнең йөрәгенә ярамый. Әнә шулай гаҗәп йомшак күңелле булып үсте ул. Хәзер бөгелеп төшеп еларга тотына. Мөлдерәмә тулы күңеле чайпалып түгелергә тора. «Йа Алла, безнең куеннан чыккач ничек яшәр? Кечкенә вакыттагы чаялыгы кая китте?» — дип уйлыйм аның турында. Әмма, каты бәгырьлерәк бул, дип өйрәтәсем килми. Илдар да, мин дә Ләйләгөлнең сафлыгына, күңел чисталыгына сокланып яшибез, һәм мин ни өчендер үземне әнә шул гүзәллекне саклаучы калкан булырга тиешмен дип хис итәм. Ләйләгөлемне яман күзләрдән, кырыс сүзләрдән курыйм. Әмма куруын курыдык та, саклап бетерә алмадык шул без Ләйләгөлебезне!..

Тәрәзәгә бәреп яңгыр ява. Ява да, күз яшьләре кебек, юл-юл булып агып төшә. Бөтен күк йөзен кара болыт томалап алгангадыр инде, өй эче караңгыланып, шыксызланып кала. Бәй, көне дә кичкә авышкан ич, нигә кайтмыйлар икән соң инде дип уйлыйбыз без Илдар белән. Шулай утка-суга төшеп, иртән-иртүк иптәшләре белән гөмбәгә дип киткән Ләйләгөлне көтеп утырабыз. «Берәр шәплеккә очраганнардыр да аерылып китә алмыйча җыялардыр. Савытлары да күптән тулгандыр инде, шул гомер җыюга», — дим. Берзаман лычма су булып, туңып Ләйләгөл кайтып керә. Бөтен киеме тәненә ябышкан, алҗыган, күгәренгән. Кәрзинендә ник бер гөмбә булсын.

— Ни булды? — дим мин, үзем дә бик каты өшегәндәй калтыранып.

— Адашып йөрдек, — ди Ләйләгөл, үзенең теше тешкә тиеп.

Тиз генә коры киемнәр бирәм. Өстен алыштырырга кушам. Кайнар ризык бүләм. Ял көне итеп пешергән таба ашларын китерәм.

— Ярый әле төнгә калганчы юл тапкансыз...

Ләйләгөл эндәшми.

Өйне авыр тынлык баса. Сүзләр бер-берсенә ялганмый. Сораулар җавапсыз кала. Бар иде заманнар, сөйләшеп сүз бетмәгән чаклар...

Ләйләгөлнең сигезенче класста укыган чагы. Бергәләп киноларга бара башладык без. Кайткач, караган картина турында сөйләшеп, бәхәсләшеп утырабыз. Бергәләп ашарга әзерлибез. Бергәләп җыештырабыз.

Бервакыт Илдар, икәү генә калгач:

— Кара, Гөлмәрьям, бигрәк матур инде безнең Ләйләгөл. Тәмам буй җитеп килә хәзер, — диде.

— Син сизенәсеңме, йөргән егете бар микән? — дип сорадым мин.

Илдар сискәнеп китте.

— Иртә әле аңа егетләр белән чуалырга. Әллә син берәр нәрсә беләсеңме? — дип төпчене башлады.

Ник сораганыма үкенеп, аны тынычландырырга ашыктым.

— Ата-бабадан килгән бер аннан гына калмас. Мәктәп елларында табылган дус ышанычлы була ул, — дидем.

Илдарның барыбер минем белән килешәсе килмәде:

— Басылып кына укысын. Егетләр качмас, — дип кырт кисте.

Бик шулай да бит! Ләкин тормыш кайчагында син дигәнчә генә бармый. Хәзер менә бөтен гаепне үземнән эзлим. Ни өчен Илдардан яшерә-яшерә тегендә-монда җибәрдем Ләйләгөлне? Ни өчен иремнән яшерә-яшерә акча бирдем? Ни өчен әтисе рөхсәт итмәгән килеш аларның очрашуына юл

куйдым? Ни өчен? Ни өчен? Ни өчен?.. Менә шул сораулар телгәли минем бәгырьне. Шул сораулар бер генә минутка да тынгылык бирми. Дөрес, дип юатам мин кайчагында үземне, Илдар үзе дә, очрашмасыннар, дип өзеп әйтмәде. Ләйләгөлне иптәшләре белән походларга, экскурсияләргә, урманнарга барудан да тыймады. Әмма Хәмбәлгә карата хөрмәте булмавын һаман сиздереп торды, һәм шул гадәте миңа да йога башлаган иде Илдарның. Мин дә Хәмбәлнең тискәре якларын күрә башлаган идем. Бу турыда әкертенләп кенә Ләйләгөлгә дә әйткәләдем. Күрәсең, Ләйләгөл шактый иеләшкән иде аңа. «Кызганам мин аны. Әти-әни белән үскән балаларга сокланып, көнләшеп карый ул. Аның бит гел булмаган этисе», — диде. Хастаханәгә кергәч тә шул уй тынгы бирмәде миңа. Үзем дәваланам, үзем, өйдә имчәк баласын калдыргандай, Ләйләгөл өчен борчылам. Дәвалануым дәвалану булмады. Бер ай дигәндә тагын да ныграк таушалып хастаханәдән чыктым. Һәм... Шул чагында Ләйләгөлдә ниндидер үзгәреш барын сиздем. Ничек итеп сүз башларга белмичә:

— Мин ясаган чәйне сагынгансыңдыр, кызым. Әйдә, икәүләп тәмле итеп чәй эчик әле, — дидем.

Чәй эчкәч, диванга чыгып утырдык. Куеныма алып, чәченнән сыйпадым. Ләйләгөл, күкрәгемә капланып, үксеп елап җибәрде...

Ләйләгөлнең бала тудырыр вакыты якынлашкач, җиң сызганып эшкә керештем. Өйдә бер дигән пөхтәлек булдырасым килде. Түшәмнәрне акшарладым. Бүлмә обойларын алыштырдым. Балага һавалырак урын булсын дип, зур якны алар өчен әзерләдем. Нәни агач карават, сиртмәле арба алып куйдык. Танышларымнан, кем кая барса, акча җибәреп, күз явын алырдай матур күлмәкләр, башлык һәм оеклы ыштаннар кайтарттым.

*«Сабый бала чисталык ярата. Сабый баланың күлмәген дә, чүпрәген дә һәр ике яктан яхшылап утүкләргә кирәк. Аның тәне микроблар өчен ачык капка кебек. Сабый бала үзе кечкенә булса да, тәрбия зур кирәк!..»* дип, бала караваты янына язып та куйдым.

Чираттагы ялымны кичектереп торып, алар кайтышка алырга булдым. Үзем сау-сәламәт чакта Ләйләгөлгә чүпрәк тә юдырмам дип уйладым. Бәби чире — астыртын чир ул, сакланмаган хатын-кыз бик тиз өзлегә аннан.

Соңгы вакытта, үч иткәндәй, Ләйләгөлнең әнисе — Кәримә ханым күз алдыма килеп аптыратты. Тулгаклаган вакытта ук ямьсез итеп сүгенүе, бүлмәгә кертеп салгач та сөт төшмәсен өчен күкрәген кысып бәйләп куюы белән гайрәтне чигергән иде ул хастаханәдә. Ләйләгөл дә үзен шулай тотмас микән дип хафаландым. Шунда ук үземнән үзем куркып: «Юк, йөз кат, мең кат юк! Ләйләгөл андый түгел. Ләйләгөл сабыр, чыдам. Ләйләгөл дөньяда иң әйбәт кеше», — дип уйладым. Ләкин кайгы уты үтмәс пычак белән бер икән. Туктаусыз сызлатып бәгырьне телә. Ормый-сукмый гына тынычлыгыңны урлый, күзләреңнең нурын ала. Кеше арасына чыкмас, әйтер сүзеңне әйттермәс итә.

Соңгы көннәрдә Илдар да тәмам ябыгып китте, күзләре генә утырып калды. Төннәрен йоклый алмый. Яткач, бер яктан икенче якка әллә йөз әйләнә тагы. Урын-җиргә каплаган җәймә иртән торуга карар җире калмаслык булып бөгәрләнгән була. Беркөнне:

— Теге йолкыш Ләйләгөл янына һаман килеп йөриме? — дип сорады бу.

Үзе юкта килүенә Илдарның рөхсәте булмавын белсәм дә, юк дип әйтә алмадым.

— Килгәли, — дидем. Аннан: — Ләйләгөл дә, мин дә тәмам гарык булдык инде. Туктамый бит, — дип өстәдем.

Илдарым, теш арасыннан гына берничә сүз әйтеп, үзенең ачуын белдерде. Мин аның тыгыз булып төйнәлгән йодрыгына игътибар иттем. Куркып калдым.

— Яңадан килмәс инде ул, Илдар. Соңгы килүендә бик каты орыштым үзен, — дидем. Сүзне икенчегә бормакчы булып, юынырга, аннан ашарга чакырдым: — Тизрәк, Илдар, эшеңә соңга каласың, — дип, хәйләгә керештем.

Ләкин ул ашыкмады. Бик әйбәтләп душта юынды. Озаклап кырынды. Бер чынаяк чәйне буш кына эчте дә китабын алып диванга утырды.

Илдар яхшы хезмәткәр, секунд та соңга калмый эшенә ашыга торган иде.

— Бүген эшләмисезме әллә? — дидем мин, аның янына килеп.

— Эшлибез. Тик мин бүген эшкә бармыйм. Теге йолкышны көтәм. Сөйләшәсем бар, — диде.

— Аның өчен эшеңнән калма, Илдар. Бер җае чыгар әле, сөйләшерсез, — дип, эшенә барырга кыстадым.

— Ләйләгөлнең алып үстерелгәнен белә ул. Мөгаен, үзе кебек кадерсез дип уйлыйдыр. Ничек кыерсытсаң да ярый дип йөридер. Йолкыш! Күрсәтим әле мин аңа Ләйләгөлнең нинди ятим икәнен!.. — диде.

Ул бик тә ярсыган, йодрыкларын төйнәгән, арлы-бирле йөренә иде. Ташып чыгарга торган хисләрен вакытыннан алда түкмәс өчен шулай киеренке кебек тоелды ул миңа.

— Тынычлан әле, Илдар. Ләйләгөлгә андый ук куркыныч янамый лабаса. Син рөхсәт итсәң, Хәмбәл бездә торып калырга да риза. Бала тусын әле, әгәр һаман борчыса, милициягә әйтербез, — дидем.

— Милициягә чаклы атасы бар Ләйләгөлнең! Атасыз бала түгел ул! — дип басым ясады Илдар.

Мин аны үгетләп тормадым. Чөнки Илдар инде катгый бер фикергә килгән. Андый чакны уеннан бервакытта да кире кайтмый ул.

Вак-төяк эшләрне караштырганнан соң, мин тиз генә базарга барып кайтмакчы булдым. Сөт ала торган ханым гадәттә шушы вакытта килә. Ә мин Ләйләгөлгә бер генә сыер сөте булсын дип тырышам. Шуңа күрә бүген дә соңга калмаска уйладым.

— Илдар, әллә соң бергә барып киләбезме? — дидем мин, аның ялгызын калдырасым килмичә.

— Әйдә, бар, үзең генә әйлән. Машина юлларын карап йөр, — диде ул.

Яшенле яңгыр алдыннан килгән җил табигатьне ничек туздырып ташласа, минем күңелне дә уйлар өермәсе шулай актара иде. Бөтен эшемне ничектер белештерми генә эшлим кебек тоелды. Тиз генә сөт алып, ашыгып-кабаланып кайтыр юлга борылдым.

Өйгә кайтып кергәндә, Илдар китабын кочаклаган хәлдә уйга чумып утыра иде. Ишектән керүемне дә ишетмәде, ахры. Мин, аның тынычлыгын бозмас өчен, аяк очларыма гына басып, кухняга уздым, сөтне кайнатып куясы иттем. Аннары иремнең яраткан ризыгы — кыстыбый пешереп алырга уйладым. Бәрәңге әрчеп газга куйдым да: «Нишләп сөйләшмичә утыра бу?» — дип, җаным түзмичә Илдар янына чыктым, иплән кенә янына килеп утырдым.

— Хәзер, хәзер уза, — диде бу миңа, хәлсез тавышы белән.

— Нәрсә уза? — дип пышылдадым мин, аныкыннан да әкренрәк итеп.

— Йөрәк, — диде ул.

Бары шунда гына ярым йомык күзләренә, агарып киткән йөзенә игътибар иттем. Тиз генә йөрәк даруы китереп каптырдым, «ашыгыч ярдәм» машинасын чакырырга чыгып йөгердем. Мин кайтканда Илдар бераз хәлләнгән кебек иде.

— Хәзер табиблар килә, — дигән сүземә:

— Кеше бимазалап йөрисең юк иде. Уза ул, беренче генә тотып алуы түгел ич инде, — диде.

— Менә сиңа иске авыздан яңа сүз, — дип, аптыравымны белдердем мин. — Ничек инде беренче генә тотып алуы түгел? Ник мин белмим аны, синең йөрәгең авыртканны? — дидем мин.

— Бөтен кешенеке берьюлы авырткач, кызыгы калмый аның. Синеке авыртмаса, әйткән булыр идем, — дип шаяртты.

Шунда мин аның егетлегенә тагын бер кат инандым. Соң чиккә чаклы тешен кысып түзгән бит, бичара. Үзенең авыруы турында берни белгертмичә, һаман мине дәвалау хәсрәте белән йөрде. Авыр әйбер күтәртмәскә, борчымаска тырышты... Шуларны искә төшереп, күңелем тулды. Иремнең тезләренә капландым.

— Шул булыр инде синең... Юкка күз яшеңне койма! Елыйсы көннәрең алда әле, — диде Илдар.

Мин сәерсенеп аңа карадым.

— Нигә алай дип әйтәсең, Илдар? Минем шатлыктан гына елыйсым килә. Кайгыдан туйдым инде, — дидем.

Илдар җавап бирергә өлгермәде, табиблар килеп җитте. Укол кададылар үзенә. Иртәгә үк участок терапевтына күренергә, эшкә бармаска куштылар. Илдарга берничә көн өйдә утырырга туры килде. Әнә шул харап итте дә инде безнең тормышны. Моңа кадәр аның күзеннән яшереп килгән бөтен вак-төяк фаш булды, һәрберсенә эндәшмәсә дә, күңеленә салып барган икән.

— Мин синнән моны көтмәгән идем, Гөлмәрьям, — диде ул, өйдә ятуының өченче көнендә. — Карап-карап торам да, мине сабый баланы алдаган кебек юмалап килгәнсең. Кияү булырга тиешле хәшәрәткә түрдән урын бирергә уйлыйсыз түгелме соң? — диде.

— Кызың кемне яратса, киявең шул булыр, дигән борынгылар. Яхшымы-яманмы — сабыйның атасы ич инде ул, нигә алай хәшәрәт дип атыйсың? — дидем мин, гомеремдә беренче мәртәбә төксе итеп.

Шул сүзем белән утка керосин сиптем. Илдар тәмам чыгырыннан чыгып тузынды. Минем кырыс тавышымны һич кенә дә күтәрә алмады. Һәм: «...Күрәм, мин монда артык икәнмен», — дип сүзен тәмамлады.

Мин авызымны үлчәми ачуыма, Илдар авыру вакытта шулай кискен сөйләшүемә үкенеп бетә алмадым. Куркып йөрәк даруы алып килдем. Илдар эчмәде. Аны тынычландырырга теләп никадәр генә янында утырсам да, элекке кебек йомшап төшмәде, ә икенче көнне базардан әйләнеп кайтуыма өстәл өстендә менә шушы язу ята иде.

*«Гөлмәрьям, мин сиңа үпкәләмим, синнән күп кадер күрдем. Яратып яшәдем. Инде килеп, тормышыбызның мондый борылыш алуы күңелне ашый. Эч-бавырларны актара. Барыбыздан да бигрәк сиңа кыен. Соңгы вакытта бертуктаусыз алдарга мәҗбүрсең. Ә син аңа өйрәнмәгән. Шуңа күрә ялган сөйләгәндә тотлыга, кызара, газаплана башлыйсың. Авыр сиңа. Кемгә ярарга белмичә интеккәнеңне күрү миңа авыр. Мин — гомер иткән ирең. Ләйләгөл — күкрәк сөтеңне имеп үскән бала. Икебезне дә яратырга, икебезне дә якларга тулы хакың бар. Инде килеп, безнең йортка тагын бер ир-атның килергә тиешлеге мәгълүм булды. Ике тәкә башы һичкайчан бер казанга сыймый. Сез шул турыда уйлап бетермәгәнсез...*

*Мин сине бик яратам, Гөлмәрьям. Бәлки, артык яраткангa күрә кемгә булырга, ничәгә бүлгәләнергә, нинди ялган уйлап табарга белми интегүеңне карап тору авырдыр да. Инде башкача булдыра алмыйм. Әлегә кая барасымны, кемгә тукталасымны тәгаен генә күз алдына китерүе кыен. Тик мондый шартларда сезнең янда кала алмыйм.*

*Илдар».*

Хатны укып бетерүгә:

— Илдарым, бәгырь кисәгем минем, — дип җан ачысы белән кычкырып ишеккә ташландым. Урамга чыгып, кая барсам куып җитәрлек икән дигәндәй, як-ягыма күз йөртеп алдым да ул эшкә йөри торган тыкрык буйлап йөгердем. Сулуым кабып тукталышка килеп җиткәндә, халык белән шыгрым тулы автобус кузгалып китте. Илдар шул автобустадыр кебек тоелды миңа. Юл уртасына чыгып такси тотарга азапланучы исерек ирләргә ачуым килү гадәтем булса да, ашыгуымнан берни белән исәпләшмичә, үзем дә шул юньсезлекне кабатладым. Аңа карап яныма тиз генә такси да килеп туктамады. Нинди генә автобус артыннан куып карасам да, Илдарны таба алмадым. Күңелемнән бары бер генә теләк теләдем. «Йөрәге генә тотмаса, егылып кына ятмаса ярар иде. Исерек дип узган-барганы да игътибар итмәс. Исән-сау гына йөрсен иде!..» — дип кабатладым. Бертуктаусыз үземне тиргәдем. «Мин генә китереп җиткердем бит аны бу хәлгә. Ниләргә генә йонның уңаена сыйпап тормадым соң? Гомер буе тату яшәгәнне бер бүген нишләп тавышымны күтәрдем? — дип өзгәләндем. — Язмышыма шулай язылды микәнни? Картлык көнемдә яраткан кешем ташлап китәргә тиеш булды микәнни? Нишләрмен? Гомеремнең соңгы көннәрен Илдардан башка ничек яшәп бетерермен?..»

Кайтып, Илдарның сүз арасындагы фикерләрен дә укырга теләгәндәй, тагы хатка капландым. «Барып җиткәч хәбәр итәрмен, сине үз яныма алдырырмын», — кебегрәк мәгънә эзләдем. Әмма андый сүз юк иде...

Бераз уйланып утырдым да хатны тагын кулыма алдым. Шулай ук бөтенләйгә китте микәнни? Ни уйлады, башына нинди юләр фикерләр кертеп тутырды бу? Тагын мин дип, миңа уңайрак булсын дип, үзенә кыен алды ич инде. Соңгы вакытта, дөрестән дә, бөтен күңелемне Ләйләгөлгә салдым. Соң, Ләйләгөл турында да уйламыйча булмый. Гаиләгә килгән кайгы — уртак кайгы булырга тиеш ләбаса. Ни өчен соңгы минутта мәхәббәтебезгә хыянәт итте, бөтен кайгыны минем өскә өеп китте соң ул, дип ачыргаландым. Әмма күңелем белән барыбер аны якладым. «Мондый эшне Илдар эшләгән икән, димәк, шулай кирәк булган. Минем ирем ялгыша торган кеше түгел!» — дип уйладым. Күңелем белән менә-менә кайтып килер дип көттем...

Таңда кыз тапты Ләйләгөл. Дөньяга Кеше тудырды. Бар матурдан матуррак, кыйммәтледән кыйммәтлерәк, үз җаныннан газизрәк бала тапты.

Хастаханәдән чәчәкләр белән алып кайттым үзен. Кеше алдында күңеле кителмәсен дип, баланы төрергә ефәк юрган алып бардым, җиңел машина ялладым. Их, шундый бәхетле минутларны күрми бит Илдар. Юкса сабыйларны ул бигрәк тә нык ярата иде. Өебезгә томрап торган бәби алып кайтсак та, ул көнне авыз тутырып бәхетле көн дип әйтеп булмый. Тулы түгел хәзер безнең бәхетебез... Илдар язу калдырып китеп барса, Хәмбәл әйтми-сөйләми генә юкка чыкты. Без исә, ялгыз калган чакларда бугазга тыгылган төерне бер-беребезгә сиздермәскә тырышып, икебез дә балага үреләбез. Аны иркәлибез. Ләйләгөлнең дә, минем дә бердәнбер коткаручыбыз ул. Ләкин үзе борчулы булгач, кызы да елак булды Ләйләгөлнең. Тора-бара бөтенләй кулга ияләште. Дөресрәге, шул нарасыйның җылысы белән җылынырга теләп, үзебез аны куенга алабыз. Бик тә олы кеше исәпләп, иртәдән кичкә кадәр быдырдап, сөйләшеп йөрибез. Ләкин үзебезне никадәр генә алдамыйк, нарасый белән никадәр генә юанырга тырышмыйк, барыбер җанга урын табып булмый. Кая барып бәрелергә белмичә йөдибез. Илдарны юксынабыз. Тирә-юнебездәге тузан бөртегенә кадәр Илдарны хәтерләтә. Тәнебездәге һәр күзәнәккә шыплап сагыш тулган. Чиста күк йөзе дә мең йолдызы — мең соравы белән баш очыбызда тора. Хәзер мин төннәрен йоклап түгел, шул йолдызлар белән сөйләшеп чыгам. Ашыга-ашыга аларның серен ачарга тырышам. Ләкин моның өчен минем гомерем генә җитмәячәген яхшы беләм. Шуңа күрә тизрәк үстерәсе, аякка бастырасы килә сине, җиде ят сабыем. Шуңа күрә бөтен осталыгымны, бөтен җылымны биреп сине тәрбиялим, сине иркәлим, сине кадерлим. Сиртмәле арбаңнан алып калтыранган кулларым белән күкрәгемә кысам, Илдарымның зәңгәр күзләрен хәтерләтүче, галәм киңлегендә балкучы серле йолдызларга таба сузам.

— И син, мәрхәмәтле җан, гөнаһсыз сабый! — дип эндәшәм. — Кешелек өчен бары тик яхшыны гына тудырсаң иде, шәфкатьле һәм миһербанлы булсаң иде, газиз балам! Безнең ялгышларны кабатламыйча бәхетле яшәсәң иде!

*1978–1982*

## *Алма апа*

*Хезмәттәшем Илгизәр апа*
*Сәмигуллинага багышлыйм*

— Йолдызлар сагышланамы, әбием?

— Йолдызлармы? Сагышлана, кызым. Вакыт-вакыт бик моңсу була алар.

— Нигә икән, әбием? Әллә аларны да әниләре ташлап китәме?

— Китәдер, балам, дөнья бит бу.

— Әбием, кайгылы йолдызлар кабынгач туган кешеләр бәхетсез буламы инде?

— Кайгылы йолдызлар? Ә-ә, әниләре ташлап киткән йолдызларны әйтәсеңме? Иртәгә сөйләшеп бетерербез, кызым. Йокла әйдә.

— Әбием, нигә бөтен кешеләр дә бәхет йолдызлары яктыртканда гына тумыйлар? И-их, Күк йөзен гел бәхет йолдызлары гына басып китсә... Ул чагында бөтен-бөтен кешеләр дә бәхетле, әти-әниле булыр иде, әйе бит, әбием?

— Ә сез бәхет йолдызы астында тудыгыз, кызым. Бәхет йолдызы астында...

Әби кешенең тавышы ераклаша.

Ул, сигез бәбәй итәкле күлмәген җилфердәтеп, йолдызлар янына күтәрелә.

«Сигез бәбәй итәк? Димәк, әбием сигез бала тапкан. Исәннәре ничәү соң? Алма апа, Лимара апа, Илсур... Тукта, әбием күздән югалганчы сүзләремне әйтеп калырга кирәк бит», — дип уйлый ул, үз яшеннән күпкә зиһенлерәк фикер йөртеп.

— Сау бул, әбием. Сагышлы һәм саран, ялганчы һәм явыз йолдызларны безнең Күк йөзеннән куып чыгар. Үзләренә иш туганга куанып, мыскыллы елмаеп карап тормасыннар!..

* * *

Алсу күзен ачканда, бүлмә шактый яктырган иде. Урын-җиреннән шуып кына төшеп, кайсы буйга, кайсы аркылыга куелган караватлар арасыннан коридорга чыкты. Күрше бүлмәнең яртылаш ачык ишегеннән башын тыгып, апасының ятагына күз салды. Апасы стенага карап яткан, йөзе күренми. Мөгаен, йоклыйдыр, дип уйлады Алсу. Шулай да барыйм әле янына. Тасмасын кая куйды икән? Алсу барып җитәрәк, Наилә ялт итеп борылып карады. Сеңлесе килүенә тамчы да сөенмәде булса кирәк, юрганын башыннан ук каплап куйды. Йокылы-уяулы килеш танымады дип уйлады Алсу. Эндәшергә дә, эндәшмәскә дә белмичә, янында басып торган арада апасының тыелып кына сулкылдаганын ишетте.

— Апам, ни булды сиңа? Апам, әйдә әти алган тасмалар белән матурлап чәчләребезне үрәбез.

Наилә, күзләрен сөртеп, учына кысып яткан ал тасмасын тотып, урыныннан төште. Алар сүзсез генә, аяк очларына басып кына коридорга чыктылар. Тәрәзә янәгына килеп сөялделәр.

— Тарак алып чыкмаганбыз ич.

— Минем тарагым юк, — диде Наилә.

— Безнең бүлмәдә бер кызныкы бар. Кичә мин аннан алып торган идем.

Алсу, җәһәт кенә борылып, бүлмәләренә таба китә башлады.

Наилә:

— Гел кешедән сорап йөргәнче, үзебезнең Айнурныкын алып чыгыйк.

Алар тар гына озын коридор буйлап киттеләр дә, сулга борылып, беренче ишеккә керделәр. Айнур йоклый иде. Җирән чәчле бер малай аякларын бөкләп караватының урта бер җиренә менеп утырган да, тирбәлә-тирбәлә, үзалдына нидер көйли. Ишектә кызлар күренүгә, беркавым исәңгерәп торды да, очкылык тоткандай нечкә аваз чыгарып, башын мендәр астына яшерде. Алсу, кайда икәнен дә онытып, пырхылдап җибәрде. Гадәтенчә, бер-бер кызык эшләмәкче булып, аңа таба атлый башлаган иде, Наилә кулларыннан тотып туктатты.

— Кызык бит, апа. Тизрәк башын яшерә. Ә туңкайтып куйган җирен нишләтсәләр дә ярый...

— Кайда булыр икән тарагы? — диде Наилә, Алсуның юктан кызык табып көлүен бөтенләй дә ишетмәгәндәй. Күз белән генә бер-берләренә сораулы караш ташлаганнан соң, кул йөртеп, мендәр астын капшады.

— Юк.

Алсу, иелеп, абыйсының сары төстәге кечкенә чемоданын алды. Ачты. Ике теше сынган зәңгәр таракны, ак кәгазьгә төреп, чемоданы кесәсенә салган иде Айнур. Кызлар, таракны алып, кире борылдылар. Ак кәгазь эченнән зәңгәр тарак белән бер бөртек чәч тә килеп чыкты. Наилә күзләрен зур ачып әле таракка, әле чәчкә карап торды да чәч бөртеген нәни учына салып күзләренә якын китерде, иснәп карады һәм сеңлесенең җилкәсенә капланып үксеп елап җибәрде:

— Әти чәче. Әткәебезнең чәче ич бу, Алсу.

— Айнурныкыдыр ул, апам. Каян чыксын инде әтинең чәче. Әти күптән үлде ич.

— Нинди күптән? Бер ел да тулмады бит әле, — диде Наилә, борын тавышы белән.

— Айнурның чәче саргылт аның, бик беләсең килсә, бу кап-кара. Әти чәче бу.

Әллә йокысы туеп, әллә инде яңа җирдә йоклый алмыйча, алар янына Айнур да чыкты. Абыйсының киң төпле ыштанын күреп, Алсу тагын көлеп җибәрде.

— Апа, күр әле абыйны. Юри генә кара әле.

— Нишләп йөрисез, ник йокламыйсыз? — диде Айнур, кочаклашып торган туганнарын күреп.

— Ә син үзең ник йокламыйсың? — диде Алсу, чәтердәп.

— Айбар уятты. Ике кыз сумкаңнан ак төргәк алдылар, ди.

— Әллә аяк табаннарында да күзләре бармы аның? Без керүгә, җиз башын мендәр астына яшерде ич ул. Туктале, әләкләшкәне өчен күрсәтим әле мин аңа болай булгач.

Алсу җиңнәрен сызгана-сызгана ишеккә ташланды.

— Җитәр сиңа. Үзеңнең кайда икәнеңне онытасың. Өчебезне бергә куып җибәрсеннәр тагы.

— Кусалар, — диде Алсу, апасы белән карулашып.

— Кая барырсың?

— Сәнифә апаларга.

— Сәнифә апа болай да дәү әнине карый. Җитмәсә, бүлмәсе кечкенә, — диде Айнур, зурларча салмак тавыш белән. — Безнең башка барыр урыныбыз юк. Мин эшли башлап фатир алганчы...

Наилә, бөгелеп төшеп, күз яшьләренә буылды. Сулык-сулык килеп такмаклады:

— Нишләде ул безнең әни, ә? Нигә безне монда китерде ул? Әтине нишләп бик тиз онытты? Нишләде ул, ә?..

— Нишләде? Үзем ишетеп тордым. Дуга Диас котыртты аны, — диде Алсу. — Хөкүмәт ни өчен чыгарган ул интернатларны, балалар йортларын? Ятимнәрне ашатсын, киендерсен, укытсын өчен. Илт балаларыңны. Бер-ике ел йорт-җирләрне карыйк, аннан алып кайтырбыз, дип котыртты.

— Сөйләмә шуның сүзен. Ике елдан да, биш елдан да кайтмыйм мин аның янына. Әшәке кеше ул. Әтинең исемен телгә алгач әнине ничек итеп кыйнавын оныттыгызмыни? — диде Айнур, нәни кулларын йодрыклап.

— Тәрбияче килә, бүлмәләргә керик, — диде Наилә.

— Юк, чәчләребезне үрәбез әле. Синең тарагыңны алып тордык, абый, — диде Алсу.

Айнур китә башлаган җиреннән сискәнеп кире борылды.

— Их, төшергәнсездер инде. Кая, бирегез әле тизрәк төргән кәгазен. Әтинең чәче бар иде анда, — диде ул, ак кәгазьне кулларына алып. Кәгазь битендә берни дә юклыгын белгәч, учын пешергәндәй дерелдәп куйды.

— Ник кенә сорамыйча алдыгыз? Төшергәнсез ич.

— Әйттем бит әтинең чәче, дип. — Наиләнең йөзе яктырып, күзләре очкынланып китте. Саклык белән генә учларын ачып, бер бөртек чәчне ак кәгазь өстенә төшерде. Кадерләп төрде һәм абыйсына сузды.

— Мә, абый, сорамыйча алуыбыз өчен гафу ит. Абый, ә каян алдың син аны?

— Төреп куелган күлмәге эченнән чыкты, — диде Айнур. — Хәтерлисезме, әни, чемоданыңа сал, үскәч киярсең, дип, әтинең бер күлмәген биргән иде.

Наилә бер әтисе алып биргән ал тасмага, бер абыйсы кулындагы чәч бөртегенә төрелгән ак кәгазьгә карады да:

— Их, әтиебез исән булса, — дип авыр сулады.

— Җитәр инде, апа, сиңа. Шулкадәр еларга ярыймы соң? — диде Алсу, кырыс булырга тырышып.

— Елама, Наилә, — диде Айнур да, сеңлесен кочагына алып. — Күп елаган кешенең күзе сукырая бит. Укып бетерик тә... Аннан беркемнән дә җәберләтмәм мин сезне. Балалар йортыннан алып китәрмен дә үзем карармын. Күрерсез менә... — Ул сүзен әйтеп бетерергә өлгерә алмады, бугазына төер тыгылды. Сеңелләренә сиздермәс өчен, кырт борылып бүлмәсенә кереп китте. Наилә белән Алсу, юынгыч янына барып, кадерле ал тасма белән чәчләрен үрделәр, яшьле күзләрен юдылар. Ул арада бүтәннәр дә уянды. Чыр-чулы балалар йорты көне башланды.

*** * ***

Кояшның җылы нурлары, тәрәзә пыяласы аша кереп, балаларның битләрен, күз кабакларын кытыклый. Шуклык һәм дәрт өсти.

Яз җитә дип уйлады Алсу. Тиздән күп булып гөрләвекләр туачак. Кызык, әтисе кем дә, әнисе кем икән ул гөрләвекләрнең? Әтиләре — Кар, әниләре — Кояш, дисәң?.. Юк, киресенчә, әниләре Кар. Чөнки әниләр салкын. Балаларын да бик яратмыйлар. Ә менә әтиләр әйбәт тә, җылы да булалар. Безнең дә әти исән чакта ничек күңелле иде. Өебез дә һәрвакыт якты, җылы булды дип уйлады Алсу. Һәм, иренен тешләп, тәрәзәгә капланды. Чү, күзләремә күренәме? Сәнифә апасы ич. Төз басып, бераз гына

чайкалып атлавы, кул хәрәкәтләре, чем-кара чәчләре, күзе — чат Алсуның әтисенеке кебек Сәнифә апасының. Ә нигә бүген килә ул? Алар дәү әнисе белән бергәләп ял көннәрендә киләләр бит. Сумка тутырып тәмле әйберләр китерәләр. Очрашу бүлмәсендә әбисе аларны кочакларына алып, сөя-сөя ашата. Ә бүген ял көне дә түгел, дәү әниләре дә юк. Күтәргән әйберсе дә күренми.

Алсу Наилә апасына кермәскә, аны борчып тормаска булды. Юкса тагы елый башлар. Ә шулай да ник килә икән аның Сәнифә апасы?.. Алсу киенеп каршы йөгермәкче булган иде дә, кире уйлады. Бүлмәдә генә көтим әле, башта кайсыбызга керер икән, кемне ныграк ярата икән дип уйлады ул. Әмма көтеп утыру озакка китте. Димәк, Айнур абыйсы белән Наилә апасы янында тукталды. Аларны ярата. Юк, юк, хикмәт яратуда түгел монда. Алар олырак. Шуңа күрә апалары иң элек алар янына керергә тиеш, дип юатты ул үзен. Менә-менә бергәләп килеп керерләр кебек тоелды. Тик... көтеп арыды Алсу. Йөгереп Наилә янына китте. Ул бирелеп рәсем ясап утыра иде. Әй оста ясый да соң апасы рәсемне. Исән чагында әтиләре бик шатлана иде аның шулай оста рәсем ясавына. Стенага элеп куя иде. Бу җирен болай ит, монысын тегеләйрәк, дип киңәш бирә иде. Әле дә хәтерли Алсу: Наилә апасы бөдрә каен сурәтен ясаган. Янында сукмак. Шуннан кәрҗин тоткан кыз кайтып килә. Син ул, дигән иде апасы Алсуга. Әнә ич, күлмәгенә хәтле синеке. Әтисе дә охшаткансың дип мактады һәм үз караваты янындагы стенага беркетеп куйды.

— Сәнифә апа кая? — диде Алсу, апаларының монда да юклыгына гаҗәпләнеп.

— Сәнифә апа ял көнне килә, — диде Наилә, эшеннән аерылмыйча гына. — Бүген чәршәмбе.

Ялгыш күрдем микәнни дип икеләнде Алсу. Ә бәлки, абый янындадыр. Ул кырт борылып абыйсы янына йөгерде. Бүлмәдә абыйсы да, Сәнифә апасы да юк иде. Алсу, башын иеп, сүзсез генә үз бүлмәсенә юнәлде. Кемне-кемне, ничек итеп Сәнифә апасын башка кеше белән бутады соң әле ул? Күңелем белән бик нык итеп килүен теләгәнгә, күземә күренгәндер дип уйлады ахырдан. Һәм хәлсезләнеп караватына капланды. Наилә кебек елак булмаса да, вакыт-вакыт аңа да бик авыр була иде. Туганнары алдында кычкырып әйтмәсә дә, миен туктаусыз бер уй бораулады. Әниләре нигә монда китерде аларны? Шул бертуктаусыз мөштек суырып йөргән ала күзле Дуга Диасның сүзен нигә өстен чыгарды? Бераз гына безне үз янына чакырып сөйләшсен иде. Нишләде соң аның әнисе? Нигә чит кешене безнең өебезгә китерде дә безне читкә тибәрде? Җитмәсә, үз янына, әтиләре урынына яткырды... Алсуның күз аллары караңгыланып, башы әйләнә башлады. Сикереп торып, стеналарны, ишек-тәрәзәләрне тырныйсы, бөтен көченә нәрсәнедер кыйныйсы килә башлады. Әти, әтекәем минем, дип, әллә кайларга йөгерәсе, соңгы юлга озатылган әтисен барып табасы, җитәкләп өйләренә алып кайтасы килде. Үзен-үзе кая куярга белмичә, сикереп торып ишеккә ташланды. Һәм шул минутта тәрбияче белән кара-каршы очрашты.

— Алсу, сиңа директор бүлмәсенә керергә кирәк. Апаңны да чакырдым, — диде ул.

— Ә абыйны?

— Абыең белән сөйләштек инде.

Алар кергәндә, директорның йөзе борчулы иде.

— Утырыгыз, — диде ул, өстәлдән башын күтәрмичә генә, йомшак тавыш белән. — Сезгә тагын кайгылы хәбәр бар, балалар. Әниегез... бик каты җәрәхәт алган... Сәнифә апагыз килде.

— Әнигә нәрсә булган? — диде Наилә, куырылып килеп. — Нинди җәрәхәт? Тагын ире кыйнаганмы әллә?..

Алсуның исә әллә ни исе китмәде. Хәтта үзенең ялгышмавына, тәрәзә аша апасын дөрес тануына шатланып та куйды.

— Сез инде чыдам булыгыз, балалар. Хәтта... тагын... зур кайгы килсә дә... Апагызны күреп, сөйләшеп бик шатландым. Апагыз әйбәт кеше икән. Яныгызга килеп йөрер, ташламас ул сезне, — диде директор. — Хәзер менә бу таблеткаларны су белән йотып җибәрегез дә апагыз белән кайтыгыз. Аннан кире килерсез...

Наилә, директордан чыгып җиткәнне дә көтмичә, сыгылып төшеп елый башлады. Алсу исә, аның канын катырыр өчен, әнисенә карата дорфа сүзләр әйткән булды.

— Хәтта үлсә дә еламыйм мин аңа. Безне өебездән, мәктәбебездән, дусларыбыздан аерды. Монда да айга бер килә. Анда да буш кул белән. Иреннән куркадыр инде, — дип тезде.

— Ач ятмыйбыз ич әле, — диде Наилә, әнисенә тел тидертәсе килмичә.

— Ә бәлки, ач ятабыздыр? Бәлки, авырып ятабыздыр?.. — Ул ярсып-ярсып тагы ниләрдер әйтмәкче булган иде дә, апасы туктатты.

— Йә, җитәр, әни кеше белән булышма. Аның үзенә дә авыр. Соңгы вакытта берәр тапкыр көлгәнен күргәнең бармы син аның? Ялгышканын бик аңлый ул, минемчә. Әмма ул кешене куып, безне кире алып кайтырга көче җитми. Юаш ул безнең әни. Ә теге кеше шуннан файдалана. Әнинең күндәмлегеннән.

Алсу апасын бераз сокланып та, гаҗәпләнеп тә тыңлады. Ул аны елаудан башкага сәләтле дип уйламый иде. Кара ничек сүзләрен өзеп-өзеп сөйләшә. Кара ничек әнине яклый. Характеры бар икән. Ә Алсуга андый кешеләр ошый.

— Гафу ит, апам. Синең сүзләреңә каршы килмим. Әмма әнине кичерә алмыйм, — диде.

Тик алар әниләренең кичә үк үлүен, чаңгыда йөрергә чыккач, таудан түбән егылып төшеп, шунда ук кызу тизлек белән килүче машина астына барып керүен; хәзер исә әниләрен соңгы юлга озатырга кайтуларын — берсен дә белмиләр иде.

* * *

Трапка чыгып басуга ят җирне күзәтте Сәнифә. Әйләнә-тирәдә җан иясе юк иде. Ашыгып аэропорт бинасының тәрәзәләренә текәлде. Көтә микән? Сагынуы хакмы? Нинди уй-хыяллар, нинди планнар йөри икән башында? Әнә... Тәрәзәгә капланган күп йөзләр арасыннан аны табып алды. Адымын тизләтте. Заһидулла да аны күрде. Йөгереп беренче катка төште. Очраштылар. Ни гомер күрешми торганнан соң, никадәр зарыгып хатлар язышканнан соң тансык, көтелгән һәм теләп алган очрашу иде бу!

Хат димәктән, укып кына туярлык булмый Заһидулланың хатлары. Һәр сүзен көйгә салып, җырлап йөрерлек була. Моңлы да, кызык та итеп яза ул аларны. Яратып, якын итеп яза. Сәнифәгә «йөрәккәем» дип эндәшә. «Сиңа кадәр дөньяның ярты матурлыгын да күрмәгәнмен икән. Томан сарган күзләремне ачтың, мең яшә, йөрәккәем, авырма!» — ди.

Соңгы вакытларда шул хатлар яшәтте Сәнифәне. Заһидулланың һәрнәрсәгә игътибарлы булуы, акыллы киңәшләре яшәтте. Яшәтте генә түгел, яшәртте дә. Тәненә, бөтен җанына көч һәм дәрман бирде. «Көчле кешеләр бар соң дөньяда», — дип уйлады ул. Эше белән дә, акылы белән дә, йөрәге белән дә көчле кешеләр!

Сәнифә белә белгәннән бирле фәндә кайный Заһидулла. Самолетлар өчен яңа җайланмалар уйлап, шул җайланма белән эшләгәндә ягулыкның бермә-бер кимрәк тотылуын исбатларга әзерләнә.

Ишеткәне дә, күргәне дә бар Сәнифәнең фән кешеләрен. Гыйлем дөньясына чумганнан соң, бик күпләре үз-үзләренә бикләнеп, чикләнеп яши башлый аларның. Үз эшенә кагылышы булмаган өлкәдә нииндидер битарафлык кичерәләр. Холкында, күзләрендә хәлсезлек, бертөрлелек була. Дөньяның ямен, ризыкның тәмен тоймаган кебек тоела алар Сәнифәгә. Моның сәбәбе — көче җитмәслек эшкә тотынып, бер башлагач, ташлыйсы килмичә үҗәтләнеп тырышудадыр, бәлки? Бәлки, башка сәбәпләре бардыр. Әмма Сәнифәгә шул аңлашылмый. Ничек берьяклы тормыш белән генә яшәргә мөмкин икән бу ләззәтле дөньяда? Барысы да җитеш, барысы да бар лабаса. Шул кыршылып беткән портфелеңне, шул кыйшаеп беткән аяк киемеңне алыштыру өчен күп дигәндә бер-ике сәгать вакыт кына бүләргә кирәк тә бит. Юк, фән дөньясына чумган кешеләрнең ни өчендер ул мәсьәләдә гамьнәре булмый. Ә кайберләренең хатыннары шуннан ныгытып файдалана. Килбәтсез булып йөри бирсен, имеш, кызлар карамас. Иренең үзенеке генә булып яшәве хатыны өчен дәрәҗә, билгеле. Бигрәк тә бу заманда.

Аннан, ирләргә карата тагын бер үпкәсе бар аның. Шешә янында, тәмәке тарткан җирдә гомер иткән, кайтып пешергән ашын ашаган, кайнар кочагында йоклаган хатыннарын хурлап йөрүләре.

Яшерен-батырын түгел, ялгыз булгач, бер дә, ике дә килделәр аның ишегенә. Кайберәүләр боз тавыдай салкын, кайберәүләр ут кебек кайнар — якын барып булмый, дип сөйләгәннәр. Хәтта әйбәт торачагыбызга вәгъдә булса, энеләрен «начар» киленнән аерып, аңа китереп йортка кертергә тырышучылары да табылды. Ә күңелдә бушлык, ялгызлык дәвам итте. Шул буш һәм караңгы төннәрнең чиксез караңгылыгында анда-санда энә күзе кебек өмет яктысы балкып узды. Күңел ул өметнең якынаюын, яктыруын, аның өчен балкуын теләде. Әмма әкиятләрдә һәм киноларда гына була торган бәхетле очрашуларны көтеп күңел ялыкты, ышанмаска әйләнде. Һәм... нәкъ шундый өметсезлеккә бирелгән кичләрнең берсендә күңел тәрәзәсенә тагын чиртteләр... Ул батыр — хатынлы ир иде. Тупсаны атлап керүгә, юл сумкасын куйды да Сәнифәнең күзләренә текәлде. Үзләре түгел, телләре түгел, күзләре сөйләште. Ялварулы итеп, кызгандырырга теләп. Әйткән вәгъдәсен бозмады Сәнифә. Бер төнлек ләззәт өчен күңеленә бимаза аласы килмәде. Икенче көнне, сүзсез генә иртәнге чәйне эчкәннән соң, кунак кеше китте. Килгәндәге кебек тавыш-тынсыз, аңлатуларсыз, аңлашуларсыз.

Ә менә кинәт кенә авырып китеп хастаханәгә керергә кирәк булгач, шушы яшенә кадәр кыз булып яшәвеннән көлмәсеннәр өчен, тотты да бер кичтә аны чакырды. Табибка да мәшәкать азрак булыр... Аннан соң, өстенлекне нигә хирург пычагына бирергә? Берәү алдында горурлана, аңа ләззәт китерә ала ич ул!.. Шулай итеп, чәчләренә чал кергән бер мәлдә тормыш мәҗбүри рәвештә китереп тудырган зөфаф вакыйгасы булды. Ир бу хәлне башына сыймастай очрак кебек кабул итте. Әсәренде, хисләреннән исерде. Теле тәмам чишелде. Сәнифәне «командировка»дан бик сагынып көтеп алачагын әйтте.

«Командировка» озакка сузылмады. Табиблар да киләчәк өчен бернинди куркыныч янамавын әйттеләр. Әмма Сәнифәнең ялгыз күңелен тырнап яңа газап кабынды. Үзен әллә нинди әшәкелек эшләгән кешедәй гөнаһлы тойды. Хатынлы ирне аздырган, юлдан яздырган кебек сизде ул үзен. Ирдә дә хуҗа итеп чакырылган кеше гадәтләре сизелә башлады...

Моңа кадәр ул үзен «ач тамагым, тыныч колагым» дип юата иде. Хатынлы ирләрне якын җибәрмим дип максат та куйды. Ә җан дигәнең кирәксенде. Бәргәләнде, гасабиланды. Сәнифә әнә шул биологик таләпкә каршы барып, үзе белән, хисләре һәм акылы белән көрәште... Кеше алдында даным чыкмасын, туганнарым янында дәрәҗәм төшмәсен дип уйлады. Әмма теге вакытта бәйләнешкә керүе аңа яңа уйлар, яңа хыяллар белән яшәргә форсат тудырды. Танышының тар һәм салкын кочагын, иренчәк хәрәкәтләрен оҗмах рәхәтенә тиңләп үстерде. Акылы белән буш өметләргә, әкияткә охшаш, чынга ашмас тәэсирләргә кереп чумды. Аның белән сөйләште, эчен бушатты. Күпмегә? Ләкин күпмегә генә булса да, кемеңдер булып, шуның белән алданып йөрүнең ярыйсы гына кичереш икәнен төшенде. Шулай итеп, төрле сәбәпләр табып, шактый качып йөргәннән соң, тар куенлы бәндә кочагында тагы ярты төнен уздырды. Кунак бу килүдә үзен тагын да иркенрәк тотты. Күңеле тәмам тулып һәм булып, хатынын хурлады, хәләленең аңа кадәр күптән «башланган» булуын сөйләргә тотынды. Бу гадәте өчен кочагыннан гына түгел, йөрәгеннән дә куды аны Сәнифә.

Ышанмагыз сөйгән ярын сөйләп йөргән кешегә:
Бары хурлый үз-үзен ул, үз-үзенә тешегә.
Ярын ничек данласын ул — хурлагач шундук күршегә?..
Ул сөюдән күңел өши, ул хистән йөрәк күшегә.

1205 еллар тирәсендә үк грузин шагыйре Шота Руставели язып калдырган шигырьне укыды ул аңа.

— «Юлбарыс тиресе ябынган батыр» поэмасыннан, — диде, «ябынган» сүзенә басым ясап. — Инде дә хатының, чынлап та, сине җәберләп тора икән, тормыш юлдашы сайлаганда яшьлегең белән ялгышкансың икән — аерыл. Ә инде хатыныңны теләсә кемгә хурлап, мескенләнеп, шешәдәш дусларыңнан үзеңне кызгандырып йөрү егетлек түгел, — диде.

— Бала дип авыз чайкый кайберәүләр. Улымны, кызымны яратам, алар хакына яшим, ди. Бала хакына яшәргә, аларны тәрбия кылырга кирәк. Әмма балаларның да аңлый торган вакыты җитә. Инде дә түзмәслек чиккә җиткән икән, өйдәге чүпне тышка чыгармыйча гына, балаларыңның анасын теләсә кемнән каһәрләтмичә генә хәл ит...

Бу ике мәсьәләдә әнә шундый иде аның фикере. Ә менә Заһидулла белән танышкач, уйлары шактый үзгәрде. Бигрәк тә фән кешеләре турындагысы. Моңа кадәр бөтенләй берьяклы гына фикер йөртүен аңлады. Тирә-юньдәге һәр хәрәкәткә игътибарлы, яхшы ат кебек баскан җирендә таптанып торучы Заһидулланың да муеныннан гыйльми эшкә чумганын, туктаусыз тәҗрибәләр ясап, докторлык диссертациясе якларга йөрүен белгәч — утыз еллык күзәтүен күңеленнән сызды да ташлады. Заһидулла белән сөйләшкән саен, тормышның матурлыгына, җирдә яшәүнең олы бәхет булуына ныграк ышанды. Очрашкан саен офыгының киңлегенә, белеменең тирәнлегенә сокланды. Кеше акылының шулкадәр байлыкны сыйдыра алуына гаҗәпләнде.

Бергә чагында Заһидулла туктаусыз сөйли, Сәнифә йотлыгып тыңлый.

— Матур итеп тыңлый беләсең дә инде, — ди аңа Заһидулла.

— Матур итеп сөйли белгән кешене, бәй, — ди Сәнифә, иркәләнеп.

Сәнифә тыңлый да, моңарчы ишетмәгән иркә сүзләр тәэсирендә эри дә...

— Кешене мактау сүзләре, беләсеңме, күпме? — ди Заһидулла, елмаеп. — Дүрт меңнән артык. Моны мин түгел, Йосыф Гәрәй дигән фәлсәфәче әйткән. Ләкин, йөрәккәем, шул тәмле сүзләрнең кадерен белмәүчеләр дә күп, ди. Йөзе кинәт кырысланып китә. Карашына ниндидер нәфрәт һәм ачу бәреп чыга. Әмма үзен бик тиз кулга алып, элекке халәтенә кайта.

Яхшылыгына яманлык белән җавап биргәннәр икән моның, дип нәтиҗә ясый Сәнифә.

Заһидулла һаман сөйли. Аңа карап-карап ала. Карашлары бер мизгелгә генә очраша да, бер-берсеннән кыенсыныпмы, читкә йөгерә. Сәнифәнең ни өчендер аның күзләренә чумасы, җемелдәп торган кешесенә кереп утырасы килә. Тик үз уйларыннан үзе куркып, сискәнеп куя. Баягы ачуыннан күз кырыена ниндидер кырыслык, усаллык ябышып калгандай тоела. Нинди кырыслык, нинди усаллык! Сәнифә төгәл генә әйтә алмый. Бары тик: ир кеше кирәк вакытта шулай кырыс та булырга тиештер, дип нәтиҗә ясый.

— Безнең татар халкы батыр да, гадел дә, йөрәккәем, — ди Заһидулла. Үзе белгән, үзе күргән бик күп хәлләрне сөйли. Сәнифә аның хәтеренең шәплегенә хәйран калып тыңлап утыра. Һәрбер батырлыкны, һәрбер очракны ата-бабаларыбызның үткәне белән бәйли баруы ошый аңа. — Безнең авылда Нурулла исемле бабай бар иде. Ел ярым эчендә сугыштан алты медаль белән кайтты менә, йөрәккәем, — ди. — Өченче ел вафат булды, мәрхүм. Менә сөйләп куя иде үзенең күргәннәрен, үзенең ничек сугышканын, ничек итеп дошман тылына разведкага кергәнен. Тыңлаганда чәчләр үрә тора. Зөлфәт әйткән бит әле: «Пычак белән мин аюга барам, кабыргалый бәрәм — егыла!» — дип. Менә шундый көчле кеше иде... Узган ел кайткач, каберенә каен утыртып килдем. Сабакташым Тавилгә үзем кайтмаган елларда барып карарга куштым. Каберне елына ким дигәндә ике мәртәбә карарга кирәк. Яз һәм көз. Беренчесен һәрвакыт 9 майда барам мин үзем. Киевта яшәгән чагымда бервакыт шулай әкрен генә зиратны карап йөргәндә, бер татар егетенең каберенә барып чыктым. Караучысыз икәне әллә каян күренеп тора, чөнки кабере бик ташландык хәлдә иде. Утыз биш яшендә үлгән. Исем-фамилиясен,

туган-үлгән елын яңартып куйдым. Хәзер зур бер вазифам итеп ел да яз чәчәкләр утыртып кайтам. Көз барып чистартам. Кемдер күрсен өчен түгел! Яхшылык эшләү — үзең өчен дә күңелле бит ул, — ди һәм тагы авылдашлары турында сөйли башлый.

— Бер сорау бирергә мөмкинме? — дип бүлдерә аны Сәнифә.

— Әйдә.

— Сезнең авылда берәү генә булса да начар кеше бармы? Әллә барысы да, син сөйләгәнчә, чын кешеләр генәме?

— Бар, йөрәккәем. Әшәке кеше бөтен җирдә дә бар ул. Әмма мин аларны күрмим. Андыйлар юньсезлеге белән, комсызлыгы белән үзләрен үзләре ашап юкка чыгара баралар. Ә менә авырлык күргән, олы кайгы күргән, кеше газабын үз йөрәге аша үткәрә белгән кешеләр яши. Үзләре үлгәч, исемнәре яши. Халык күңелендә буыннан буынга күчеп яши. Менә, мәсәлән...

Сәнифә тыңлый. Анда Заһидулла сөйләгән кешеләргә карата ярату һәм ихтирам хисе уяна. Авылның аксакал картларын гына түгел, карчыкларны, әбиләрне дә, чын кеше иде, дип бәяли белүе ошый. Күп бала тапкан аналарга аеруча бер хөрмәт белән каравы; укырга, кеше булырга омтылган яшьләргә ярдәм итәргә атлыгып торуы Сәнифәне тәмам әсир итә.

Күңелендә әнә шундый якты тойгылар калдырган Заһидулласы янына, хисләре белән генә түгел, тәнендәге һәр күзәнәге белән сагынган якын кешесе янына килде ул бүген. Заһидулласы йөгерә-атлый янына килеп баскач, сүз белән әйтеп бетергесез рәхәтлек кичерде. Әмма бөтен эч-бавырларын көйрәткән ялкынын бары тик күзләрендә калдырып, кайберәүләр кебек яратам дип кычкырмыйча, шаша-шаша үпмичә генә, итагатьле генә итеп, ике кулын сузып күреште. Заһидулла исә Сәнифәнең кочагына язгы нәркисләр салды. Сәнифә, нәркисләрнең хуш исенә исергәндәй, сүзсез калды. Чәчәкләр ярата ул. Иртә яздан алып салкын көзгә кадәр бакчасында чәчәкләр үстерә. Өйдә дә өстәленнән чәчәкләр өзми. Гадәтен белеп алган туган-тумачасы, таныш-белеше һаман букет күтәреп килә аларга. Шул чәчәкләргә карап, әнисе кайчагында сүз башлый. Кеше гомере дә чәчәк гомере кебек. Хәзер сула, хәзер уза. Яшь гомереңне әрәмгә уздырасың, балакаем, ди. Узган гомер дә, үлгән кеше дә кире кайтмый. Тукта Әлиф дип саргаюыңнан, ди. Бәлки, әнисе хаклыдыр да. Әмма Сәнифәнең бигүк килешәсе килми. Беренче мәхәббәтен югалтканнан соң, никадәр дөнья гизде, дөньяның кайсы гына почмакларында булмады, турист рәвешендә чит илләргә чыкты, бик күп яхшы кешеләр очратты, әмма аларның берсе дә... хәтта Заһидулла да узганнарны күңеленнән тулысынча чыгарып ташларга хокук бирми иде.

* * *

Укытучы булудан да изгерәк эш юк, кызым. Бәләкәй чактан ук балага дөрес юнәлеш бирү, аң-белемгә дәрт уяту кирәк!

Әнисенең һаман саен әйтеп торган шул сүзе тәэсир иткәндерме? Авылдан биш кыз китте алар педучилищега. Өчесе үтә алмады. Икесе, барлык сынауларны да биреп, студент булып кайтты.

Имтиханнарны тапшырып бетергәнче эчендәге әллә нинди җепләре өзелде Сәнифәнең. Авылына яңадан кайтып җитә алуына өмете өзелгән кеше сыман, көн дә бер күңеле тулып елап ала иде.

Беренче сентябрь җитүгә, бөтен мәктәпләрдәге кебек, училищеда да укулар башланды. Әмма ул көнне училищега түгел, урта мәктәпнең тугызынчы классына китте Сәнифә. Әнисе: «Иптәшләрең керә алмаганга борчыла. Син кергән өчен көяләнәсең», — дип тиргәп карады каравын, ләкин көчләмәде. Сагына бит. Ирексезләп җибәреп әллә ни күрерсең дип уйлады. Әмма кызының быел бармаса, яңадан училищега кереп укымаячагын аңлап, бик хафалана иде. Чын укытучы булам дигән кешегә нәкъ менә педагогия училищесыннан башларга кирәк дип исәпли иде ул. Шуңа күрә үзе укыган педагогия училищесында укытасы килде аның Сәнифәне. Балалар белән аралашуында, кызының үз-үзен тотышында күптәннән шул һөнәргә сәләте барлыгын чамалап йөри иде. Ә инде имтиханнарын уңышлы тапшырып та, барасым килми, дип аяк терәп каршы торуы әни кешене тәмам аптырашта калдырды. Әмма аның һәр көнне үзенең укытучылары, педучилищеның методик яктан көчле кадрлар әзерләве турында сөйләве, сөйләгәннәрен халык мәкальләре, әйтемнәр белән бик урынлы бәйләп куюы, Ян Амос Коменский, Пестолоцци, Макаренко әйткән тәкъбирләрне онытмыйча күңелендә саклавы, тамчы ташны тишкәндәй, Сәнифә дә ясаган хатасына карата беркадәр үкенү тудыра башлады. Әнисенә шул гына кирәк иде. Ул кызының икеләнүен сизүгә юлга чыкты. Училищега барып, директорның туры үзенә керде. Авырды дип тә түгел, матур ялган уйлап та түгел, чын турысын әйтеп сөйләште. Озын буйлы, бераз тотлыгыбрак сөйләшә торган бик ягымлы рус кешесе — Ильядор Борисович Уткин атлы иптәш иде училище директоры. Аңлашкач, үзенең секретарена беренче курс студентларының исемлеген кертергә кушты. Сәнифә, чынлап та, исемлеккә теркәлгән, килмәве дә билгеләп куелган иде.

— Укый башлагач ташлап китеп сезнең дә, безнең дә теңкәгә тимәс микән? Училище тарихында андыйлар белән очрашкан бар безнең, — диде директор.

— Бер килеп урнашса китми. Холкын беләм мин аның, — диде Хупҗамал ханым.

— Курсташлары әле колхозда. Өч көннән кайталар. Уку төгәл бер атнадан башлана, — диде директор. — Аннан да соңга калса, кабул итеп булмаячак.

Директор, чынлап та, мәрхәмәтле кеше булып чыкты. Хәтта фатир мәсьәләсен дә сорашты. Тулай торакта урыннарның аз булуы, уку елының беренче көннәрендә үк бүленеп бетүе хакында әйтте. Болай да түбәсе күккә тигән ана, фатир мәсьәләсендә берниндн мәшәкать ясамаячагын аңлатып, урамга чыкты. Тиз генә кызының имтихан биргәндә торган хуҗасына китте.

— Сораучы кеше бетәсе түгел. Вәгъдәләшкәч, һич югы, берәр ай көтәргә булдым. Кеше, бәлки, авырып киткәндер, — дип, ачык чырай белән каршы алды аны хуҗа хатын. — Ошаттым, ошаттым кызыңны. Басынкы да. Ялт итеп идәнне дә юып куя, — дип тезде. Баласы турында яхшы сүз ишетү Хупҗамалга рәхәт булды.

Юлының шуның кадәр дә уңуына сөенеп бетә алмады ул. Өйгә кайтып җиткәндә өйлә авышкан, авыл мәктәбендә укучы балалар барысы да кайтканнар иде. Ә Сәнифәләр, ике көнлек азык алып, Чәчер басуына эшкә киткәннәр икән. Хупҗамал, кайтып керешкә үк, Сәнифәнең укытучысына хат язып, уртанчы улын басуга йөгертте. Үзе исә матрас, мендәр, юрган ише әйберләрне төйнәп, төреп әзерләп тә куйды. Сандыгын ачып берничә ак җаймә, тотылмаган сөлгеләр алды. Кызы кайтканда, һәрнәрсә әзерләп куелган иде. Бу юлы исә Сәнифә дә карышып азапланмады. Икенче көнне өчәүләп юлга чыктылар.

— Юлны яхшылап кара. Исеңдә калдырып бар. Апаң янына бер атнада син, бер атнада мин барып торырбыз, — диде Хупҗамал улы Зөфәргә.

Студент тормышы әнә шулай башланды Сәнифәнең. Баштагы көннәрендә качып китмичә һич кенә дә түзә алмас кебек тоелса да, тора-бара үзеннән-үзе эшкә кереп чумды. Поэзия, музыка түгәрәкләренә язылды. Спорт белән шөгыльләнде. Училище белән терәлеп торган Мулланур Вахитов исемендәге мәктәптә бишенчеләрнең пионервожатые булды. Шулай итеп атнаның һәр көне бүленгән, һәр сәгате саналган иде. Аның өстенә класс җитәкчеләре Сәүбән Каюмович абыйлары: «Суларга гына вакытыгыз калсын, — дип тыгызлый. — Физик эш белән шөгыльләнгән кеше гомере буе таза була. Йөгерегез, хәлдән тайганчы чабыгыз, шартлагыз — әмма кушылганны үтәгез. Бүген шулай газаплаганым өчен, акыл кергәч килеп рәхмәт әйтерсез», — ди торган иде. Берсен төгәлләүгә, икенче шөгыль уйлап таба. — Бөтен бәрәкәт — хәрәкәттә. Бер минут тик тормагыз, — дип тәкрарлый.

Сәүбән Каюмович — гражданнар сугышын үткән кеше. Ә бабаларының бабалары исә Пугач яуларында катнашкан.

— Әтиемнең карт әтисе сөйләп калдырган, — ди ул. — Татар белән башкортның терәлеп торган ут күршеләр икәнен беләсез. Менә шул күршеләрнең ул заманда ирекле итеп өйләнешергә мөмкинлеге булмаган. Әгәр дә мәгәр берәр башкорт татардан кыз ярәшә башлый икән, беренче эш итеп Казан губернаторыннан рөхсәт алу тиеш булган. Рөхсәт ителгән очракта хөкүмәткә бер драгун аты бирелә. Ә инде рөхсәтсез өйләнешүчеләр өчәр драгун аты бирергә тиеш булган. Сәүбән абыйлары сөйләп бетерә дә, күзләре белән генә хәйләкәр елмаеп, Сәнифәгә, аның артында утырган Әлифкә карап ала. Һәм башкалар исен җыеп өлгергәнче, сүзен икенчегә борып алып китә.

— Бер атна ныклап әзерләнегез дә, шәплӛп класс кичәсе уздырырбыз, — ди. — Кайсы якта нинди уеннар, нинди кызык йолалар бар — шуларны барлый торыгыз. Язып барыгыз. Язганнарыгызны югалтмагыз. Өченче курста дәресләр бирә башлыйсыз. Шуңа күрә телегезне хәзердән үк шомарта торырга, балалар уеннары белән һәрвакыт таныш булырга кирәк. 45 минут бик күп вакыт ул. Кайчагында тәнәфесне җиткерә алмый кара тиргә төшүчеләр дә очрый. Менә шул чакта инде сезне сүз запасыгыз, бүген өйрәнгән табышмакларыгыз, шигырьләрегез һәм дә ныклы белемегез генә коткара ала, — дип өйрәтә Сәүбән абыйлары.

Әллә Сәүбән абыйларының гел үгетләп торуы, әллә нәселдән килгән кыюлыгы, тәвәккәллеге булганга — һәрнәрсәне уңайлы хәл итә иде Сәнифә. Шуның өстенә искиткеч кешелекле булуы, ярдәмгә атлыгып торуы башкалардан бер башка күтәреп куйды аны. Шуңадырмы классларындагы иң чибәр башкорт егете аның янында бөтерелә башлады. Ул инде шактый акыл утырткан, җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң колхозда эшләп, армиядә хезмәт итеп кайткан иде.

— Башкорт кыдлары ла бетмәгән һиңа. Басымны катырып йөремәгедсәле, — ди иде аңа Сәнифә, шаяртып, ике телне бергә бутап.

— Мин һиннән күбрәк яшәгән, Сәнифә һеңел. Кәләшкә кемде һайларга кәрәген һиннән яхшырак беләмдер, — дип җавап бирә иде тегесе.

Шулай беркөнне аларның классларына училищеның шәфкать туташы йөгереп керде. Шәһәр хастаханәсенә авыр хәлдә бер баланы китергәннәр. Кайнар шулпага пешкән. Ашыгыч рәвештә тире һәм кан кирәк. Кемнәр?.. Сәнифә, Әлиф, тагы ике студент шәһәр хастаханәсенә йөгерделәр. Сәнифә тиресен бирде. Әлиф — канын. Кайчакларда Сәнифә Әлифне үз яныннан куа башлады исә: «Безнең хәзер уртак улыбыз бар, Сәнифә сеңел. Синең белән безне язмыш үзе кавыштырды», — дип үрти иде. Сәнифә ирексездән көлеп җибәрә. Кешеләргә игелек кыла алуына, әлеге сабыйның исән калуында үзенең дә өлеше булуына горурлана. Үзе генә түгел, классташлары да сокланды Сәнифәнең

батырлыгына. Сәүбән абыйсы, редакциядән корреспондент чакыртып район газетасына мәкалә дә яздыртты. Шулай итеп, шаулы студент еллары кабаттан да әнисен сагынып өзгәләнергә, дөресрәге, суган суы сыгарга ирек бирмәде аңа. Хәер, әнисе дә, энесе Зөфәр дә, башка кардәшләре дә еш килеп тордылар. Семестр ахырында, озын ялларда үзе дә кайта торган булды. Җәй көннәрендә колхозда эшләде. Сыңар канат белән дүрт бала тәрбияләгән әнисенә ничек тә ярдәм булсын дип тырышты. Колхоз эшеннән кайткан арада керен, идәнен юды. Чигүен чикте, урындык-ятакларга әллә нинди матур җәймәләр бәйләде.

Кергән-чыккан күршеләре исә:

— Хупҗамал җиңги, ничекләр итеп өйрәтә белдең бу кызыңны? Кулларыннан гөл тама бит, билләһи, — дисәләр:

— Өйрәткәч сантый да эшли. Кирәген һәркем үзе белеп эшләргә тиеш, — дип җавап бирә иде Сәнифәнең әнисе. Кыз үзе дә һәр эшләгән эше өчен мактау өмет итеп үсмәде. Шулай тиеш дип кабул итте. Әнисенең бу тәрбиясе эшли башлагач зур таяныч булды аңа.

* * *

Дүрт ел вакыт үтеп тә китте. Училищеда уку еллары тәмам булды. Эшкә билгеләү башланды. Бер өстәлдә — исемлек, икенче өстәлдә — географик карта. Өченче өстәлдә —класс җитәкчесе, укытучылар, райком вәкиле. Сәнифә беренче булып керде алар янына. Аның артыннан — Әлиф. Әлиф шарт буенча шактый соң керергә тиеш булса да, иптәшләре махсус икенче кеше итеп керттеләр. Чөнки аларның бер-берсе өчен яратылган һәм гомергә аерылмаска тиешле кешеләр икәнен һәркем сүзсез дә белә иде инде. Аннан соң, һәрвакыт ачык йөзле, һәрвакыт кешелекле мөнәсәбәте, җор телле булуы белән дә курсташлары арасында зур мәхәббәт казанган иде Әлиф. Көлдерергә, күңел күтәрергә дисәң, аны куй. Юктан гына эчең катып көләрлек кызык ясый да куя.

— Бервакыт, — дип сөйли Әлиф, — институттан безнең төбәк авылларына экспедициягә студентлар килде. Юл күрсәтеп йөрү өчен җирле халык әйбәт булыр, кайбер серләрне дә ачмасмы дип булса кирәк, төркемнәренә мине дә алды болар. Ярар, хуш, киттем мин ияреп. Эшемне дә эшлим, үзләрен дә күзәтеп йөрим. Араларында бер бик кызыгы бар бит. Ашханәгә бервакытта да кеше белән килми. Юкса ара ерак түгел. Мәктәп бинасының бер классында торабыз, икенче баштагы классында ашыйбыз. Бу көнне дә шулай булды. Без тамакларны туйдырып, табынны җыеп йөргәндә, шалт ишек ачылды. Һәм бусагада салават күперенең бөтен төсләрен үзенә җыйган түгәрәк баш пәйда булды. Йокысыннан кеше белән бергә торса да, бизәнеп, иннек-кершән ягынып, чәчләренә әллә нинди ялтыравыклы әйберләр беркетеп, шулай соңга кала икән бу. Кайтып китәргә дә берничә көн генә калган иде югыйсә. Әмма телемне тыя алмадым. Ишектә күренүе булды, минем:

Елка, елка, без сине
Сагынып көттек ел буе.
Син тагы да матуррак
Бизәнгәнсең бу юлы, —

дип җырлап җибәрүем булды, бөтен группа күтәрелеп көлә башлады. Мин, ялгышымны аңлап, кая керер тишек тапмыйча уңайсызландым. Кызык кыз йә яңагыма китереп сугар, йә ашханәдән чыгып йөгерер дип уйлаган идем. Ә ул берни булмагандай түргә узды һәм үз өлешен ашый башлады. Берничә көннән алар безнең районнан китеп бардылар. Кызыкайга да Елка кушаматы тагылып китте.

— Башын ашагансың икән бичара баланың, — диде арада берсе, әллә җәлләп, әллә көлеп.

— Башын ашар өчен башның булуы кирәк бит әле аның, — диде Әлиф.

Иптәшләре тагын көлделәр.

— Чәч бөртекләрегезгә чорнап куегыз, укытучы булып эшләячәк иптәшләр, хәзер мәктәп юморы сөйлим, — ди ул, көлдерүен дәвам итеп.

— Шулай бервакыт укытучы: «Йә, балалар, инша язарга әзерләнеп килдегезме?» — ди икән. Укучылар: «Килдек, апа, килдек», — диләр. — «Берәрегез сөйләп тә бирегез инде. Өйдә ничек яшисез? Яле, Тимгелҗан?» — «Без күгәрченнәр кебек яшибез, апа». — «Менә яхшы. Аңлатыбрак әйт инде, ничек була ул күгәрченнәр кебек яшәү?» — «Соң, ничек дип, апа, получка көнне әти ишектән кайтып керә, без әни белән тәрәзәдән чыгып очабыз», — ди икән укучы...

— Әлиф, тагын сөйлә әле! — диләр кызлар, рәхәтләнеп көлә-көлә.

— Сөйлә инде, ялындырма, дисезме? — ди ул, артык әһәмият бирмәгәндәй кыланып. — Тыңлагыз алайса. Тик аң булыгыз, үзегез шундый хәлгә юлыкмагыз.

Студентлар колакларын тагы да ныграк торгыза төшәләр.

— Янә дә мәктәп тормышы.

Укытучы: «Әйдәле, Баязит, сөйләп җибәр, тургай кайда кышлый?» — ди икән. «Нәрсә дип әйтәсез, абый? Моннан бер соравыгыз да ишетелми», — ди Баязит. «Нишләп ишетелмәсен, күршеләрең җавап бирә бит». — «Ишетелми инде, абый, ышанмасагыз үзегез минем урынга утырып карагыз».

Укытучы риза була. Урыннарын алмаштыралар да, укучы сорау бирә моңа: «Абый, кич җитте исә, апа янына нишләп тәрәзәдән кереп йөрисез сез?» — ди Баязит. «Нәрсә-ә?» — дип гаҗәпләнә укытучы. «Соң әйттем бит, моннан бернәрсә дә ишетелми дип», — ди Баязит. «Әйе шул, чынлап та ишетелми икән аннан, укучылар», — дип йомгакларга мәҗбүр була укытучы.

Менә шулай бөтен кешене авызына каратырлык җор телле иде Әлиф. Барысы да яратты аны. Шуңа күрә иң соңгы минутта, хәтта эш урыны сайлаган чагында да бик теләп үз чиратларын бирделәр.

Бүленеш вакытында Сәнифә белән бер районга туры килде алар. Әмма барып җиткәч, икесен ике авылга, бер-берсеннән байтак кына ерак мәктәпләргә билгеләделәр. Әлиф завроного кабат керергә теләсә дә, Сәнифә: «Берәр ел аерым эшләп, әниләребезгә, туганнарыбызга булышыйк. Икенче елга бер мәктәпкә сорарбыз», — дигәч, күнде. Чөнки Әлифнең дә туганнары күп, һәркайсын укытып аякка бастырасы бар. Менә шулай итеп, бер ел эшләгәч тә өйләнешергә вәгъдәләр куешып, икесе ике тарафка юнәлделәр. Шатланып беренче хезмәт иртәләрен башладылар. Әмма... кавышулар насыйп булмады аларга...

Әллә инде артык яратканга?..

Әллә Таһир-Зөһрә кебек парлар җырларда гына калсын дип, язмыш гомерлеккә, юк, мәңгелеккә аерды аларны. Юкса барысы да әйбәт кенә иде. Кыз ягына да, егет ягына да кайтып, әти-әниләренең фатихаларын алдылар. Сабантуйга өйләнешәбез, дип, туганнарына да хәбәр бирделәр. Һәм кинәт, һич көтмәгәндә, язгы явымлы көннәрнең берсендә фаҗигале төстә вафат булды Әлиф. Җан биргәнче телендә булган. Җан биргәнче Сәнифә дип өзгәләнгән. Сәнифә исә Әлифнең мәете өстенә генә барып җитте. Туганнарына ияреп, егетенең авылына кайтты. Аннан соң да еш барды ул Башкортстанга. Булдыра алган кадәр әнисенә ярдәм итте. Әлиф дип кан-яшь түгүче ана Сәнифәнең бу изгелегеннән бик канәгать булып рәхмәт укыды.

— Үлгәннәрнең безнең дөньялыкта гаме юк инде. Җирдә яшәп калганнарга авыр. Яшь гомереңне елап уздырма. Әлиф кебек егет очраса, кияүгә чык! — дип үгетләде ул Сәнифәне.

— Ул хакта сөйләшмик, — диде Сәнифә, Әлифнең әнисенә гел «әни» диясе килеп.

Шулай барып йөргән арада, өрлек кебек улын югалткан ана күңеленә кара канның гомерлеккә урнашып калуын белде. Аңа үзеннән дә авыррак икәнен аңлады.

— Әлифемне кешелеге генә харап итте. Изгелек кылуның да чамасын белергә кирәк икән, — дия башлады.

Әлиф чынлап та изге юлда вафат булды. Бер укучысының әти-әнисе өй салган чак була. Шуларга ярдәмгә бара ул. Явымлы юлда батып калган арбаны, төялгән йөге белән бергә күтәреп, корыга чыгармакчы була. Күтәрә, арбаны астыннан кереп күтәрә. Йөкне коры җиргә күчерә. Әмма үзе дә эчен тотып янтаеп төшә. Өзелде, нәрсәдер өзелде, шартлаганы үземә дә ишетелде, ди ул, хәлсезләнгәннән-хәлсезләнә барып... Әнә шундый риясыз, әнә шундый көчле була Әлиф.

«Инде дә теленнән төшермәде. Син килеп җитсәң, терелер кебек сизде үзен, — диде авыл халкы, кан елап. — Бу кадәр дә үкенечле булыр икән. Әйттек, күтәрмә, бушатып чыгарабыз, дидек, тыңламады», — диделәр.

Шулай итеп, табигатьнең иң матур чагында, хисләренең үтә кайнар вакытында яраткан кешесен югалтты Сәнифә. Беренче мәхәббәтен югалтты. Югалтты дип әйтү генә җиңел... Бу якларда яшәү аның өчен искиткеч газаплы минутларга әйләнде. Каядыр чыгып китәсе, туктаусыз барасы да барасы килә башлады. Озын юл үткән саен, хәсрәте коела барыр, гәүдәсе җиңеләер сыман тоелды. Шуңа күрә, җанына урын тапмаганга күрә туктаусыз йөрде. Эшләгән районыннан күчеп, үз якларына кайтып урнашты.

Анда да үз-үзенә урын тапмады. Һич кенә дә бер җирдә тора алмаска әйләнде. Кайдадыр, җиде диңгез артында Әлиф йөридер сыман тоела иде аңа. Күңеле белән һаман нindидер могҗиза, аңа гына хас әкият көтте. Бала-чага кебек, әллә ниләр уйлап таба һәм шуларның тормышка ашуын көтеп йөри башлый. Күңеле һаман ераккa ашкына. Барган чакта ашыгып, дәртләнеп бара да, соңгы ноктага килеп җиткәч, күңеленә яман да авыр булып китә. Үзен дөньяда нindидер кирәксез кеше итеп тоя башлый... Шулай итеп, мәрхәмәтсез язмышы белән килешкәнче, булган хәлләрнең әкият тә, төш тә түгеллегенә тәмам ышанганчы, дистә еллар үтеп китте. Җир йөзендә бер тамчы су кебек бер-берсенә охшаган кешеләр була, диләр. Юк икән дип нәтиҗә ясаганда гына... Заһидуллага тап булды.

Табигать барысын да тигезләп тора, ахры. Шартлап сынмас өчен, Сәнифәгә Заһидулланы табып бирде дә... балык тотарга барган җирдән, йөрәк чиреннән, энесе Зөфәрнең күзләрен йомдырды. Кайгыдан айнып, күзләреннән яшьләре дә кибеп бетмәгән бер көндә киленнәре Рәмзия кияүгә чыкты. Өч баласын балалар йортына илтеп бирде. Ана кешенең бу кыланмышын бернинди кысага да сыйдыра алмый йөргән Сәнифә барып үз сүзен әйтмәкче булган иде дә, әнисе аркылы төште. «Зиһене чуалган

аның, кызым. Юкса алай эшләмәс иде», — диде. Чынлап та, зиһене нык чуалган булгандыр бичараның. Яшь ире белән язылышып алты ай ярым гына торып калдылар. Үлде Рәмзия. Хастаханәгә илткәч, бик озак җан бирә алмый тилмергән, диделәр аны. «Инде дә агу гына каптырыгызсана...» ,«Йөрәк турысына пычак белән генә кадыймчы...» — дип газапланган. Каенаналарыңа, балаларыңа әйтик, дигәч: «Кызларымны чакырмагыз, исләрендә тере булып калыйм. Ә улым белән әнкәйләргә күзем йомылгач хәбәр итәрсез. Оят чынлап та үлемнән көчле икән, күзләреннән куркам», — дип әйтеп әйткән ди. Шулай итеп сишәмбе көнне көн буе, төн буе үлем белән тартышканнан соң, чәршәмбе иртәсендә, җиргә төшеп җиткәнче төкерек ката торган суык көндә дөнья куйган. Бәрелүдән, тапталудандадыр, билгеле, бөтен тәне, йөзе кара күмер кебек көеп, каралып дөньядан киткән.

* * *

Дәү әниләре Алсу ярата торган «Кырмыска оясы»н пешереп көткән иде аларны. Кайтып керүгә, кулларын юып чәйгә утырдылар. Оныкларының дөм ятим калуларына көенде, кызының өчесен дә үз янына алуына сөенде әби кеше. Күңеленнән Сәнифәсенә рәхмәт укыды, исәнлек теләде.

— Бирмибез дип йөдәттеләрме әллә, бик озак тордың? — диде ул, кызы артыннан кухняга чыгып.

— Тере җаннар бит, әни. Директорлары балаларны чакырып, башта берәм-берәм үзләре белән сөйләште. Тәрбиячеләр белән киңәште. Ризалыкларын биргәннән соң гына, өч баланың да документ эшен тәртипкә китереп озатты.

— Шулай, һәр эшнең үз тәртибе, — диде Хупҗамал әби. Шатлыктан бер кухняга чыкты, бер балалар янына керде.

— Ашагыз әле, гел хөкүмәт ашы туйдыргандыр, — дип кыстады.

— Әбием, шушы «Кырмыска оясы»н пешерергә өйрәтерсең әле, — диде Алсу.

— Өйрәтермен, — диде әбиләре. Тезелешеп чәй эчеп утырган оныкларының күзләре сагышлы да, шатлыклы да булып күренде аңа.

— Минем дә өйрәнәсем килә, — дип сузды Наилә.

— Соң, аның бер авырлыгы да юк. Камырын иттурагычтан чыгарып печенье пешерә беләсез бит. Менә шул печеньеларны бик әйбәтләп ваклыйсың да, озак итеп кайнатылган куерган сөт белән болгатасың.

— Аннан?

— Аннан матурлап өеп куясың.

— Кырмыска оясына охшатып, — дип өстәде Айнур. — Иртәгә сез пешергәнен ашыйбыз инде болай булгач.

— Әллә пешермәс дип уйлыйсыңмы? — дип чәчрәде Алсу.

— Тату гына итеп пешкәнен ашагыз башта, — диде аларга әбиләре. — Әтиегезгә охшасагыз, эштән курыкмассыз, боерган булса.

Алсу, нәрсәнедер исенә төшереп, сикереп торды. Кечкенә чемоданын ачып, әллә ничә кат кәгазьгә төреп китап эченә салган открытканы алды. Сервантның пыяла ишеген ачып, уртада торган вазага сөяде. Открыткага ука белән яздырткан сүзләрне тагын бер кат укып чыкты: «Любимой доченьке — от папы! Крым», — диелгән иде анда. Үз чиратында Наилә дә шул ук эшне эшләде. Сәнифә апалары, өйдә авыр тынлык урнашканны күреп, сүзне икенчегә борды. Укулары, кемнәр белән дуслашулары турында сорашты. Һәркайсына эш бүлеп бирде.

— Алсу безнең аш-су остасы, — дип аңлатма бирде Айнур. — Кечкенә чагында ук кара җимеш белән чөгендер салаты ясап әтинең ушын алган иде.

— Нинди салат дисең, улым? — дип кабатлап сорады әбиләре.

— Пешереп угычтан чыгарылган кызыл чөгендергә вак кына итеп туралган кара җимеш һәм чикләвек төше салынган салат. Кырыйларына исә бүрттерелгән, үз төше урынына чикләвек төше тутырылган кара җимеш тезәсең. Өстенә шикәр комы белән каймак саласың, — диде Алсу, Айнур өчен җавап биреп.

— Сиңа эш, — диде Сәнифә апалары, — Айнур абыеңның туган көненә шундый салат әзерләрсең.

— Ә Наилә җылы кофта бәйләр. Ул безнең кул эшенә бик оста, — дип өстәде Айнур. Үзләренең бу өйдә артык кашык булмаячакларын, һәркайсының кул арасына кирәрлек һөнәре барлыгын аңлатасы килә иде, күрәсең, аларның.

— Соң, син үзең нәрсәгә оста? — дип, урынлы гына каптырып алды әбиләре.

— Идән юарга.

— Безне үртәргә, — диделәр кызлар бер-бер артлы.

— Икесе дә егетләр һөнәре, — дип шаяртты әбиләре. — Ярар, балалар, Аллага тапшырдык. Моңарчы безнең өйдә тарткалашып тору булмады. Кем нәрсәгә махир, шуны башкарды. Әмма эштән тыш бер гадәт бар безнең өйдә: зурларны, бер-береңне тыңлау!

Сүз арасында гына әйтелгән кебек булса да, әбиләре әйткән кисәтү һәркайсының күңеленә барып иреште шикелле.

Әнә шулай сөйләшә-сөйләшә тәмләп чәй эчү, бер-беренә карата җылы мөгамәлә күрсәтү белән башланды аларның яңа тормышы. Чәйдән соң тиз генә өстәлне җыеп куйдылар. Айнур коридордагы җәймәләрне селкергә алып чыгып китте. Кызлар идәнен сөртеп алды. Икенче көнне Сәнифә апалары аларны үзләре янындагы мәктәпкә алып керде. Шулай итеп, өч бертуган Иштугановлар әтиләре үлгәннән соң бер ел эчендә өченче мәктәпкә күчтеләр.

* * *

Гаҗәп бит дип уйлады Сәнифә. Кеше җаны да нәкъ табигать кебек. Вакыт-вакыт буран чыга, гарасат куба. Көннәр буе пыскып елак яңгыр сибәли, кинәт кенә кояшлы яңгыр ява, йә булмаса болытлар таралып, чалт аяз көн башлана...

Ул да үзенең шушы балалар өчен яшәргә тиешлеген аңлады. Әнисе әйтмешли, күңеле җитеп алып кайткач, укытып аякка бастырырга кирәк инде ул ятимнәрне. Әмма юлында искиткеч миһербансызлык, тел белән әйтеп аңлата алмаслык явызлыклар торуын белми иде әле ул.

Әшәкелекнең бер төре белән балаларның әти-әниләреннән калган мирасын алырга баргач очрашты. Энесе шунда гомер иткән, әлеге балалар шунда туып, шунда тәпи баскан юкса...

Йортка килеп кергәндә үк кара көеп каршылады аларны «хуҗа» кеше. Сәнифә, балаларга тиешле әйберләрне тавышгаугасыз, судсыз гына бүләргә килүләрен әйткәч, «хуҗа», тагы да ныграк дугаланып килеп:

— Миндә боларның бер әйберсе дә юк. Тиешле киемнәрен аналары балалар йортына илтеп бетерде. Ә бу әйберләрне без хатыным белән бергә тора башлагач алдык, — дип, өй эчендәге өстәл-урындыкларга төртеп күрсәтте.

Сәнифә телсез калды. «Хуҗаның» сары тешләрен ыржайтып мыскыллы елмаюы исә Айнурны бөтенләй чыгырыннан чыгарды.

— Бу шифоньер, бу шкафларны да син алганмы? Бу суыткычны, бу элгечләрне дә син алганмы? Бу караватта — мин, бусында сеңелләрем йоклап үсте. Ә бу диванга — әтиебезнең әле суынмаган да урынына — син үрмәләп менден... — Тешләрен кысып, йодрыгын төйнәп, ялганчы кеше өстенә ташланырга әзер торган малайны Сәнифә чак тыеп калды.

Ул арада Алсу чәчрәп чыкты:

— Әниебезнең алтын алкасын, алтын балдагын бир. Берсе — миңа, берсе Наиләгә тиеш аларның.

— Алкалары түгел, эчәгеләренә хәтле өзелеп беткән иде анагызның, — дип мыгырданды «хуҗа». — Калдык-постык күлмәк-ыштаннарыгызны алыгыз да аттырыгыз моннан.

Сәнифә, бу кеше белән сөйләшеп торуның файдасыз булуын, балаларның йөрәген бозмас өчен тизрәк китәргә кирәклеген аңлап, ишеккә борылды.

— Әниебезнең сандыгы кая? — дип, ишек төбенә килеп җиткәч исенә төшеп кире борылды Алсу. — Әтиебез исән вакытта ук безгә бирнәгә дип җыя башлаган сөлгеләре, ак җәймәләре, чигүле тәрәзә пәрдәләре кая? Кая алар?

— Мин кияү булып килгәндә сезнең өйдә бернинди дә зәңгәр сандык юк иде, — диде Дуга Диас.

— Каракның үзеннән сорама, сүзеннән сора, — диде Сәнифә. — Сандыкның төсен үзең үк әйтеп торасың.

«Хуҗа» бер мәлгә югалып калгандай тоелды. Әмма котсыз күзләре белән нәрсәдер эзли башлады. Сәнифә биредә озак торырга ярамаганлыгын аңлады. — Синең белән бәхәсләшеп тә, сөйләшеп тә торасыбыз килми безнең, — дип, балаларны әйдәкләп, урамга алып чыгып китте.

Кимсетелгәннәр өчен иң иркә назларның берсе — кояш нурларыдыр, мөгаен. Йомшак җил иркәләве дә кушылса — тагы да яхшы. Шул җылылыктан күңеле нечкәрепме, урамга чыгуга сулкылдап елый башлады Наилә. Айнур исә, егет кеше була торып сеңелләрен якларга көче җитмәвенә әрнеп, иреннәрен тешләде.

— Песи балалары сурәте төшерелгән бокалым бар иде, карадым, тапмадым. — Наиләгә кушылып ни чыдам Алсу шыңшырга тотынды. Бирешмәскә теләсә дә, Сәнифәнең дә бугазына төер килеп тыгылды. Иң авыры — кайчандыр гөр килеп әти-әнисе кочагында яшәгән өч сабыйның, кадерле кешеләрен югалту өстенә, үзләре уйнап үскән, әллә никадәр якты хатирәләр саклаган өйдән хурлыклы рәвештә сөрелүе булды.

Бары бергә, югы — уртак дип уйлады Сәнифә, буш кул белән урамда басып калган сабыйларны кочагына алып. Минем хезмәт хакы янына әз булса да әнинең пенсиясе, сезнеке бар. Энәдән-җептән киендерә алмасам да, ач итмәм...

Ул да булмады, күз яшьләренә коенып, укмашып торган балаларны күреп, күрше-күлән җыйнала башлады.

— Куып ук чыгардымы әллә, Ходаем?

— Бу кадәрле дә комсыз алабай булыр икән! Хатыны үлеп ята, бу төне буе әйбер ташый.Ниләр ташыды, кая ташыды, белгән юк. Ә сез китмәгез. Үзегез туып үскән йорт, аяк терәп торыгыз!

— Киленегезне әйтәм, — дип сүзгә кушылды ап-ак чәчле әби. — Иллә ялгышты, иллә ялгышты да соң. Балаларын бераз аякка бастырмыйча нигә кирәк иде аңа ир? Үлем исереге белән шулай миңгерәп йөргәндер, мөгаен...

— Чаңгы шуарга баргач тавышланышканнар да, машина астына да шул комсызы төртеп төшергән, ди бит.

— Акылың булса, хатын аерган иргә якын барма инде син...

— Рәхәт күрмәс, сабыйлар яше ерак илтмәс...

Киңәш-тәкъдимнәр, янау-сүгүләр күбрәккә китә башлады. Кайсы ятимнәрне кызганып елады, кайсы Дуга Диасны каргады. Кайсы ата малын суд белән бүлеп алырга киңәш итте. Сәнифә ул сүзләрне ишетер хәлдә түгел иде. Аның миен бары бер генә сорау бораулады: ничек итеп шундый кешене сайлаган бу Рәмзия? Беренче ире белән монысы арасында җир белән күк аермасы лабаса...

Балалар алдында җебеп төшмәс өчен эндәшмичә кайтты ул. Аның янының башларын салындырып, кыр казлары кебек тезелеп атлаган дөм ятим калган туганнарына карап: шушы яшьтән кеше күңелендәге явызлыкны күрделәр. Йөрәкне ташка әйләндерерлек хурлыклы минутлар кичерделәр бит, газизләрем, дип өзгәләнде. Әмма гаделлек җиңәргә тиеш, дип юатты ул үзен. Кайтып, балаларны тынычландырып йокларга яткыргач, ата мирасыннан балаларга өлеш чыгаруны үтенеп, судка гариза язды.

Бер каршы килсә, гел каршы килеп тора, диләр бит. Суд вакытында икенче әшәкелек — кеше дигән затның тел белән әйтеп каләм белән язып бетерә алмаслык башка төр усаллыгы белән очрашты.

— Мин ул йорт җиһазларын, шкафны, суыткычны да хатыным белән бергә тора башлагач алдым, — дип, үз сүзендә торды Дуга Диас.

Судны туктатып, өйгә комиссия җибәрергә булдылар. Әлеге кеше какшый башлаган урындыкларга кадәр яңа «печать» сугып чыккан иде. Суд «документ»ка ышанды. Үзен-үзе тыя алмыйча, хулиган дип әйтеп җибәргән Сәнифәгә йодрыгын күтәреп килә башлаган ирне судья туктатты.

— Минме хулиган? Таптырырмын мин сиңа хулиган! Эш урыныннан бирелгән характеристикамны кычкырып укуыгызны үтенәм! Син андыйны төшеңдә дә күрмисең, — диде ул, сары тешләрен шыгырдатып.

Характеристика буенча сүз йөрткәндә, чынлап та, дөньяда моннан да яхшы кеше юк икән дип нәтиҗә ясарга мөмкин булыр иде. Сәнифә аптыравыннан, гаҗәпләнүеннән көчсезләнде. Югалып калды. Күптән инде андый суыткычлар чыгарылмавы, барлык мебельләрнең дә бу кешегә кадәр алынуы, соңгы вакытта өйгә бернинди дә ремонт ясалмавы турында аңлатырга тырышып карады. Әмма алларында бер кочак кәгазь өеме булган судьялар Сәнифәнең йөрәгеннән әрнеп чыккан сүзләренә таяна алмадылар. Сүзләрнең ул кадәресе кәгазьгә язылмаган, бернинди мөһер һәм имза белән дә расланмаган иде. Шулай итеп, дөм ятим калган өч бала хакын — әлеге комсыз ирнең хәләл көче белән булдырылган әйберләр дип раслады суд.

— Кызым, йөрмә, — диде аңа сиксәнне узган әнисе, — йөрәгең генә бозыла. Әшәке кешене җиңеп булмый аны.

Шулай дисә дә, бу эшкә үзе дә нык итеп хәйран калган иде ана кеше. Тик нишләмәк кирәк? Алга таба көрәшүнең файдасыз булуын аңларга кирәк иде. Шуңа күрә сүзне икенчегә борырга тырышты.

— Сәхия тутаң китергән сарык йоны бар бит әле. Шуларны җегерләп һәркайсыгызга оекбаш, бияләй бәйләсәм, ничек булыр, кызым?

— Минем оекбашларым бар, әни, балаларга бәйләрсең, — диде Сәнифә, битараф кына.

Хупҗамал әби кызының күңеле өйдә түгел, әллә кайда, башка җирдә булуын аңлады. «Мондый чагында кешене сөйләштереп торырга, күңелен газаплы уйларга бирмәскә кирәк», — дип уйлады ул... Һәм:

— Дача турысындагы койма аръягына күп кенә итеп бәрәңге утыртыйк әле быел, кызым. Энең дә бераз булышкалап торса, яшәрбез, боерган булса. Бер дә кайгырасы юк, — дип, кызына кырын күз белән карап ала-ала, үз планнарын тезеп китте.

Сәнифә күңеле тулудан елап җибәрмәс өчен иреннәрен тешләде. Әнисенең шушы яшьтә дә сәламәт акыллы булуына, барысын уйлап, барысы өчен борчылып торуына сөенде. Сәнифәнең әтисе ягы туганнары белән гомере буе тату яшәвенә сокланды.

— Музейларга куеп, татар карчыкларының өлге-үрнәге итеп күрсәтерлек кеше бит син, әнием! — диде ул, аның ак чәчләреннән сыйпап. — Яшибез, билгеле. Һәркайсыбызның кулы эш белә. Белмәгәннәрен бергә өйрәнербез. Тик менә Диасның директорына барып, чыраен карап кайтасым килә. Шундый характеристиканы үз куллары белән язды микән ул? Әллә, кайбер җитәкчеләр кебек, үзенә яздырып укымыйча гына кул куеп җибәрде микән? — диде Сәнифә, гаҗәпләнүен яшерә алмыйча.

Әнисе Сәнифәдә ирләр ныклыгы булуын, уйлаган уеннан бервакытта да кире кайтмавын яхшы белә. Шуңа күрә туктатырга исәпләмәде ул аны. Бары тик: «Кеше белән сүзгә килмә, тәмсезләнмә, кызым. Дөрес эшләмәсә, үзенең дә жаны тыныч булмас», — дип озатып калды.

Юлда ни өчендер Б.Горбатовның «Бер төн» әсәрен искә төшереп барды ул. Татарстанның атказанган артисты Ирек Баһманов уйнаган Новожилов ролен. Кибет мөдире Новожилов кеше бәхетсезлегеннән файдаланып әйбер талый. Комсызлыгы канына сеңгән шул кешене балаларның үги атасына тиңләп барды. Ни җитми икән кешегә? Кемнәрнеңдер өлешенә керә-керә кассага акча җыялар. Куанычсыз акча. Моңа кадәре дә төрмәдә утырып чыккан кеше икәнен белә торгандыр бит инде җитәкчесе. Ничек караны ак дип яза алды икән? Әллә соң теге анекдоттагы:

— Минем сезнең яхшылыкка яхшылык эшләрлек мөмкинлегем юк. Булмаса бер-бер дошманыңны кыйнап бирим дигән хулиган кебек астыртын эшләре бармы?

Хулиган, дип кабатлады ул эченнән, «Хулиган» сүзенең элек Англиядә яшәгән башкисәр бер кешенең фамилиясе булуын исенә төшереп.

Өстәл артыннан башы гына күренеп торган, муены тәмам җилкәсенә сеңеп беткән кеше янына чират торып кергәч, үзенең кемлеген, ни өчен килүен бәян итте Сәнифә. Директор исә туры сүзле булып чыкты. Аты-юлы белән:

— Минем сезнең белән бала чукындырасым юк, ә менә Диас Дуглимович белән эшлисем бар. Башын төрмәгә тыксам, алтын кулларын үзем белән калдыра алмыйм мин аның. Минем бүтән андый оста куллы белгечем юк, — диде.

— Димәк, сез, аның кем икәнен белә торып, ялган характеристика язгансыз, ялган документлар тутырырга булышкансыз?

— Файда китерә торган ялган гөнаһка керми, — дип кеткелдәде ир.

— Мин бу турыда тиешле органнарга җиткерүне үземнең бурычым дип саныйм, — диде Сәнифә.

— Һем, ә анда мин әйткән сүзләрнең хаклыгын кем раслый булып чыга инде? Менә бу таш стеналармы?

Сәнифә тагы мыскыллы караш белән очрашты. Нинди икейөзлелек? Нинди түбәнлек? Нинди оятсызлык?! Бары тик:

— Ничек итеп кеше хакыннан, сабыйлар хакыннан курыкмыйсыз соң сез? — дип кенә әйтә алды.

— Мал өмет итеп аларны урыныннан кузгатмаска иде, тәти кыз. Мин сезгә ул балаларны торган җирләренә кире илтеп тапшырырга киңәш итәм. Хәер, сез аларны мин әйтмичә дә илтеп ыргытачаксыз. Әлегә «бала» исеме белән әйберләрен алырга кирәк сезгә. Бары шул, — диде ул тагын да мәсхәрәлерәк көлеп.

Сәнифә сынды. Бары тик бераздан гына, әзме-күпме ушын җыеп:

— Сез — начар җитәкче. Чөнки сез үзегез начарлык ягына үрнәк күрсәтәсез, яшәү кануннарын бозасыз. Кул астындагы кешеләрегезне бер-берсенә әшәкелек эшләргә, бер-берсен таларга, мыскыл итәргә өйрәтәсез! — дия алды. Аннан: — Әгәр минем асрамага алып кайткан берәр балам кайчан да булса гаделсезлек эшләп суд каршына баса икән, анда сезнең дә өлешегез булачак. Сез начар җитәкче генә түгел, сез безнең җәмгыять өчен куркыныч кеше, — диде һәм өстәл артына сеңә барган башка тагы бер карап алды да бүлмәдән чыгып, икенче каттан аска йөгерде.

Урамда күкрәген кысып торган ниндидер кыршауны өзәргә тырышып еш-еш сулады. Сукмак янына утыртылган яшь наратка сөялеп бераз тын торды. Кинәт аяк буыннарының хәле китеп, җиргә чүгәсе килде. Күзе белән тирә-юньне күзәтте. Якын-тирәдә бер генә утыргыч та юк иде. Маңгаена, кулларына салкын тир бәреп чыкты. Кендегеннән чак кына астарак нәрсәдер дөрләп яна башлады. Башы әйләнеп куйды... Юк, юк, бирешмәскә кирәк. Ни дип җебеп төштем соң әле?.. Нарат агачы кочагыннан чыгып, әкрен генә өйләренә таба атлады.

* * *

Сәнифә кайтып кергәндә, өйгә тәмле ис таралган, балалар мәктәптән кайтып өсләрен алыштырган, йөгерә-йөгерә өстәл әзерлиләр иде. Әнисе Сәнифәнең йөзенә күтәрелеп карауга ук эшнең уңышсыз тәмамлануын сизсә дә, оныклары алдында сүз кузгатасы килмәде. Ләкин уйнак колын кебек сикергәләп, ишек төбенә килеп җиткән Алсу:

— Алма апам, син әллә курыктыңмы? Кулың калтырый, — дип әйтеп салды.

Сәнифә шунда гына алып куярга дип сузган сумкасының селкенеп торуын күрде.

— Сезнең янга чәйгә өлгерергә дип ашыктым. Баскычтан йөгереп мендем, шуңа бераз гына тыным кысылды, — дип җаваплады. Һәм тиз генә салкын су белән юынып, өстәл янына утырды.

Алсу инде Алма апасының куркуы турында онытып та өлгергән. Көлә-көлә үзләренең классларындагы Әнвәр турында сөйли иде.

— Казан эмблемасын ясап килгән. Матур. Кем дә кем бөтен башваткычларны да чишеп җиңүче була — эмблема итеп эшләнгән Сөембикә манарасы шуңа, ди. Аның башваткычларын беркем чишә

алмый. Кичә бөтен классны аптыратты. Аннан соң: «Өй эше булыр. Иртәгә җавабын табып килегез», — дип, өйгә биреп җибәрде.

— Әйдә берәрсен безгә дә әйтеп кара, — дип, күзләрен очкынландырды Айнур. — Без чишә алмаган нинди башваткыч бар икән бу дөньяда?

— Бик теләгәч, тыңла алайса, — диде Алсу. — Димәк, домино уйныйсың. Иптәшең бер доминоны ала да читкә китә. Калган егерме җидесеннән чылбыр төзергә куша. Сез эшкә керешәсез. Иптәшегезнең нинди домино алуына карамастан, тоташ чылбыр төзисез. Шуннан соң иптәшегез, сезнең чылбырга күз дә салмыйча, баш-башларында нинди очколар икәнен әйтә. Моны ул ничек белә?

— Уйларга кирәк, — ди Айнур, көттереп кенә. — Хәзер эшләп карыйбыз аны. Каяле безнең домино?

— Башта ашыйк, аннары иркенләп чишәрсез, — ди әбиләре.

— Алайса, табын әзерләгәндә дә чишеп була торганын әйтәм мин сезгә, — дип челтери Алсу.

— Әйдә, әйдә, — дип тәкатьсезләнә Айнур.

— Кеше башында уртача йөз илле мең чәч бар дип исәпләнә. Әгәр ай саен шуның өч меңе коелса, баштагы чәчләрнең гомерен ничек исәпләп чыгарырга мөмкин?

— Пүчтәк бу, — ди Айнур, күңелдән исәпли үк башлап. — Бер ай эчендә өч мең коелгач, унике айда утыз алты меңе юк була. Шуннан йөз илле меңне утыз алты меңгә бүләбез. Төгәл бүленми. Димәк, һәр чәч дүрт елдан бераз гына артыграк яши.

— Дүрт ел да биш көн, — дип төгәллек кертә әбиләре.

— Алай бик кызып киткәч, инде мин дә берне әйтим, — ди Сәнифә апалары. — Мисал өчен, мин сезгә кавын алып кайтырга куштым ди. Каршыгызда берсенең әйләнәсе 60, икенчесенеке 50 сантиметр чамасындагы ике кавын тора. Әмма беренчесе икенчесеннән бер ярым тапкырга кыйммәтрәк. Кавыннарның кайсын алу уңышлы?

— Минемчә, кечкенәсен, — ди Наилә. — Чөнки ун сантиметр өчен никадәр акча артык түләргә кирәк.

— Ә минемчә, зурысын алу файдалы. Бу очракта кавынның ашарга яраклы өлеше тышкы озынлыгы буенча түгел, радиусы белән исәпләнә, — ди Айнур.

— Дөрес, — ди Сәнифә апалары. — Андый очракта сез кавынның да, карбызның да зуррагын алсагыз — отасыз.

Сәнифә апалары үзе дә балалар кебек мавыгып, табын турында да онытып, балаларның араларына кереп утыра.

— Үлчәү берәмлекләре турында сүз чыккач, тагы бер сер ачыйм әле үзегезгә.

— Әйтик, кулыгызда метр да, сантиметр да, гомумән, бер нәрсә дә булмаганда, әйбернең озынлыгын ничек үлчәр идегез?

— Адым белән.

— Әгәр ул әйбер сезнең адымнан кыскарак булса?

— Шырпы кабы белән.

— Ә мин яныгызда бернинди әйбер дә булмаганда дип әйттем. — Апалары, шук кына елмаеп, аптырашта калган балаларга карый.

Әбиләре, тамак кырып, Алсуга үзенең карышын җәеп күрсәтә.

— Ә карышның ничә сантиметр икәнен каян беләбез? — ди Алсу, бөтен бүлмәне яңгыратып.

— Менә шуңа күрә һәркем үз карышының ничә сантиметр икәнен белергә тиеш, — ди Сәнифә апалары, укытучы Сәүбән абыйлары өйрәткән һөнәрне искә төшереп. Укучыларың теләсә нинди уен вакытында файдалы мәгълүмат алсын, ди торган иде аларга Сәүбән абыйлары. Мөмкин булганда хәрәкәтле уеннар белән әвертегез. Хәрәкәттә — бәрәкәт булуын онытмагыз, дип тәкрарлый иде. Аннары кызларны бер почмакка җыеп алыр иде дә, ярым пышылдап: «Хуҗагыз, ягъни мәсәлән, җитәкчегез хатын-кыз булса, ул бар җирдә аны уздырып киенмәгез. Укытуыгыз менә дигән булса да, өстен чыгармас», — дияр иде дә безнең белән бергә күтәрелеп көләр иде. Һәм: «Сәүбән абыегыз күпне күргән, шуңа күрә күп белә ул», — дип өстәп куяр иде... — ди.

Студент елларына кайтса, үзәкләре өзелеп, күңелендәге әллә кайсы кыллары сулкылдап сызлый башлый Сәнифәнең. Училищеда бергә укыган сабакташлары альбомын алып утыра да дуслары белән озаклап күзгә-күз карашып тора. Утыз ике кешенең җидесе мәрхүм дә булган бит инде, и бу гомер, дип куя. Кызык вакыйгалар исенә төшеп, көлеп тә җибәрә.

Бервакытны солдатлар белән хат язышу гадәткә кереп китте алар классында. Исем-фамилияне дә белмәстән, класс журналындагы фәләненче номерлы кызга диләр, дә хат язып җибәрәләр бит болар. Почта, гадәттә, икенче дәрестән соң килә. Хатны китереп кулга тапшыруга, дәрес башлана. Ничек итеп тагы кырык биш минут көтеп торасың? Ачып укый башлыйлар һәм әйдә шунда ук җавап язарга. Берсе бер абзац, икенчесе тагы бер абзац яза. Ә Альбина исемлебез, солдатлардан килгән хатларны тигезләп кисеп, зур осталык белән муенса ясый. Шулай итеп, дәрес беткәнче җавап хаты белән муенса конвертка салып бикләнгән, җибәрү өчен адрес язылган була. Тик укытучы да аларның нindидер этлек

белән шөгыльләнүен сизеп ала. «Бу гореф-гадәтегез белән ерак бара алмассыз, Кишербанулар. Менә бу аслы-өсле ноталарның ничек әйтелүен күңелегезгә киертеп куймасагыз, мин сезне кайда кунакка җибәрергә белермен», — ди каерылып торган чәнти бармагын өскә күтәреп. Һәм бик мәзәк итеп, күзләрен яшьләндереп көлә.

Үз-үзен тоту әдәбе бик тә сәер бу кешене нигә монда эшкә алдылар икән дип йөргәндә, Яңа ел кичендә, аның төрле уен коралларында өздереп уйнавын күреп, хәйран калды укучылар. Шактый музыкантлар, хәтта композиторлар белән аралашып, бүгенгә кадәр андый итеп уйнаган кешене очратмады Сәнифә. Бармакларына кушылып, кеше күзенә күренә торган һәрбер күзәнәге уйный иде аның: күзе, кашы, йөзе, маңгаендагы һәрбер җыерчыгы. Һәр хәрәкәте көйнең эчтәлеген ачып: көлеп, елмаеп, газапланып яки елап тора иде. Шуның кадәр бирелеп, шуның кадәр мавыгып уйный... Аның өзгәләнүенә карап, шул бер минут вакыт эчендә укытучысының үзе белгән кадәр гомерен күз алдына китерә иде Сәнифә: томрап торган ир бала, көләч йөзле хатын, нык бәдәнле ир. Машинада каядыр баралар. Бармыйлар, тигез асфальт юлдан очалар. Һәм кинәт... фаҗига. Улы белән хатыны шунда ук үлә, ә руль артындагы ирне авыр хәлдә хастаханәгә озаталар. Ул терелә. Тик бер аягы, уң кулының чәнти бармагы гарипләнеп, зиһене чуалып кала. Гармун уйнаганда әнә шул газапларын бәгыреннән йолкып-йолкып чыгара музыка укытучысы. Һәм төсле, тере фотокадрлар итеп, тамашачыларга ыргыта. Мәгез, карагыз. Мине гаепләгәнче, ниләр күргәнемне белегез... Ул, җан ачысы белән кычкырып җибәрмәс өчен, елмайган булып кылана. Яшь элпәсе каплаган күзен еракка, әллә кая теки... Йөрәгенең парә-парә телгәләнүен үтәли күреп торган бик күп тамашачы мышкылдап елый башлый. Гармунчы шунда гына айнып китә. Сискәнеп кешеләргә карый: «Юк, мин сезгә начарлык теләмим. Сезгә мин күргәнне күрергә язмасын. Башыгыз да, уйларыгыз да яньчелмәсен. Борчуым өчен гафу итегез...» — ди.

Кайвакытта, өстәмә дәресләр үткәргәндә берничә укучы белән генә аулакта калганда, беркатлыланып, тәмам ачылып китә музыка укытучысы. Сөйрәбрәк атлаган аягын икенчесе белән ышкып-ышкып утыра да:

— Сезнең менә мунчадан гөмбәчек дигән авыру ияртеп кайтканыгыз бармы? — дип сорый. — Бармак араларыгызны ләззәтләнеп, ачуланып, тешегезне кысып, канатканчы кашыганыгыз бармы? Аннан ничек әрнетә, ә? Сез алай итмәгез. Җилем башмаклар сатып алыгыз. Йоктырмагыз ул әшәке чирне, — ди...

Бик сагынып искә ала Сәнифә училище елларын. Андагы олы җанлы, чын мәгънәсендә кешелекле укытучыларны сагына. Әйтик, Мөхәммәт абыйларын. Татар теле һәм әдәбиятыннан укыта иде, мәрхүм. Дөньядагы бер генә нәрсәгә дә битараф калмавы, «Казан утлары» журналы белән хат аша даими сөйләшеп торуы сокландыра иде Сәнифәне. Язуың матур, дип, күп хатларын аңа күчертә иде. Аннан имзасын куеп редакциягә җибәрә. Җавап килгәч, берәрсеннән кычкырып укыта. Мөхәммәт абый укыткан елларда байтак укучы әдәбиятка гашыйк булып, язу-сызу эшләре белән шөгыльләнә башлаган иде. Тора-бара кайсы журналист, кайсы язучы булып китте аларның.

Класс җитәкчесе Сара Әминовнаны, искиткеч йомшак табигатьле, ирле-хатынлы Сания Гомәровна һәм Ясәви Хадиевичларны, һәр җөмләне тәмләп, тәфсилләп аңлата торган Хәния һәм Рифкать Вәлиевләрне; бөтен бер училищены нәни генә йодрыгына сыйдырып тота алган, таләпчән һәм акыллы Нурбисал Ибраһимовнаны; һәр егеттән биюче ясап чыгаручы Васил Хадиевичны — һәммәсен дә хәтерли Сәнифә. Шундый кешеләрдән белем алуына тора-тора шатлана. Әнисенең тәвәккәллегенә, баласы язмышы өчен вакытында кайгырта белүенә рәхмәт укый. Инде хәзер үзе җай чыккан саен Наилә белән Алсуда педагог хезмәтенә мәхәббәт тәрбияләргә тырыша. Айнурны ни өчендер хәрби кеше итеп күз алдына китерә. Бу турыда исенә төшкәч үк, Сәнифәнең күңелен бер уй җылытып үтә. Заһидулла хәрби училищеда укыта бит. Ярдәм итми калмас, шәт.

Теге юлы яннарына Сәнифә барып төшкәч, мәгәр шатланган да иде Заһидулла. Ике көнне ике театрга билет алып куйган, шәһәрнең истәлекле урыннарын күрсәтергә планлаштырган. Ә инде шактый зур кыз булып үсеп килгән Язгөлеме, әни назын эзләптерме, һаман Сәнифәгә сырпаланды. Сәнифә белән бөтен шатлыгын уртаклашты. Бүләк күлмәклекләрен күрсәтте. Сәнифә дә бер утыруда ике күлмәк тегеп бирде үзенә. Һәм бу өлгерлеге, осталыгы белән баланың гына түгел, әтисенең дә, әбисенең дә ихтирамын яулады. Көннәре санаулы иде Сәнифәнең. Берничә кибеткә кереп, дусларының үтенечен үтәде дә килгәненең дүртенче көнендә кайтып та китте. Киткәндә:

— Үзегезне көтәбез, — диде ул Заһидулланың колагына.

— Быелга булмый. Җәренгә, сабан туена җыенам, — диде Заһидулла. — Минем бит сез торган шәһәрдә бертуган апам яши. Баргач таныштырып кайтырмын әле. Хәзер үк белгертсәм тынгы бирмәс, бик йөремсәк ул, — дип елмайды.

— Ә без кунак килгәнне яратабыз, — диде Сәнифә дә, көлеп.

— Кунакның төрлесе була аның, Сәнифәкәй, — дип куйды Заһидулла.

Кабаттан ул турыда сүз кузгатучы кеше булмады.

Бер елга якын вакыт эчендә Сәнифә генә түгел, балалар да күнегеп беткән иде Заһидулланың хатларына. Һәрвакыт яшел кара белән язган матур, пөхтә почеркына, назлы сүзләренә. Ә беркөнне?!

Сабан туйлары якынлашкан язгы бер иртәдә, диванга җәйлап утырып, Алсу кертеп биргән хатны ачты Сәнифә. Хатны кулга алуга, күңеленең әллә кайсы төшләре кытыкланып, укырга җыенды. Даими килеп торучы хатларга шуның кадәр ияләшкән, шуның кадәр көтеп ала, Заһидулланы да, кызы Язгөлемне дә, әнисен дә күңеленнән бик якын тоеп яши башлаган иде. Тик бу хат бөтен дөньясын астын өскә китерде аның. Ышанып, күңелен тәмам беркетеп өлгергән, үзенчә бик акыллы дип исәпләгән ирнең кинәт кенә Сәнифәгә яла ягуы башка сыймаслык хәл булды.

«Мине тормышта күп алдадылар. Әмма өч баласы булган хатынның «кияүдә булмадым» дип ышандырырга теләгәне юк иде. Ялганчыларны кичерә алмыйм, гафу ит...» — дип, берничә генә җөмлә язган иде Заһидулла.

Сәнифә ни уйларга да белмичә аптырап калды. Шунда ул беренче тапкыр балаларның бик тә алар ягына охшаганлыкларына игътибар итте. Шунда ук, күптән түгел бакчага йөрергә чыккач, бер хатынның килеп, мишәрчәләп сөйләшеп торуын, барысы да үзеңнекеме, наным, дип соравын исенә төшерде.

— Барысы да үземнеке. Барысы да үз сөягем, — дигән иде аңа Сәнифә, шаяртып.

— Шулайдыр шул, бик охшаганнар бит, — диде аңа хатын. Һәм ашыгып китеп тә барды.

Апасы булмады микән? Димәк, түзмәгән, адресны биргән. Апасының гадәтләрен өнәп бетермәсә дә, сүзләренә ышанган. Кеше сүзе кеше үтерә, диләр, хак икән. Бәлки, аңлатып җавап язаргадыр?.. Файдасыз булачак. Мине йөрәгеннән мәңгегә алып ыргыткан инде бу. Сәнифә дә «җирләде» Заһидулланы. Күңелендә «җирләде»... Шул көнне... киндек астыннан икенче мәртәбә нидер көйрәп яна башлады. Маңгаена тагын салкын тир бәреп чыкты. Секунд эчендә шыкырдап ирене кипте, хәле китте.

— Су бирегез әле миңа, — диде ул, бөтен хәленә кычкырып әйтергә тырышып.

Оныкларының оекбашларын ямап янында гына утырган Хупҗамал әби, сискәнеп, кулындагы әйберен төшереп җибәрде.

Ни гомер бергә яшәп, болай күргәне юк иде аның Сәнифәне. Эчендә бер-бер чире бармы әллә? Әллә зиһененә зыян килгәнме дип уйлады. Һәм, гаҗәпсенеп:

— Нәрсә булды, кызым? — дип сорады.

— Хәзер уза ул, — диде Сәнифә, әнисенең каушавын күреп. — Су гына бирегез.

Су эчкәч, маңгаена салкын чүпрәк куйгач, Сәнифәнең хәле, чынлап та, бераз җиңеләйде. Алсу белән Наилә дә әбиләренең йөгергәнен күреп, Алма апаларының баш очына менеп утырдылар.

— Апа, Заһидулла абый берәр кайгылы хәбәр язганмы әллә? Әнисе үлмәгәндер ич? — дип сорады Алсу.

— Әйе, үлгән, — диде аларга апалары. — Заһидулла абыегыз үзе үлгән.

Наилә, «үлгән» сүзен ишетүгә үк, диван башына капланып елап җибәрде. Ә Алсуы тал куышыннан очып чыккан коштай сикереп торды да, идәнгә төшкән конвертны алып: — Хатны бит үзе язган. Үлгәч ничек үзе язалсын ди инде? — дип чәчрәде.

— Минем өчен үлде, — диде Сәнифә, «минем» сүзенә басым ясап.

Наилә мендәрдән башын күтәрде. Кызлар бер-берсенә карашып җилкәләрен җыердылар. Тере кешенең ничек итеп бер Сәнифә апалары өчен генә үләргә тиешлеген аңламадылар. Шул ук вакытта артык сорау белән авыру апаларын да борчыйсылары килмәде. Соңыннан исә бөтенләй оныттылар.

Әнисе никадәр генә тыкырдатса да, Сәнифә хастаханәгә бармады. Шушы яшенә җитеп бер генә көн дә авырып ял алганы юк иде аның. Әмма соңгы вакытта ниндидер сәер хәл бетү җәфалый башлады үзен. Спорт белән шөгыльләнергә дигән карарга килде ул. Училищеда укыганда чаңгы буенча район беренчелеген тота иде бит. Ә хәзер? Үзен-үзе бик шәлләп тиргәгәннән соң, бер көн дә калмый су коенырга, бер көн дә калмый физзарядка ясарга, кыш айларында бер көн дә калмый чаңгыда йөрергә дигән катгый карарга килде һәм сүзендә торды. Аңа гына ихтыяр көче җитәрлек иде Сәнифәнең. Кайчагында башына «Заһидуллага әллә хат язып карыйммы?» дигән фикер килсә дә, кире уйлады. Димәк, баштa ук ышанмаган булган. Шундый матур итеп бөтен серләрне уртага салып серләшкәннән соң, матур хыяллар, планнар корганнан соң — ачыкламый-нитми генә ничек итеп кырт кисәргә мөмкин? Кеше сүзе белән шулай тиз хөкем чыгара икән, димәк, үзе дә ышанычлы кеше түгел дип уйлады Сәнифә. Һәм бу мәсьәләгә кабат әйләнеп кайтмаска тырышты. Ләкин нәкъ шул көннәрдә Айнур үзенең хәрби училищега китәчәген төгәл хәл итүен, күрше егете Шакир белән бергә барырга җыенуларын, әзерләнә башлау өчен Заһидулла абыйларыннан программа сорарга кирәклеген үтенде. Ир бала шул инде. Заһидулладан күптәннән хат юклыгын да, ул кайтырга тиешле сабан туйларының үтеп китүен дә игътибарга алмаган булып чыкты.

— Мин сезнең гадел яшәвегезне телим, Айнур. Син дә, Шакир да, меңләгән яшьтәшләрегез кебек, үз көчегез, үз тырышлыгыгыз белән керергә тиешсез укырга. Нәкъ башкалар кебек, программаны да үзегез сорарга тиешсез. Әзерләнергә, беркемнең дә ярдәмен өмет итмәскә кирәк. Менә шуннан соң,

бөтен эшләрегезне бетереп курсант булып урнашкач, Заһидулла абыегызны эзләп тапсагыз да ярый. Шул вакытта сезгә дә, безгә дә күңелле, кеше алдында да йөзебез якты булыр, — диде Сәнифә апалары.

— Апаң бик дөрес әйтә, улым. Сүзегез беттеме? — дип, ак кәгазь, каләм тотып, Хупҗамал әби килеп чыкты.

— Кичә ахирәтемнән хат алдым. Җавап кына языйк, әйтеп торам, — диде ул Сәнифәгә. — Тик торганда күзе сукырайды бит. Аның күзе күргәндә кешегә ялынычыбыз юк иде. Рәхәтләнеп кадимчә языша идек. Юк, хәзер укый алмый, күзләре күрми. Мин кадимчә язсам — балалары аңламый. Азапланабыз да соң кеше кешесе булып...

— Ник, мин авырсынмыйм ич, әни, сиңа хат язып бирергә, — диде Сәнифә.

— Соң юк та, кызым. Барыбер турыдан-туры үзең эшләү түгел бит инде эшне, — диде ул, кәгазен Сәнифәгә сузып.

— Багъбостан Мөэминованы белә идем мин. Теге мәктәп ачып, хатын-кызларны укытып, тегү-чигүгә өйрәтеп йөргән Багъбостанны. 1905 еллар тирәсендә ачкан түгәрәкләренә хатын-кызлар килә башлый моның. Шуннан җидееллык кызлар мәктәбенә әйләнә. Халык Багъбостанның зирәклегенә, зиһенле булуына сокланып, ул ачкан мәктәпләрне «Багъбостан мәктәбе» дип йөри башлый. Күрше Мәндәй авылыннан, дип сөйли иде аны ахирәтем, Минзәлә өязеннән. Шагыйрь Шәехзадә Бабич белән дә таныш булган ул. Менә шуларны ныклап сораштырып калырмын дигән идем, — ди Хупҗамал әби. Аннан тагы сүзен дәвам итеп: — Һай, безнең татар хатыннары арасында нинди генә зыялы кешеләр булмаган?.. Замана авырлыгы белән чәчәктә килеш корыганнар, җаннарым, — ди.

— Корымаганнары да күп ич, әни.

— Алар шул задурланып эшкә җигелгәннәре. Тәвәккәлләре. Ә талант ияләренең барысына да андый көч бирелмәгән. Күбесе нечкә бәгырьле була бит аларның. Дошманы белән беренче тапкыр бәрелешкәндә үк бөгелеп төшә.

— Мин барыбер мескен талантлар яклы түгел, — дип сүз көрәштерә Сәнифә.

— Синең үз холкың мескен түгел. Шуңа өнәмисең син андыйларны. Бала чагында ук бер мәртәбә дә еламадың бит син. Мин энеңне тудырганда кендек әбисе булуыңны хәтерлисеңме соң? Шул чагында әллә миннән, әллә каннан куркып, күз яшьсез генә бер мәртәбә шыңшып алдың алуын.

— Ипи пычагыннан курыктым мин ул вакытта. Бәбинең кендеген кис, дигәч, суярга кушасыңмы әллә дип торам. Ә мин, ул тугач бергә уйныйсым килеп, бик көткән идем бәбине, — диде Сәнифә, елмаеп.

— Тәвәккәллегең, ныклыгың шунда ук билгеле иде, кызым, күз тимәсен үзеңә! Ун яшьтә кемнең кендек әбисе булганын ишеткәнең бар? — дип көлә-көлә яшьләгән исенә төшерә Хупҗамал әби. — Үзем сиңа кендекне ничек кисәргә кирәклеген өйрәтәм, үзем ярты юлда ташлап чыгып йөгермәсә генә ярар иде, дип куркам. Җитмәсә, өйнең салкынлыгына чыдар әмәл юк. Кан агып чыга тора, боз булып ката тора. Тик шунда энеңә дә, үземә дә салкын тигермәдең бит син, кызым. Әйбәтләп төрдең, җылыттың. Мең-мең рәхмәтләр яусын үзеңә! Бу килештән мин бик риза, кызым, синнән. Җылы түреңдә яшәтәсең, йөзең һәрвакыт якты, Аллага шөкер.

— Әтинең кәгазьләрен ягып коймак пешергәнне дә хәтерлим әле мин, әни, — диде Сәнифә. — Ничек итсәм иттем, тәки пешереп бетердем бит тугыган камырны.

— Элекке балалар нык иде инде, кызым, эшләп үскәнгә шулай булгандыр. Син өченче класста сыер сава, ипи сала идең. Басуда хәлем китеп егылгач, мине күрше авыл хастаханәсенә илтеп салдылар. Шунда җиде чакрым ераклыгындагы авылга ике көннең берендә килеп тордың бит. Килгән саен коймак пешереп алып килә идең. Укырга да, өйдәге эшләрне карарга да, суын ташырга да, берсеннән-берсе кечкенә өч туганыңны карарга да җитештең, Алланың рәхмәте! Ана сарылы булдың син үзе. Бәхетең генә... тулы булмады шикелле, — дип тезде Хупҗамал әби.

Хатны язып бетергәннән соң Сәнифә мәктәпкә йөгерде. Киткәндә:

— Балалар кайткач утырып ашагыз, мине көтмәгез. Бүген педсовет безнең, соңрак кайтырмын, — диде.

— Хәерле юл, балам, исән йөре, — дип озатып калды аны әни кеше.

Хупҗамал әби һәр баласы, балаларының баласы артыннан шундый изге теләктә калса да, ул көнне башка сыймаслык вакыйга булды. Хәер, Алсу урамга да, юлга да чыгып китмәгән иде юкса. Мәктәптән кайтып ашап-эчкәч, үзләреннән өч кат өстә яшәүче Шакирларга гына менде. Ул да менеп китте, биш-ун минут вакыт үткәндерме, юктырмы, урамда халык гөрли дә башлады. Хупҗамал әби белән Наилә тәрәзәгә барып карасалар, кемнәрдер өскә төртеп күрсәтә, кемнәрдер йөгерә, кемнәрдер елый, түгәрәкләнеп басып нидер карыйлар иде.

Хупҗамал әби, тәрәзәдән чыгып китәрдәй булып, нәрсә булганын аңышырга теләде.

— Кемдер егылган бит монда, балалар. Кемдер харап булган, — диде ул, тыны кысыла-кысыла. — Айнур улым, йөгер Шакирларга, Алсу шунда микән? — Үзе өйдә йөргән башмагы, юка күлмәге белән урамга чыгарга җыена башлады. Наилә аңа тиз генә мамык шәлен китереп бирде.

— Юньле хәл түгел бу, балам. Тикмәгә чит кеше еламас, — диде Хупҗамал әби.

Наилә белән алар чыгып җиткәндә, «ашыгыч ярдәм» машинасы килгән, кан эчендә яткан гәүдәне алганнар, Шакир белән Айнур да арткы ишектән машинага утырып маташалар иде.

Бәлагә юлыгучыны озатып калган халыкның кайберсе: «Кеше булмас, дүртенче каттан егылган кешенең исән калганын күргәнем юк», — дип сөйләнә. Кайсысы: «Ярый әле йомшак җиргә туры килгән, асфальтка төшсә, тын да тартмас иде», — ди. Ә төшкәнен үк күргән кешеләр: «Парашютта очкан кебек кенә килеп төште, бик бәләкәй гәүдәле кыз, ә юбкасы бик киң иде», — диделәр.

Алсу дип нәтиҗә ясады Хупҗамал әби. Наиләне тизрәк кире борды. Сеңлесенең канын күрмәсен. Бераз хәл алгач, чыгып, үзем күмеп куярмын дип уйлады. Исән микән бала, шуны беләсе иде. Исән генә була күрсен! Сәнифәсенә ничек әйтергә менә? Соңгы вакытта тәмам телгәләнде бит... Тыны-көне бетеп, йөзе ак җәймә кебек булган Шакирның әнисе Фәтхия йөгереп керде.

— Тәрәзәгә якын барма, дип, сүземне дә әйтеп бетерә алмадым. Рамнарны буяп яткан Шакир янына барып та басты, өй ишеге ачылып китеп, ачык тәрәзәдән җил алып та очырды, — дип аңлатты ул, яшенә буылып. — Мин хәзер хастаханәгә барам. Сәнифәгә әйтми торабызмы әллә? — диде.

— Айнурны кайтарып җибәр. Исәнлек хәбәрен ишеткәнче, ут йотып торабыз без монда, — дип калды аның артыннан Хупҗамал әби.

Әмма Айнур бертөрле дә юньле хәбәр алып кайта алмады.

— Сәнифәгә әйтмичә эш барып чыкмас. Чирен яшергән үлгән, — дип үзалдына сөйләнде Хупҗамал әби, каушавыннан әле тегендә, әле монда бәрелеп.

— Булмаса, бар апаңа шалтырат, кызым, — диде ул Наиләгә. — Ә син, улым, салкын су белән юын да бераз ятып тор, — диде ул Айнурга. Аннан: — Юк, улым, ятып тора торган чак түгел. Апаң янына үзең бар әле син. Кайтканда ипләп кенә әйтерсең. Кинәт әйтмә. Юк, булмаса, болай ит син, улым. Кайтып кергәч кенә әйтербез. Бар, улым, йөгер. — Үзе башын кысып бәйләде дә диванга утырды. Наиләне чакырды. — Тынычлан, кызым. Күз яше берәр нәрсәгә файда итсә, кешенең бөтен эше елау булыр иде. Сиңа үз-үзеңне бераз кулга алырга кирәк. Сәнифә апаңнан үрнәк ал. Күз яше күрсәткәне бармы сезгә? Аның да борчуы аз түгел. Ирләр йөген дә, хатын-кыз йөген дә берүзе тарта. Җыенybызны әвәләп ясасаң бер кеше чыкмый бит бездән. Бөтенебез апаң тәрбиясендә торабыз. Инде аңа чыдамлык бирсен, сәламәтлек бирсен Ходай Тәгалә! Наилә әллә хәлсезлектән, әллә арудан, әбисенең тезенә башын салып, күзләрен йомды.

— Йә инде? — дип куйды Хупҗамал әби. — Тугачтын да михнәт чигә башлый адәм баласы, үлгәнче газаплана. Ни гөнаһлары бар инде бу балаларның моның кадәр дә җәфа күрергә? Карчыклар белән сөйләшә башладыңмы, «бисмилласыз туган балалар китте. Шуңа бер тыныч көннәре дә юк» дип нәтиҗә ясыйлар. Борын заманнарда аларның картлары кичатна белән җомга көнне генә яннарына килгән. Мунча яктырып, юынып чыккач кына, имеш... Чисталык бәндәгә һәрвакыт кирәк анысы. Әмма бөтен уңышсызлыкны тышкы чисталыкка гына кайтарып калдырып булмый. Эчке пакьлек кирәк. Күңел матурлыгы, күңел чисталыгы. — Хупҗамал әби әнә шулай үзалдына уйланып утыра бирде. Аңа Сәнифәләр кайтып кергәнче ничек тә вакыт үткәрергә кирәк иде. Әмма Айнурның киткәненә бер сәгать кенә түгел, бер ел үткәндер кебек тоела башлады. Яшь кешегә ике генә сикерерлек ара ич мәктәп. Нишләп йөри икән, дип пошыргаланды. Бераздан Айнур Сәнифә белән түгел, күрше Фәтхия белән кайтып
кергәч аңлады, туры хастаханәгә китеп барганнар икән.

— Алсу аңына килде. Сәнифә апа Шакир белән хастаханәдә калды, — диде Айнур.

— Чыкмаган җанда өмет бар, — дип кабатлады Шәмсениса әби. — Узгынчы кайгы-хәсрәтләр булсын, терелер, боерган булса. Табиблар ни әйтә соң, балам? — диде ул.

— Кул сөяге сынган. Баш мие селкенгән. Мин бөерләреннән курыккан идем, аларында әлегә ул-бу сизелми, диделәр. Шакирны әйтәм, үзен бик гаепле сизә. Тотып кала алмадым, дип газаплана. Алсу аягына басмыйча, хастаханәдән чыкмыйм, дип әйтә, — дип тезде Фәтхия.

Сәнифә икенче көнне иртән генә кайтты. Табиблар Алсуның исән калачагын тулысынча ышандырып әйтә алмасалар да, яшь организмның көрәшергә тиешлеген, дарудан һәм шәфкать туташларының хезмәтеннән тыш, кешенең үзенең дә яшәү өчен тырышырга тиешлеген әйттеләр. Үлем кинәт килмәгәндә, һәркемнең үз гомере үз кулында, дигән аңа ак чәчле профессор. «Һәркемнең үз гомере үз кулында, картлык чире чабуыннан ябышканчы», — дип кабатлады Сәнифә, үз эченнән генә. Кара яндырып ике чынаяк сөтле чәй эчте дә мәктәпкә китте. Кайтышлый тагы хастаханәгә сугылды.

Алсу терелеп хастаханәдән үз аягы белән чыкканда, бөтен табигать ак мамык юрганга төренгән иде. Тирә-юньдә уйнак кар бөртекләре сибелә. Учларга, керфекләргә куна.

— Кар бөртеге ничә канатлы? — ди Алсу, һаман да шул ук шук тавыш белән.

Каршы алырга килгән классташлары берсен-берсе бүлдереп гөманлый башлыйлар:

— Биш, дүрт, алты, сигез...

— Учыгызга яудырыгыз да санап карагыз.

Утызга якын бала, кулларын алга сузып, бияләйләренә кар бөртеге төшкәнен көтәләр.

— Алты канатлы.

— Алты бит, әй.
— Минекенең берсе алты, берсе дүрт канатлы гына.
Алсу шуклануын дәвам итә. Гүя ул бүген үзенең дөньяга икенче кабат тууы тантанасында йөзә.
— Ә бер сигарет ничә минут гомерне кыскарта? — дип сорый Алсу, зур кара күзләрен үзе янынннан атлаган Толяга текәп.
Толя, саргая башлаган тешләрен күрсәтмәскә тырышып:
— Күрәсезме, кешенең хастаханәдә ятуы әллә каян күренеп тора, — дигән була.
Арттан килүче берсе шигырь белән җавап бирә:

Ты выкурил всего пять сигарет,
Часа жизни твоей нет.

— Җавап әзер, димәк, һәр сигарет кешенең унике минут гомерен кыскарта, — дип нәтиҗә ясый Алсу.
Сәнифә апасы, класс җитәкчесе, Айнур, Шакир, Алсу һәм классташлары чыр-чу килеп кайтып кергәндә, Хупҗамал әбисе белән Наилә күп итеп өчпочмак пешергәннәр, табынның иң уртасына зур «Кырмыска оясы» өйгәннәр иде.
Алсуның һәрвакыттагыча шат, шаян, җиңел гәүдәсенә карап-карап торды да: «Ул-бу сизелми бугай. Кыз бала бит, гарип кенә булып кала күрмәсен», — дип уйлады Хупҗамал әби, көлешә-көлешә чәй эчкән балаларга карап.
— Алсу, — дип эндәште шунда бер иптәше, — нигә сез апагызга «Алма апа» дисез? Алмалар үстерергә яратамы әллә ул?
— Сәнифә апабыз бакчада алма да, башкасын да үстерергә ярата. Әмма «Алма апа» дигән исемне аның өчен әйтмибез без. Хөрмәтләп, яратып шулай эндәшәбез. «Алма апа» дигән сүз Изге Ана дигән мәгънәне аңлата, ди әбиебез.
Ул арада балалар китәргә кузгала башладылар.
— Бала-чага диген инде. Юкка да күңелләре була, — дип сөйләнде Хупҗамал әби, «Спасибо, бабуля!», «Әби, зур рәхмәт!» дип таралыша башлаган малайлар һәм кызларга карап.
— Укытучылары әйбәт кеше күренә. Шулар сүзен сөйләп, шулар көен көйләп килгән бит әнә.
Алсуга тагы өч көнгә мәктәпкә бармаска кушылган иде. Әмма кем-кем, ул түзеп өйдә утырамы соң? Икенче көнне үк абыйсына ике сумка күтәртеп укырга китте. Гыйлемгә шулай дәрт булуы ошый иде аның Хупҗамал әбигә. «Үзебезнең якка тарткан», — дип уйлады ул, зур бер канәгатьлек белән. «Бар балаларым да гыйлемгә дәрт булдылар. Барысы да урында эшли, биргәненә шөкер. Кем баласы дигәндә, Сабак Кәлимулла балалары, дип горурланып әйтерлек булды. Үзе генә күрмәде багалмаларыбызны. Укып, балаларының кеше булганын күрә алмады. Каһәр суккан сугыш йотты. Аны гына түгел, һай күпләрне нәүмиз итте бу сугыш...»
Ул арада:
— Буш сәгатем, конспектымны онытып калдырганмын, — дип, Сәнифә кайтып керде. — Соңгы вакытта нишләптер әйберләремне оныта башладым әле, әллә картлык чире инде, — диде ул әнисенә.
— Язмаганны. Мин картайдым димәгәндә син картайдым дип торырга, — дип шелтәләде аны әнисе. — Бүген иртән «Здоровье» бакчасына чыктыңмы син? Йокыга әвереп, сизми калганмын, — дип сорады.
— Чыктым. Бер йөри башлагач, үзеннән-үзе барасы килеп тора икән анда. Теге бик суык көнне чыкмаган идем бит, көне буе әллә ни җитмәгән кебек йөрдем, — диде Сәнифә.
— Суыкта да чык син анда, кызым. Чыныккан кешегә суык тими аңа. Аннан балаларны да йөртә башларга кирәк. Әкрен-әкрен өйрәнсеннәр.
— Алып чыгарга күптән ниятем бар да, уятырга кызганам. Соң яталар бит, йокылары туймас дип куркам, — диде Сәнифә.
— Бер тәртипкә салгач, үзләре үк иртә ята башларлар. Йөртә башла син аларны, — диде Хупҗамал әби ашыгып тагы эшкә җыенган кызына.

* * *

Сәнифә никадәр нык булырга, никадәр бирешмәскә тырышса да, Дуга Диасның директоры яныннан чыккач булган хәл борчый иде аны. Һаман спорт белән шөгыльләнеп, иртә яздан башлап туктаусыз су коенырга йөреп, әнисе әйтмешли, җыен юк-барга игътибар итмәскә тырышса да, беркөнне эчен тотып ятканда учына күгәрчен йомыркасы кебек шар килеп кергәч, йөрәге жу итеп китте. Нәрсә булыр? Баскач югала. Ятып, кендек турысыннан аска таба капшап төшсәң, йомры әйбер тагы кулга килеп керә. Үзе авыртмый. Сәнифә беравык үз сорауларына үзе җавап таба алмыйча урынында ятты да, җәһәт кенә сикереп торып, форточканы ачты. «Ни булса да балаларны тәртипкә өйрәтеп, аякка бастырып калдырырга тиеш мин. Үз канатым астына алганмын икән, ана вазифасын да, ата вазифасын да үтәргә

тиеш». Ул, кичтән сөйләшенгән буенча, иплән кенә Алсуны уятты. Ә Алсу җиз кыңгырау белән бер. «Башкаларны алып чыкмыйбызмы әллә?» — диюгә, Айнур белән Наилә дә сикереп тордылар.

— Солдатлар ничек киенә, балалар?

— «Ә» дигәнче, — дип шаяртты Алсу.

— Менә рәхмәт. Бер әйтүдә сикереп тордылар. Минем оныкларым йоклап ятамы соң? — дип, балаларны дәртләндереп җибәрде ак яулыгын чөеп, алар янына чыккан әбиләре. — Беренче көнне чама белән генә кыланыгыз. Ахырдан саныгызны җыя алмассыз.

Сәнифә исә үлемгә хөкем ителгән, язмышы белән килешүдән башка бернинди чарасы калмаган кеше итеп сизде үзен. Урамга чыккач, беренче тапкыр шулай комсызланып, йотлыгып, саф һава сулады. Күк йөзендә, кар сарган агач башларында, күбеккә чумып утырган куакларда — гаҗәеп матурлык, моңа кадәр күзенә чалынмаган гүзәллек тойды. Күзләренә моңа кадәр күрергә өлгермәгән әллә никадәр гүзәл төсләр кереп тулды. «Нинди рәхәт әйбер бит бу яшәү! Нинди ләззәтле эш бит бу тормыш итү! Балаларга да, әнигә дә әлегә сиздермәскә кирәк. Картлар әйтмешли, әҗәлеңә тигән чир булса, бер әмәлең дә юк. Талчыбыгым, Наиләм нишләр», — дип уйлады Сәнифә. Алсуы югалмас. Дүртенче каттан егылып төшеп тә әнә берни булмады. Айнуры да егет кеше. Ә менә Наилә сыек. Тормышның зәмһәрир җилләреннән ышыклардык канат кирәк аңа. Әбиләре дә карт бит, җитмәсә...

— Алма апам, нигә һаман авыр сулыйсың син? — дип челтерәде Алсу, кара күзләре белән көйдереп карап.

— Сезне уйлап барам әле. Кайсыгызны беренче итеп кияүгә бирермен микән, димен.

— Айнур инде, Айнур өйләнә башта. Дәресләр бетүгә, һәр көнне Машасы көтеп тора бит абыйны, — диде Алсу, Айнур яныннан апасы ягына елгыр гына чыгып басып.

— Ә-әй, үзеңне бел. Әнвәрне сөйли башласаң, күзләреңдә йөз дә бер шәм кабына.

— Менә серләр ничек ачыла! Йә, җитәрегез, — дип тынычландыра аларны Сәнифә апалары. — Килеп җиттек. Әнә иң алда басып торган кеше Мөршидә апагыз булыр. Табибә Мөршидә апагыз Уразова. Ул оештырган «Сәламәтлек» бакчасына әнә никадәр күп кеше йөри. Таякларыгызны ул күрсәткәнчә җилкәгезгә салыгыз да түгәрәккә басыгыз. Бүгенгә күнегүләрнең барысын да эшләмәгез. Син, Алсу, үзеңнең табибың кушканнарны да онытма!

Йөгерешеп кайтуга, башларына җилем башлыклар киеп, кызлар душ астына кереп китте. Айнур юеш киндер сөлге белән кызыша башлаганчы аркасын ышкыды.

— Алдагы көннәрендә күрелмәгән бәхетләре күп булсын, Йа Раббым! — диде Хупҗамал әби, алма кебек алсуланып ваннадан чыккан балаларына карап. — Ә синең яхшы эт кебек, борының суык, — диде үзенә килеп сарылган Айнурга.

Барысы берьюлы көлеп җибәрде һәм куллары белән борыннарын тотып карадылар.

— Әгәр борын җылы булса? — дип сорады Айнур.

— Авыру эт була. Яхшы этнең борыны суык, аңкавы кара булыр, — диде Хупҗамал әбиләре, балаларны табынга чакырып.

Бүлмәгә иртәнге кояш нуры кереп тулган. Өстәлдә, буларын бөркеп, Хупҗамал әбинең каенанасыннан калган җиз самавыры утыра. «Уртанчы улым тимердән чәчкә ясый торган иде, — дип сөйли ул. — Авылдан күчеп килүгә, күмер самавырын ялт итеп электрга көйләп биргән иде. Һаман шул хезмәт итә. Көненә ничә мәртәбә чыжлап, балкып өстәл өстенә менеп утырадыр?»

Күңелле итеп чәй эчкәннән соң, һәркайсы үз эше белән таралды. Сәнифәнең тешен кысып, үз эченә яшергән борчуын берәү дә сизмәде. Юк, ул башкалар кебек гасабиланмады, еламады. Алай гына да түгел, хәтта уен-көлкегә күбрәк тартылды. Мөршидә Уразованың «Сәламәтлек» бакчасына көн дә чыгу белән беррәттән, су коену, кыш көннәрендә чаңгыда чыгу кебек гадәтенең әзлеклелеген бозмады. Табигать белән сөйләшеп, тәэсирләнеп кайта торган булды. «Кара, бер җирем дә авыртмый ич минем. Ничек итеп шул төер аяктан егарга тиеш?» дип фикер йөртте. Дөресрәге, ул аны күпмедер вакытка онытып та торган иде. Беркөнне исенә төшеп, яткан килеш төерне эзләп карады. Әмма таба алмады. «Күчеп йөри микән? Әллә эчкәрәк киткәнме?» — дип уйлады. Әллә соң Ходайның рәхмәте белән үзеннән-үзе эреп юкка чыкканмы? Тик шулай да күренергә кирәк табибларга дип катгый фикергә килде Сәнифә. Кайбер авырулар озак сузып йөргәнне яратмый бит...

Хәтта үләсе килмәүдән генә дә түгел, балаларны кеше итәргә, чын егет һәм кызлар итеп үстерергә кирәк булганга, үзенә: һичшиксез яшәргә, сәламәт итеп яшәргә кирәк, дип, максат куйган иде ул. Ятим туганнарын җыеп алып кайткач, бөтенләй башка, яңа тормышта яши башлаган кебек сизгән иде үзен. Бетеп тә бара микәнни гомере?..

Әнисеннән яшерергә тырышуы да файдасыз булды.

— Кызым, йокыңда көрсенеп, авыр сулап куясың, бер-бер борчуың бар, ахры? Чир дияр идем, сызланмыйсың. Балалар хакында уйланасыңмы соң? — дип текәлеп карады аңа әнисе.

— Чирем бар кебек шул, — диде Сәнифә, төшенке тавыш белән.

— Кайсы җирең авырта? — дип сорады мондый җавапны бөтенләй көтмәгән ана.

— Авырткан җирем юк, әни, ләкин... — дип, үзендәге шикшөбһәләрне сөйләде Сәнифә. Әнисе аны шул сәгатьтә үк тикшерелергә җибәрде. Ә инде ике-өч сәгатьтән кояш кебек балкып кайтып кергән Сәнифәне күргәч, шатлыгыннан аңын җуя язды.

— Соң инде, — дип битәрләде ул кызын, — бу заманда — әллә нинди тикшерү җайланмалары булган дәвердә шиккә калып, эчкә хәсрәт җыеп йөримени кеше? Шундый зур ихтыяр көченә ия булып, чиреңне белер-белмәс килеш җебеп төшүеңә гаҗәпләнәм мин синең, — дип, тагын да ныграк шелтәләде.

Сәнифә шатлыгыннан сумка тутырып тәмле әйберләр алып кайткан иде. Әни белән кыз әле көлеп, әле елап озаклап чәй эчтеләр.

— Борын салындырып йөрү сиңа, гомумән, хас түгел бит, балам! — диде әнисе, кистереп. — Башка алай эшләмә! Сиңа «кайтып китәргә» һич кенә дә ашыгырга ярамый. Җилкәңдә тау кадәр эш әнә!..

Ишектә кыңгырау шалтырады. Бит очлары кызарган, күзләре очкынланып торган балалар кайтып керде. Алар белән бергә өйгә шатлык, көч-куәт, яшәү дәрте тулды. Әбиләре балаларны бәйрәм өстәле кебек итеп әзерләнгән табынга утыртты. «Бу сабыйлар күңеленә хәсрәт керергә тиеш түгел! Ходаем-Аллам, рәхмәтеңнән ташлама! Хәвеф-хәтәрләр җибәрмә!» — диде ана, оныкларының аркаларыннан сөя-сөя.

* * *

Һава лайнеры күрше республиканың башкаласына китереп җиткерде. Томан арасыннан иренеп кенә яңгыр сибәли иде. Юлчылар, асфальтка төшеп басуга, баш өстенә зонтикларын чөйделәр... Каршы алырга килгән стюардесса автобуска чакырды.

— Әллә санап кертә инде, — дип шаярттылар егетләр.

— Юк, матурым, санамыйм, арагызда танышларым юк микән дип кенә карыйм, — диде чибәр кыз саф татар телендә.

Гаҗәпләнүдән туктап калган егетләр:

— Татар кызы, менә сиңа!.. — дип тел шартлаттылар.

— Татарның юк җире юк бит аның. Ник шаккаттың, әйдә алга уз, — диде аның артындагы абый.

Ишек яныннан узганда, Сәнифә дә сокланып текәлеп карады татар кызына. Бер секундка күзләре очрашты. Сәнифә, аяк астына карап, бер адым алга атлады да тагы кыз ягына каерылды. Кыз да аңа текәлгән иде.

Ул да булмады, кыз:

— Сәнифә апа, сез ич, — дип каршына килеп басты.

Бу — Язгөлем иде. Алар бер-берсенең кочагына ташландылар.

— Нинди йомыш белән, Сәнифә апа? — дип, ярым пышылдап, ягымлы һәм якын итеп сорады Язгөлем.

— Ял итәргә, — диде Сәнифә.

— Бүген беркая да җибәрмим, мин сезне үзебезгә алып кайтам.

Сәнифә:

— Юк, рәхмәт. Барып урнашыйм әле. Алдан килгән урын өчен, — дип әйтеп караган иде дә, Язгөлем чат ябышты:

— Мин хәзер кияүдә, Сәнифә апа. Сезне үзебезгә алып кайтам, — диде, «үзебезгә» сүзенә басым ясап. — Эш сәгатем дә бетте. Һәм үзенекен итте дә. Шунда ук такси чакыртты. Сәнифәне алып та китте. Юл буе сөйләшеп кайттылар.

— Беренче күргәч үк сез... миңа ни өчендер гел әниемне хәтерләттегез. Сез әтием белән хат язышканда, мин үземнең ятимлегемне бөтенләй оныткан идем. Миңа шундый рәхәт иде, ерактан сезнең җылыны, ана назын тоеп яшәгәндәй булдым. Кинәт кенә апаның хаты килеп төшкәч, күпме еладым, ләкин әтиемне күндерә алмадым. Өч бала белән булмый, дип кырт кисте. Бер елдан ападан тагын хат килде килүен. «Гафу ит, наным, Сәнифә чынлап та кияүдә булмаган, үлгән туганының балаларын алып кайтып тәрбияли икән» дигән иде. Ә ул вакытта эш узган. Әти өйләнгән, хәтта малае туган иде инде. Әбием дә бик уфтанды. Ах, бу апагызны, теләсә кая борынын тыкмаса?! Кем кушкан иде аңа тикшереп йөрергә, диде. Әбием вафат инде хәзер. Менә бүләк итеп биргән сервизы гына калды, — диде Язгөлем, — уймак кебек чәшкеләргә кофе салып. — Мин кияүгә чыкканда әбием аягында иде әле. И мине ярата, и сөйләшә иде. «Үз телебезне белүеңә сөенепләр бетә алмыйм, кызым», — дия иде, мәрхүмә. Баштагы елларда бик юксындым үзен, — диде ул, яшьле күзләрен сөртеп. — Ә сез әбием өчен беләсезме кем идегез, Сәнифә апа? «Изге җан! Андый адымны ясарга бөтен кешенең дә йөрәге җитми. Бирәү генә түгел, өчәү бит алар, өчәү. Берәр кашыктан өч кашык, берәр оектан да өч пар оек кирәк аларга», — дия иде. Гафу итегез, хәзер ничек анда тормышыгыз? Үзегез турында, тәрбияләгән балаларыгыз турында сөйләгез әле, — диде ул сабый вакытындагыча, яңадан да Сәнифәнең куенына керердәй булып.

— Мин дә әниемне җирләдем, — диде Сәнифә, көрсенеп. — Әниләрне озату авыр. Әллә гомер буе бергә яшәгәнгә бик юксынам, — дип өстәде. — Ә балалар? Һәркайсының үз гаиләсе хәзер. Вакыт-вакыт оныкларны гына китереп куйгалыйлар.

— Сәнифә апа, рөхсәт итсәгез, сезнең килгәнне әтиемә шалтыратып әйтер идем, — диде Язгөлем, кыюсыз гына.

— Юк, юк. Сүз җае чыкса, мин бөтенләй кайтып киткәч әйтерсең, — диде Сәнифә, урыныннан кузгалып. — Менә үзебезнең татар чәкчәге. Гаиләгез белән бергә җыелгач, чәй эчәрсез, — диде ул, кәгазь тартмага матур итеп бизәп өелгән чәкчәк чыгарып. — Мин китим.

Язгөлем Сәнифә апасын берәр кич кунып китәргә кыстаса да, күндерә алмады.

— Алайса, мин сезне илтеп куям. Чит җирдә каңгырып йөрмәгез, — диде ул, телефоннан тиз генә такси чакыртып. Билгеләнгән урынга җитәр алдыннан авыр сулап: — Безнең әтинең бәхете булмады аның, Сәнифә апа. Сигез яшьлек бала калдырып икенче хатыны да вафат булды. Сезнең янга барырга әллә ничә талпынып карады да, батырлыгы җитми. «Минем хат иң авыр вакытларында барып төшкән булырга тиеш. Кызы бик катлаулы операцияләр кичергән. Үлемне җиңеп яши торган кешеләр алар, кызым. Бик көчле рухлы ул Сәнифә апаң. Мине кабат сынамаячак» диде, — дип, сүзен төгәлләде.

— Ялгыз хатынның көчле булмыйча чарасы юк. Тормыш аңа бернинди дә ташламалар ясамый. Ә гомумән алганда, көчле булып, җир йөзендә үз кадереңне белеп яшәргә кирәк, Язгөлем. Дөньяга килгәнбез икән, димәк, кирәк булганга туганбыз. Җирне ямьләргә, яшәртергә һәм яшәтергә туганбыз. Үзем тудырмасам да, җәмгыятькә кирәкле кешеләр итеп тәрбияләдем мин энемнең балаларын, шуңа куанам! — диде Сәнифә.

— Рәхмәт, Сәнифә апа! Сезнең белән горурланам мин. Сезне белүемә шатланам! — диде Язгөлем. Такси бик матур бина янына килеп туктады. — Биш кенә минут көтегез, мин туганымны кертеп чыгам, — диде Язгөлем шофер егеткә, русчалап. Бинага килеп керүгә, каршы алучылар белән җирле халык телендә сөйләшә башлады.

— Ничә тел беләсең? — дип сорады аннан Сәнифә, сокланып.

— Күп түгел, дүртне генә, — диде Язгөлем, елмаеп. Кунагының чемоданын йомшак кресло янына китереп куйды да кочаклап битеннән үпте. — Яхшы ял итегез, Сәнифә апа. Без һичшиксез килеп чыгарбыз әле сезнең янга, — диде.

— Небось дочка?! — дип, әллә көнләшеп, әллә кызыгып сорау бирде аларга, кара яулыгын алга китереп бәйләгән рус карчыгы.

— Да, мать! — диде Язгөлем, әбинең сүзен игътибарсыз калдырмыйча, Сәнифә өчен җавап биреп. Аннан кулын болгый-болгый таксига кереп утырды. Якты йөзе белән тәрәзәгә капланып тагы нәрсәдер әйтте.

«Җир җылысы гына микән бу балада», — дип уйлады Сәнифә, муенындагы зәңгәр шарфының бер канатын җилкәсенә салган, чәчен нәкъ татарча итеп уртадан ачып төйнәгән Язгөлемгә текәлеп. Әллә ятимнәр барысы да шулай ана сарылы, шәфкатьле була микән дип уйлады, үзенекеләрне дә күз алдына китерде.

Машина ераклашкан саен, Язгөлем йолдызларга якыная барадыр кебек тоелды Сәнифәгә. Татар кызының әкияти гүзәллеген бөек Күкләргә күрсәтеп, күңелен илаһи нур белән баетып, бөтен кешеләр дә бәхет йолдызы астында тусын өченгә галәм киңлегенә фәкать бәхет йолдызлары гына кабызып, яңадан безнең арага кайту өчен!..

*1985*

## *Мизгел*

Я помню чудное мгновенье...

*А.С.Пушкин*

Беләм... Син юк! Ләкин минем өчен, минем газиз балаларым өчен син бар. Син исән. Син яшисең. Син һаман безнең белән бергә!..

Сагындык, бик сагындык сине. Бигрәк тә төпчек кызыбыз Резеда өзгәләнә. Безнең йөрәкләр елый, эчтән янабыз. Ә Резеда — талгын гына җилдә тирбәлгән агач яфрагы кебек. Агач яфрагының да шундый нәфисе, нәние. Сине юксынуы бик көчле аның. Сагынуы шуның кадәр сагышлы, хәтта кайчагында катырак тавыш белән эндәшү дә ярамый үзенә. Хәзер: «Әти, әти-и, әти-ем!» — дип елый башлый. «Әтием, кайт, зинһар! Мин сине яратам, әтием! Мин сине сагындым, әтием! Мин сине көтәм, әтием!» — дип өзгәләнә...

Сине җирләп күп тә тормастан кыш килде. Җир өстен агартып кар яуды. Олылар моны яхшыга юрадылар. Яңа кабер туфрагы явым-төшем тигәнне ярата, изге кеше булган, диделәр. Соң, ул кадәр яра

белән тилмереп, сызланып ятуга нинди гөнаһ калсын, дип сөйләштеләр. Ә Резедабыз өчен карның икенче бер хикмәте бар иде. Бик тә көтте ул карның ятып калуын. Тизрәк чана тартып йөрисе, тизрәк Яңа елны җиткерәсе, Кыш бабай белән очрашасы килде аның. Әнә шул гап-гади, һәр бала тансыклап көтеп алган Яңа ел бәйрәменең тагы да сиңа барып тоташуын белгәч, имәнеп киттем. «Беләсеңме, әнием. Кыш бабай килә дә: «Яңа елда ни телисең, Резеда?» — ди. Кыш бабай әтиемне алып кайтып бирәчәк миңа...»

Бугазыма эндәшә алмаслык булып төер килеп утыра. Резеда исә мөлдерәп минем күзләремә карый. Җавап ишетәсе, үзенең уен: «Шулай, кызым», — дип раслатасы килә аның. Мин сабыйны алдаудан, ялганлаудан, миңа булган ышанычын югалтудан куркам. «И бәләкәчем, әтиең юк бит инде. Аны хәзер Кыш бабай гына алып кайталмый», — димен. Ул елый. Җанымны кая куярга белмичә мин бәргәләнәм...

Икенче көнгә Резеда яңа план корган була. Күрәсең, көне буе уйланып йөргән. Сине алып кайтуның башка юлларын эзләгән. Йокысыннан торганда ук тәвәккәл, җитди булып күренде ул. Юынып өстәл янындагы үз урынына кереп утырды да зурларча итеп сүз башлады: «Әни, көрәк тап. Тунын алып барабыз да әтине казып чыгарабыз!» Тавышына шундый ук ышаныч, көч салып: «Үзем казыйм!» — дип тә өстәде. Шулчак биш яше дә тулмаган сабый башына төшкән кайгы-хәсрәт, дөнья нужасы куркытты мине. Рәхәтләнеп сөелер, ата-ана кочагында иркәләнер вакытта әйтеп бетергесез олы сагыш кичерә бала. Шушы биш яше дә тулмаган сабый кадерле кешесен югалту газабы белән яна, теле «үлем» сүзе белән чуарлана.

Үлем ачысы!

Юксыну, сагыш ияртеп, нарасыемның нәни йөрәгенә кереп тулды ул. Югалту газабы булып бәгырен телде. Эре-эре тамчылар булып коңгырт күзеннән коелды. Белмим, нихәл түзгәндер аның бәләкәй йөрәге бу тамашага?..

Ишетәсеңме? Синең изге рухың алдында имтихан бирәм мин бүген. Синең белән сөйләшәм. Әйтерсең син исән, әйтерсең, мәзәкчеллегеңне тагын бер кат раслап, качып кына торасың, әкияттәге сыман, күзгә күренмәс кеше булып яныбызда йөрисең. Кайнар хисләрем белән кагылып сискәндерәсем, күз нурымны сөртеп терелтәсем килә, терелтәсем! Сине эзләп әкиятләргә китәм, карурманга кереп адашам. Каф таулары артында төпсез упкыннар янында тилереп йөрим. Бар ятимне, бар толларны җыеп, илереп-илереп кычкырасы килә... Шушы мизгелдә аяк астымнан калкып, иңнәремә орынуыңны, сулышың белән керфекләремә кагылуыңны телим! Мин телим, мин уйлыйм, мин хыялланам, ә хакыйкать дәвам итә...

Хәзер безнең өйдә синең шәхси әйберләреңә табыну, аларны изге итеп карау тәртибе урнашты. Юк, балаларга бернинди дә күрсәтмә бирмәдем. Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты. Әйтик, олы кызыбыз Раушания үзенең язу өстәле тирәсен син иң яраткан рәсемнәр белән бизәде. Бөтен китапларыңны тәртипләп тезде. Җаныңдай күргән иң кадерле әйберләрең китаплар булганын яхшы белә ул. Шул вакыт аңа карап бер нәрсәгә шатландым. Балаларыбыз күңелендә ата-анага ихтирам тәрбияли алганбыз икән бит. Раушаниянең ир-егетләрчә ныклык, тәвәккәллек белән синең эшләрне үз кулына алуы — миңа һәрвакыт ярдәм итәргә, терәк булырга тырышуы шул турыда сөйли. Ә мин моны синдәге иң олы кешелеклелек сыйфатына — әниеңә булган мәхәббәткә, яхшы мөнәсәбәткә бәйләп аңлатасым килә.

Әни бездән илле-алтмыш чакрымнардагы бик матур бер шәһәрдә яши. Шомырт кара чәчле, какча гәүдәле, чандыр буйлы, җиңел сөякле карчык. Инде олы яшьтә булса да, күзе әйбәт күрә, колагы әйбәт ишетә. Белә башлаганнан бирле бервакытта да керләнгән күлмәктән күрмәдем мин аны. Яулык астыннан тузгып чәче чыгып торуын, аягына кигән оегының җыерылып төшүен хәтерләмим. Төнлә бәйләп яткан яулыгы белән бервакытта да кеше күзенә күренмәс, иртүк торып, шалкан мае сөртеп чәчен тарар да кершән кебек ак яулыгын бәйләп куяр иде. Аклыкны-чисталыкны яратуы, чынлап та, сокланырлык, үрнәк алырлык сыйфаты әнинең.

Ак төсләрне син дә яраттың. Җәй җитте исә ак күлмәк, ак чалбар кияр идең. Шуңа күрә иптәшләрең, шаяртып, «плантатор» дип йөртте үзеңне. Ә бервакыт, кунакка килгәч, әни сине тәрәзәдән карап озатып калды да: «Кара, нинди матур минем улым. Ничек кызларның күзе төшмәсен», — дип, мине үртәгән, шаярткан булды. Шаян сүзле ул. Бу сыйфаты сиңа да мул булып күчкән. Әмма нинди генә шук, җор телле булмасын, синең үлемең әнине дә тетрәндерде, тәмам аяктан екты. Такмаклый-такмаклый да: «Картлар үлем көтә, яшьләр үлеп китә. Моңарчы кайгым булмаган икән. Улым күмәр, улым җыяр дип яши идем», — дип куя. Карап торсаң, олы кеше кызык бит ул. Үлемгә туйга әзерләнгән кебек әзерләнә. Хәер-садакага бирер өчен дип, сандык-сандык әйбер җыя. Тастарлык, кәфенлек, кыскасы, тотылмаган энә белән җебенә кадәр әзерләп, хәсиятләп салып куя...

Авыр, әнигә бик авыр. Ничә барсаң, урыны җәюле, йөзе моңсу булыр. Ак яулыгына төреп куйган фоторәсемеңне алып, шуның белән сөйләшә. «И улым, улым, улым! Бу башларың бик авырткандыр бит инде. Ничек түздең икән, улым?» — ди. Сүзен әйтеп бетерә алмыйча, урынына каплана. Олы кызыбыз, дәү әнисенең караваты янына тезләнеп, кулларыннан тота, чытырдатып иреннәрен тешли. Сүзсез генә сулкылдап дәү әнисенең иңнәренә башын куя. Резедасы ашыгып урын-җиргә үк менеп

китә. Баш очына утырып, кечкенә куллары белән әбисенең күзләрен капшап таба. «Дәү әнием, елама инде, елама, дәү әнием!» — ди. Ә үзенең коңгырт күзләреннән туктаусыз яшь коелуын сизми сабый. Шулай итеп, очрашуларыбыз тоташ газапка әйләнде безнең. Һәр сүз сиңа барып кагыла. Шулай беркавым ятып тора да янына син килгән вакытларны искә төшерә әни. «Кара, нинди эре өрек җимеше алып килдем. Йөрәккә файдалы дип әйтәләр аны, күп итеп аша» дияр иде», — ди.

Син тамаксау кеше түгел идең. Ләкин әни кеше өендә пешкән аш тәмле буладыр, күрәсең. Әни янына килгәч, һәрвакыт аш пешертә идең. Пешергән ашны кат-кат бүлдереп, тирләп чыгып, мактый-мактый ашый идең. Аннары, кыш булса, әнинең кара плүш жикетын, тирән эчле галошын, папыен (бәйләнгән башлыкны шулай дип йөртә идегез) киеп, сарайга чыгып китәсең, иске китаплар җыеп керәсең. Бераз актарып, карап утырасың да, шәп китап, дип, портфелеңә салып куясың.

Китапны бервакытта да беренче битеннән укый башламый идең. Башта урта битләрне ачып, күз йөртеп чыгасың. Икеләнсәң, тагы бер-ике битен карыйсың. Күңелеңә хуш килсә, йотлыгып укый башлыйсың. Аерылмыйча, йокламыйча укыйсың. Төп фикерне тиз тотып аласың, әсәрнең ни белән төгәлләнәчәген алдан әйтеп куясың һәм сирәк очракта гына ялгышасың. Ялгышканда гаҗәеп бер соклану, шатлык кичерә идең син. Күзләрең әсәренеп яна башлый. Үзең кызу-кызу ишекле-түрле йөрисең. «Кара, ничек көтелмәгәнчә китереп чыгарган. Шәп, шәп, шәп!» — дип туктаусыз кабатлыйсың.

Күп укый идең син, Фаил. Йөгерек укый идең. Кечкенә генә мәкалә язарга алынсаң да, башта әллә никадәр әдәбият актарасың, кич буе укып ятасың да иртүк торып яза башлыйсың. Эшне, гомумән дә, иртән эшләргә яратасың. Кеше йокыдан торганчы язасын язып, өстәлнең бер кырыена пөхтәләп куйган, юынган, кырынган була идең.

Синең эш сөючән, вәгъдәле булуың турында балаларга еш сөйлим мин. Әйтик, редакцияләргә бер-бер эш эшләргә алынсаң, нинди халәттә, нинди шартларда булуына карамастан, җаен таба, җиренә җиткереп башкара идең. Әле дә хәтеремдә: «Яшь ленинчы» газетасына китапларны саклау, ярату, уку турында мәкалә бирергә тиешсең. Өйгә бер кочак балалар хатлары алып кайттың. Башта дикъкать белән танышып чыктың, кайберләрен үрнәк рәвешендә безгә дә укып күрсәттең. Аннан, идәнгә түгәрәкләнеп утырып, балалар белән китаплар тупләдегез, махсус әңгәмә корып җибәрдең. Бу, билгеле, пионер яшендәге балаларның китап турында ничек фикер йөртүен белү өчен иде. Раушания рәхәтләнде генә. Бәхәсләшергә дә, сөйләшергә дә ярата иде ул синең белән. Үзе укыган китаплардан мисаллар китереп, сораулар белән күмеп ташлады.

— Ошап китте, — дидең син, көлеп, кызыңның бик күп сорауларына җавап биргәннән соң. Аннан: — Йә, булды, комачауламагыз, «Яшь ленинчы» газетасына мәкалә бирәсем бар, — дидең.

Балалар тынып калдылар. Бераздан Резедасы түзмәде, сузып кына:

— Әти-и, — дип эндәште, — ә «Яшь ленинчы» газетасы кызмы, малаймы?

Син тәрәзәләрне зыңлатып көлеп җибәрдең. Резеданы кочагыңа алып, шашып үбәргә, яратырга тотындың. «Бик башлы булырсың әле син, кызым», — дидең. Балаларны шулай ярата, эшең нинди генә тыгыз булса да, алар белән уйнарга вакыт таба идең. Гаҗәп җиңел сөякле булдың син. Өч яшьлеген дә, унөч яшьлеген дә ияртеп качышлы уйнау дисеңме, ат булып җилкәңә утыртып йөрү дисеңме, куеныңа алып, җырлап йоклату дисеңме... Әле дә күз алдымда, кечкенәсен күтәреп, сүзне килешләрдә төрләндереп, җырлый башлыйсың: бәллүр, бәллүрнең, бәллүргә, бәллүрне, бәллүрдән, бәллүрдә.

Шулчак, күзләрен очкынландырып, олысы йөгереп килә:

— Әти, мине дә, мине дә, әти!.. — ди.

«Уйлаганыем аны», — дип кычкырып көлеп җибәрәсең һәм, кечкенәсен төшереп, үзең буе булып үскән олы кызыңны куеныңа аласың. Җитди кыяфәткә кереп, бишек җырыңны аңа да җырлый башлыйсың. Мин, сезнең яннан аерылып китә алмыйча, балаларымның яратылуыннан искиткеч зур ләззәт кичереп басып торам. Кайвакыт, кызып китеп, мине дә беркавым күтәреп йөрисең. Аннан, уф, арыдым, дип, диванга барып утырасың. Раушаниягә телевизорны кабызырга кушасың. «Вакыт» программасын,
«Киносәяхәтчеләр клубы»н калдырмаска тырышып, яратып карыйсың. Юрий Сенкевичка ихтирамың аеруча зур иде. Тур Хейердал белән «Тигрис» кораблендәге сәяхәтләрен күзәттең син аларның. Ахырдан нәтиҗә ясап: «Өченче тапкыр бергә чыгалар бит. Икесе дә ас инде болар, тәҗрибәле», — дип куйдың.

Тапшырулар турында сүз чыккач, әйтим әле. «Язның унҗиде мизгеле»н яратып карадык без.

— Бәхет басты. Авызыңны да җыя алмыйсың, — дидең син миңа шул чагында.

Чынлап та, вакытында җыелып, бөтен гаиләң белән бергә тезелешеп кино карау — бик тә күңелле эш. Режиссеры Татьяна Лиозновага рәхмәт. «Безгә генә килгән бәхет түгелдер бу. Күпме гаиләне чәчәк бәйләме кебек бергә җыеп утырта бит шушы кичләрне», — дип уйладым. Бигрәк тә Исаев ролен башкарган артист — Вячеслав Тихонов ошады безгә. Андагы табигыйлек, андагы тотнаклылыкка сокландык.

Күп нәрсә уйландыра иде сине. Мәсәлән, Василий Шукшинга гашыйк идең. Шәп режиссер, шәп артист, шәп язучы буларак, аның якты образы каршында баш ия идең. Үзе үлгәч, берәмтекләп китапларын җыйдың. Укыган әсәрләрен кабаттан укып чыктың.

Шушы урында тукталып, үлем турында уйлыйм. Дөньяда әллә ниләр майтарырга сәләтле адәм баласы мәрхәмәтсез үлем алдында сабыйлардан да көчсез, телсез-тешсез... Йа Алла! Әйтик, Шукшин. Әйтик, син. Япь-яшь башыгыз белән үләргә тиеш кешеләр идегезмени? Шуның кадәр куәт, шуның кадәр иҗади уйлану, шуның кадәр тормышны сөю хисегез белән! Туган җир табигатен, кошларны, хайваннарны, диңгезләрне, чишмәләрне шуның кадәр дә олы ярату белән! Әсәрләрең аша синең ул яратуың, ул олы мәхәббәтең күз күреме җитмәс офыкларга — зәңгәр эңгер, тирә-юньгә якты елмаю булып тарала.

«Быел да мин авылга аны күрергә дип ашкынып кайттым...

Шулкадәр сагындырган икән — кич булганын да көтеп торырга тәкатем җитмәде. Төш авышкач, өйдәге кешеләр кайсы кая таралып беткәч, киенеп-ясанып, бакча артлап кына язмышым чакырган, хыялларым әйдәгән якка юнәлдем...»

Сүздән-сүзгә олая, яктыра барган мәхәббәткә генә игътибар итегез. Укый башлаганда, нindидер сәбәпләр аркасында бергә кушыла алмаган сөйгән кызын — яшьлек мәхәббәтен сагынып кайткан инде бу дип фараз кыласың. Әмма «Ник бу турыда хатынының төп йортында — бабасы белән сыйланып утырганда уйлый» дигән сорау туа. Ирексездән «Әмма дә оятсыз бу ир-ат халкы» дип нәтиҗә чыгарасың. Ә автор нишли? Белмәс борын кеше турында начар уйлавы өчен укучыны оялтып: «Исәнме, якты чишмәм! Бик сагындым мин синең шифалы суларыңны, бик сагындым назлы чылтыравыңны!..» — дип сүзен төгәлли. Таулар куенында челтерәп агучы көмеш сулы чишмәгә, тирә-юньдәге сихри матурлыкка укучы күңелендә дә соклану уята.

Никадәр генә тырышсам да, синең стилеңә, телеңә тиешле бәяне бирә алмаячакмын мин. Артык сокланган, артык хисләнгән вакытта шулай буладыр ул. Аннары, синең иҗатыңа бәя бирү максаты да тормый минем алда. Ләкин шөбһәсез бер әйбер бар: ирем, балаларымның атасы булу белән бергә, минем өчен олы язучы да идең син. Талантлы, үткен телле публицист, нечкә зәвыклы юморист, каләмдәшләреңә һәрвакыт игътибарлы, ихлас күңелле дус...

1981 елгы ел йомгакларын һәм анда балалар әдәбияты буенча ясаган «Кешелек тавына күтәрелгәндә» дигән чыгышыңны күпләр хәтерли торгандыр. Докладың җиңелчә генә шуклык-шаянлык белән өртелгән, ә фикерләрең — төпле, акыллы, уйланган.

«Бүгенге фәнни-техник революция чорында балалар җидене генә түгел, унны бетереп туалар. Балалар хәзер өченче класста ике билгесезле тигезләмә чишәләр, һәр фатирда ук булмаса да, өч-дүрт фатирның берсендә пианино шыңгырдаталар...

Тик нишлисең, кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың дигәндәй, яратырга туры килә аларны, шул килеш, бөтен сәерлекләре белән яратырга туры килә. Язучы кулында — тәрбия коралы, язучы кулында — бай тормыш тәҗрибәсе һәм, ниһаять, язучы кулында — ата-бабаларыбызның рухи мирасы. Ә бала кулында — киләчәк. Язучы саграк эш итмәсә, әйткән сүзләренең чынлыгына, дөреслегенә баланы ышандыра алмаса, китте барды бала киләчәккә шәрә кулын селкеп. Утырып калыр аннары язучың тормыш тәҗрибәләрен, тәрбия коралларын, рухи мирасларын кочаклап...

Без батыр малайлар турында язарга яратабыз, тик еш кына әнә шул күркәм сыйфатны кешелек төшенчәсеннән чыгып бәяләмибез.

Зур батырларның батырлыклары турында сөйләгәндә, аларның зур җаннарын да укучыга ачып күрсәтә алсак иде без һәм шулай ук кечкенә геройларның да зур җанлы булырга сәләтле икәнлекләрен онытмасак иде.

Бу җәһәттән Ләбибә Ихсанованың «Наил, Фаил һәм башкалар» дигән яңа повесте гыйбрәтле. Нәкъ менә кечкенә геройларның зур җаннарын шактый тулы ачып бирүгә ирешкән автор.

Повестьның төп герое — тискәре персонаж. Аны күпләр яратмыйлар, үзенең Алла каргаган характеры аркасында байтак «кыен» ашарга туры килә малайга. Әмма аның күңел тәрәзәсен классташларына да, эти-әнисенә дә күренми торган якты нур балкытып йөри. Бөтен бәла дә шунда шул: тирә-юньдәгеләр күрмиләр, дөресрәге, күрергә теләмиләр малайның күңел тәрәзәсендәге яктылыкны. Хәер, малай күңел тәрәзәсен һәркемгә күрсәтергә үзе дә ашыкмый. Чөнки аның алган тәрбиясе, холкы-фигыле, характеры шундый. Чөнки күңел тәрәзәсендәге яктылыкның зурая барачагына, шул яктылык төшкән җирдә кайчан да булса шифалы үсентеләр шытачагына ышана ул. Шул ышаныч — малайның рухи башлангычы. Шул ышанычның ныгый баруы исә — нәни йөрәктә кешелеклелек сыйфатларының да үсә, ныгый баруы дигән сүз.

Бала кешелек тавына күтәрелгәндә һәр җирдән маҗара эзли. Аңа табигатьнең һәр күренеше кызык, һәр үләне, һәр бөҗәге серле булып тоела, серле булып күренә...»

Кыскасы, балалар әдәбияты турында күп уйлана идең син. Шул елда китаплары чыккан тагын бик күп язучыларның, шагыйрьләрнең иҗатына тукталдың. Гадел хөкем йөртергә, яхшы эшне яхшы сүз белән бәяләргә тырыштың...

Ә икенче елда?..

1983 елда үткәрелгән ел йомгакларында аягүрә басып, бер минутка тын калып искә алдылар сине! Синең үлем татар совет әдәбияты өчен зур югалту, авыр югалту булды! Ул елны балалар әдәбияты буенча Роберт Миңнуллин чыгыш ясады. Ике сүзнең берендә синең исемне телгә алды. Юксынып, сызланып телгә алды. Синең үлемсез геройларыңның матурлыгына, ихласлыгына сокланды. Әнә бит бер якта шундый да әче итеп көлә белгән Хисмәт, Бәкер, Ходайбирде, Хөрмәтша, Фәрхенурларың торса, икенче якта биләүдәге сабыйдай гөнаһсыз, күз яшедәй үтә күренмәле Ләйсән, Әлфинур, Фирүзәләрең тезелеп киткән синең.

Фирүзә...

«Кар дөньясында Фирүзә исемле кар бөртеге оча иде. Ни өчен Фирүзәме? Асылташтай җем-җем итеп җемелдәгәнгәдер, бәлки? Ә бәлки... Хәер, әти-әниләребезнең безгә ни өчен нинди исем кушуларын ничек белеп бетермәк кирәк тә һәм бу хакта бәхәсләшүнең нигә кирәге бар? Фирүзә икән Фирүзә. Хикмәт аның исемендә түгел...»

Миңа гына шуның кадәре дә илаһи, шуның кадәре дә кадерле тоелды микән бу хикәя? Белмим. Әмма аның белән сюрприз ясаган идең син. Язган вакытта түгел, хикәя булып «Яшь ленинчы» газетасында чыккач кына күрдем мин аны.

Фирүзә турында сүз чыккач, бергәләп зиратка барган вакыт искә төште. Үзегезнең рәссамыгыз Иван Хантимеровтан, матур итеп, «Шәфигуллина Фирүзә Фаил кызы» дип яздырып алган идең син. Шуны рамлатып, чардуганга беркетергә килүебез. Кулыңда алсу чәчәк аткан бер савыт яран гөле. Йөзең уйчан. Килеп җитсәк, ни күзебез белән күрик, янына тагын бер нәни кабер казыганнар да кызыбызның чардуганын яртылаш читкә күчергәннәр. Син, ярсып, зират хуҗалары янына киттең. Көрәк алып килеп, чардуганны батырып, ныгытып куйдың. Шул чагында балаларыбыз өчен синең ныклы калкан булуыңны, исәннәрен беркайчан да, беркемнән дә кактырмаячагыңны аңладым мин. Болар барысы да синең вазифаңа кергән гадәти эш булгандыр, бәлки. Ләкин кайчагында гадәти әйберләр дә гадәттән тыш тойгы уяталар икән. Әйтик, минем балаларым хакына тагын кем шулай калкан булып баса ала? Мәрхүмәм турында тагын кем шулай якын итеп яза, нидер әйтә ала? Юк. Җир шарында, шушы олуг кыйтгада синнән гайре беркем дә юк! Минем кадерле балаларым — йөрәк җимешләрем турында үз итеп, үзенеке итеп башка беркем дә, беркайчан да андый сүзләр әйтә алмаячак...

«Язмыштан узмыш юк, үзеңне бетермә, син балаларыңа кирәк», — диләр миңа. Килешмичә чарам юк. Мин балаларыма кирәк. Әмма йөрәкне буйсындырып булмый. Әгәр сине терелтүнең берәр юлын белсәкме? Меңнән бер генә ихтимал булса да, юк, миллионнан, ун-йөз миллионнан бер мөмкинлек булса да, эзләр идек. Күз нурларыбызны түгеп бетергәнче... Әмма андый мөмкинлек юк. Бу дөньяның ятимнәрен, бу дөньяның толларын яңадан бәхетле итәр өчен йөз миллионнан бер генә ихтимал да юк.

Ләкин адәм баласында өмет бар. Адәм баласында яхшылыкка ышану бар. Әнә биш яше дә тулмаган сабый бала әтисенә хат яза. Көн дә яза ул аларны. Нәни конвертка сала да сумкасына җыя.

— Әнием, — дип сорау бирә кызларымның олысы, — дөньяда шундый могҗиза булырга мөмкинме? Япон кызы ак кәгазь торналар ясаган. Кәгазь торналар меңгә тулгач, аның хыялы тормышка ашарга тиеш булган. Әгәр без дә әтиебезгә мең хат язып карасак?

— И алтыным минем, синең дә сабыйлыгың чыкмаган икән әле, — дим, аны куеныма алып.

Ул аңлый, күңелсезләнеп уйга чума. Ә кечкенәсе, карандаш очын юешли-юешли, тырышып рәсем ясавын, хат язуын белә. Шушы кечкенә кешенең олы мәшәкатькә батуы, бөтен егәрен җыеп югалтуны җиңәргә тырышуы, үз яшенә хас булмаган җитди кыяфәт алуы йөрәкне әчеттерә...

Үзең дә өч яшеңнән әтисез калып, ятим үскән кеше син. Әтиеңнең муенына атландырып йөртүен (әллә чынлап та хәтереңдә калган, әллә әни сөйләве буенча күзаллый идең син ул кадерле минутларны) сагынып сөйли идең. Еш кына кызларыбыздан: «Әти» дип әйтерлек кешегез булгач, рәхәтме? Бергәләп, җитәкләшеп йөргәч, күңеллеме?» — дип сорый торган идең.

Бик тә күңелле, бик тә рәхәт булган икән ул көннәр. Ятып еласак та кире кайтмаслыгын гына белмәгәнбез.

Белмибез шул. Иртәгә нәрсә буласын кайсыбыз әйтә ала, йә? Ә бәлки, шул белмәвебез белән беркадәр бәхетледер дә әле без. Ә бәлки, белмәвебез хәерлерәктер дә. Чөнки мондый авырлыкка, мондый югалтуга алдан әзерләнү үзе үк кешеләрдән тере мәет ясар иде.

Миңа калса, «үлем» сүзе ничектер йомшак әйтелешле. Үзе китергән газапка тәңгәл булырга тиеш дип уйлыйм мин аны. Һич югында, Газраил кебек зырылдап, ырылдап торуы белән. Ә бәлки, юри шулай атаганнардыр? Әйткәндә үк кешеләрнең котын алмас өчен. Элек әнә күзгә күренеп йөргән ди бит ул Газраил. Кешеләр бик елаша, бик ялвара башлагач, бәндәләрнең җанын алу

кыенлашкан Газраилгә. Шуннан соң, иплəп кенә килеп, кешеләрне төп башына утыртып китәргә кушылган, имеш, аңа. Уен уен белән, әмма өеннән кутмәгәндә олы мәет озаткан кешенең йөрәге бозылып, төп башына утырып калуы — бәхәссез.

Бервакыт Аккош күлендәге иҗат йортына барганда, синең белән шул хакта сүз чыккан иде. Агачның иң гүзәл өлешен кисеп алалар да, сиңа шул җиткән дип, төп башын калдырып китәләр, дидең син. Чынлап та, утырдың ни, ятып еладың ни инде син ул төп башына. Күзеңне ала алмый сокланырлык, давыл купса ышыкланырлык зифа буйлы агачың юк. Тормышта да ире үлгән хатынның төп башына утырып калуын шулайрак аңлатып булмый микән? Тукта әле, киселгән төп тирәли яшь үсентеләр шытып чыга ич. Тамырлар төп кәүсәгә биреп бетермәгән ашны аларга бирә. Соң, шуларга карап теләсәң күпме сокланырга, хозурланырга була лабаса. Юк, аларга арка терәп утырып, ышыкланып булмый. Зәгыйфь алар, кавырсыннары катмаган. Сине алар түгел, аларны син үзең сакларга тиеш. Хикмәт әнә кайда!

Ә бу дөньяның җилләре күп. Һай, күп икән! Бергә чакта сизелмәгән ул. Син исән чакта балаларга да, үземә дә зәмһәрир җилләре кагылмаган. Сине югалтудан йөрәгем кысылып килгәнгәме, бер мәлгә тормыш итүдән куркып калдым мин. Шул ук җаваплылык, шул ук балалар, үзем шул ук лабаса. Әмма син исән вакытта бермә-бер ким булган миңа төшкән җаваплылык. Бермә-бер ваемсыз һәм тыныч булганмын. Менә хәзер исемә төшерсәм, башларым әйләнеп китә. Җил-яңгыр тидермичә үстерә алырмынмы балаларымны? Аякка бастырып, чын кешеләр итә алырмынмы? Үземдә шундый көч булырга тиешлеген, ана булып та, ата булып та тәрбия кылырга кирәклеген яхшы аңлыйм. Барысына да әзер торырга, нык булырга тырышам. Ә иң мөһиме — балаларымның ата балалары булуы белән горурланам. Табынырлык мирасың, җырларлык җырларың калуына шатланам. Кызларыбызның син язган һәр әсәрне белеп үсүләрен, тәмен, матурлыгын тоя алуларын телим. Хикәяләреңне үзләреннән үк русчага тәрҗемә иттерәм, шигырьләреңне ятлатам, җырларыңны өйрәтәм. Әле Зиннур Гыйбадуллин язган көйгә «Яшьлегем тугае»н җырлап утырдык. Берничә кат җырлагач, кечкенә Резеда:

— Әни-и, кемнең күзләре сагышлы дигән ул эти? — дип сорады.

— Безнең инде, кызым. Безнең күзләргә менә шулай моң, сагыш туласын алдан күргән ул этиең, — дидем.

Балалар, җырлаудан туктап, тынып калдылар.

Соңгы көннәрдә, чынлап та, әллә нинди сызлану бар иде синең йөрәгеңдә. Безгә карата нindiдер сәер җәлләү тойгысы бар иде. Мөгаен: «Каласыз бит, җанкисәкләрем», — дип уйлагансыңдыр. Мөгаен, безгә генә әйтмәгәнсеңдер...

Соңгы көнеңне секундына кадәр күз алдымнан кичерәм. Эштән гадәттәгегә караганда иртәрәк кайттың. Пешергән ашымны мактап, кат-кат бүлдереп ашадың. Аннары аякларыңны бөкләп идәнгә утырдың, аяк киемнәренең сүтелгән җирләрен тектең. Ватылган караватны башын рәтләп куйдың. Чалбарларыңны чистартып үтүкләдең. Соң гына йокларга яттык. Икенче көнне, иртәрәк торырга теләсәм дә, яныңнан җибәрмәдең. Никтер сөйләшәсең килә иде ул көнне. «Әллә нинди язмаган төшләр керә. Төш күргәндә баш мие ял итми икән», — дип, газетада медицина белгече чыгышын укуыңны әйттең.

— Бүген нинди төш күрдең? — дип сорадым мин.

— Өерелеп этләр килде, таларга. Каяндыр ысылдап елан шуышып чыкты, — дидең.

— Әй, өнеңдәге этләр кергән. Бу арада ак маңгайлы бүреләр, әллә нинди этләр белән хыялланып йөрисең бит, — дидем.

Чынлап та, нәкъ шул көннәрдә үк булмаса да, күптән түгел «Ак маңгайлы бүреләр» исемле повесть төгәлләгән идең син. Балалар өчен язылган бу әсәр — урманга качып киткән, шундый да акыллы эттән үрчеп таралган ак маңгайлы бүреләр һәм үзеңнең балачагың турында. Шул чакта этләр, бүреләр турында күп укыдың. Шуңа күрә әлеге төшнең дә шул повесть шаукымы булуы бәхәссез иде.

Соңыннан игътибар иттем: этләр турында язып алган мәгълүматларың шактый калган. Колли, лайка, овчарка, эрдель-терьер дигән эт токымнарын теркәп куйгансың. Атаклы сәяхәтче һәм географ Георгий Седовның Фрам кушаматлы эте булуын, озын сәяхәт вакытында Седовның зәңгелә авыруыннан үлүен, диңгезчеләрнең аны Рудольф утравына җирләвен язгансың. Ә Фрам, сәяхәтчеләр никадәр генә үзләре белән алырга теләсәләр дә, кабер яныннан китмәгән. Берничә көн буена шыңшый-шыңшый улаганы ишетелеп торган.

Куен дәфтәреңә күп сүз язмый идең син. Әмма ишеткән-күргәнеңне һәрвакыт ике-өч сүз белән теркәп куя идең. Әйтик: «Аракы югала, аракы түгелә. Районнан вәкил килгәч». Яки «Тәрбияләп үстергән хатын. Поезд. Хатын гел егеткә карый. Вагон, поезд, пассажирлар йоклый.

— Син кайсы авыл?

— Каракитә...»

«Берәү дустыннан акча ала да оныта (бәлки, онытмыйдыр да). Дусты көтә-көтә дә, бирәчәген исенә төшерер, шәт, дип, моңа тагы акча биреп тора...»

Әнә шундый өч-дүрт җөмләле сюжетларың тора-бара менә дигән хикәя була иде. Тора-бара дип, гадәттә, суынганчы язарга тырыша идең син аларны. Кәгазь әзерләп куясың. Күзлегеңне киясең. Каләмеңне кулыңа тоткан килеш ишекле-түрле йөри башлыйсың. Йөрисең-йөрисең дә кинәт рәхәтләнеп, шаркылдап көлеп җибәрәсең. Аннан, утырып, тиз-тиз яза башлыйсың. Юмористик хикәяләрне күбесенчә шулай яза идең. Шома кәгазь яратасың, беренче вариантка сүзеңнең дә, җөмләңнең дә яртысын гына, хәтта кайбер сүзләрнең бер-ике хәрефен генә куеп чыгасың. Артыңнан кемдер куып килгәндәй кызу кыланасың. Әле хәзер уйлыйм: уйларың куган сине. Уйларыңа җитешергә тырышып, ак кәгазь өстеннән каләмең, каләмеңне кысып тоткан бармакларың йөгергән. Менә шулай. Язып бетерәсең дә әкрен генә, җайлап кына күчереп чыгасың. Күңелеңә аеруча хуш килсә, көлә-көлә бездән ике генә кат түбәндә яшәүче Зөлфәткә төшеп китәсең. Ләкин бервакытта да язган әсәрең белән мактанып йөргәнеңне хәтерләмим. Ничектер көндәлек хезмәт итеп карый идең син бу эшкә. Дөнья мәшәкатьләре белән өстәл артына озаграк утыра алмый торсаң, эчең поша башлый. «Язасы әйбер күбәйде, чистый туйдым бу вак-төяк мәшәкатьләрдән», — ди торган идең. Каядыр аулакка, шау-шусыз, тыныч җиргә китәсең килә иде. «Урман каравылчысының эше шәп, ичмасам, һавасы саф, машина гөрелтесе юк», — дияр идең. Аннан соң тагын бер мәртәбә диңгезгә чыгып кайту теләгең дә юк түгел. Ләкин энинең өлкән яшьтә булуы сагайтты сине. Олы улы кайтса да: «Соңгы күрүемдер, бәхил бул», — дип хушлашып кала. Ә Шәүкәт абый йомшак кына итеп: «Үлмисең әле, эни, исәнлектә күрешәбез», — ди.

Шәүкәт абый — синең бертуганың. Бер ата, бер ана балалары сез. Кыз туганнарыгызның гомере булмаган. Наилә исемле апаң Казанның Татар зиратына күмелгән. Фирүзә белән син яткан төбәккә.

Уйларым һаман синең юклыгыңа барып кагылса да, мин бүген исән вакытыңны гына уйларга тырышам. Матур гадәтләреңне исемә төшерәм. Үземчә терелтәм, үземчә яңартам.

Иң соклангыч якларыңның берсе туган җанлылык иде. Шәүкәт абый белән, мәсәлән, гаҗәп нык яратыша, хөрмәт итешәсез. Очрашкач, ирләрчә бер ныклык белән кочаклашып күрешә, озаклап балачак истәлекләрен сөйләшеп утыра идегез. Икегезнең дә хәтере яхшы. Сез сөйләгәндә кечкенә вакытыгыз энәсеннән җебенә кадәр күз алдына килеп баса. Яшь аермасы өч кенә ел сезнең. Бергә уйнагансыз, кая барсагыз да, бергә йөргәнсез, хәтта бер үк классларда укыгансыз. Билгеләрегез икегезнең дә яхшы. Синең җидееллык һәм урта мәктәпләрне тәмамлаган документларыңны хәзер дә сокланып, горурланып кулга алам.

«Матур әдәбиятны күп укыдык», — ди торган идең. Сөйләвеңә караганда, авыл китапханәсендәге китапларны ярышып укыгансыз. Тик Шәүкәт абый алданрак укып бетергән.

Балигъ булгач, җирнең бер читеннән икенче читенә, диңгез белән коры җир арасында ихлас күңелдән язылган, шуклык, шаянлык белән тулган хатлар йөри башлаган. Абыеңның кара-каршы сөйләшеп утыргандай оста итеп язылган хатларын көтеп аласың, озаграк җавап килми торса, хафалана башлыйсың. Көндәлек кебегрәк бер дәфтәргә язылган менә бу истәлек, мөгаен, шундый борчулы көннәреңнең берсендә теркәлгәндер:

*«Җир шарының кайсы почмагында икән син? Мин монда «Казан» дигән ноктаның бер читендә ялгызым.*

*Ә син зур океанда. Кайсы портка якынлашып киләсең икән син, абый? Кайсы илгә, кайсы шәһәргә, кайсы ноктага, кайсы төрткегә?.. Бәлки, әти каберенәдер?*

*Җир шары зур... Син дүрт океанның берсендә... Син Атлантида шәһәрләренең берсендә, айга карап, туган авылны сагынып:*

*Урман аша юлларым...*
*Урман аша, сулар аша,*
*Сузсам, җитми кулларым, —*

*дип җырлап утырасыңдыр...*
*15/VIII–77, Казан, төн».*

Бу көйне, бу җырны син үзең дә бик җырлый идең. Ә Шәүкәт абыйны әйткән дә юк. Татар көен, татар моңын бик сагынып кайта. Илгә кайтуга, Г.Рәхимкулов, И.Шакиров, Ә.Авзаловаларның җырлары язылган пластинкалар җыя башлый. Аннан соң, һәр кайтуында классташы һәм балачак дусты Рәмзи Вәлиевне күреп китәргә тырыша. Рәмзи абый хәзер В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының тарих кафедрасында тарих фәннәре кандидаты. Авылда укыганда ук русчаны бик шәп белә иде, дип сөйлисез сез аның турында. Әти-эниләре бакча тутырып кыяр утырта торган булганнар. Кайчагында, Рәмзинең үзен ияртеп сыйланырга керә идек, дип көлешәсез.

Шәүкәт абый — ана телендә бер утырып сөйләшергә зар булып, чит җирләрдә җирсеп йөргән илдәшләребезнең тере шаһиты. Ләкин ул Ватан алдындагы изге бурычын үтәп йөри. Җаны яраткан хезмәтне башкара.

Синең язмаңдагы *«Кайсы портка якынлашып киләсең икән син, абый?.. Кайсы ноктага, кайсы төрткегә?.. Бәлки, эти каберенәдер?»* дигән җөмләгә аерым тукталасы килә. Әтиегез Шәфигуллин Хафиз Рәхмәтулла улы Зеленодольск районының Карашәм зиратына күмелгән сезнең. Үзең үлгәч, Карашәм китапханәсеннән сезнең нәсел шәҗәрәсен күчереп китерделәр. Рәхмәтулла бабаңнан соң: Ибраһим, Монасыйп, Габдерафик, Гаделша, Хөрмәтша, Ибраһим, Дусмәмәт, Абделхалик бабаңнар теркәлгән анда. Синең белән унике буын.

«1943 елның әче буранлы кышы иде, — дип сөйли әни. — Атагызны шундый көнне күмделәр. Язга чыккач чардуган куючы кеше булмады. Сугыш чоры: чардуган кайгысымы кешедә? Ә еллар узгач, күмүче кешеләр үзләре дә таралып бетте. Шулай итеп, кабер югалды».

Яшең олыгайган саен, этиеңнең баш очына утырып бер сөйләшү теләге көчәйде синдә. Каберен чардуганлыйсың, агач утыртасың килде. Әмма вакыт күп узган, син эзли башлаганда, этиеңне җирләгән кешеләрнең иң соңгысы да дөнья куйган булып чыкты. Әмма күңелеңдә этиеңә карата олы мәхәббәт яшәде. Синең аша мин дә каенатамның агач эшкәртү серен яхшы белүен, әйбәт балта остасы булуын, үләр алдыннан гына тәрәзә капкачларын, кәрнизләрне бизәкләп, алты почмаклы зур өй салып калдыруын, тәрәзә каршына куш миләш утыртуын, авыру сәбәпле сугышка бара алмавын, иң авыр елларда колхозны җитәкләвен, риясыз кеше булуын беләм. Әҗәленә дә шул риясызлыгы сәбәпче булган. Соңгы сулышына кадәр халык өчен, ил өчен, фронт өчен көрәшкән тынгысыз бәндә ат белән район үзәгенә киткән. Кайтканда, көчле буран чыгып, адашкан. Бик каты салкын тидереп, көч-хәл белән өенә кайтып егылган һәм, ике як үпкәсе дә шешеп, үлеп киткән...

«Шәүкәт абыйны гел әтигә охшатам, эти кебек күрәм», — ди торган идең син. Кечкенәдән үк һәр яхшы эшне аның үрнәгендә башлагансың. Әйтик, шигырьләрне иң әүвәл Шәүкәт абый язган. Рәсемне дә иң элек ул төшергән. Диңгезгә дә башлап Шәүкәт абый чыгып киткән. Аның артыннан син дә Ерак Көнчыгышка юл алгансың. Аны кабатлап, хәтсез матур рәсемнәр ясагансың. Абыеңнан уздырырга тырышып, шигырь язгансың. Аннан, чит җирләрдә шактый гына каңгырып йөргәннән соң, Зеленодольск каласына кайтып урнашкансың. Анда исә Идрис ага Туктар синдәй өметле яшьләрне бер түгәрәккә җыйнап торган. Назыйм Ханзафаров, Азат Вергазов, Вил Шәрәфетдинов... Еш булмаса да, очраша, күңелле итеп сөйләшә, гәпләшеп утыра идегез.

Вилләр дә күптән түгел килеп урнашканнар Зеленодольск шәһәренә. Ул училищеда эшли. Бик еш аның осталыгына хәйран кала идең син. Ул бүләк иткән, агачка яндырып ясаган В.И.Ленин портретын гомер буе кадерләп саклады. Кулыннан гөл коя торган бу иптәшең турында очерк язарга йөрдең. Әмма... Әнә шулай, теләгең булып та үти алмый калган эшләрең ничектер минем өстә аманәт булып калгандай тоела.

Син якын иткән бөтен кеше кадерле миңа. Мәсәлән, «Яшь ленинчы» газетасы редакторы Роза Туфитуловага соклана идең. «Әгәр мин рәссам булсам, иң беренче чиратта күзләрен ясар идем аның. Сөйкемле, җәмал күзләрен. Җаны үлә башлаганнарны җылы карашы белән терелтә ала...» — ди идең.

Изгелек кылучы кешеләр Исрафил фәрештә нәселеннән яралган, ди безнең әни. Иске китапларны күп укый ул. Без дүрт нәсел, дүрт фәрештә балалары, ди: Исрафил, Җәбраил, Микаил, Газраил. Әйе, Газраилдән — җан алучыдан да таралган икән кеше дигәнең. Дөньялыкта усаллар да кирәктер шул. Юньле бәндәләргә аяк чалыр өчен, кәефләрен бозар өчен, җаннарын кыяр өчен... Болар — борынгы китаплар авазы. Ә без бүгенге көннән чыгып фикер йөртәбез. Кешене кылган эшләренә, күрсәткән хезмәтенә карап бәялибез. Үткән юлын күз алдыннан кичерәбез.

Синең егерме өч яшеңдә Рәсәйнең аркылысын-буен гизеп, кабат туган якларыңа кайтып урнашуың турында яза башлаган идем бит әле... Кайтуга, район һәм республика газета-журналлары белән тыгыз элемтәгә кергәнсең син. Һәм шул елларда ук матур-матур шигырьләр бастыра башлагансың.

Уйлама син: йөрәгеңнең уты
Учак кебек янар-янар да
Салкын җилдә кинәт тетрәп сүнәр,
Көл дә калмас, диеп, аңардан...

Районыгызның «Идел ягы» исемле газетасында Шәүкәт абыйның да байтак шигырьләрен туплап чыгаргансың. Өйләнешкәч, менә нинди туганым бар дигәндәй, олы бер горурлык хисе белән миңа да күрсәттең. Ләкин шигырьләренә караганда рәсемнәре гүзәлрәк Шәүкәт абыйның. Үз күзе белән күргәнне, үз күңеле белән тойганны төшерә ул полотнога. Диңгездә әзерләгән күргәзмәсен караган СССР Художниклар берлеге әгъзасы И.Рыбачук язган мәкалә әнә шул турыда сөйли.

«Командировкада Петропавловск-Камчатскига кадәр «Илья Мечников» теплоходында барырга туры килде миңа», — дип яза ул. (Нәкъ шул вакытта теплоходта Шәүкәт абыйның утыздан артык рәсеме куелган була.) «Рәсемнәрнең күпчелегендә диңгез күренешләре. Сәнгатьне тоеп ясалганнар. Мин аларны зур кызыксыну белән карадым. Шундый рәссамнары булуы белән экипаж горурлана ала!» — дип тәгәлли язмасын Рыбачук. Шушы мәкаләне укыгач: «Зур кеше биргән бәя, белгеч биргән бәя», — дип утыруың әле дә күз алдымда, Фаил.

Шәүкәт абый, дөрестән дә, сәләтле, талантлы кеше. Ләкин бик тыйнак ул. Үзен рәссам дип түгел, иң беренче чиратта диңгезче итеп хис итә. Түш кесәсендә махсус паспорт йөри аның. Йөк ташучы теплоходта чит илләргә чыга. Әнә соңгы хатында да, Яңа Зеландиягә китәчәкбез, дип яза. Хәерле юл аңа. Үзе әйтмешли, исәнлектә күрешергә язсын, хәерле юл! Хәерле сәгатьне мин генә теләмим Шәүкәт абыйга. Әнигә, хатынына, ике баласына кушылып, Фаилнең дә ике кызы тели. Бу дөньяда әтиләреннән кала иң кадерле, иң якын кешеләре ич ул аларның!

Еш кына безгә җибәргән рәсемнәре янына киләбез, оста кулына сокланабыз. Шул чагында гаҗәп охшатып ясаган зәңгәр күзле туганы гүя телгә килә. Зәңгәр офыклар, алтын иген кырлары артында гүя Фаилнең көчле тавышы яңгырый...

Бүген шуңа бик сөенәм мин: безнең өйдә магнитофон тасмасына язылган тавышың калды синең, Фаил. Хәер, эндәшүең, сөйләшүең гел колак төбендә тора торуын, ләкин бу язмалар икенчерәк. Беренчесе — өйләнешкән елларны, мәрхүм Тәүфикъ Камалиев, Зөлфәт, син бергә утырганда, икенчесе Балтач баҗаңа кунакка баргач (ул да мәрхүм инде хәзер) язып алынган. Өченчесе — үләреңә бер атна чамасы калгач... Тавышың көр. Баштагыларында — шигырьләрең, соңгысында Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ут чәчәге» романыннан бер өзек укыйсың.

Тәүфикъ турында сүз чыккач, сезнең арада дустанә мөнәсәбәт, бер-берегезгә карата олы ихтирам булуын әйтмичә кала алмыйм. Берәр шатлыгы булса, Тәүфикъ һәрвакыт сиңа эндәшә. Без дә, еш кына гаиләбез белән җыелып, аларга китә идек. Шулай бер баруыбызда өч альбом китереп тоттырды Тәүфикъ. Альбомнарында олы кызлары Миләүшәнең рәсемнәре җыелган. Кайсы ябыштырып, кайсы тегеп куелган. Боларның барысын да Тәүфикъ үзе туплаган иде. Балаларны әнә шулай бик яратты ул. Гаиләсен хөрмәт итте. Томрап торган ике кызы, чәчәк кебек хатыны калды Тәүфикъның. Аларга караган саен җан сыкрый. Нәрсә теләсә, шуны тәмле итеп әзерли белгән Розасы ир тәрбияләр өчен генә, түгәрәк гаиләдә бөтерелеп йөрер өчен генә яратылгандай лабаса...

Тормыш аяусыз. Кайсыбызның ни өчен яратылуында эше юк аның!..

*«Шагыйрь Тәүфикъ Камалиев арабыздан вакытсыз китте. Ул чын мәгънәсендә бала җанлы кеше, балаларның эчкерсез дусты иде.*

*«Ялкын» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшләгән чорында, Т.Камалиев балалар иҗатын үстерүгә күп көч куйды. Берәр укучыдан уңышлырак иҗат ителгән рәсем, шигырь яки хикәя килсә, Тәүфикъ чын күңеленнән шатлана һәм һич кичекмәстән, яшь авторны котлап, теләкләр теләп, киңәшләрен әйтеп аңа хат яза иде. Бер генә яшь талант та читтә калмый иде Т.Камалиев игътибарыннан»,* — дип яздың син аның «Казан утлары»нда чыккан шигырьләренә сүз башында.

Үлгәч тә өч көнлек эш кала, диләр. Синең, чынлап та, мин белгән бер олы эшең калды. Ул Тәүфикъның мирасын, сүз башы язып, китап итеп чыгару иде. Кызганычка каршы, Тәүфикътан соң үзең дә озак яшәмәдең шул.

Кеше уйлана. Көннәр-төннәр буе уйласаң да, айлар-еллар буе уйласаң да, очына чыгып булмый ул уйларның. Әмма уйны да, сүзне дә озынга сузмыйча, өзеп җавап бирерлек хакыйкать бар. Ул — булган гомереңдә көлеп, тормышның кадерен белеп яшәвең. Елап яшәгән, елап сөйләшкән кешене гомергә өнәмәдең син. Мәсәлән, олы яшьтә булуына карамастан, кулындагы бизәкле таягын тылсымчы кебек бөтерелдереп, гөр итеп торган Нури ага Арсланов ошый иде сиңа. Ул кара көздә... юбилей елы иде Нури абыйның. Сине юбилей үткәрү комиссиясе әгъзасы итеп сайлаганнар. Бу безнең парлап барырга тиешле беренче зур мәҗлес иде. Хәтта Пицунда ял йортында да шул турыда берничә тапкыр искә алдык, ничек киенеп бару турында сөйләштек. Мин озын зәңгәр күлмәктән, ә син сөтле чәй төсендәге батник һәм кара костюмнан барырга тиеш идең.

— Фаил, Нури абыйны кайчаннан беләсең син? — дип сорадым мин шулчак.

— «Казан утлары»нда бергә эшләдек бит, — дидең.

Хәтерлим, яхшы хәтерлим. Бервакыт шагыйрь Нури Арсланов иҗатына багышланган телевизион тапшыру булды. Тапшыруда катнашу өчен, шәкертләре буларак, Зөлфәт белән сине чакырды ул. Бик матур көзге паркта сөйләшеп йөргәндә кинога төшергәннәр иде үзегезне.

Ул вакытта «Казан утлары» журналы Бауман урамындагы унтугызынчы йортның хәзерге Язучылар берлеге бүлмәләрендә иде. Зәки Нури, Ләбибә Ихсанова, Вакыйф Нуруллин, Фәрваз Миңнуллин һәм башкалар эшлисез. Шул чакта килеп чыккан кечкенә генә детальдән, әдәбият-сәнгать өлкәсендә эшләүче бөтен Нуруллин һәм Миңнуллиннарны бутап, бик кызык хикәя язган идең. Аннан соң Мөштек Әпкәли Төребкәле псевдонимы белән шактый шаулап алдың син ул елларда. Язучылар берлеге каршында чыга торган «Тынгысыз каләм» стена газетасы редакторы буларак, күңел биреп мәкаләләр яза идең. Шундый оста ягың бар: кешенең нинди дә булса үзгә сыйфатын тотып алырга дисәң, сиңа куш. Шул гадәтен хәзер, чебеннән филгә кадәр дигәндәй, үстереп бирәсең. Менә дигән хикәя яки портрет язып куясың.

Бу урында тукталып, шул вакытта ук язылып та, китабыңа керми калган бер эскизыңны укучыга тәкъдим итәсе килә. «Казанга Пеле килгәч» дип атала ул.

*«Ташаяк урамында Мәхмүт Хөсәенне бер кеше туктатты. Алар арасында мондый сөйләшү булып алды.*

*— Мине танысыңмы? — диде таныш түгел кеше.*

*— Юк, танымыйм, кем соң син? — диде Мәхмүт Хөсәен.*

*— Мин Пеле бит. Бразилия футболчысы.*

*— Мин татар шагыйре Мәхмүт Хөсәен. Мусаны ишеткәнең бармы?*

*— О, Муса!*

*— Гуд бай, Пеле!*

*— Гуд бай, Муса!*

*Күңелсезләнеп кенә барганда, Пелегә Нәби Дәүли очрады.*

*— Мине танысыңмы? — диде Пеле, Нәби Дәүли белән кул биреп күрешкәч.*

*— Ә син мине танысыңмы?*

*— Соң, мин Пеле ләбаса. Атаклы футболчы.*

*— Булмагаең.*

*— Мине бөтен дөнья белә.*

*— Анда минем ни эшем бар?*

*— Мин Пеленең үзе.*

*— Синең кебек Пелеләр буа буарлык безнең Казанда...*

*— Бонжур, алайса.*

*— Бар, бар, әйдә, юлыңда бул...*

*Пеленең тәмам кәефе кырылды. Буфетка керде. Анда Мөдәррис Әгъләмов чәй эчеп утыра иде.*

*Пеле ашыгып аның янына барды, кулын бирде:*

*— Мине танысыңмы, иптәш?*

*— Таныйм, билгеле, — диде Мөдәррис Әгъләмов, — ничек соң әле исемең? Тел очында гына тора.*

*— Пеле мин.*

*— Ә, әйе, әйе, Пеле. Мин башта сине Хуан Себастьян дель Кано белән бутаган идем.*

*— Ә, «Виктория» каравелласы капитанын әйтәсеңме? Соң, ул сәяхәтче бит, ә мин футболчы.*

*— Себастьян дель Кано да футбол уйнаган.*

*— Нишләптер ишеткәнем юк.*

*— Уйнаган. 1525 елның җәендә Филиппин утрауларында испаннар ягында уйнаган ул. Капкада Гарсия Хофре де Лойза үзе торган. Испаннар Пунта Аренас командасын 12 : 2 исәбенә откannар.*

*— О!*

*— Аннары, 1531 елда Трухильо шәһәрендә...*

*— Бонжур, Мөдәррис, ашыгам...*

*Ишек төбендә Пеле Рәдиф Гатауллинны күреп алды:*

*— Сәлам!*

*— Сәлам!*

*— Пеле мин.*

*— О, даһи Пеле!*

*— Футболчы Пеле мин.*

*— Тәкъсир...*

*— Мин Пеле.*

*— Күрдеңме, бөек Пеле, минем шигъри репортажымны газетага басканнар.*

*— О!*

*— О!*

*— Пока!*

*— Пока!..*

*Буфеттан чыккач, Пелегә Галимҗан Латыйп очрады.*

*— Пеле мин, танысыңмы? — диде Пеле.*

*— Ә, шулаймыни? — диде Галимҗан Латыйп, елмаеп. — Нишләп йөрисең?*

*— Пеле мин. Бразилиянең атаклы футболчысы.*

*— Сибгат Хәкимне күрдеңме соң?*

*— Юк.*

*— Әле торасыңдыр ич Казанда?*

*— Торам әле.*

*— Алай булгач, кайгырма, күрерсең.*

*— О’кей!*

*— Исән бул, Пеле!*

*Ашыгып урам буенча барганда, Пеле чак кына Гәрәй Рәхимне бәреп екмады.*

*— Мине танысыңмы? — диде Пеле гадәтенчә.*

*— Кайдадыр күргән дә кебек, — диде Гәрәй Рәхим, кызарып.*

*— Пеле мин.*

*— Кит аннан! Кая урнаштың?*

*— «Дружба»га.*

*— «Татарстан»га кирәк иде. Ярар, Союзга кайткач, мин Фәйзуллинга әйтермен.*

*— О’кей!*

*Гәрәй Рәхим урам чатына кереп күздән югалган гына иде, Пеле каршысына Миркасыйм Госманов килеп туктады. Пеленең күзләрендә өмет чаткылары кабынды.*

*— Әллә мине таныйсыңмы? — диде ул, шатлыгын тышка чыгармаска тырышып.*

*— Синеме? Сине мин, мичкә керсәң, аяк табаныңнан таныйм.*

*— Пеле бит мин.*

*— Пеле, атаң башы! Булат Сөләйманов син. Елына ун шигырь язып, шуларны бөтен Рәсәй буенча бастырып йөри торган шагыйрь...»*

Шулай итеп, синең симпатияңә әйләнгән геройларың әллә каян аерылып тора. Хәтта иптәшләрең дә, урамда берәр кызыграк кеше күрсәләр: «Әнә Фаил герое килә», — диләр. Тышкы кыяфәтләре белән әкәмәтрәк булсалар да, чынлыкта исә көр тавышлы, сүзне өзеп сөйләшүче, җор телле кешеләр алар. «Сафура, Бәкер һәм трактор» исемле хикәяңне генә алыйк. Ир белән хатынның характерын язышкан хатлары аша ачасың син. Уенын-чынын бергә кушып, аларның кырыс мәхәббәтләрен, бер-берсенә тугрылыклы ярлар булуын сурәтлисең. Җәмәгать интересларын үз интересларыннан өстен куеп яшәүче, дәүләт милкен күз карасыдай саклаучы чын җир кешеләре турында бу хикәя. Драматизм көчле анда. Шуңа күрә артистлар тиз күреп алды аны. Бу әсәреңә генә түгел, тагын башка бик күп хикәяләреңә сәхнә гомере насыйп булды.

«Чаян» журналында эшли башлагач, юмористик хикәяләр язуга игътибарыңны арттырдың син. Бервакыт яныңа райондашың, Бәчек авылы егете, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, филармониянең нәфис сүз остасы Рәшит Сабиров килде. Бик тә итагатьле, тыйнак бу егет сәхнәдән уку өчен махсус язылган юмористик хикәяләр кирәк булуын әйтте. Тиз генә җавап бирмәдең. Эстрада өчен хикәя язу — җитмәсә, юмористик хикәя язу — уен эш түгеллеген яхшы аңлагансың, күрәсең. Байтак уйлаганнан соң, карап карарбыз, дидең. Менә шуннан башлап шактый күп эш эшләдегез сез Рәшит белән. Талантыңны бөтен тирәнлеге белән кабул кылган, бөтен тирәнлеге белән таныган хәлдә мөрәҗәгать иткән иде ул сиңа. Тора-бара Рәшит Сабировның репертуарын синең иҗатыңнан тыш күз алдына китерүе дә авырлашты. Гомумән, кыска гына вакыт эчендә шактый күп эшләп алдың син филармониягә. Татарстанның атказанган артисткасы Римма Ибраһимова өчен «Туган җир — туган ана» исемле махсус композиция яздың. Лекторий группасы белән иҗат кичәләре, композитор Зиннур Гыйбадуллин белән мини-оперетта, дистәгә якын монтаж, скетч, диалог һәм башкалар... Шулай итеп, драматургиягә якынлашып килә идең. Һәм бу эшне дә башкарып чыгасыңа ышанычым зур иде минем.

Бик еш пьесалар укыйсың. Драматурглар, сәхнә әсәрләре турында язылган тәнкыйть мәкаләләре белән танышасың. Кайберләрен язып та аласың:

*«...Соңыннан геройның җиңүе әһәмиятле түгел, тамашачының театрдан нәрсә алып китүе әһәмиятле...»* Монысы кем сүзләре булгандыр, белмим, әмма латыш драматургы Паулс Путныньның фикере түбәндәгечә: *«Мәгълүмдер ки, драматургия — конфликтлар әдәбияты. Кешеләр арасындагы конфликтлар җитди көрәшкә җирлек тудыру сәләтенә ия булсын өчен, каршы якларның көчләре тигезләшергә, якынаерга тиеш. Олы, изге көчкә каршы зур һәм куркыныч золым куелырга тиеш. Болай караганда барысы да гади, аңлаешлы шикелле. Әмма һәрбер аерым очракта мәсьәлә алай җиңел генә хәл ителми. Әсәрнең персонажлары җанлы һәм тормышчан булырга тиеш.*

*Яхшылык һәм золым еш кына бергә үрелеп тә бирелә. Кайчагында аларны аерып алу бик үк җиңел дә булмый. Кыскасы, яхшы пьеса тормышның үзе кебек үк катлаулы булырга тиеш».*

Соңгы вакытта бик еш академия, драма һәм комедия театры артистлары уйнаган спектакльләрне карый идек. Химиклар сараенда Илдар абый Юзеевның «Кыр казлары артыннан», «Командировка» исемле спектакльләрен карадык. «Ай-яй, халыкчан! Кайчан язып өлгерә?» — дип гаҗәпләндең һәм:

— Әйтте диярсең, бөтен кеше эчен уып көләрлек комедия язам әле мин сиңа, — дидең.

— Ә ни өчен миңа?

— Гонорары кемгә була соң?

Шул кыска гына сөйләшүдән соң, син язган, мин баегандай рәхәтләнеп көлгән идек без.

И бу тормыш!

И бу гомернең кыскалыгы!

Никадәр эшләдең, ә эшләячәк эшең аннан да күп иде. Күп иде, әмма яза башлаганы да тәгәлләнмичә калды аларның. Синең турыда «эшләде» дип сөйлибез хәзер. Каләме үткен, әйткән сүзе саллы иде, дибез. Саллылыкка, чынлап та, саллы. Ә әйтеләсе сүзләрең, бәлки, боларыннан да саллы булгандыр. Соңгы вакытта комедия язу теләгең көчәйде. Ат һәм ат караучы турында булырга тиеш иде

ул комедия. Синең сөйләвең буенча, киртәләре тузып беткән ихата тирәли үлән чемченеп йөргән ялгыз карт алашаны күз алдына китерә идем...

Яшүсмер чагында атлы эштә йөргәнсең. Шуңа күрәдерме атларга мәхәббәтең аеруча зур булды. Авыл тирәсенә кайтып атка утырсак, дилбегәне үз кулыңа аласың, йомшак кына: «На-а, малкай!» — дип эндәшәсең. Синең «Өй салуның ние бар?» дигән повестеңны укыган кешеләр Рәсимнең Карлыгач исемле атына нинди мөнәсәбәттә булуын яхшы хәтерлиләр булыр. Карлыгач, чынлап та, синең кечкенә вакытта җигеп йөргән атың. Акыллы, сөлек кебек суырылып чабучы Карлыгачның, картайгач, ит нәрәтенә озатылуын белдең син. Аның карусыз, күндәм булуын, сине әллә каян танып кешнәп җибәрүен кайтып-кайтып исеңә төшерә идең. Аның турында кеше хезмәтен бәяләгән кебек матур итеп сөйлисең, дөньяда иң әйбәт җан иясен сурәтләгәндәй, һәр кыланмышын тасвирлап күрсәтәсең. «Өй салуның ние бар?» исемле повестеңда язылып бетмәгән өлешнең күбесе шул Карлыгач турында булырга тиеш иде, минемчә. Болар барысы да гөманлау, фараз кылу гына. Ә чынлыкта, Рәсимнәрнең, Тәслимәләрнең, Хәбирләрнең киләчәк язмышын төягән Карлыгачың белән бергә киттең дә югалдың!.. Җигүле ат сыяр күңелең, бихисап күп серләреең белән киттең. Ләкин йөзләгән геройларың халык күңелендә калды. Аларны нинди дә булса башка язучы персонажлары белән бутау мөмкин түгел. Һәркайсы: «Без Фаил хыялында яралдык», — дип кычкырып торалар. Аларга карата туган мәхәббәт, торган саен илаһилана барып, безнең күңелләрдә яши!

Нәрсә сөйләп озатып калды сине ак каен,
Балачагымның хыялы — акбүз аткаем?
...Җанны назлый якты бер моң — исемә төшми;
Кайдадыр таулар артында акбүз ат кешни...

Ата-бабадан килгән атка өмет белән карау, туйдыручы итеп карау гадәте бу. Шатлыклы ат ярату галәмәте. Гражданнар, Бөек Ватан сугышы елларында өермә булып дошман өненә томырылган атларның каһарманлыгын күрә алу сәләте. Шигърият символы булган Пегас кебек, мәһабәт ялларын җилфердәтеп, хыялларыбызда чабучы канатлы ат романтикасы.

Әйбер җыярга әвәслек юк иде безнең. Синең дә, минем дә. Шулай да Күктүбәгә («Планерское» иҗат йортына) баргач, бумази материалга өч ат сурәте төшерелгән ковер димме сатып алдык. Кыйммәтле әйбер түгел, әмма атлары сиңа бик ошады. Шуннан бирле озак вакытлар стенада эленеп торды ул. Үтешли кергән Альберт абый Яхинны да битараф калдырмады ул. Ләкин сыный карагач, рәссамның әллә никадәр ялгышын таптыгыз. Шул вакыт син Альберт абыйның туры сүзле кеше булуын, гади комбайнчыдан «Чаян» журналы редакторы, филология фәннәре кандидатына кадәр күтәрелүен әйттең. Ә минем күңелемдә аның шәхесенә карата икенче яклап ихтирам уянды.

Кофены үзе төеп, үзе әзерләве турында сөйләгәндә үк мин аның хуҗалыклы ир булуын аңладым. Бераздан табынга карап сорау бирде Альберт абый. Өстәлең гел шушылай буламы, сеңлем? Тиз генә әзерләгән гадәти табыныма карап, кыенсынып куйдым. Ә ул сиңа карады да: «Хатыныңның кадерен бел! Сакла!» — диде. Белмим, әзрәк чуалган чакларны ишетеп әйтүе булгандырмы аның, әллә болай гынамы, әмма бу сүзе күп еллар җанымны җылытып яшәде минем. Мөһер сугылган мактау кәгазьләреннән, кыйммәтле бүләкләрдән дә кыйммәтлерәк булып күңел түремне бизәде!

Хатын-кыз була торып, миндә дә атларга карата ярату хисе уятуыңны һәм бу хиснең синнән йоккан чир икәнен әйтәсе килә.

Синнән йогып калган «чир»ләр байтак безнең гаиләдә. Кызларымның сиңа охшап иртәчел булуларына, йоклап ятмауларына шатланам. Икесенең дә рәсем сәнгатенә битараф булмауларын күреп куанам. Ләкин балаларымның «әти» дип әйтер кешеләре булмавын күреп йөрәк яна. Бер-беребезгә күрсәтелә торган кадер-хөрмәтнең ярты юлда тукталып калуына күңел гасабилана.

Кадер-хөрмәт дигәннән, хатын-кыз өчен ир тәрбияләү, гаилә карау — ләззәтле бер эш.

Син яшелчә ризыклары ярата идең. Иртә яздан яшел суган, редиска салаты ясый башлыйбыз. Май кычытканы ашы пешерәбез. Еш кына йомырка белән уып кәбестә пирогы әзерлибез. Тозлырак итеп пешерелгән ярмалы бәрәңгедән көненә ничә пешерсәм дә ялыкмыйсың. Әмма боламыгын һәм ит турагычтан чыгарган итне өнәми идең. Инде авылга кайтсак — шулпалы ит бәлеше. Синең сөйгән ашны әйтмичә дә беләләр анда. Иртән торуга, бәлеше пешкән, мунчасы томаланган була әнкәйнең. Үзе, яңа сауган сөтен тотып, синең янда басып тора. Йомшак тавышы белән: «Кияү-ү, йокыңны ачмый гына менә бу сөтне эчеп җибәр әле», — ди.

Соң гына торып, әткәй-әнкәй барып, «тәмләтеп» кайткан мунчага без китәбез. Син чабынырга хирыс. Эссе мунча яратасың. Ял итә-итә чабынасың да чоланга чыгып хәл аласың. «Чабыну — үзенә күрә бер массаж ул, нерв системасын ныгыта», — дисең. «Ничә көн чабынсаң, гомерең шуның кадәр озын була», — дип, халык әйтемен искә төшерәсең.

Әткәй-әнкәй генә түгел, авыл халкы да зурлый, олылый иде сине. Исемең — әдип кенә, балаларыбыз — әдип балалары. Кайтып күзләренә күренүгә, урамның бер очыннан икенче очына ашка йөртәләр, моң-зарларын, күргән-белгәннәрен сөйлиләр. Хәтсез еш кайта идек без минем үскән

авылыма. Кайткан саен нәрсә дә булса яза идең син. Авыл халкы белән гади итеп, үзең белән тиң итеп сөйләшә идең. Таң белән торып, басуларны, тауларны, чишмәләрне әйләнеп чыга идең.

— Тәмле сулы бер чишмәгез бар икән, эткәй. Менә бераз суын алып кайттым, зәм-зәм суын, — дип, эткәйгә бер шешә сузасың.

— Кайсы чишмәгә бардың? Качкын очынамы, Галләм чишмәсенәме? — ди эткәй, синең сүзеңә ышанып.

— Иллә беркатлы да инде, — ди әнкәй киявенең хәйләсен аңламаган эткәй турында. Аннан, сүзне уенга борып: — Бу арада тешләре сызлый әле этиегезнең, — ди.

— Молодец, әнкәй, синең белән сөйләшеп була, — дисең көлеп. Минем әнкәй-эткәйгә һәрвакыт ягымлы итеп «эткәй-әнкәй» дип эндәшәсең. Эшләрен эшләшәсең, күңелле итеп гәпләшеп утырасың. Берничә көннән безнең китәр вакыт җитә.

— Санаулы көн бик тиз үтә, күргән күк тә булмадык, тагы кайтыгыз, — дип озатып калалар безне.

Кайткан булыр идек. Тагы күп мәртәбәләр кайткан булыр идек, билгеле. Тик синең гомерең генә шундый кыска булып, үкенечле булып төгәлләнде! Юкса кайчан гына күрешеп-таныштык та, кайчан гына... беренче очрашуларга чыктык...

Семинар вакыты. Байтак кына башлап язучылар белән рәттән синең дә иҗатыңны тикшерделәр ул елны. Сөйләүчеләр — Хәсән Туфан белән Нәби Дәүли. Миңа беркетмә язарга кушылган. Моңа кадәр андый чыгышларны тыңлау бәхете тигәнмени миңа? Язучыларны канатсыз фәрештәләргә тиңләп йөргән авыл кызына бу баштан ашкан шатлык иде. Мөкиббән китеп язуымнан туктаганмын. Кинәт: «Эльмира, мәрткә киттеңме әллә?» — дигән таләпчән тавышка сискәнеп киттем. Ашыгып яза башладым. Бу синең көчле тавышың иде. Онытылып тыңлап, нәкъ синең турыда әйтелгән әйбәт сүзләрне теркәми калдыра язганмын, имеш.

...Аннан соң ап-ак чәчле, җор телле Идрис Туктар белән танышып киттем мин. Ул берничә йомышы барлыгын белдерде. Шул «йомыш»ның үтәлешен белергә Зеленодольск каласыннан син килә башладың...

Безнең дуслык әнә шулай башланды. Эш сәгатем бетеп урамга чыгуга, зур зәңгәр күзләреңне елтыратып син көтеп торасың. Киногa керергә тәкъдим итәсең. Паркта йөрергә чакырасың. Озаграк тоткарланып, поездга соңга калган чакларың да булган. Соңыннан, өйләнешкәч сөйләдең, кире кайтканда йокыга талып, берничә тапкыр Канашны да узып киткәләгәнсең. Ул вакытта заводта эшли идең. Эшеңнең гаять авыр булуын, сиңа кияүгә чыгып, шәһәрегезгә күчеп килгәч, син эшләгән заводка эшкә урнашкач кына белдем мин. Ул вакытларда үзеңне шактый таныткан алдынгы эшче идең. Фоторәсемең — заводның Мактау тактасында, үзең шәһәр Советы депутаты. Еш кына завод газетасында мәкаләләр белән катнашасың, эшче тормышы турында язасың. Шигырьләр, хикәяләр бастырасың. Заводта эшләп, кичке мәктәпне тәмамладың, университетка, тарих-филология факультетының журналистика бүлегенә кердең.

Синең хакта җыр язасым килә, Фаил. Бик тә эшчән, тырыш кеше булуың турында. Синең гаҗәп тә сәер һәм гаҗәп тә гадәти кеше булуың хакында. Без яшәгән елларның дүрт фасылы, син колачлаган диңгезләрнең аяусыз дулкыннары, судан утка, уттан суга салып шөбһәләндергән мәрхәмәтсез соңгы төне хакында. Юк, җырның сүзләре авыр кичерешле түгел, җиңел һәм дәртле, көләч һәм якты булырга тиеш. Анда, һичшиксез, син яраткан арыш шавы, муллык вәгъдә иткән яңгыр җиле, безнең сөю бакчасында борын төрткән балаларыбыз булырга, анда безнең тормышның иң гүзәл мизгелләре теркәлергә тиеш...

Исән булсаң, тиеш әйберләр күп булыр ул дияр идең син. Ә мин көләр идем. Көләр идем дә ничек итеп өйләнешүебез турында сөйләп китәр идем.

Кызык булды ул безнең өйләнешү... «Борынгылар шәригать буенча шушы көнне өйләнгәннәр», — дип сөйләшенгән вакытны да көтмичә килеп җиттең син.

Ә мин:

— Бөтен әйберләрем дә әзер түгел ич әле, — дип каршы төшмәкче булдым.

— Аның каравы урамда машина әзер, — дидең.

Киттек. Таксига әйберләрне төядек тә киттек. Алгы утыргычка үзең кереп утырдың, мендәр-ястыкларым янына — мин...

Көз үтте, кыш үтте, яз үтте, тагын җәй җитте. Зур чемоданга китаплар тутырып, Казанга җәйге сессиягә килдек без. Фатирга урнашып, бары бер генә көн тыңлап калдым лекцияләрне. Шул ук көнне кич бала тудыру йортына илттең. Ә таң белән кызыбыз туды! Безнең мәхәббәт җимешебез! Җаннарыбыздан, каннарыбыздан яралган беренче балабыз!

Хастаханәдән чыгып бераз хәл алуга, бөтен көчемне җыеп укый, әзерләнә башладым. Үҗәтләнеп зачетларга, имтиханнарга йөрим, ничек тә курсташларымнан калышмаска тырышам. Үзем генә булсам, яңа туган бала белән тулы бер сессияне җиңеп чыгарга көчем җитмәс иде, бәлки. Әмма нәкъ авыр вакытта бәби юрганы, бәби мендәре, бәби ашлары күтәреп, ерак юлны якын итеп, әнкәем килеп төште.

Квартир хуҗам Хәлимә апа белән баланы үземнән дә оста карап, мине тәрбияләп, уку өчен мөмкинлек тудырдылар. Мең рәхмәт аларга бу изгелекләре өчен, аларның олы ярдәме белән сессияне бернинди койрыксыз тәмамладым. Аннан сессия беткән көнне үк Зеленодольскига, әни янына кайтып киттек.

Шулай итеп, икәүләп киткән җирдән гаиләбез ишәеп кайтып төштек. Әни суга чыккан иде. Синең күзләреңә карап: «Менә шулай була ул тик кенә тора белмәсәң», — диде. Син әнинең шаяртуыннан бик канәгать булып кычкырып көлдең. Без өйгә уздык. Унбер квадрат метрлы бүлмәдә тагын бер җан иясе артты. Өйне тыгызлап, бала арбасы куелды.

Әле архивыңны актарып, сакланып калган документларыңны карап утырам. Шушы кечкенә генә бүлмә дә нинди зур авырлык белән алынган. Татарстан Язучылар берлегенең күпме тырышлыгы куелган. Менә 1965 елның 17 августында язылган 84 нче номерлы хат. Син эшләгән заводның хуҗаларына Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең ул вакыттагы җаваплы секретаре Зәки ага Нури тарафыннан язылган ул. Акыллы, таләпчән, кешелекле хат. Зәки абый, гомумән дә, сиңа бик күп яхшылыклар эшләгән кеше. Әле хәзер нәтиҗә чыгарам. Кечкенә генә почмак алыр өчен егермешәр-утызар ел эшли кешеләр. Малайлары үсеп өйләнерлек, кызлары кияүгә китәрлек була, ә чират һаман җитми. Ә синең 1962 елда килеп урнашып, дүрт елдан үз фатирың булу, билгеле, өлкән каләмдәшләреңнең әнә шулай аталарча кайгыртуы нәтиҗәсе.

Гомумән, әдәбият дөньясында башта ук ышанычлы, ныклы кулларга килеп эләккәнсең син. Яшь язучылар семинарында шигырьләреңнең иң могтәбәр шагыйребез тарафыннан югары бәяләнүен әйткән идем. Инде килеп, беренче проза китабыңа фатиха бирүчеләрнең язмалары:

Гариф Ахунов. 1966 ел, 17 апрель. Әлмәт.

*«Фаил Шәфигуллин. Хикәяләр. 4 табак.*

*Бүгенге башлап язучылар арасыннан әдәбиятка чынлап торып килүче прозаиклар бик сирәк. Әнә шул җәһәттән Фаил Шәфигуллин хикәяләре — игътибарга лаек әсәрләр.*

*Авторның берничә әйбәт сыйфаты бар: ул күзәтә, күрә белә. Күргәнен кыска итеп яза, сюжет төзи белә. Таушалмаган татарча теле дә бар.*

*Җыентыктагы ун хикәянең барысы да җиңел укылалар, ялыктырмыйлар. Яшь автор авыл кешеләренең төрле-төрле тойгыларын, омтылышларын шактый ук уңышлы итеп сурәтләп бирә. Монда баласын өзелеп көткән ана да, туган авылында лаборантка булып калган комсомолка кыз да, авылга кайткан яңа мулланы хур итеп җибәргән икенче бер чая кыз да, инвалидлыкка сылтаулап, урлашып яткан вак карак та, ат өчен җанын корбан итәргә әзер конюх та бар.*

*«Ана күңеле», «Өч бәти» кебек өчәр битле генә хикәяләр дә күңелдә хис уяталар. «Ана күңеле» хикәясендә улын көтеп зарыгып яшәгән ананың тойгылары матур бирелгән. Күпме вәгъдәләр биреп тә, һаман да туган авылына кайтмаган улын көтүдән ана һич туктамый. Төн. Тышта яңгыр. Ана ишегалдына чыгып керә.*

*— Әни, синме ул? — дип сорый аңардан кызы.*

*«— Мин, — диде хәлсез карчык тавышы, — әле син дә йокламадыңмыни? Кичә почта ящигын карарга оныткан идем, имеш. Хат-мазар килеп чыланып ятмасын дип чыккан идем... Карале, кызым, абыең соңгы хатында плащ алам дип язган идеме әле? Алды микән соң, Ходаем?.. И ява инде...»*

*Хикәя әнә шулай тәмамлана. «Чыланып ятмасын» дигән хат, «чыланып йөрмәсен» дигән олы малай (плащ детале) — болар хикәяне чын итеп, ананың олы күңеллелеген арттыралар.*

*...Гомумән алганда, җыентык кызыклы, хикәяләрдә автор үзе тапкан, үз күңеле белән ирешкән, укучыларга әйтәсе килгән сүз бар. Әнә шунысы кирәк тә инде аның. Редактор белән җентекләп бер карап чыккач, җыентык тагын да яхшырыр дип уйлыйм.*

*Китапны бастырып чыгарырга кирәк.*

*Хәерле юл Фаилгә!»*

«Авылым сандугачы»на икенче рецензия — Барлас Камаловныкы. Шулай ук иренмичә, эш булсын дип эшләнгән. Кызыклы һәм синең иҗатыңа бирелгән бәя буларак, кыйммәтен бүген дә югалтмаган.

Тәпи басар алдыннан үзеңә таба сузылган мондый ышанычлы кулларны күрү, талантлы кешеләрнең үз эргәләренә чакырып торган җылы карашын тою — һәркемгә тәтеми торган бәхет дияр идем мин. Өметле булуыңны вакытында тану, юнәлеш күрсәтү үзе ни тора!

1969 ел. Беренче балабыз Раушания туды. Шушы ук елны безнең кечкенә генә өебезгә икенче бер бәхет ургып керде. Ул бәхет, ул олы шатлык — синең СССР Язучылар берлегенә кабул ителүең иде.

Әле дә онытмыйм. Кояшлы, җылы көн. Син Казанда. Түземебез бетеп, кызым белән инде урамга чыгып, сине көтәбез. Бервакыт җил-җил, йөгерә-атлый кайтып киләсең. Өстеңдә — юка гәүдәңә сыланып торган зәңгәр буйлы бәйләм күлмәк, киңчә чалбар. Озын чәчең киң маңгаеңа төшеп, тузгып тора. Ара-тирә «Сәйдәш тарагы» белән, ягъни биш бармагыңны җәеп, чәчеңне төзәткәләп куясың...

Язучылар берлегенә Хәсән Туфан, Нәби Дәүли, Зәки Нури рекомендацияләре белән үттең син. Өлкән аксакалыбыз — Хәсән ага Туфанның һәр сүзен изге бер сүрә итеп кабул кылган хәлдә, сиңа биргән фатихасын тагын бер кат укымыйча кала алмыйм.

*«Әгәр дә Фаил авылда, әтисез гаиләдә түгел, ә шәһәрдә, яхшырак шартларда үскән булса, әдәби мәйданга иртәрәк килгән булыр иде. Җидееллык мәктәптән соң хезмәт дөньясы мәктәбендә (һәм әле дә шунда) яшәгән егетне бүген инде без байтак сынаулардан соң язучылар сафына чакырабыз.*

*Безнең сафка ул «әдәбичәнлек»тән — литератургщинадан түгел, тормышның — хезмәтнең үзеннән килә. Әйтми калмаслык шигъри хис-фикерләре бар хәлдә килә. Ничек итеп әйтергә кирәклеген тормыш инде шактый әйбәт өйрәткән аңа. Матбугатыбыздагы шигырьләре, аз сүзле, ләкин киң мәгънәле шигырьләре шуны раслыйлар. «Туган-үскән нигез ташларына» дигән шигыре — эчтәлегенең киңлеге, тирәнлеге белән Дәрдмәнднең «Кораб»ы янына куярлык шигырь.*

*«Алтын эзләүчеләрнең төп фикере — «алтын тапты да шунда ук үзен югалтты» рәвешендә дидактик фикер генә кебек. Ләкин шул ялангач фикерне сурәтләүләр аша әйтә белүе белән кат-кат укырлык әсәр хәленә китерә. Халыкның шигъри телендәге гади, табигый гүзәл үзенчәлекләрне иҗади рәвештә куллана белә. Традицион шигырьнең потенциаль мөмкинлекләрен киңәйтү-үстерү үрнәкләрен дә бирә бу тыйнак шагыйрь.*

*Модернизмның ритмсыз «ритмика»сы, шигъри уенчыклары кызыктырмый аны. Фаилдә Әхмәт Фәйзинең яхшы йогынтысы ачык сизелә.*

*Фаилнең хикәяләре дә реаль тормышны яхшы белүе, лирик тел белән сөйли, сурәтли алуы сокландыра.*

*Фаил Шәфигуллин иҗаты белән дә, кешелек сыйфаты белән дә Союзга алынырга лаеклыларның берсе булып тора».*

Ә син остазларыңның ышанычын акладың. Поэзия өлкәсендә генә түгел, проза өлкәсендә дә. Туктаусыз эшләдең, яздың, һәм ничек кенә яздың әле! Өлкән кешеләр шундый ышаныч белдергәннән соң синдәге җаваплылык хисенең бермә-бер артканын күрдем мин. Әсәрләреңә искиткеч таләпчән карадың. Әгәр килеп җитмәгән ягын күрсәң, бер дә җәлләп тормыйча, чүп дип, ертып ыргыта идең. Илһамсыз, ягъни теләгең булмаганда язарга утырып, бервакытта да күңел газабы кичергәнеңне хәтерләмим. Сиңа карап тору — үзе бер хозурлык. Әйтерсең хәрефләр, сүзләр язмыйсың, бәлки йөрәгеңнең кардиограммасын төшерәсең син. Шуңа күрә, нәкъ менә йөрәк тибешеңне язганга күрә, әсәрләреңдә төгәл ритм, классик җыйнаклыкка ирешкәнсеңдер дә!

Синең холкыңда, гомумән, таләпчәнлек бар иде. Иң беренче чиратта үз әсәреңә, билгеле. Аннары тормышка, иптәшләрең язмышына. Туры, нык сүзле кеше идең. Күзгә карап дөресен әйтә алдың, әмма болар барысы да кешелеклелек таләпләреннән чыгып, яхшылык теләп эшләнгән эш. Шуңа күрә, арабыздан иртә китүеңә карамастан, талантлы шәкертләрең калды. Мөгаен, кешенең кыйммәте әнә шундадыр да. Үзенең дәвамчысын, үзенең эзен калдырудадыр!

Халыкта «Дусларыңның кем булуын әйтсәң, үзеңнең кем икәнеңне әйтәм» дигән тапкыр сүз бар. Бу җәһәттән караганда, Зөлфәт һәм Ризван белән аерылгысыз дуслар идегез сез. Сез «йөгәнсезләр»не тәртипкә чакырып, ара-тирә «колхоз»га өндәп, Мәгъсүм абый Хуҗин килеп кушыла. Компаниягезне Хәлим Җәләлов тулыландыра. Бергә очрашсагыз, юк кына нәрсәдән кызык табып, бөтен дөньяны яңгыратып көлә идегез. Көлеп туйгач, Хәлимне җырлата башлыйсыз. «Артистларны бөтен шәһәр белә, собакы», — ди идең син, сарай сүтәргә баргач, такталарын алып кайту өчен Хәлимнең тиз генә машина табып килүен исеңә төшереп. Физик көч кирәк булганда, син еш кына аңа эндәшә торган идең. Минем энемне, баҗаңны чакырыр идең. Фанины, сиңа ияреп, бөтен иптәшләрең «баҗай» дип йөртә башлады. Ә энем Рәшит барыгыз өчен дә каениш булып калды.

Дуслар димәктән, гаиләләр белән аралашкан дусларыбыз буларак, Әхмәт Гаделләргә тукталып үтәсе килә. Ихтыяр атлы бик акыллы уллары бар аларның. Шул малаеның киләчәген күздә тотып, кызы булган һәр әни кешегә «кодагый» дип эндәшә Әхмәт. Менә шул «кода» тиешле Әхмәт белән соңгы елларда Мамадыш, Балык Бистәсе якларында күп йөрдегез сез. «Социалистик Татарстан» газетасына, «Чаян» журналына килгән дәгъвалы хатларны тикшердегез. «Юлга чыксаң, иптәшең үзеңнән яхшы булсын» ди халык. Бу җәһәттән Әхмәтне һәрчак мактый идең. Кешеләр белән бик тиз аралашып китүен, җайлап сөйләшә белүен бәялисең. «Кая барма — туган авылы, һәм шул авылда, чынлап та, колач җәеп, мунча ягып каршы алалар үзен!» — дип көлә идең. Әхмәт Гаделне без шагыйрь буларак беләбез. Әмма моңарчы беркемгә дә күрсәтмәгән дүрт-биш табаклык хикәяләрен укыдың син аның. «Күбесе Шәриф Камалча — тәфсилле-моңсу сурәтләү чаралары кулланып язылган. Рәис Даутов яки Кыям Миңлебаев кебек шәп редакторларга эләксә, менә дигән китап чыгачак», — дип язып та куйгансың.

Командировкалар турында сүз чыккач, синең төгәллегеңне раслый торган тагын бер сыйфатыңа тукталасы килә. Ул — юлга зур әзерлек белән чыгуың. Сөлге, сабын, алмаш кием турында әйтеп тормасам да аңлашыла. Аларны сәфәр чыккан һәркем ала. Син тагы энә, җеп, шырпы, кайчы, пәке кебек әйберләр дә ала идең. Безгә бик ошаган тагын бер гадәтең — барган җиреңнән бервакытта да бүләксез кайтмадың. Кайчакта, шуларны әйтеп, кеше алдында мактап, үсендереп җибәрә идем үзеңне.

Син:

— Күпкә китте. Күрше булгач, Фирая гадәте йога башлады, ахры, — ди идең.

Әмма Фираяны һәрвакыт зур хөрмәт хисе белән телгә алдың. Бу ихтирамыңны Фирая Маликовага багышлап язган «Кушамат ничек кушыла» дигән юмористик хикәяң дә раслап тора.

Авыру кешегә хастаханәгә йөрү дисеңме, кайгылы кешенең кайгысын уртаклашу дисеңме — күпләребез булдыра алмый торган игътибарлылык, кешелеклелек бар Фираяда. Якты күңелле, искиткеч саф күңелле хатын ул. Шушы авыр көннәремдә алар белән күрше булып калуыма сөенеп бетә алмыйм.

Чынлап та, сүз сүзне тарта бит менә. Бервакыт Фирая үзләренә чакырып төшерде безне.

— Фаил, — диде ул, «ф» хәрефен үзенчә матур итеп әйтеп. — Дустыңны орыш әле бераз...

— Да-а, обойлар шәп сезнең. Шома, матур. Ябыштырылуы да шәп. Шә-әп...

Синең йөрешеңнән, кыяфәтеңнән үк көләсе килә, һәм, бар нәрсә онытылып, сүз үзеннән-үзе хуҗалык эшләренә кереп китә, күпчелек очракта ахырдан күңелле итеп, гөрләшеп чәй эчү белән төгәлләнә иде.

Бу алымыңны еш куллана идең син. Бергәләшеп утырганда әңгәмә кирәкмәгән якка борыла башласа:

Урман ничек шаулар,
Ишелмәсме таулар, —

дип җырлап та җибәргәли идең. Тавыш көчле. Ләкин... Юк, моң юк дип әйтеп булмый синдә. Тальян гармунда уйнавың әле дә күз алдында. Күреген бөтен барлыгына тартып-тартып аласың. Иягең — сул җилкәңдә. Авыз эченнән көйләгәнгәдер, бәлки, яңак, муен мускулларың тирбәлеп тора. Яшьлегеңдә музыкаль белем алу мөмкинлегең булсамы? Җырлар идең дип әйтмим, әмма нинди дә булса уен коралында шәп кенә уйнар идең син!..

Калды... Барысы да сагынып сөйләргә генә калды. Моңлы булуың да, кешеләргә мәрхәмәтле булуың да, эштән курыкмавың да.

Эштән чынлап та чирканмый идең син. Бервакыт шулай авылда чакта Риф абый белән урманга утынга бардыгыз. Кайткач, кисеп әрдәнә итеп өйдегез. Сол белән эшли, дидең син абыкайны, ягъни җаен белеп. Ә абыкай сине мактады, кара, тырыш егет икәнсең син, диде. Дөрестән дә, тыгыз мускуллы идең син. Гомумән, матур ир идең. Корсак үстереп йөргән кешеләрне бер дә яратмадың. Үзең һәрвакыт режим белән тукландың, ятар алдыннан артыгын ашамадың. Туклandым дигәч тә, ашказанына ярты тәлинкә аш сыярлык урын калырга тиеш, ди торган идең.

Кызык инде: бервакыт шулай Тукай районының Мусабай авылында яшәүче Рәсим абый Абдуллиннарга кунакка бардык. Гомергә җор булдың, шаяртырга яраттың бит син. Килеп керүгә, тирән итеп борыныңны тарттың да: «Сөйгән кешем белән кайттым, әмма хатынга әйтеш түгел», — дидең. Мин инде, синең холкыңны белгәч, ул сүзне шунда ук оныттым. Ә Рәсим абый белән Тәслимә апа пошаманга калган. Җитмәсә, табын янында, син ит яратасың, дип, мине бик каты сыйлап утырдың. Ахырдан Тәслимә апа яныма килде дә: «Сеңел, кайткансың, кунак итәм, ләкин кеше гаиләсен бозма, рәхәт күрмәссең», — диде. «И Тәслимә апа, җаным, үз ирем бит ул минем, Фаил сезне шаяртты гына», — дидем.

— Булса да була инде дөньяда әйбәт кешеләр, кем инде без аларга, җаннарын ярып бирергә әзер торалар, — дидем мин Рәсим абый белән Тәслимә апа турында.

— Кем дуслары соң алар? — дидең син, горурланып.

Рәсим абыйның гаҗәп музыкаль кеше булуы, күкрәге тулы моң ятуы дулкынландырган иде безне. Казанга килгәч, бик тырышып Вараксин гармуны эзләдегез сез аңа.

Дусларың өчен тырыша, кирәк чагында һәрвакыт булыша белә идең син. Арада иң якын иткәнең Ризван Хәмид булды. Мәгәр дә яраттың син аны! Ышандың, таяндың. Ризванның беренче пьесасы Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы академия театрында куелгач, шатлыгың эчеңә сыймады. Үз әсәрең, үз повестең дөнья күргәндә дә алай ук куанганыңны хәтерли алмыйм. Спектакльнең премьераларына йөрдең һәм «Хәбировлар» дип аталган зур мәкалә яздың. «Социалистик Татарстан» газетасында басылган әлеге рецензиядә пьесага бик тә объектив бәя биргән идең. Андый мәсьәләләрдә гомумән таләпчән идең син. Әдәбият мәйданында кода-кодагый, дус-дошман дигән әйберне белми идең. Үзеңнең язучылык хезмәтеңдә чын гражданин, коммунист идең. Сөйләшеп утырганда, Ризван: «Хастаханәгә бер кочак кәгазь алып килде. Кулыма ручка тоттырды. Яз, син язарга тиеш, дип әйтте. Фаил — минем укытучым, остазым. Мин аннан үлгәндә дә аерылмаячакмын, Фаилгә гомерем буе бурычлы мин», — ди иде.

Икенче җан дустың — Зөлфәт. Зөлфәтнең талантын таныган хәлдә, аны һаман да орыша килдең. «Поэма артыннан поэма, шедевр артыннан шедевр тудырыр чагың. Самый яза торган вакытыңны заяга уздырасың...» — ди торган идең. Зөлфәтнең байтак шигырьләрен яттан белә идең. «Шәп, шәп, шәп! Шәп яза, собакы, гениальный шагыйрь!» — ди торган идең.

Очрашуларыгыз кайчакта, чынлап та, зур фикерләр уята иде сезнең. Язган әйберләрегез турында җитди сөйләшү, бер-берегезгә укып күрсәтү, сюжет тәкъдим итү, шунда ук төзәтү дисеңме... Әгәр

нәрсәнедер тиз генә үзгәртү кирәк булса, Зөлфәт секундында менә дигән фикер әйтергә, борылыш кертергә мөмкин. Әмма мәсьәләне уйлап хәл иткәндә, арада иң төпле, иң аек фикерлесе син була идең. Уен сүздәме, озак утырудамы чамадан аша башласалар, иптәшләреңне тәртипкә чакырып бер генә эндәшәсең. Дусларың сүзсез буйсына. Чөнки алар синдә акыл күрә, кеше күрә, кешелеклелек күрәләр иде!

Хәзер исә сине бик сагынып, бик юксынып, күңелләребездә әнә шундый якты хатирәләрне саклыйбыз.

Минем өчен бик тә кадерле хатирәләрнең тагын берсе — егет чагында язган хатың. Өстәл зурлыгы ватман кәгазенең ике ягын да тутырып язылган хат ул. Мин авылда вакытта бандероль итеп җибәргән идең син аны. Почмагына шундый матур рәсем төшергәнсең. Гомумән, һәр хатыңа ясый идең син ул рәсемнәрне. (Блокнотларың да гел сурәт кенә.) Хатыңда миңа «коңгырт күзле кызый» дип эндәшкәнсең. «Син хәзер ни эшлисең, кемне уйлыйсың икән?» дип язгансың. Сине уйлаганмындыр инде. Синең белән танышкач, синең белән дуслашкач, кемне уйлыйм тагы?

Әй, тукта әле, башка сөйләшер сүзебез юкмы әллә?

Кичә олы кызыбыз укыган мәктәпкә ата-аналар җыелышына бардым мин. Класс җитәкчесе Полина Тимофеевна бик әйбәт доклад сөйләде. Яхшы кеше тәрбияләү, ата-ананың бурычы, балалар өчен ата-ананың һәрвакыт үрнәк булырга тиешлеге турында иде аның чыгышы. Ахырдан: «Нинди этине әйбәт кеше исәбенә кертергә мөмкин?» — дип сорау куйды, һәм үзе үк җавап та бирде. «Әгәр эти кеше гаиләсе өчен өй салса, агач утыртса, балалар тәрбияләп үстерсә. Көнчыгыш мәкалендә әнә шулай әйтелгән», — диде ул. Полина Тимофеевнаның сүзләрен синең үткәнеңә кайтарып утырдым мин. Син өй салдыңмы? Салдың. Агачлар утырттыңмы? Утырттың. Балалар үстердеңме? Үстердең. Димәк, бу яктан караганда да, син безнең җәмгыятьнең лаеклы гражданины булгансың.

Аңым белән, булгансың, дип әйтергә мәҗбүрмен. Әмма йөрәгем белән һич кенә дә юклыгыңа ышанасы килми, һаман ышанасы килми. Тирә-юньдәге һәр җисемгә синең исең, синең төсең сеңгән, һәр хәрәкәткә синең йөрәк ритмың, тавыш тембрың кучкән. Әнә радиодан еш кына «Яшьлегем тугае», «Арышлар», «Мин гармун булыр идем», «Язгы җыр» дигән җырларыңны тапшыралар. Тагын әле син үзең ишетмәгән «Коммунистлар» көе бар. Татарстанның халык артисты Хәйдәр Бегичев җырлый аны. Синең иҗатыңа зур ихтирам күрсәтеп, иң җитди эшләренең берсе санап, «Яшьлегем тугае»н пластинкага яздырып йөрүен дә хәтерлим әле. Җырларлык җырларың гына түгел, рәхәтләнеп, ләззәтләнеп укырлык алты повестең калды синең: «Әлфинур», «Сыерчык бураны», «Ак маңгайлы бүреләр», «Бер малай, өч аргамак», «Бәхет йолдызы астында» һәм «Өй салуның ние бар?» Ләкин соңгысын төгәлләп бетерә алмадың. Пицунда иҗат йортына баргач яздың син аны. Озынга китте, яртысы гына язылды, дидең. Кайтыр алдыннан повестеңның соңгы битләренә күз төшердем дә: «Нишләп бетә инде бу Рәсимең?» — дип сорадым. Син, көлеп: «Ашыкма», — дип, бер генә сүз белән җавап бирдең. Кайткач та кызуында язып бетерергә мөмкинлегең булмады. Хәер, көньяк кояшында кызынып, чибәрләнеп, тазарып кайтканнан соң нибары ундүрт көн яшәдең бит син. Шул ундүрт көн эчендә кайчагында айларга, елларга сузыла торган эшләр эшләнгән... Саубуллашып йөргәндәй, бөтен туганнарны әйләнеп чыктык. Әни янына кайтып, кунып килдек. Актанышта, Балтачта булдык. Кунакка баргач та эшсез тормый идең син. Безнең колхоз рәисе турында зур гына мәкалә яздың...

Әй бу дөнья!.. Читен чакта коткаручым — китапларың. Йөз кат укыганмындыр синең ул Рәсим турындагы повестеңны. Бигрәкләр дә үзеңә охшаган, бөтен кыланмышы, бөтен сөйләшүе син. Соң, чыннан да шулай. «Ак маңгайлы бүреләр», «Бер малай, өч аргамак», «Бәхет йолдызы астында», «Өй салуның ние бар?» — синең тоташ бербөтен булып агылган автобиографик повестьларың лабаса. Китапларыңны ачам да ярым пышылдап укыйм. Гүя бераз гына басынкы, бераз гына кыюсыз Рәсим белән сөйләшәм. Нәкъ синеңчә эндәшә, нәкъ син булып карап тора ул. Онытылып китеп, каршыңда утыргандай хис итәм үземне. Аның китап битеннән чыкмавын белеп, синең юклыгыңа хәйран калып үзәк өзелә. Көненә мең дә бер кабат исемә төшеп, миемне бораулаган сорауга җавап эзлим. Нигә, ни өчен? Синдәй кеше ничек үлә алсын ди?!

«Фоторәсемнәрен күз алдында тотма, әйберләрен ераккарак яшер, үз йөрәгеңә үзең чир ясама!» Болар — тормыш күргән олы кешеләр сүзе. Бәлки, алар хаклыдыр. Ә мин, киресенчә, яңадан-яңа фотоларыңны табып, стендлар төзим. Синең иҗат бүлмәңне портретларың белән бизим, төннәр буе блокнотларыңны актарып утырам. Синең кулларың белән язылган бит алар. Никадәр миһербанлы әсәрләр язып калдырган алтын кулларың белән!

«Түземле булсаң, пешмәгән җиләктән дә менә дигән хәлвә әзерләргә мөмкин».
«Һавада кош эзе, ташта елан эзе, хатында ир эзе — вәсвәсәле тойгы...»
«Теле — кынысыннан чыккан кылычтай, уңга-сулга селтәнә башлады».
«Карчыкларны асрыйлар нәнкә кирәккә күрә».
«Өйдәге уй мунчада ярамый».
«Кош караганга да акча, тирес түккәнгә дә акча».

«Һәр иҗат кешесенең нindидер ноктасы була. Шул нокта табылса, эш җайга салына».
«Күңелне дәваламыйча, тәнне дәвалап булмый. Сократ».
«Бар да көмеш путалы,
Бар чагында юк кадерем,
Сагынырсыз, туктале».
«— Шулай, наный, нишләргә дә белгән юк.
— Галстук тагып кара!»
«— Үлде, мескен.
— Ничек үлсен, аның миңа өч сум акча бирәсе бар ич...»
«Алай ашыктырсаң, мин бөтенләй бармасмын, дип әйтә ди ташбака».
«Кем белән кара булсаң, шуның белән ак бул!»
«Хатын-кызның тагы бер минуттан соң ни теләгәнен Ходай үзе дә белми».
«Конюх турында хикәя: икенче кайту. Югалган гомер, югалган еллар, бушка узган гомер».
«Бер курыккан эт өч көн өрә».
«Шайтан акчаны ясагач ук күзенә куйды да авызын ерып җибәрде, ди. Шуннан бирле кешеләр дә, акча күргәч, авызларын ералар, бик яраталар, ди».
«Как всегда, у Чехова маленькие детали дают читателю бесконечно много».
«Талант — это знание жизни, талант — это смелость».
Әнә шундый кыска, әмма мәгънәле цитаталар шактый синең блокнотларыңда. «Талант ул — тормышны белү, талант ул — кыюлык» дигән соңгы язмаң турында уйланам. Синең үзеңә бик туры килә бит бу, Фаил. Кыюлыгың бар, тормышны белүең бәхәссез иде. Димәк, синең чын талант булуың да бәхәссез. Унҗиде яшьтән Коми АССРда урман кисәргә, казакъ далаларында чирәм күтәрергә, Ерак Көнчыгышта булырга, төзелештә эшләргә, диңгездә йөзәргә, заводта тир түгәргә туры килә сиңа. Романтика эзләп йөргәнме син анда, үзең әйтмешли, язарыңа азык эзләпме? Һич юк. Үзебезнең туган җиребездән дә бик әйбәт таба идең син матурлыкны, романтиканы. Иртә язда яшел чирәм өстенә сузылып ятасың да болытларны күзәтәсең. Аларны төрле җанварларга, кошларга, тере җан ияләренә охшатып, үзалдыңа сөйләнәсең: «Кая, нинди уйлар белән агасыз сез? Нинди тылсым көче бар сездә, болытлар?» — дисең. Хыял канатларыңда әллә кайларга очасың, күңелең белән әллә кайларга барып кайтасың... Хыялда гына түгел, тормышта да өлгер кеше идең син! Өлгер кеше, игътибарлы кеше идең.
«Казан утлары»н әйткән дә юк. Көндәлек матбугатны җентекләп күзәтеп, әдәби әйберләр белән танышып барырга, аның өстенә әллә никадәр матур әдәбият укырга җитешә идең. Кайтып-кайтып өлкәннәргә, борынгы әдипләргә мөрәҗәгать итәсең. Әдәбиятның узган юлын белми торып, бүгенгесе, киләчәге турында фикер йөртү мөмкин түгел, дисең. Кол Галиләр, Мөхәммәдъярлар, Акмуллалардан башлап бүгенге көнгә киләсең. Дәрдмәнд, Хисам Камалов шигырьләрен күңелдән укыйсың. Үлеп Лермонтовны яратасың. Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Чыңгыз Айтматов, Василь Быков әсәрләрен кат-кат кулыңа аласың. Радиодан «Ак әби» постановкасын тапшырганда, онытылып тыңлыйсың. Кыскасы, гаҗиз булып китаплар ярата идең. Китап ярату ул — инде кешеләрне ярату, тормышның үзен ярату дигән сүз. Ә андый мәхәббәт — безнең яшәвебез, җирдә яхшылык, иминлек өчен көрәшүебез дигән сүз!
Шулай. Гомерең буе эшләдең, гомерең буе көрәштең син. Беренче чиратта каләмең белән, үтемле сүзең белән.
Мин синең искиткеч табигый, искиткеч чын, искиткеч күңелгә ятышлы «Верочка», «Кырмыска турында баллада», «Бал», «Сукыр бабай, карт мәче һәм елан», «Сугышчан бурыч», «Дезертир», «Солдатлар кайта», «Ак мөгез», «Фирүзә» һәм башка бик күп гүзәл хикәяләреңне искә төшерәм. Балалар өчен язылган повестьларыңдагы илаһилыкка табынам. Бу әсәрләрең салмак кына, ләкин ярларын тутырып агучы елганы хәтерләтә. Елга ага. Аның тирә-юнендә һушыңны алырлык матурлыклар очрый. Чәчәкле үзәннәр, сихри урманнар, текә таулар. Ә елга өстендә кояш нурлары уйный. Кайчагында әнә шул гүзәл елгага кемнәрдер таш, чүп ыргытып китәләр. Суы болганчык йә булмаса сай, дип сөйләнәләр. Ләкин ничек кенә булмасын, елга үзенең горурлыгын, матурлыгын ахырга кадәр саклап кала. Алдагы көннәргә ага да ага. Андагы яктылыкка, киңлеккә карап, ирексездән безнең дә күңелләребез күтәрелә, җаныбыз пакьләнә. Анда безнең уртак идеалларыбыз чагыла...
Елга дигәннән, бервакыт шулай балалар белән үзебезнең авылдагы Баҗана елгасы буена килдек. Кечкенә Резеда апасы ясап биргән көймәне суга куйды. Көймә безнең яннан әкрен генә кузгалып агып китте.
— Әнием, көймә кая китте? Ничек бара ул? Елга ничек ага? — дип гаҗәпләнде сабый.
Мин аңа елгаларның гомер буе агуын, аннан зур суга барып кушылуын аңлатырга тырыштым. Әйтик, дөнья әдәбиятына барып кушылган әтиең иҗаты кебек. Халык әдәбияты дигән олуг диңгез — күңел диңгезе бар. Ә әтиең иҗаты, мең төрле төс биреп балкучы асылташ кебек, шул мәйданнан урын алды. Кызыма шулай аңлаттым. Күзәтүчән, сизгер күңелле ул. «Әни, әни?!» — диде бала бераздан,

бата башлаган, яртысы гына күренеп калган кояшка күрсәтеп. Бик тә гаҗәпләнгән йөзенә карап, мин аның бу күренешкә беренче мәртәбә игътибар итүен аңладым.

— Бүгенгә китеп тора да иртәгә таң белән тагын туа ул, — дидем.

Резедам минем «туа» сүзен эләктереп алды. Кояш тикле кояш кире тугач, ник әле аның әтисе кабат тумаска тиеш? Шундый зур ачыш ясагандай, кабаланып:

— Әни, безнең әти дә яңадан туамы? Бәби булып? Менә-ә-ә болай гына, нәни бәби булып? — диде. (Әгәр туа калса, үзенең шундый нәни әтигә дә риза булуын аңлатасы килде аның.)

Резеда миннән җавап көтеп тормады. Хыялында инде аның әтисе туган, фани дөньяга кире кайткан иде. «Әнием, беләсеңме, мин ул вакытта әни булам, синең кебек зур әни. Әтине җитәкләп бакчага илтәм. Үзем эшкә барам», — диде.

Аның шулай фикер йөртүе Колумбның Америка ачуына тиң булгандыр, бәлки. Шул минутта әлеге бәләкәчнең йөрәк тибешен, очкынланып янган күзләрендәге нур агышын үлчисем килде минем. Әгәр шундый мөмкинлек булса, үлчәү берәмлегенең иң югары ноктасын күрсәтер иде бу нарасый шатлыгы.

— Ә мине? — дип сорадым мин. — Мине кая куясың?

Резеда уйга калды. Үлмәгәч, шул ук кеше яңадан бәби була ала микән соң, янәсе. Аннан:

— Син әби булырсың. Әтине бакчадан алып кайтырсың, безнең эштә җыелыш булганда, — дип өстәде.

Бала, бала... Үзенең саф, чиста күңеле белән дөньяны да әкият кебек итеп күрә ул. Әкият белән чынбарлыкны кушып, әллә ниләр уйлап чыгара. Ни әйтсәң дә, аларның үз дөньясы, үз уйлары, үз хыяллары. Әле генә кайгыра һәм шунда ук онытылып уйный башлый. Әмма апасы белән бик дус, тату яши алар. Үзләренә карап тордым да, әллә кайчангы бер вакыйга исемә төште. Зеленодольскидан ерак та түгел Раифа урманына гөмбәгә барган идек. Бик матур арыш басуы. Басуның нәкъ уртасыннан салынган юлда син мине билемнән алган идең. Хисләргә бирелеп байтак барылгандыр, күрәсең. Артка борылып карасак, ялгыз Раушаниябез тавышсыз гына елап килә. «Ни булды, нигә елыйсың», — дибез. Ул: «Сез икәү-үү, сез сөйләшеп барасыз. Мин берүзем», — ди. Бәгырь кисәгем, ялгызлыктан үзәге шулай өзелгән икән. Менә хәзер мин кичерәм ул ялгызлык дигән яман чирне!..

Без, кызыбызны уртага алып, Раифаның уйлы юллары буйлап киттек. Ни өчен уйлы соң ул Раифа юллары? Ни өчен шушы кечкенә генә төбәк зур тарихка кергән? Бу — 1918 еллар белән бәйләнешле авыр вакыйга нәтиҗәсе. Казан янында җиңелгәч, үзенең гаскәре белән Емельян Пугачев чигенгән аннан. Шул юлдан үтеп, акгвардиячеләр качар өчен Раифа монастырена килгәннәр. Шул юлдан өч чекист һәм дүрт кызылгвардияче акгвардиячеләрнең иярченнәрен эзләп юлга чыкканнар. Раифа монастыре каршында фаҗигале рәвештә кыйнап, яндырып үтерелгән бу батырлар арасында хәзерге көнгә кадәр исеме ачыкланмаган бер татар егете дә булган...

Синең белән сөйләшеп сүзнең бетәсе юктыр, мөгаен. Озынга китмәсен, кабатлау булмасын дип, сайлап-сайлап кына сөйлим мин аларны. Синнән соңгы көннәрнең иң тәэсирлеләрен, иң сагышлыларын гына искә алам.

Менә яз килде. Синнән соң беренче яз. Бәхет күзәнәкләремнең күбесе яшәүдән туктаса да, табигатьтә тереклек дәвам итә икән әле. Агачлар бөреләнгән, үләннәр борын төрткән. Ләкин минем күзгә алар барысы да җансыз булып тоела. Салкын булып тоела. Көнгә дә теләр-теләмәс кенә багалар кебек алар. Гомумән, бөтен дөнья торгынлык кичерә иде сыман миңа ул язда...

Аяк аслары тәмам кипшенеп, утыртасын утыртып дигәндәй, кешеләр инде бөтен язгы эшләрен бетергәч кенә, ике кызымны ияртеп, мин дә бакчага киттем. Яңа бакча әле ул. Анда да бөтен эш ярты юлда калды. Ләкин анысына да эчем пошмый. Эшләнмәгәне эшләнмәгән көенчә торыр. Үзәкне өзгәне — балаларыбызның әтисез калуы...

Поезддан төшүгә, борылып урманга керәбез без. Матур нарат урманына. Шулчак кызларым, йөгәннән ычкынган чыгымчы тайлар кебек, таралып китеп йөгерә-уйный башламасыннармы?! Синең кайгы белән ябылып яткан күңелләрен табигать шулай алгысытып җибәрде, күрәсең. Шаярып арыгач, Раушания, нәкъ синең шикелле итеп, Резеданы муенына атландырды, кызу-кызу атлап алга узды. Борчылган чакларымда түзәм мин, бәгырем. Кыенлыкны ялгызым да күтәрергә ризамын. Ә менә балаларның матурлыкларын сиңа күрсәтәсе, бергә сөенәсе, бергә шатланасы, бергә көләсе килә. Иңне иңгә куеп, үзебез тапкан балакайларыбызның әйбәт гадәтләренә сокланасы, рәхәтләнеп ләззәтләнәсе иде дә бит... Без моңа соңлаганбыз, Фаил. Ай, юк, өлгерә алмаганбыз. Ул ләззәт безгә быел, менә шушы җәйгә планлаштырылган булгандыр, мөгаен!

Вакытны туктатып, бөтен парлылар игътибарына сөрән саласым: «Бергә чакларыгызның кадерен белегез! Сокланырдай чакта сокланып, көләр чакта көлеп калыгыз! Ә иң мөһиме — тапкан балаларыгызны тигез багыгыз!» — диясем килә. Тикмәгә генә дөнья күргән ил картлары: «Балаларыгызны тигезлек белән карап үстерергә язсын!» — димиләр икән. Әмма тигезлек сүзенең кыйммәтен, олылыгын бергә вакытта бәяләп бетереп булмый. Үзеңә тиң итеп, якын итеп сайлаган кешең белән картайганчы бергә яшәү — чынлап та олы бәхеттер. Ә безнең ярты юлда өзелде ул бәхет. Тормыш корабындагы хыял җилкәннәрен киереп алга барган чакта. Кемгә кагылды, кемгә тиде ул

безнең хыял корабы? Нинди упкын корбан сорады? Кем кыйды синең газиз җаныңны? Бу бетмәс һава, бу иркен җиһан кемгә тар тоелды? Кем сыймады аңа? Кем ятим итте минем газиз балаларымны? Кем?..

...Бергә үткән унбиш елның һәр көне күз алдымда. Бервакыт, иртә таңда, икебез дә уянып киттек. Син күргән төшеңне сөйли башладың.

«Диңгез. Корабта каядыр барабыз икән, — дидең. — Шулчак безнең баш очында кап-кара болыт җәелде. Ныклабрак карасам, болыт дигәнем альбатрос булып чыкты. Кош ул. Шундый дәү, үзе тамчы да селкенми, баш очында эленеп тик тора. Шуннан кемдер аттымы, шалт, минем аяк астына егылды бит бу!..

— Соң, болыт кебек кара булгач, җиргә егылгач, кайгыларыңның аяк астында калуы инде, — дидем мин, үземчә юрап.

— Юк, альбатросның үлеме яхшыга түгел, — дидең. — Тик менә вакыты гына... Яткач та күрдем бугай мин аны. Димәк, тиз килми әле бу кайгы, — дип куйдың.

Әллә соң синдә бер-бер сихри көч булды микән дип тә уйлыйм. Ничек шулай алдан күрә алдың икән? Әйтик, нәрсәнең дә булса куйган урынын онытсак, бервакытта да эзләп тормый идең. Идән уртасына басып, урта бармагыңны борын очына куясың да кисәк кенә хәрәкәт ясап бер якка төртеп күрсәтәсең, һәм, эзләүгә бер минут та вакытыңны әрәм итмичә, әйберне шундук табып аласың. Кешенең башына да килмәс сәер якларың байтак иде синең. Кайчагында: «Прәме сюжетлы төшләр керә, утыр да хикәя итеп яз», — ди торган идең. Авыр төшләрдән соң мин һәрчак сине тынычландырырга тырыша идем. Бу юлы да:

— Ничек юрасаң, шуңа китә, төшне яхшыга юрарга кирәк, — дидем. Сүзне икенчегә борып: — Синең альбатросны күргәнең бармы? — дип сорадым.

— Юк, — дидең. — Ә менә абыйның әллә ничә күргәне бар. Нык зур була ул. Бер-бер канаты икешәр метр. Очмыйча, бөртек тә селкенмичә бер урында сәгатьләр буе эленеп тора ала, — дидең.

...Көннәр үтә. Айлар, еллар үтә. Гомер үтә. Ләкин һәр сәгате, һәр минуты сиңа багышланып үтә ул көннәрнең. «Ничек сине балалар күңелендә саклап калырга? Иптәшләреңә ничек итеп онытырга ирек бирмәскә?» — дип уйлыйм. Шуңа күрә, әз генә сәбәбе чыкканда да, эледән-эле өйгә чакырам мин аларны. Сүземне бүлеп, монда да Резеданы искә төшереп үтәсе килә. «Әни, ник минем туган көнем елына бер генә, ник әтинең туган көне бик күп?» — ди ул. Әтиеңнең дуслары килә, дигәч, безнең һәр җыелу синең туган көнеңә багышланып үтә дип уйлый икән, бичара бала. Чынлап та, туган көнеңдә, кырыгыңда, елыңда бик олылап, озаклап искә алып утырдык үзеңне. Кабереңә барып чәчәк салу оештырдык. Истәлеккә дип каен агачы утырттык.

Сагынырлар әле безне таулар:
Таулардай хөр, горур яшәдек.
Баш очында безнең каен шаулар,
Чирәм чыгар язын яшәреп...

Каен яктысы, каен аклыгы, каен матурлыгы, гомумән, күп әсәрләреңә кереп калган бу образ. Шуңа күрә баш очыңда ак кәүсәле каен шаулавы иҗатыңдагы аклык символы булыр дип уйлыйм.

Янәдән шигыреңә кайтып, «Таулардай хөр, горур яшәдек» дигән юлларга игътибар итәсем килә. Хөр яшәдең! Горур яшәдең син. Иптәшләрең аңында, коллектив алдында нәкъ шулай булып калдың да. Менә синең кемлегеңне, синең хезмәтеңне беркадәр бәяләгән мактау кәгазьләре. Ике дистәгә якын алар. Арада РСФСР Язучылар берлегеннән идарә рәисе Сергей Михалков үзе кул куйганы да, ВЛКСМ Үзәк Комитетыныкы да, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумыныкы да, Комсомол өлкә комитетыныкы да, В.И.Ленинның 100 еллыгы уңае белән чыгарылганы да, пионериянең 50 еллыгына бирелгәннәре дә, актив хәбәрче буларак газета-журналларның юбилей кәгазьләре дә, заводта социалистик ярышта җиңеп чыккан, мәктәптә яхшы укыган өчен бүләк ителгәннәре дә бар.

Уку димәктән, аттестатларыңа карап, кабат-кабат сокланып утырам. Гел биш тә биш. Дүртле — анда-санда гына. Балаларга үрнәк итеп куям үзеңне. «Әтиегез менә ничек укыган. Сез аннан да шәбрәк укырга тиеш», — димен. «Ни өчен без шәбрәк?» — дип сорау бирә Раушаниясе. Тел төбен бик яхшы аңлыйм мин аның. Янәсе, эти барыбер үрнәк булып калырга тиеш дип әйтәсе килә. Ә мин: «Әтиегез бик авыр заманда, сугыштан соңгы ачлы-туклы елларда укыган, — димен. — Өсләренә юньле киемнәре, ашарга туклыклы ризыклары булмаган чакта. Ә шулай да ничек тырыш булган сезнең әтиегез! Җидееллык мәктәпне тәмамлаган. Биектау районы Чебакса авылына барып механизаторлар училищесында укыган. Кичке мәктәптә, В.И.Ульянов-Ленин исемен йөртүче Казан дәүләт университетының журналистика факультетында белем алган һәм һәркайда бары тик яхшы билгеләренә генә укыган. Шулчак, тын алырга да куркып, күзләремә нәүмиз булып карап торган кызларыма, әй минем газизләрем, әтиегез дә сезнең кебек ятим үскән бит, диясем килә. Рәхәтләнеп ата ышыгында балалык елларын кичерер вакытта, тормыш җилләре турыдан-туры үзенә килеп бәрелгән аның. Авырлыкны үзенә җиңәргә, юлны үзенә ярырга кирәк булган. Ә тормыш дигәнең һәркайсыбызга мәгълүм: бер тапкыр йөзен күрсәтсә, биш тапкыр арты белән борыла. Ә ятим балаларның күзләре яшь

элпәсе белән капланып, анысын да, дөньяның әллә нигә бер чагылып киткән йөзен дә абайламый каладыр, мөгаен...

Бүген көне буе яңгыр яуды. Томалап, томанлап яуды. Куерып, күк йөзен каплап алган болытның бер генә чите ертылып, бер генә бөртек кояш нуры төшсен иде, ичмаса... Безнең күңелләрнең дә әнә шулай бер чеметем җылы сүзгә, ягымлы карашка сусап яшәгән чагы. Әйтәм әйтүен, тик бер генә дә якты чырай күрмәгән икән бу дип уйларга җирлек тудырам, ахры. Беләсеңме, ул син эшләгән коллективның күрсәткән изгелеге, олылар әйтмешли, дөньялыкта кайтарып бетерә торган да булмады. Материаль яктан да, мораль яктан да булышты алар безнең гаиләгә. Яңа елда үз балалары белән рәттән безнең ике кызыбызга да күчтәнәч төрделәр. Сигезенче мартта, нәкъ сиңа охшатырга тырышып, өчебезне дә бүләкләп котладылар. Аннан соң да һаман хәлне белеп, очраган саен балаларның сәламәтлеге белән кызыксынып тору дисеңме; кече күңел белән сөйләшү, иң кирәкле, иң авыр минутларда үз канатлары астына алып, киңәш, юнәлеш бирү дисеңме... Шуңа күрә мең-мең рәхмәт син эшләгән «Чаян» журналы коллективына, аермаенча... Юк, берәм-берәм, аерып-аерып рәхмәт әйтергә кирәк аларга.

Рәшит Кәрипович Зәкиевкә. Бөтен әйбәт эшләрнең нигезен салучы ул булды. Мәгъсүм абый Хуҗинга, Вадим Луценкога, Борис Бронштейнга, Равил Хаҗиевка, Мөнирә апа Гатауллинага, Ләйлә апа Тәхтиевага, Саимә апа Зәйнетдиновага, Фәния Хафизовага.

Менә шулай, дускай. Әмма китек күңел бик кызык икән. Хәзер чайпалып түгелергә, хәзер уалып ватылырга тора. Иркә хатын булып та яшәмәдем анысы, тик кайчагында ачык йөз белән сәлам бирү дә ярамый башлады үземә. Йомшак сүз, изгелек алдында бөтенләй көчсезләндем. Кыерсытылуга, дорфалыкка каршы әллә кайчан иммунитет туган иде. Тик, чуваш аты кебек, бер-бер артлы килгән кыенлыкка өйрәнеп җиткәч кенә аяктан егылмасам, дип курка идем...

...Җир йөзендә әкият яши. Җир йөзендә золым яши. Җир йөзендә Гиппократ законы да яши. Әз генә миһербаны булган кеше, яралы җан иясенә кагылу түгел, чиертми дә.

Тукта, күңелне төшенкелеккә бирмик әле, Фаил. Иң яхшысы, архивыңда сакланып калган «Тынгысыз каләм»нең бер санын, андагы «тизәйткечләр»не укыйк:

«Мөдәррис Әгъләмовка шиш лоджийлы фатир биргәннәр».

«Ура! Эдуард Мостафин бу бишьеллыкта да шигырьләр язган».

«Драматург яшь авторларга: «Өстәп шуны мияуларга тиешмен —сезнең әсәрләрегездә заманча мыраулау җитенкерәми».

«Яхъя киткән штаттан,
Нәшрияттан эш тапкан».

«Игътибар!
Гафил булып калмагыз!

«Тынгысыз каләм» үзенең тырыш һәм фидакарь авторларын Әпкәли премиясе белән бүләкли башлады.

Премияләр комитеты быел Әпкәли премиясен бертавыштан газетаның шушы санында басылган пародияләре өчен Гәрәй Рәхимсезгә һәм Әпкәли архивында армый-талмый казынганы, шул казыну нәтиҗәсендә «Чалымнар» дигән эпик мемуарлар көлтәсе тудырганы өчен яшь әпкәливод Гөргөригә бирергә карар чыгарды».

«Тынгысыз каләм» газетасында язучылар актив катнаша иде. Мәсәлән, синең даими авторың Тмин — Туфан абый Миңнуллин. Туфан абый авторың гына түгел, синең иҗатың белән даими кызыксынып баручы, аралашып, Казаннан читтә вакытта да хатлар язып торучы ышанычлы остазың булды. Икегездә дә юмор җитәрлек, шуңадырмы хатларыгыз да уен-көлке, шаян шигырьләр белән тулы була иде.

Бер уйласаң, кызык бит. Илкүләм, дөньякүләм проблемалар күтәреп, җелегеңә үтеп керерлек әсәрләр язган Туфан Миңнуллин сезнең белән, ул вакытта әле бик үк танылмаган да яшь язучылар белән әнә шулай туганнарча якын итеп, дус итеп, үз итеп хатлар язышкан. Шушы кечкенә генә деталь дә кешенең олы шәхес булуын сөйләүче дәлилдер, минемчә.

Якты шәхесләрнең, бөек кешеләрнең хатлары бик күп синең архивыңда. Чөнки син талантлы, өметле булуың белән яшьтән үк аларның игътибарларын үзеңә җәлеп иткәнсең.

*«...«Гайнан агай монологы» безне кызыксындырды. Беркадәр кыскартып, мин аны журналның 19 нчы санына тәкъдим иттем... Казанда була калсагыз, керегез...»* Монысы Аяз ага Гыйләҗевнең «Чаян» журналында эшләгән вакытта 1964 елның 25 августында язган хаты. Ахырдан да синең һәр уңышыңа сөенеп яшәүче кеше булды ул. Үлемеңне дә бик авыр кичерде. Гаҗәп авыр кичерде. Әле искә төшереп утырам. Икегез дә язучы булсагыз да, китап сүзләре белән сөйләшми идегез сез. Әмма сөйләшүегез һәрвакыт эшлекле, акыллы була иде.

Аккош күлендә «Мең чакрым юл» исемле китабын укып чыктык без Аяз абыйның. Кычкырып укыдык, минем күз арыгач — син, синең күз арыгач — мин. Шәп прозаик, ди идең син аның турында. Әле бүген уйланып утырганда, моннан унҗиде еллар чамасы элек булган сөйләшү искә төште. Безнең

танышып, дуслашып йөргән чак. Союз коридорында ничектер кара-каршы килдек. Шулчак Аяз абый үтеп китте. «Кем икәнен беләсеңме?» — диден син. «Юк», — мин әйтәм. «Аяз Гыйләҗев», — диден. Мин җилкә сикерттем: барыбер белмим, янәсе. «Өч аршын җир!» — диден син. «Соң, нигә башта ук шулай димисең аны, «Өч аршын җир»не кем укымасын да, кем белмәсен инде», — дидем мин...

Синең үлү хәбәреңне ишеткәч тә, ашыгып, ярсып килеп керде безгә Аяз абый. Читтән карап торган кешегә «бирәмме соң Фаилне үлемгә, бирәмме соң» дигән кебек иде аның йөрүе, йөзе. Гүя үлем белән бугазга-бугаз килергә әзер иде ул... Әнә шундый дусларың була торып, суырып алды бит сине нәләт төшкән үлем. Юк, соңгы минутларында яныңдагылар дусларың булмаган синең!..

Без хатлар турында сөйләшә идек.

Хатлар!..

Менә бу «Фаил мелла!» дип эндәшүчесе Гамил Афзал була.

*«Фаил дус!*

*...Эчке рецензиянең бер данәсен сиңа җибәрәм... Бу инде уйлана тору өчен. Билгеле, ничектер бер очрашып, шигырьләрне бергәләп актарып карап чыксак, шәп булыр иде. Андый форсат та булыр әле.*

*Ярый, әлегә хуш. Чүтеки, артыгын борчылмасын егет, дидем.*

*Уңышлар теләп: Шәүкәт Галиев».*

«Фаил туган, Фаил иптәш, Фаил абый, Фаил улым...» Барысы да сиңа мөрәҗәгать итеп йә киңәш сорап, йә эч серен уртаклашып язылган. Авылдан да, шәһәрдән дә, укытучыдан да, игенчедән дә алар.

Түбән Кама шәһәрендә яшәүче китапханәче Каширина хаты. «Азат хатын» журналында «Ул бит Майорова» дигән мәкаләң чыккач язган ул аны. «Минем иңнәремә канат куйдыгыз. Авыр вакытта сезнең мәкаләгез чыкты», — дип, үзенең рәхмәтен белдергән. Ә «Казан утлары» журналында «Өй салуның ние бар?» әсәрең дөнья күргәч, Әлмәт районы Колшәрип кошчылык фермасы кызлары Варвара Брагина, Әминә Нуриева, Гасимә Исмәгыйлева һәм башкалар повестеңның укучыга көчле тәэсир итүе турында язалар. «Яшь ленинчы» газетасында «Бер малай, өч аргамак» повестең басылгач, йөзләгән укучы бала үзләренең рәхмәтләрен, соклану хисләрен белдергәннәр.

Үзең вафат булгач та тукталмады ул хатлар. Ачыргаланып, үзәкләре өзелеп, сине югалтуга ышана алмыйча язылган иде алар. Чиләбедән Камил Мостафин, Казаннан Фәнис Яруллин, Ригадан Зәки Зәйнуллин, Уфадан Якуб Колмый, Ленинградтан Риза Халит, Каракалпакстаннан Ибраһим Юсупов, Махачкаладан Нуретдин Юсупов, Алабугадан Равия Абдуллина, Лаештан Роза Кушмина, Кама Тамагыннан Фәридә Хәйруллина, Карашәмнән Нәфилә Садыйкова... Кыскасы, Советлар Союзының, республикабызның төрле почмакларында яшәүче дусларыбыздан, танышларыбыздан, туганнарыбыздан хатлар явып кына торды.

Әнисе үлгәч, шагыйрь Камил Мостафин менә нәрсә язган булган сиңа: *«...Һичнәрсәгә кул бармый. Әмма тормыш дәвам итә... Аерым кешенең гомере ике яктан да чикләнгән. Ә менә тормыш — мәңгелек. Бу — иң төп философия. Эстафетаны алга алып барырга һәм яңа буыннарга тапшырырга кирәк!..»*

Искиткеч акыллы хатлары белән син дөнья куйгач та күп ярдәм итте безгә Камил. Үзенең йөз дә бер эше — мәшәкате булса да, энҗе кебек матур почеркы белән даими рәвештә хатлар язып, киңәшләр биреп торды.

*«Фаил — зур талант. Мин аны күреп белүемә шатланам. Китапларын кат-кат укыйм, дулкынланып укыйм. Фаил үзеннән соң озак еллар яшәрлек олы мирас калдырды. Ул мирас — сезнең кызларыгызның горурлыгы. Кызларыгызга гына түгел, оныкларыгызның оныкларына да бетмәс горурлык китерәчәк әле Фаил иҗаты!»* — дип язды Латвия башкаласында яшәүче полковник Зәки Зәйнуллин. Сезне Мирсәй ага таныштырган иде Зәки абый белән. Синең аша олы җир, олы әдәбият белән бәйләнеш тота иде ул. Җыйнак һәм чая хикәяләр язып, синең хөкемгә җибәрә, җавап, киңәш көтә. Алда синең белән иҗади дуслыкта яшәп, олырак эшләр майтарырга исәбе бар иде аның.

Әнә шулай күпләрнең үзәген өзеп киттең син. Шуңа күрә синең нигезең белән дусларың арасында ачыргаланып язылган хатлар йөреп кенә торды. Олы юаныч алып килде алар безгә үз вакытында. Мең рәхмәт хат язган, кайгыбызны уртаклашкан ул әйбәт кешеләргә!

Җир шарында чынлап та игелекле кешеләр күбрәк икән. Атналар, айлар узганчы гына түгел, еллар буе ярдәменнән ташламаган иптәшләрең булды. Тикмәгә генә, дуслар авыр вакытта сынала, дип әйтмәгәннәрдер шул.

Ихтирам хисе белән тагын бер кешене — Камил Кәримовны искә аласы килә. Синнән күргән игелеккә җавап рәвешендә дип әйтимме, юк, алай түгел, сине остазы итеп таныган хәлдә, аның безгә, безнең гаиләгә күрсәткән ярдәме әйтеп бетергесез зур булды. Үзеңә лаеклы, чын алмаш калдыруың турында сөйләмимени бу?!

Әмма дөньяда бер хакыйкать бар. Дуслар никадәр генә әйбәт, никадәр генә киң күңелле, кешелекле булмасыннар, никадәр генә үз итмәсеннәр, ир белән хатынның бары тик бер-берсенә генә әйтерлек серләре була икән, Фаил. Минем дә бары тик синең белән генә уртаклаша алырлык шатлыгым, син генә белергә тиешле кайгыларым бар. Шуңа күрә бик тә юксынам мин сине. Үз кулларым, үз күзләрем

белән озатсам да, юклыгыңа ышана алмый йөдим. Бөтен эч-бавырларым актарылып, үзәгем өзелә. Бөртекләп иҗатыңны туплыйм. Бер генә хәрефеңне дә югалтмаска тырышам. Шуның белән юанам. Үз-үземә: «Түзәргә кирәк, тешне кысып түзәргә кирәк», — дип кабатлыйм. Синең хакка. Иҗатыңны дәвам итү хакына, балаларым, аларның киләчәге хакына!..

Синнән ике кыз табып калуыма (исәннәре ике) шатланам. Балакайларымның ата балалары булуы белән горурланам! Аларда калган чалымың, рәвешең, килеш-килбәтең сине онытырга бервакытта да ирек бирмәячәк миңа!

Миндә генә түгел, бөтен татар халкы күңелендә яшәячәк кеше син, Фаил! Үлемне җиңеп яши алырлык мактаулы хезмәтең калды синең. Әдәби әсәрләрдән тыш иҗат кешеләре турында гадел хөкем йөртеп, тирәнтен уйланып, күп хезмәт куеп язган мәкаләләрең, очеркларың, хикәягә биргесез иҗат портретларың, үткен публицистикаң калды. Укучыларыңа язган искиткеч эшлекле, кешелекле хатларың, дусларың күңеленә уелып кергән акыллы киңәшләрең калды. Менә шулар белән яшисең син халык күңелендә. Якты хатирәләрең белән яшисең!

«Яшисе, мең, миллион ел яшисе килә. Ләкин моңарчы булган кызганыч тән яшәве белән түгел, башка бер яшәү белән, матур, изге, бөек яшәү белән яшисе килә» дип язган Галимҗан Ибраһимов.

Син нәкъ шулай яшәдең!

Синең җирдә яшәү дәвереӊ бик кыска бер мизгел генә булды. Әмма ерак йолдызларның үзләре сүнгәннән соң да миллион еллар килеп торган яктылыгы кебек, синең иҗатың да гасырлар буе кеше күңелен тәрбия кылачак әле. Гасырлар буе кешеләр күңелен нурландырып, дәвалап торачак. Чөнки син, нәкъ югарыда әйтелгәнчә, тән яшәве белән түгел, башка бер яшәү белән гомер сөрдең!

Бер тотам гомерең гүя бер мизгел булды. Әмма искиткеч якты, нурлы мизгел! Мең төрле чагылышы белән Төньяк балкышын хәтерләткән, зилзилә дуенында альбатрос очышын күз алдына китергән, күк йөзенең чиста зәңгәрлеген күрсәткән мизгел булды ул...

Хәзер исә... Юк, хәзер дә син безнең янда. Безнең арада рухың яши синең. Әйткән сүзләрең, фикерләрең, хыялың, киләчәгең яши. Катлам-катлам булып яткан елларны үтеп, тавышыңны тонықландырырга тырышкан җил-давылларны җиңеп, көчле аһәңең яңгырый: «Әй, кешеләр, тирә-юнегездәге матурлыкның кадерен белегез, тыныч яшәгез, гадел булыгыз! Мәгънәсез бер тән яшәве белән гомер үткәрмәгез, — дип тәкрарлый ул аһәң. — Җир йөзендәге бер мизгел гомерегезне изге эшләргә, бөек максатларга багышлагыз!»

*1982–1983*

## *Мәхәббәтнең җиде төсе*

### **Зәңгәр чәчәк**

Шигърият дөньясына юл алган, хыял диңгезенә чумган ике җан иясе. Икебезнең дә бик тиз күңеле кырыла. Икебезнең дә юк кына нәрсәгә исебез китә.

Әйтик, беребез уйламаган, көтелмәгән вакыйга китереп чыгарырга яратса, икенчебез күзгә кереп торган купшы гөлләрне әйләнеп узып, кыргый гүзәллеккә омтыла.

Без чәчәк болынында йөрибез. Әнә, күренер-күренмәс кенә, үзенә игътибар аз булганга үпкәләгәндәй ямансу елмаеп, Зәңгәр чәчәк тирбәлә: «Синең күз карашың миңа тукталмый инде, беләм. Мин бит махсус үстерелгән чәчәкләр кебек озын торыклы түгел. Юлчылар шулай ди дә үтеп китә. Син дә карап торырсың да...» Шул сүзләрне әйтә алу батырлыгыннан Зәңгәр чәчәкнең таҗ яфраклары тирләп чыга. Минем аны тыным белән иркәләп дәртләндерәсем, төшенке уйларыннан арындырасым, башкалар алдында күрекле итәсем килә. Тамырларын тирән җибәртеп, көч, гайрәт алып, Табигатьнең иң затлы чәчәге булып кукраеп утыруын телим. Ниндидер могҗиза эшләмәк булам. Иплэп кенә Зәңгәр чәчәкнең янына чүгәлим: «Ялгышма. Син кызгануга мохтаҗ түгел. Син дөньядагы иң якты чәчәк! Язларың үтсә дә, җәйләрең бәхет китерәчәк», — дип юрыйм...

Мин шулай чәчәкләр белән сөйләшеп йөргән арада, егетем юкка чыккан. Аны эзләп як-ягыма карыйм. Шулчак йөрәгем, өзелеп төшкәндәй, жу итеп китә. Бик якындагы киселгән агач төбендә бөгәрләнеп елан ята.

— Әстәгыйм! Фа-ил, син кайда?

Бераз көттереп, шаркылдап көлеп, агач артыннан Фаил килеп чыга.

— Елан күргәч нишләр икән дигән идем.

— Өстенә утырган булсам?

— Менеп ятсаң да чакмый ул. Тузбаш бит. Кояшта кызынырга чыккан.

Минем үз гомеремдә беренче мәртәбә шундый зур елан күрүем. Тузбаш икәне дә, тузбашның кешеләргә тимәве дә ышандырмый. Елан минем аңымда — чага, чакса — үтерә торган иләмсез куркыныч җан иясе булып кына яши.

Котымны алып куркытса да, Аккош күлендә алган матур тәэсирләрне елан сурәте генә юып төшерә алмады. Без бергә өйләнешкәч тә, кызыбыз Раушания тугач та көймәдә йөрергә еш кына килә торган булдык. Фаил — диңгезче. Күзләре зур, зәңгәр. Прокатка бирелә торган көймәләрнең дә һәрвакыт зәңгәрен сайлый. Аккош күленең зәңгәр киңлегендә ике шигъри җанның әле ачылып кына килгән **зәңгәр күзле Мәхәббәте** тирбәлә.

**Сөюләрдән без бер чибәр идек...**

Ул елларда юлларыбызга каршы чыгып Хозыр Ильяс үзе көтеп тордымы әллә? Кызыбыз туды. Фаилнең китабы чыкты. Язучылар берлегенә әгъза итеп алынды.

Без сихерләнеп, очанлап, сөюләребездән дөньяда бер чибәр булып Мәхәббәт диңгезендә йөздек. Шул хисләр белән хозурланып тагын да биеккәрәк күтәрелдек. Җаннарыбыз тагын да сихәтләнеп, йөрәкләребез тагын да дәртләнебрәк китте. Яшәргә, зур эшләр майтарырга дип кайнар хисләребезне бергә куштык. Без ул чакта Күкнең җиденче катында, ләззәтләрнең иң биек хозурында идек!

Минем туган якларыма кайтып, чибәрлектә чиге булмаган болын Баҗанасына төштек. Зөбәер болынының түр башындагы Бикбау, Калморза ярларына сыенып аккан Ык култыкларында җитәкләшеп йөрдек. Төнгә калып Баҗана елгасында коенганда, Ай безгә яп-якты юл тукып бирде.

— Әйдә, шул Ай юлыннан дөнья читенә кадәр бергә йөзеп барабыз.

— Әйдә соң. Йөзеп арыгач җәяүләп китәрбезме?

— Ә нигә җәяү? Кулларыбызны канат итеп очып алырбыз...

Су май кебек йомшак, җылы. Ай сукмагы шундый сихри, шөбһәле. Ул безне тагын да эчкәрәк, тирәнгәрәк чакыра. Без һичнәрсәдән курыкмыйча алга барабыз. Бер-беребезне шашып сөюдән туган Мәхәббәтебез безне гүя үлемсез иткән!.. Аннан соң бу бит минем туган ягым. Туган Табигать үз баласын батыра димени?..

Күкрәкләребезгә сыймыйча үзебездән алда йөгергән хисләребез шигырь юллары булып агыла.

Син яшәгәч җирдә, тау күтәрәм,
Йолдыз ясыйм төнге яшеннәрдән,
Коңгырт күзле кызый.
Сөюем өчен сине өзелеп-өзелеп,
Бирдең, ахры, миңа үлемсезлек,
Коңгырт күзле кызый...

Мәхәббәт безне әнә шулай дәрманлы иткән иде. Бүген мин шул мәңге дә сүнмәс, сүрелмәс кебек тоелган **коңгырт күзле Мәхәббәтемне** балаларыма, оныкларыма, хәтта оныкларымның оныкларына ишетелерлек итеп сөйләргә тиештер, мөгаен!

**Әллә инде артык яратканга?**

Таһир-Зөһрә, Хөсрәү вә Ширин, Галиябану белән Хәлил, Аксинья һәм Григорий сөешүләре ничек язылган да, төрле риваять, кыйсса, мәрсияләр каян килеп чыккан? Саф һәм оялчан, яшерен һәм тыелгысыз, һәлакәтле һәм үкенечле мәхәббәтләр... Алар бездәйләрнең тормышыннан алып язылган. Аерылуны алдан тоеп, канатлары каерылып, көйри-көйри янган йөрәк хисләреннән. Алар тормышта сирәк очрый торган фаҗигагә дучар булган парлар. Алар кыска гомерле, каршылыклы, каргышлы, сагышлы язмышлар...

Иртәләрне таң нурына манып,
Үземнекен атлавыннан танып
Яраттым!..

Әмма... Һай шул «әмма»ны!

Егәр кергәч кенә беләкләргә, кай арада безнең йөрәкләргә кан сауды соң? Кай арада? Тик кан сауганчы без инде оя корган идек. Бәхетле булсыннар дигән теләк белән балалар тудырдык. Оябыз янына да, Мәхәббәтебез сагына да айбалталар тоткан сакчылар куймадык. Дошманыбыз юк дип уйладык. Икебез дә беркатлы, хәйлә-хикмәтсез авыл баласы. Бәхетебездән көнләшерләр, яраткан өчен җәзага тартырлар, беребезнең җанын кыярлар дигән уй башыбызга да килмәде...

Юк, юк, безнең **Мәхәббәтебез җете кызыл** булганы өчен күзсенмәде. Бәла шунда: яратышуыбыз артык кайнар иде. Юлымның кыл уртасында аны югалтуым да, мөгаен, шуңа күрәдер.

**Тик дөньясы гына әллә ничек...**

Кара төн. Караңгы төнне тагын да шыксызландырып күңелгә шомлы уйлар килә. Иремнең эштән соң өйгә кайтмавының сәбәбе нәрсәдә?..

— Фаил кайда икән, белмисезме?

— Кызлар янында, конечно! Ә сиңа көнләшү өчен җитә калды, ха-ха-ха!..

«Көнләшү» сүзе бәгыремә агулы хәнҗәр булып кадала. Чарасыз калып, әтиләрен көтеп ала алмаган балаларымны йоклатып, ике якка чыккан тәрәзә арасында йөрим.

Өйдә сәер салкынлык. Тәрәзәбезнең сул якка караган өлгесеннән торбадан өргәндәй нәзек, ачулы җил агып керә. Үтәли йөрәккә кадалып, тәнне өшетә. Уң якка караган тәрәзә артында төнге бушлык. Тора-бара урамда трамвай гөрелтесе, машина тавышлары да тына. Мин өстәл лампасы яктысында күңелдә кайнаган хисләремне кәгазьгә төшерәм.

Безнең күңел нигә моңлы икән,
Безнең күңел ничә кыллы икән?..

1982 елның 5 октябрь төне. Усал җил уйларны өзгәли. Матур хатирәләремне ерткалап уңлы-суңлы бәрә. Ике битем дөрләп-дөрләп яна башлый. Әмма минем күңелем җан тынычлыгы тели. Тормыш гарасатларына кереп югаласым да, теләмәгән гөнаһларга ураласым да килми. Пар-алтын канат белән тыныч кына итеп балаларымны үстерү нияте белән яшим.

Теләк теләк белән. Ә тормыш башка. Чыгымчылап чапкан уйларым әле ярсый, әле моңсулана, тагын әллә нинди, тел белән әйтеп бетергесез халәтләр кичерә.

Кушылырга сайрар кош кирәк, —

дип дәвам итәм мин, очсыз-кырыйсыз уйларымны тәртипкә салырга тырышып.

Әмма безгә бер-беребезгә кушылып, парлашып сайрарга насыйп булмаган. Гөрләшеп яшисе елларны ут йотып, җилкәмә тау кадәр йөк күтәреп үтәргә язган булып чыкты миңа. Утыз биш яшемдә башымны — исәп, күңелемне уй басты. Мин исәнгерәп, **Мәхәббәтнең кара урманына** кереп адаштым...

Йа Алла, Таһир кебек батыр, Зөһрә кебек матур булып та кушыла алмаган ярлар никадәр күп бу дөньяда. Кавышып та тигез гомер кичерә алмаганнары никадәр.

Әмма ул елларда «Тик дөньясы гына әллә ничек» дигән шикне белдерергә дә ярамаган, күрәсең. Минем дә бу шигырем «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») газетасыннан, инде басылып бетте дигәч, шушы бер юлы — болай да һәркемгә мәгълүм гап-гади фикере өчен төшеп калды. Татарстан радиосының худсоветыннан үтәр өчен дә нәкъ шушы юлларны үзгәртергә кирәк булды. Әсәрне беренче булып башкаручы җырчы Миңгол Галиев аны берлек санда, ягъни үз фаҗигасе итеп: «Дөньям гына менә әллә ничек» — дип җырлады.

...Мин әнә шул кара төндә тол калдым. Шул кара төндә минем иремне, балаларымның газиз әтисен, татар совет язучысы дигән горур исемне йөрткән Фаил Шәфигуллинны үтереп ташладылар...

**Бер кычкырды кәккүк**

Фаил вафатыннан соң аңа багышлап бик күп шигырьләр язылды. Шигырьләремне төрле кеше төрлечә бәяләде. Куанганнары да, гел үлем турында язасың, теманы үзгәрт, дигәннәре дә булды. Темам алмашынды. Ләкин минем ачы фаҗигам — тагын бик күп толларның уртак язмышы. Хәсрәтне юарга күз яшьләре дә кирәк. Иҗатымда мин әнә шуңа инандым. Ничек кенә тырышсаң да, фаҗигане сандугач тавышы белән сөйләп булмый. Андый язмышны язганда, бәхетсез Мәхәббәтне тасвирлаганда яшелле-күкле авазлар да килеп керә. Синнән сорап та тормыйча. Бәреп... Билгеле, пычаклары май өстендәге иркә ярларга сәер тоеладыр андый газаплы уйлар. Саруларын да кайнатадыр. Ләкин алар — җан авазы. Бары бер кычкырып алган кәккүк кебек күзгә күренеп, кулга тимәгәндәй югалган **Мәхәббәтнең яшелле-күкле җан авазы!**

Кагылмагыз кайнар хисләремә,
Кагылмагыз зәңгәр төсләремә,
Кагылмагыз минем сөюемә,
Үксүемә, янып-көюемә,
Кагылмагыз!

Шәхес яки шәхеснең хатыны булып яшәү ләззәтле дә, авыр да вазифа. Фаил моны белеп китте. Аның бик еш тынычлыкта, гаиләсе белән аулакта калып яшисе килде. Заман чирләренә бирешмәс өчен төрле сәбәпләр уйлап тапты. Чирәм чыкканчы салмаска, кар төшкәнче авызга хәмер алмаска кебек шартлар куеп тирә-юньдәгеләрне дә шуңа өндәде. Андый вакытларда Фаил, үзе әйтмешли, шәп итеп эшләп ала, «запаслана» иде.

Алданып адашкалап алуын да, гаиләсенә чит көчләрнең тәэсирен дә сизде. Китергән газаплары өчен ахырдан җаны сызлана, иң олы ярату белән яратуын әйтә торган иде. Ихласлыгы, гомере буе «батыр малай» теләсә дә, кызларыбызны чын йөрәктән үз итүе гаиләбезне өзелә дигәндә саклап калды.

Халык әйтмешли, бер генә кешенең дә сарае буш түгел. Бер генә өйдә дә табак-савыт шалтырамый тормый. Булгандыр. Безнең кашык-тәлинкәләребез дә зеңләгән-чыңлагандыр. Әмма ул зәгыйфь зеңләүләр онытылган. Күңелдә илаһи Сөю, галиҗәнап Ярату гына яшәп калган!

**Ялгыз агачка ышык юк**

Дөнья күргән картлар: «Суд юлларында йөрергә язмасын», — дип тә теләк телиләр. Бик урынлы һәм дөрес теләк бу. Чөнки суд юлында йөргән кеше мораль яктан миңри, сәламәтлеген югалта.

Прокуратура юлында озын ел буе йөреп, ахыр чиктә йөрүләремнең файдасыз бер эш булуын аңлап туктадым. Ләкин өметсез шайтан, диләр. Еллар үткәч булса да, икенче бер җинаяткә бәйле рәвештә булса да, үтерүченең кем икәне ачыкланыр дип уйладым. Инде ул өмет тә әкрен-әкрен сүнеп бара. Әмма күңелгә мәңге сөртелмәс булып бер сурәт сеңгән. Ул — кыйналган әтиләре мәетен күргән балаларымның шашынган-әсәренгән күз карашлары; мондый ерткычлыкны кабул итә, аңнарына сыйдыра алмаудан туган гасаби уйлары; балалык көчсезлегеннән күңелләре елавы!.. Менә шул сурәт үлгәнче дә җуелмас, тетрәнгеч бер сәхнә булып күз алдында саклана.

Вакыт-вакыт миңа аларның һәрбер күзәнәгеннән кан саркып торган шикелле тоела. Әтиле балалар бер секундта хәл итә торган эшләргә алар җан тирләрен түгеп, тырышып-тырмашып ирешә. Әтиле балалар назланып-иркәләнеп «Әти» дигән кодрәтле сүз хозурында йөзгәндә, алар бер кырыйда нәүмиз булып басып тора. «Ятим бала кебек» гыйбарәсе менә нинди югалту-әрнүләрдән килеп чыккан бит ул! Шуңа күрәдерме, хәзерге көндә хисапсыз күп атыш-үтерешләрне ишеткәч тә, иң беренче булып аларның үксез калган балалары турында уйлыйм. Тол хатыннарын кызганам. Ялгыз агачка бер җирдә дә ышык юк лабаса. Һай, кем акылларын кемгә бирәсең дә, явыз ниятле кешеләрнең кулын ничек күтәрелмәс итәсең...

Зур юанычым — җирләү-җыю җәһәтендә мин үземнең кулымнан килгән, динебез, гореф-гадәтебез кушкан бөтен йола-кануннарыбызны җиренә җиткереп үтәргә тырыштым. Фаилдән соң өч ел чамасы яшәп вафат булган каенанамны да мин җирләдем. Өчесен, җидесен, кырыгын, елын үткәрдем. Бертуган энемнән чардуган эшләтеп каберенә куйдык.

Фаил Шәфигуллинның иҗатын яшәтү мәсьәләсенә килгәндә, теләкләрем зурдан, исәбем томлыкларын чыгару иде. Ул хыялым тормышка ашмады. Алай да өч китабын җыеп чыгара алдым. Дөрес, соңгы — 1991 елда чыккан «Өй салуның ние бар?» исемле китаптан «Төзүчесе Эльмира Шәрифуллина» дигән җөмләне төшереп калдырдылар. Ә бераздан «Социалистик Татарстан» газетасында «дуслары җыеп нәшриятка тапшырган китап дөнья күрде» дигән ялган мәгълүмат чыкты.

Өсте-өстенә килгән борчу, әрнү, сагыну йөземә сары моң булып ятты. **Мәхәббәтем сары сагыш төсен алды.**

**Ышанам**

Мин гомерем буе могҗизага ышанып яшәдем. Бу шагыйрә булуымнан киләдер, мөгаен. Хәзер дә гаиләмә шатлык керсә, кемдер изгелек эшләсә, ярдәм вәгъдә итсә, Фаил рухының теләге түгел микән дип уйлыйм. Кайберләре рас килә, кайчакта ялгышам. Ләкин шунысы бар: үлгәннәр белән киңәшләшеп булмый. «Киңәшле эш таркалмас», «Бер баш яхшы, ике баш тагын да әйбәтрәк» кебек мәкальләрнең кыйммәте ачы хакыйкать булып алга килә.

Могҗиза дигәннән, тиз ышана торган гадәтемә дәлил итеп, бер вакыйга сөйлим әле.

1989 ел. Фаилнең 50 еллыгы. Шул уңайдан Фаил Шәфигуллин иҗаты Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге бүләгенә кандидат итеп күрсәтелде. Бик күпләр бу эшне күркәм, изге гамәл буларак кабул кылды. Булган гомерендә халкына хезмәт күрсәтүдән башканы белмәгән, әдәбиятыбызның алтын хәзинәсен тәшкил итәрлек әсәрләр калдырган шәхеснең якты рухы каршында баш ияр өчен туган мөмкинлек иде бу! Фаил кандидатурасын яклап әдәбият сөючеләрдән йөзләгән хат килде. Газеталарда мәкаләләр чыкты. Телевидение оештырган тапшыруда балаларым әтиләренең

әсәрләрен яттан укып катнашты. Әмма... Тукай бәйрәменә берничә көн кала премия мәсьәләсенең инде хәл ителүен, Фаилгә бирелмәвен ишеттек. Куырылып килеп, сулкылдый-сулкылдый елаган йөрәгемне учыма кысып, әкияти бер хыял белән имза җыярга тотындым. Чама белән ярты көн, бер төн вакыт бар иде.

Республикабызның Габдулла Тукай бүләген бирү комиссиясенә адреслanган бу хатка Фаилнең иҗатын белгән, хөрмәт иткән, яраткан зур, мөхтәрәм шәхесләр кул куйды. Барлыгы 90(!) кеше. Хатны комиссия председателенә җиткерү әмәлен дә таптык. Тик минем яраланган җәнлек кебек соңгы көчемне җыеп редакциядән редакциягә, нәшрияттан Язучылар берлегенә, бер күршемнән икенчесенә, күренекле шәхесләргә ишек шакып бәргәләнеп йөрүем кемгәдер көлке генә булып тоелгандыр. Премия мәсьәләсе үзгәрешсез калды.

Ләкин, Ходайга шөкер, шул көлке гамәлләремә дә, алданган саен һаман ышана алуыма да үкенмим. Бу — минем холкым, һәм хәзер дә, сабыйларча сабыр калып, нindидер могҗиза көтәм. Гаделлек җиңәргә тиеш. Фаил Шәфигуллинның зур иҗаты, кадерле мирасы киләчәктә үз бәясен алыр! Минем гаиләмә, минем газиз балаларыма, оныкларыма Ходаем-Аллам җан тынычлыклары бирер. Яралы җаннарыбызда казынучы явызлар арып та, оялып та туктарлар.

Ышанам. Безнең кулларыбыздан тартып алынган Бәхет, безне мәхрүм калдырып китәргә мәҗбүр ителгән Шатлык — кайдадыр бик якында. Ул бәхет елмаеп килеп чыгар да: «Менә ул мин, синең хыялыңда күптән **ак төскә кергән Мәхәббәтең!»** — дип, оныкларыма: Сәйдәш белән Сәгыйтемә күрсәтер...

Фаилнең теләгән тормышка ашырып туган «батыр»ларым, ниһаять, безгә — тормышның давыллы диңгезендә
минем белән бергә айкалган-чайкалган кызларыма да ышык ясар. Сынмаска, биеклекләр яулаганда туктап калмаска көч бирер дип өметләнәм! Амин!

*1999*

## ***Миһербан чишмәсе***

Мин — Ана!

Карынымдагы балама бүген җан иңде. Хыялымда мин аның хәтфәдәй яшел болында күбәләкләр куып йөрүен, аллы-гөлле чәчәкләрдән такыя үреп баш очына чөюен, кояш нурларына коенып тәнен чыныктыруын, яшь колыннар белән узышып буыннарын ныгытуын, алай гына да түгел, кулларын йолдызларга сузып Галәм белән элемтәгә керүен күз алдына китерәм. Үсеп җитәр дә, ил корабына ал җилкәннәр корып, җиде диңгез гизәргә китәр. Чыгып җилләр, кубып дулкын, корбан итеп җанын сорамасмы упкын? Әгәр шулай була калса, тәнен пакьләп, башкаларны саклап үзен корбанга бирә алырмы?

Әйткәнемчә, ул әлегә минем йөрәк катымда. Әлегә ул мин сулаганны сулый, мин уйлаганны уйлый. Мин аның якты дөньяга туар өчен һәрвакыт талпынып торуын тоям. Әмма мин аның авыру йә булмаса кадерсез булып тууын теләмим. Ишетәсезме, теләмим! Алыгыз Күк гөмбәзендәге, минем баш очындагы, туачак сабыемның бишек сиртмәсендәге хәвеф тамгасын! Кешеләрнең куллары бер-берсенә яманлык эшләргә дип түгел, фәкать изгелек кылырга, дога укырга дип кенә күтәрелсен!

Мин — Ана!

Бүген таңда Кешелек дөньясына бала тудырдым. Бу олуг җиһанга Кеше бүләк иттем. Сабыемны бисмиллалы Кендек әбисе кабул итеп алды. Йомшак куллары белән эч-бавырымны сылап, дөньядагы иң матур сүзләрне әйтә-әйтә бәбиемне биләп куеныма салды. Ул шуның кадәр дә нәни, шуның кадәр дә газиз җан иясе чупылдатып күкрәк сөтемне имә башлады. Изге сөт аша мин аның бит очларына аллык иңүен тойдым. Мин аңа тагын яшәү дәрте, егәр көче, иман нуры күчүен дә теләдем. Сабыемның күкрәгемә сарылып имүе миңа әйтеп бетергесез рәхәтлек һәм ләззәт китерде. Ул үзе дә мине көчле һәм бәхетле итте! Ләкин... аналарын кадерсез иткән балалар, балаларын бәхетсез иткән аналар да байтак бит дөньяда...

Ни өчен?

Ник кенә шулай килеп чыга соң бу?

Вакытлар, вакыйгалар үтү белән элек изге саналган әйберләр әкренләп кенә хәтеребездән сөртелә, төссезләнә бара. Мәсәлән, сүзне югарыда әйтеп киткән Кендек әбисеннән башлыйсы килә. Ана булырга тиешле хатын-кыз өчен искиткеч мөһим бу мәсьәлә соңгы вакытта әһәмиятен тулысынча югалтты. Бигрәк тә шәһәр җирендә. Әйтик, тулгак тота башлаган йөкле хатынны «ашыгыч ярдәм» машинасы кайсы хастаханәгә илтә, балаңны кем кабул итеп ала — бу күпләргә билгесез. Ана өчен дөньяга Кеше тудыру гамәле, икенче төрле әйтсәк, сабый бала өчен Җир йөзенә беренче аваз салу мизгеле — әйтеп

бетергесез шатлык, олы вакыйга булса, Анага булышучы, баланы кабул итүче табибә яки шәфкать туташы өчен бу гадәти эш сәгате. Ярый ла синең бәхетеңә мәрхәмәтлеләргә очраса? Хезмәт хакының түбән, иренең исерек, баласының наркоман булуыннан тәмам миңгерәп калганы туры килсә? Йә булмаса адәм баласын кулына аламы ул, әллә эт баласынмы — шундый бер битарафлык белән эшләүче кычыткан теллесенең эш сәгатендә чирләсәң?.. «Ир белән йоклаганда бер дә авыртмагандыр... Көчән... Синең өчен мин тудырмам...» кебек тупас, ямьсез сүзләр белән җаныңны кыйнап, түбәнсетеп кешелектән чыгарса? Изге догаларга, дөньядагы иң матур сүзләргә лаек чагында урам сукбае кадәрле дә кадерең калмаса?..

Кадер һәм кадерсезлек.

Гомумән, безнең кирәксенеп, теләп тапкан балаларыбыз туганнан соң нинди үрнәкләр күреп үсә соң? Тирә-юнендә җанын җылытырдай, кешелеген саклардай изге затлар бармы? Аларның нинди гамәлләре синең балаларыңа өлге булып тора? Бу җәһәттән безнең авыл тормышы, пакь күңелле әбекәйләребез нәниләребезгә олы бер мәктәп гыйлеме бирә, билгеле!

Шәмсенур әбиегезнең кулы бик йомшак, шифалы иде, дип сөйләгәне хәтердә энкәйнең. Алты бала таптым. Алты баланың алтысыннан соң да бәби мунчасын ул кертте. Өчегезгә Кендек әбисе булды.

Зөбәер халкы Шәмсенур әбекәйне Кендек әбекәй дип тә йөртте. Ул елларда ярты авыл халкын аның куллары кабул итеп алгандыр якты дөньяга. Йомшак сүзле, сабыр табигатьле, искиткеч чиста, пөхтә бу карчык безнең күршебез ерак әбиемнең ахирәт дусты иде.

— Элек кеше керне көлдән селте ясап юды бит. Берәр чүмеч селте сулары калса да, «бер-ике кисәк кереңне сыгып куймыйсыңмы?» дип, бер-берсенә кертәләр иде. Менә шулай тату яшәделәр, — ди энкәй.

Димәк, Асылъяр кызы Шәмсенур әбекәй — минем өч туганымның Кендек әбисе.

Бәби тоткан Кендек әбекәем,
Ераклашкан саен — янәшә.
Кендекләрне кистең,
Җиргә тектең,
Хатирәгә күчтең,
Мең яшә!

Әбекәйләр!

Үз гомеремдә икәү булды алар. Әтиемнең әнисе дә, әниемнеке дә мин белгәндә исәннәр иде.

Әтиемнең әнисе, минем якын әбием — Бәгъделбәнат, какча гәүдәле, бәләкәй генә бер карчык. Хатыны үлгән кешегә ярәшелеп өч ир бала тапкан. Әтием аның уртанчы улы. Бәгъделбәнат әбием өч баласын да бер-бер артлы Бөек Ватан сугышына озатып, бары тик бер генә улын исән килеш каршы алган. Олы улы Нигъмәтулланың да, төпчек улы Габдулланың да «хәбәрсез югалды» дигән язулары килгәннән соң елый-елый күзләре сукырайган.

Чарасыз калган әбиемне әткәй төп нигезе Мөслимнән торган җиребез Актанышка алып килде. Ул, берничә ел үтүгә, уйларыннан сарыга сабышып, тәмам урын өстенә ятты.

— Сукыр күздән дә яшь чыга икән, бер генә еламаган көне дә юк, — дия иде энкәй.

— Безгә еламый яшәргә язмагандыр инде, — ди якын әбекәй, аңа җавап итеп.

Көннәр, еллар үтте. Якын әбием көннән-көн хәлсезләнде. Соңга таба мендәрләргә сөяп кенә утырта башладык. Әбекәйнең Мөслим районында яшәүче үги кызлары: Зур түткәй белән Мулла түткәй, сеңлесе Хәят апа, олы килене Фәрхикамал җиңгәчәй һәм башка туганнары, оныклары: Миңнур апа белән Ания апа еш кына хәлен белергә киләләр иде. Үзләре пешергән камыр ризыкларын буранкалап төреп әбекәйнең ятагы тирәли кыстырып куюлары истә калган. Ул вакытта өебез бәләкәй. Үзебез ун кеше һәм тагын күпме кунак. Көндезләре ярый, кичләрен кайларга урын җәеп, кайларга урнаштырып бетергәндер энкәй? Ә менә табыныбыз һәрвакыт идән уртасында була иде. Башта энкәй миннән идәнне юдырта. Аннан җәймә, җәймә өстенә зур ашъяулык җәеп ике табаклык аш әзерли идек. Ничә утырсак та алдыбыздан катык, эремчек өзелми. Чөнки ул елларда ике сыер асрый идек. Хрущев заманы юкса. Бер гаиләгә бер генә сыер тотарга рөхсәт ителә. Ә безнең бабакай белән әбекәй үз исемнәрендә тагын бер сыер тоталар иде. Әмма без бер вакытта да аерым гаиләләр булып яшәмәдек. Әбекәй дә, бабакай да, урыннары җәннәттә булсын, безнең өчен үлеп торалар иде. Якын әбиемә дә мөнәсәбәтләре искиткеч яхшы булды. Мәсәлән, якын әбием хәтта чәчен дә тарый алмый башлагач, ерак әбием сабый баланың башыннан сыйпаган кебек йомшак кына итеп тарап, аның чәчен үрә иде. Энкәй әледән-әле яулыгын алмаштырып тора. Энкәйнең якын әбекәй турында әйткән сүзе әле дә истә: «Әй аның чисталыгы. Аштан кайтыр, кулмәген шундук салып кер бавына чыгарып эләр иде», — ди. Юк, безгә энкәй сез дә шулай эшләгез, киемегездән кер исе килеп йөрмәсен, дими. Һәм бу сүзләрне без ишетсен өчен дә әйтми кебек. Әмма аның әбиебезнең шушы сыйфатын күтәренке итеп күрсәтүе минем аша минем балаларыма да күчте.

Якын әбием, мәрхүмә, ни чиста, ни эшчән, ни сабыр карчык булмасын — бәхетле гомер кичергән дип әйтә алмыйм. Унсигез яшендә үзеннән күпкә олы кешегә кияүгә биргәннәр. Бик яшьли ирдән калып, өч баласын фәкыйрьлектә үстергән. Әнә шул зур михнәтләр чигеп тәрбияләгән балаларын югалту кайгысы таушалтып аяктан еккан да инде үзен. Әтиемнең кече энесе Габдулла абыемның зурайтылган фоторәсеме мин белә-белгәннән бирле безнең өйдә эленеп тора. Үзем ана булып бала тәмен татыгач, мин аның сурәтенә тыныч кына карый алмый башладым. Дулкынланып торган чәчләренә, зур инсафлык бөркелгән карашына күз сирпү белән якын әбием исемә төшә. Егет булып үсеп җиткәч кенә шушындый да чибәр, сау-сәламәт баланңы җуй әле. Кайгырмаслык, елап сукыраймаслыкмы соң?..

Якын әбием җитмеш өч яшендә дөнья куйды. Әмма бер нәрсә белән горурлана алам, ул безнең җылы өебездә, исән калган бердәнбер улы кулында, килененең яхшы тәрбиясендә вафат булды.

Әбекәйләр...

Икенчесе — Шәмсениса исемлесе — ерак әбием. Алар белән дә бергә тордык, бер өйдә яшәдек. Әнкәй аларга әткәй дип, анакай дип эндәшә иде. Үз әнисе бәбидән соң өзлегеп вафат булгач, Сабир бабакай белән Шәмсениса әбекәй әнкәйне җиде атналык вакыттан тәрбиягә алып үстергәннәр. Әмма бу хәлне мин, үзем балигъ булгач, әнкәй сөйләгәннән генә белдем. Димәк, алар арасында бервакытта да бер-берсен үгисеткән мөнәсәбәтләр булмаган.

Ерак әбием бик тәвәккәл, нык куллы карчык иде. Бөек Ватан сугышы елларында колхозның балта остасы вазифаларын башкарган. Без белгәндә дә ихатадагы бөтен вак-төяк эш аның кулында иде. Мунчага мич чыгару, коега бура бурау, киле ясау, тәрәзә каршына утыргычлар эшләү... Шуның өстенә авылның оста тегүчесе дә. Ә чиккән чигүләрен күрсәң, күзеңнең явын алырлыклар. Аннан соң әбекәй бик яхшы бакчачы да иде. Авыл кешесе хәтта суган утыртмаган бер вакытта, безнең әбекәй беләк-беләк кыярлар үстерде. Түтәлләрне ачык абзарга ясый. Бакча артындагы чирәмлектән кәс куптарып «гөл балчыгы» алып керәбез. Ярмаланып торган кара туфракны түгәрәк-түгәрәк итеп берничә урынга ясалган түтәлләргә җәябез. Кыяр үсентесе ике «колаклангач», әбием безгә яңгырдан соң «ат тоягы» җыйдыра. Җыйган берен кыяр үсентеләре тирәли тезә. Дымны саклау өчен шәп җайланма! Суны иртән ташып куярга куша. Көн сүрелә төшкәч, үзе ясаган тишекле чүмеч белән кояшта май кебек булып җылынган суны кыяр түтәлләренә сибә иде.

Әби-бабамның ныклыгы, гаиләбезнең бердәмлеге аркасында тормышыбыз таза иде. Әйтик, мунчадан өзелеп яшәмәдек. Башта кара, аннан ак мунча җиткерделәр. Мин бәләкәй чакларда авылдашларыбызның бик күбесе мунчабызга юынырга, коебызга суга, килебезгә ярма онларга йөриләр иде әле. Мунчаны без, гадәттә, әбекәй белән бергә керә торган идек. Әбекәй безне ай-ваебызга карамыйча эссе салып чаба. Ә инде үзе чабынганда кызуга һич кенә дә чыдамалы булмый иде.

Тагын шунысын да әйтим, Зөбәер авылында без бердәнбер хәлле гаилә түгел, әмма киле бары тик бездә генә иде. Шуңа күрә иң ерак Качкын очыннан да безгә килеп тары ярмасы онлыйлар иде. Ул елларда тары тәбикмәгенең иң модада чагы булган, ахры. Сары май белән майлап кайнар килеш ашаганда телеңне йотарлык тәмле була бу ризык. Тик, әллә инде килеләр беткәнгә, татар халкының бу милли ризыгы хәтта авылларда да сирәк пешерелә хәзер.

Сүзем Шәмсениса әбием турында иде бит. Шушы әбиемнең, көне-төне колхоз эшендә йөргән бабамны көтеп алып, сәкегә үзе суккан ашъяулыкны җәеп, җиз самавырдан парлап чәй эчүләрен әле дә сокланып күз алдына китерәм. Иртәнге һәм кичке табыннар күп чагында бергә була иде. Ә менә көндезге чәй — аерым. Күрәсең, бабамның әбәткә кайта торган үз вакыты булган. Алар, самавырның икесе ике ягына утырып, парлашып чәй эчәләр. Самавыр әбием янындарак була, чәйне ул ясый. Сәке түрендә ашъяулыкның бик матур ачык урыны кала. Менә шул урынга еш кына берәребез менеп кунаклый идек. Ләкин бервакытта да безгә әбием белән бабамның кырын караганы йә булмаса, тынычлап чәй эчәргә ирек бирегез әле, дигәне булмады. Ә бит без биш бала. Тавышланган, туйдырган чакларыбыз булмый калмагандыр. Ләкин әбием дә, бабам да безнең белән әвәрә килүне бәхеткә саныйлар иде, күрәсең. Шуның ачык мисалы итеп, ел да килә торган сабан туена бабабызның колхоздан ат алып кайтып, безне хасиятләп бәйрәмгә озатканын исемә төшерәм. Даими шулай. Ничә еллар рәттән шулай. Без йокыдан торуга, ихатабызда печән салынган арбага бәйләп куелган ат була иде. Әнкәй теккән яңа күлмәкләребезне киеп, ишегалдына йөгерешеп чыгабыз.

— Арбага утырмый торыгыз, яшь печән күлмәгегезне буяр, — ди бабакай.

Ул атны җигә, печән өстенә җәймә җәя, аннан безгә аякларыбызны эчкә алып ике яклап тезелеп утырырга куша. Әткәй белән әнкәй икесе ике якка алга утыралар. Шулай итеп, без бик күп пешкән йомырка, пешкән ит, камыр ризыклары, әйрән, чәй алып сабан туена китәбез. Әбекәй белән бабакай капканың икесе ике ягына басып озатып калалар. Ә инде без кайтуга әбекәйнең яңа ипие мичтән чыгарылган, мендәр өстенә икенче ягы белән әйләндереп тезелгән, күпереп пешкән көлчәсе майлап, табак түбәсеннән итеп өеп куелган, мунчасы ягылган була иде.

Бабам картлык көннәрендә амбарда каравылда торды. Үләренә бер атна кала эшеннән туктап түшәккә егылды. Беркемгә авыр сүз әйтмичә, беркемгә зыян-зәүрәт салмыйча якты дөньядан китеп барды. Шуңа күрә Зөбәер халкы аны бүгенге көнгә кадәр Сабир бабай дип олылап искә ала.

Уйласаң, шактый кызык нәтиҗә чыгарырга була. Ишегалдына кое казып бөтен авыл халкын кинәндерүче хуҗалар юк шул инде хәзер. Кеше түгел, җил дә керә алмаслык итеп эшләнә бүген капкалар. Күбесе тимер йозакта. Милләтебезнең тәбикмәк кебек милли ризыклары да, киле кебек кайбер көнкүреш әйберләре дә киң күңелле әбием белән бабам кебек бездән ераклаша баралар. Ә алар бөтен тапканнарын уртак итеп, безнең өчен яшәгәннәр. Без дип сулаганнар, безгә бәхет теләп намазлыкка басканнар!

Бары — бергә, югы уртак булган,
Әбекәем, синең милкеңдә.
Сеңдергәнсең олы хөрмәт хисе
Ипекәйгә, яшәү күркенә.

«Валчыгын да җиргә төшермәгез,
Гөнаһысын кая куярсыз?» —
Күңелләрдә һаман шул сүз йөри:
«Бисмилланы әйтсәң — туярсыз...»

Ап-ак төскә киендерде сине
Кадер киче,
туйлар,
гаетләр...
Ак намазлык өсләренә чүккән
Ак җаныңны кемнәр гаепләр?

Очты-очты ап-ак карлар белән,
Ап-ак җаннар очты көз җиткәч.
Башларыңны ташка орсаң да син,
Кайтмый алар, кайтмый бер киткәч.

Соңгы юлга чыга тыныч кына
Әүлиядай җанлы әбиләр...
Тәүбә, тәүбә!
Исән була күрсен
Әбекәйләр булыр әниләр!

Әбекәйләр...

Бала чагыма кайтып шушы сүзне әйтүгә, гаҗәеп дөнья күз алдыма килә. Авылда бөтен тирә-юнебез ак яулыклы, пакь җанлы әбиләр белән әйләндереп алынган булган ич безнең. Әйтик, терәлеп торган күршебез Нурлый (чын исеме Нурҗыян) әби, ул безне — бөтен авыл баласын җыеп, карга боткасына алып чыга торган иде. Табигатьне ярата, аның серләрен, хикмәтләрен аңлый. Ул белмәгән төбәк, ул кагылмаган куак калмагандыр да болында. Әмма елак яки үшән кешеләрне үзенә юлдаш итмәде. Аның белән бергә болынга бару бәхетенә ирешергә теләсәң, аннан калышмаска, болында адашып кычкырып йөрмәскә тиешсең.

Икенче күршебез — Маму әбкәй. Аның турында бераз әйттем.

Чак кына арырак Галимәттәй белән Мәчтүрә җиңгәчәй, алар ерак әбиемнең килендәшләре, бездә еш була торган кунаклар.

Бик чибәр булып күз алдында калган, ятим килеш өч бала тәрбияләгән, картаеп та өлгермәс борын дөнья куйган Фәрхенур апа.

Үткәндә дә, сүткәндә дә хәл белеп чыгучы Нурый бабай корткасы.

Әллә каян урам башыннан ук ап-ак булып күренүче Хәмдениса әби.

Йөз яшькә чак кына җитми калган Кафия абыстай һәм башка берсеннән-берсе күркәм әүлия җаннар. Ничә еллар бер авылда, бер урамда яшәп, берсенең-бер мәртәбә ямьсез итеп кычкырганын, бала өстенә әйткәнен, тавышын күтәреп сөйләшкәнен йә булмаса кизәнгәнен күрмәдем мин аларның. Вакыт шаһит, нәкъ шушы әбиләребез үзләренең яшәү рәвешләре, кылган гамәлләре белән безнең җаннарыбызга тәүфыйк орлыгы чәчкән иң сабыр, иң түзем мөгаллимнәребез булган икән. Мең рәхмәт аларга! Урыннарын җәннәттән әйлә, Раббым Алла!

Аларга булган ихтирамым, соклану һәм ярату хисем күңелемнән шигырь булып агыла.

Йөгерек юллар ул,
Дәһшәтле еллар ул —
әбием күңеле.
Тулы бер авыл ул,
Шигъри давыл ул —
әбием күңеле.

Нәселнең яме ул,
Изгесе, гаме ул —
әбием күңеле.
Җиләкле алан ул,
Чәчәкле ялан ул —
әбием күңеле.
Сер чыкмас йозак ул,
Акыллы тозак ул —
әбием күңеле.
Шифалы угыз ул,
Һаман да яшь кыз ул —
әбием күңеле.
Мәкамле намаз ул,
Моң тулы азан ул —
әбием күңеле!..

Соңгы вакытта балаларыбызның әби-бабадан аерым үсүе, очрашкан вакытта да тел белмәү нәтиҗәсендә бер-берсе белән аңлаша алмаулары, үзара якынлык тоймаулары бик аяныч. Балдан татлы оныгына җанын ярып бирергә әзер торган әбиләр елый-елый нарасыеның башыннан сыйпаудан уза алмый. Чөнки оныгы аңа тартылмый. Аның сафлык, тапкырлык, инсаф-мәрхәмәт тулган әкият-җырларын аңламый. Ул гарип күңелле. Ул әбисенең, үзен тудырган әнисенең телен белми. Алай гына да түгел, хөрмәт итми. Буыннан буынга күчеп килгән күңел байлыгыннан: Мәгънә, Мән, Миһербан чишмәсеннән сыйлана алмый. Гомер-гомергә милләтебезнең йөзен билгеләгән, горурлыгы булып саналган тыйнаклык, итагатьлелек кебек сыйфатларыбыз — оныкларына нәүмиз булып карачы әбиләребезнең моңлы күзләре белән бергә йомыла бара. Ә иң куркынычы — күңел күзебез сукырая. Күрә карауга әйләнә. Әгәр шулай булмаса, без тудырган балалар безне тудырган әни белән ымлап, төртеп күрсәтеп сөйләшер идеме? Һәм без ничә дистә еллар буе шушы кадерсез мөнәсәбәткә юл куеп, риза булып яшәр идекме?..

— Ни кайгың, әйтсәнә, әбекәй,
Улларың, кызларың исәнме?
Бармы соң оныклар-татлылар,
Авырмый, сәламәт үсәме?

— Барын бар,
Барын бар оныклар,
Әмма да җибәрдек зур ялгыш.
Шул ялгыш ясаган гариплек
Гүрләргә кергәнче бер сагыш:

Ашкынып,
яшәреп,
дәртләнеп
Беренче оныкны көтүләр.
Кемем бар?!
Күрегез, диген күк,
Урамнан ирәеп үтүләр...

Булмастыр, дидем мин шул чакта,
Бәхетнең моннан да олысы.
Булмастыр, башкада һич булмас,
Сабыйның мондаен нурлысы!

Ярattым,
уйнаттым...
Ә алар?..

Без — XX гасыр ата-аналары. Үзебезне чәчәк аткан совет илендә яшибез дип ышандырып, бик тиздән коммунизмның ал таңын күрергә хыялланып яшәүчеләр идек. Әти-әниләребезгә, телебезгә, милләтебезгә бармак аша караган балаларыбыздан миһербан көтеп, бәхетле картлык өмет итүчеләр...

Инде килеп шунысына рәхмәт. Кушканны гына эшләргә өйрәнеп җиткән башларыбызга бераз гына булса да уйланырга форсат туды. Тирә-юнебезгә күз салдык, укыдык, ишеттек, күрдек. Менә бит Ходайның рәхмәте: берничә буыны чит илдә туып та туган җире белән тәмам элемтәсе өзелгән татарлар да ана телләрен онытмаган. Менә ерак Австралиядән килгән бер әни саф татарча сөйли: «Мин үзем дә, әнием дә чит илдә туганбыз. Үз балаларым да Австралиядә дөньяга килде. Ләкин телебезне онытмасыннар, нинди кавемнән булуларын белеп яшәсеннәр өчен мин аларга көн дә: «Хәерле иртә, балам, син татар кешесе», — дип эндәшәм. Йокларга яткырганда: «Тыныч йокы, балам. Син мөселман, догаларыңны укы», — дип колакларына пышылдыйм, татар халык җырларын өйрәтәм, «Йосыф

кыйссасы»н укыйм...» Ә монда, туган Татарстаныбызда үз баласын татарча өйрәтә алмаган, татар теленең кирәге юк, аны укып кайсы югары уку йортына керәсең, дип вәсвәсәләнгән эти-әниләргә нәрсә дисең? Ә менә өч-дүрт буыны Австралиядә туган бу нәселгә татарча белүнең нигә хаҗәте бар икән соң? Алар да бит балаларын ана телендә укыта алмый. Хикмәт — телнең белем алу өчен кирәклегендә генә түгел икән шул. Серләр — тирәндә. Тел әле ул белем бирү чыганагы гына түгел, тел — тәрбия бирү чыганагы да. Тел белү ул — безнең үткәнебезгә, тарихыбызга, нәселебезгә, әби-бабаларыбызга хөрмәт билгесе дә.

Баш тартабыз мәллә хакыйкатьтән?
Күңелләрен кырдык, рәнҗеттек.
Кулларыннан ямьне тартып алдык,
Ни сөйләшсәк, шунда чит иттек.

Сөйләмәче, зинһар, эч пошырып,
Әбиеңнең сүзен, дидек без.
Әбиеңә барып сөйлә әнә,
Мыскыл итеп шулай көлдек без.

Нәрсә бирә, кая алып бара,
Имеш, надан әби мәктәбе?
Ялгышканбыз,
Фәкать шунда булган
Оят, намус, әдәп, әхлагы...

Бик сөйләшер идек әби сүзен —
Аңламыйлар хәзер оныклар.
Егерменче гасыр торбасыннан
Күңелләргә кунган тутыклар.

Йөрәкләрне юшкын басып киткән,
Баш миңгерәп йөргән арада.
Өмет кипкән —
Бары тәне туып,
Аңы тумый калган балада...

Әйткәнемчә, без — ата-аналар үтеп киткән XX гасырныкылар. Балаларыбыз, оныкларыбыз исә өченче меңьеллыкныкы. Димәк, күбебезнең ыру башы — бер дәвамы — икенче ярда. Кайчагында әби белән онык икесе ике кыйтга, ике планета вәкиле кебек. Бик кызганыч. Буын чылбырыбызны күп җирдән өздек шул. Бер-беребезгә ихтирам, кеше кадере, изгелек дигән төшенчәләрне оныттык. Иң мөһиме, бу сыйфатларның ана сөте аша гына түгел, ана теле аркылы да күчүен шәйләми калдык. Бүген безгә яңабаштан туарга, рухи туарга, күңелләребезне кыра-кыра юарга кирәк, күрәсең. Олы-карыга, әткәйләребезнең һәм әнкәйләребезнең эти-әнисенә хөрмәт ул — безнең тарихыбызга, үткәнебезгә, киләчәгебезгә, ягъни үз-үзебезгә хөрмәт!

Миһербан чишмәсе һаман челтерәсен, саф суы белән безне һаман туендырып торсын дисәк, әби-бабаларыбыз канаты астына якынрак килик. Телебезне дә, динебезне дә аңлый һәм санлый торган балалар үстерик!

*2002*

## *Толларның да җаны бар*

Мин аның аякларын кочаклап, тыелгысыз бер сызлану белән бәргәләнә-бәргәләнә еладым. Нигә, ни өчен? Китергән газапларым аз кебек күренә микәнни?.. Арыдым. Хәлсезләндем кана...

Ул мине сөеп сыйпады. Кулларымнан тотып торгызды. Идәннән югары күтәрде. Башымны күкрәгенә куйды да кочаклап сүзсез калды. Мин исә беркадәр тынычланып, оеп киткәндәй булдым. Әмма... шул мәлдә чәч араларымнан кайнар тамчы саркып керде. Ул да булмады, әлеге көйдергеч дым, тамчы гына түгел, эссе чишмә булып колак яннарыма, муеныма агып төште. Шул вакыт үзем сыенган тәндә эчке бер калтырану тойдым! Тагын да тирәндәрәк йөрәк бәргәләнә. Тук-тук-тук дип еш-еш сугып ала да тынып тора. Колакларыма ышанмый кабат тыңлыйм: тук-тук-тук, юк-юк-юк. Тук-тук, юк, тук-тук-тук... Йа Аллам, йөрәге кага бит!.. Ана йөрәге кага! Сулкылдый-сулкылдый, әрни-әрни, өзгәләнә-өзгәләнә кага! Сискәнеп, урынымнан куптарылып аның күзләренә карыйм. Әнкәемнең ияк очларына кадәр тоташ юл булып сузылган күз яше ага да ага. Ашыга-каударлана битләреннән, ак яулык астыннан чыгып торган чәчләреннән үбәм. Җайлап кына урынына яткырам. Әнкәем, елама, елама, әнкәй генәм! Син елагач, миңа тагын да кыенрак бит... Әнкәемә тәэсир итү ысулын дөрес файдаланганмын. Ул үзен жәлләүдән түгел, миңа «кыенрак» булмасын өчен елавыннан туктый.

«Сөйләмәскә иде. Болай да тузып беткән йөрәген кузгаттым, их, мине!» — дип, эчемнән үземне тиргим. Тизрәк даруларына йөгерәм. Ул уйларымны сүзсез укый.

— Сөйләвең әйбәт булды. Эчеңә кара кан сауганчы тышка чыгардың. — Чабулавыма җавап итеп: — Курыкма, кызым, хәзер үтә ул, — дип өсти.

Учыма алган кулларыннан әнкәемнең йөрәк тибешен тыңлыйм. Иплән кенә, кадерләп кенә иңнәреннән иркәлим. Атылып чыгарга әзерләнгән йөрәге беркадәр тынычланган кебек тоела.

— Атлап килеп керүеңнән үк беләм бит мин синең хәлеңне, кызым. Бүлешкәч, икебезгә дә җиңелрәк булды менә. Бөтен кайгы-авыртуларыңны үземә генә алыр идем дә соң...

И минем әүлияларга тиң, газизләрдән газиз әнкәем! Якты дөньяда син юк инде! Әнә шулай бишебез биш яктан борчу-мәшәкатьләргә сала-сала тәнеңнең сихәтен, гомереңнең күпмедер елларын киметкәнбездер, мөгаен. Әмма син безнең хәсрәтне күтәрүдән бервакытта да курыкмадың. Киресенчә, киңәшләшү, serebезне чишү сине тагын да көчлерәк итә иде.

Әйткәнемчә, без гаиләдә биш бала.

Һәркайсыбызның вакытында урнашып, вакытында үз оябызны коруыбызга әткәй-әнкәй шатланып риза булды. Яннарына кунакка кайтуыбыз алар өчен әйтеп бетергесез бәйрәм иде. Күктән ай төшеп иңнәренә кунаклаганмыни? Кая басканын да тоймыйча, йөгерә-йөгерә мунчасын ягып, бәлешен салып, тәмле-тәмле таба ашлары пешереп өлгертә иде әнкәй безнең торышка... Күпләп тавык чебиләре үстереп, ит итеп, көз көне шуларны күтәреп китерә килә. Кышлыкка эре малның бер саны, үрдәге-казы, аларның эче-башы — һәр баласына өлешләп куела.

Менә шулай безнең тулы бәхетебез өчен малларын гына түгел, җаннарын да кызганмый яшәгән көннәрендә, аяз күктән яшен суккандай, ике кызы бер-бер артлы тол калды аларның. Икебезнең дә иңнәрендә икешәр бала. Балаларыбыз ваклар. Ә үзебез яңа гына утызны узган. Шулай итеп, ир белән яши генә башлап, гаилә җитешсезлекләренең кыен чакларын үткәреп, тормыш диңгезенең нәкъ уртасына җитеп барганда, кинәт канатларыбыз сынды. Дәрдмәнднең «Кораб» шигырендәгечә, исеп җилләр, кубып дулкын безне бер тарафтан икенче тарафка ыргытты. Йөзгә бәреп, тынга капланып, салкын җил ыжгырды. Җаннарыбызны суырып алырга теләп давыл дулады. Сыңар канат корбан сорап үкергән упкынга үзен бирмәс өчен түгел, сабыйларын саклап калыр өчен каерыла-каерыла кагынып алга омтылды. Кунар урын эзләде. Илдар Юзеевның «Бөркет турында баллада»сындагыча, канап-канап, балаларын тормыш түбәнлекләреннән саклады...

Безнең башларыбызга ишелеп төшкән толлык ачысы тормышыбызга әнә шулай бәреп керде. Бу фаҗига беребезнең дә көтеп тә, теләп тә алган язмышы түгел иде...

Еллар үтеп, яраларыбыз күпмедер ямалып, күзләребез яктылык төсмерен абайлый башлагач, әнкәй:

— Ятим баланың йөрәк башыннан кан тамып торыр. Үксезне этиле итеп булмый, әмма ир кешенең кайчагында ым кагуы да ярап куя, — дип әйткәли башлады.

Әткәй исә:

— Бигрәк яшьли калдыгыз, кызым. Тол хатынның ишеге ачылмаса да шыгырдый бит, — дип уфтана иде.

Без тол калган көннән башлап әйтерсең алар үзләре өчен яшәүдән туктады. Әйбәт кеше очраса, ияле булуыбызны теләделәр. Әнкәй еш кына: «Ялгызны ялкын ялмый, кызым, ә ялкын өтеп кенә калмый, кара күмергә калдыра», — дип өзгәләнә иде. Минемчә, алар безнең фаҗигане бер генә минутка да күңелләреннән чыгара алмадылар. Менә шул вакытта мин Нурия Измайлованың:

Каты кагылма кешегә,
Кешенең әнисе бар! —

дигән гап-гади сүзләренең даһи мәгънәсен аңладым. Әйе, кемгәдер эшләнгән начарлык иң беренче чиратта әнисенең йөрәген телә, әни кешене утларга сала икән!.. Әмма ничек кенә булмасын, безгә яшәргә, балаларыбызны аякка бастырырга кирәк бит әле.

...Вакыт елгасы челтерәр. Ялгыз гомер итүләрнең каһәрле дә, каһкаһәле дә яклары йөзләребезгә язылыр. Кыенлыклар кыяфәтебезне генә түгел, холык-фигылебезне дә төкселәндерер. Хатынлы ирләр белән куркып кына сөйләшү, үзеңне һәр җирдә кыюсыз тоту кебек гадәтләр, корт кебек күңелне кимереп торган кимсенү хисе эшләү сәләтен киметер. Алай гына да түгел, балаларга багышланган кадер-хөрмәт, мәхәббәт тойгысы да тәртәсеннән чыгар. Уйлар чуалыр, чәбәләнер. Йөрәк дигәнең, кая барып бәрелергә белмичә, кагылып-сугылып йөрер дә рәхимсез язмышы белән ризалашырга мәҗбүр булыр. Ә берзаман... керфек очларында яшь тамчысы булып мөлдерәгән хис дулкыны, көчле ташкынга әверелеп, изаланган йөрәкне үзе белән агызып китәр. Һәм... Ходайның рәхмәте белән сихри бер атауга — Шигърият дөньясына илтеп туктатыр.

Калды ак чәчле аналар,
Калдылар үкенечтә...
Бергә багасы балалар
Калдылар ялгыз көчтә...

Кайгы-сагыш ялгыз йөрмәс,
Килерләр яңалары.
Сабыр булыгыз, кызларым,
Сез — Ата балалары!

Шигърият атавы! Илаһи да, шәфкатьле дә киң дөнья! Ул минем барлык серемне сыйдыра. Мин аңа курыкмыйча, шикләнмичә үземнең җанымны ачам.

...Яшь җан бит ул,
Көтә, өмет итә,
Мәңгелеккә ярны җуйсак та.
Тыныч көндә тол калуы авыр,
Язмышларга сылтап куйсак та...

Тормыш катлаулы. Алдан күреп булмый, исән әти-әниең дә саклап кала алмый торган әллә нинди сәер яклары бар аның. Каныкса, тиз генә ычкынырмын димә. Бер утларга ыргыта ул, бер суларга сала. Утыннан тере, суыннан коры чыгып, үз йөзеңне җуймыйча яшәп калу өчен, ай-һай, зур көч кирәк адәм баласына!

Күзләренең карасында
Үзәк өзгеч моң ята.
Каты кагылма толларга,
Ясама ялгыш хата.

Толлар турындагы гайбәт
Тубыктан түгел, тездән.
Арала син, кеше булсаң,
Яман күз, ялган сүздән.

Толлардагы хис-тойгылар
Чишмә булып бәрсәме?..
Тик
Аларга явыз дөнья
Күпсенгән күп нәрсәне...

«Тик...» дип исем куелган әлеге шигырь «Татарстан яшьләре» газетасында басылды. Минем «Сабантуй» («Яшь ленинчы») редакциясендә эшләгән чагым. Илгизәр апа Сәмигуллина, Фәридә Вагыйзовалар белән бер бүлмәдә утырабыз. Бервакыт таягына таянып, Риза абый Ишморат килеп кермәсенме?! Йөзе һәрвакыттагыча ягымлы, мөлаем. Исәнләшеп, минем өстәлем янындагы урындыкка килеп
утырды. Хәл-әхвәл сорашып, бераз сөйләшеп алгач: «Шигырьләреңне укыдым... Сине кем рәнҗетә?.. Яшермә, без бит якташлар», — ди бу, җитдиләнеп. Мин гаҗәпләнә калдым. Үзем шатланам: шигырьләрем тәэсир иткән бит!.. Җылы сүзе, ярдәм тәкъдим итүе өчен әлләниләр бирергә әзер булсам да, өлкән кешене хафага саласым килмәде. Аннан соң, килүе белән генә дә ярты терелткән, күкнең җиденче катына күтәргән иде инде ул мине! Шуннан соң Риза абый блокнотына эш телефонымны яздырып, үзенекен миңа калдырып китеп барды. Олы башын кече итеп, кеше кайгысы белән исәпләшеп, ихлас күңеленнән изгелек теләп яныма килгән бу якташым мәрхәмәтнең үзе булып, гомерлеккә күңелемә кереп калды!
Әмма табигатьтә дә, тормышта да акка — кара, яхшыга — начар, изгелеккә — явызлык кебек төсләр һәм хисләр капма-каршы итеп яратылган. Әйбәтләр әнә шулай гел уйламаганда килеп шатландырса, һич көтмәгәндә күңел кыручы пырдымсызлар да байтак. Хагын да, нахагын да күтәрә-күтәрә сыгылып төшкән көннәремдә мин тагын шигърияткә килеп егылам.

Кыйнамыйлар яраланган кошны
Чат кан гына чакта йөрәге...

Күңелең үксеп елаганда, бөтен дөньяңны ялкын биләп алганда, йөзеңдә елмаю сакларга тырышу шактый кыен. Әдәп-әхлак кануннарының, «ярый-ярамый кагыйдәләре»нең түбән тәгәрәгән, имансызлык чире чәчәк аткан еллар. Хисси бөлгенлек матди фәкыйрьлектән күпкә артык! Дөнья безнең кулда, һәрвакыт шулай булачак, дип алданучылар да, кеше күзенә карап яшәүче ятим-җилпеләр дә, тормышлары тигез парлылар да, ярты кеше булып көн итүче ялгызлар да аз түгел. Шигырьләрем, китапларым басылып чыккан саен мин үзем кебекләрнең күплегенә ышана бардым. Бер-бер артлы килгән хатлар, телдән әйтелгән рәхмәт сүзләре аша иҗатымның шул күпләргә терәк булуын, рухи көч бирүен күрдем.
«Минем язмышымны язгансыз», «Күңелемдәге уйларымны укыган кебек белеп әйткәнсез», «Сезнең шигырьләрегез исән калырга ярдәм итте...» кебек фикерләр бихисап хатларның төп эчтәлеге. Ә инде

«Мизгел» исемле повестема ияреп, байтаклар үз тормышларын язды. Шуларның берсе — «Әле дә син бар әле дөньяда» җырының авторы Шәриф Биккол хатыны Рәисә ханым — китабымны Гөлшат апа Зәйнашева аркылы соратып алды.

Үтә көннәр, айлар, еллар үтә. Җаны яралыларга күңелем белән әллә нинди изгелекләр эшләргә теләсәм дә, шигырь язудан уза алмыйм.

Үз ишләрем эзлим кешелектән, —
Тол хатыннар минем тиңнәрем.
Барчагызның кайгыларын җыйсам,
Күтәрәлер микән иңнәрем?

Киңәшләшер һәм серләшер сүзләр
Хәл ителә ялгыз баш белән.
Шуңа микән толлар еш ялгыша,
Җавап ала ашка — таш белән!

Шуңа микән толлар бакчасына
Күсәк төшә, салкын боз ява.
Шуңа микән толлар җилкәсенә
Кеше күтәралмас йөк ава.

Шуңа микән нахак бәла белән
Кыерсыткач, җаны таплана.
Мәкерле сүз теләү бәгырьләрне,
Сүз ярасы озак саклана.

Эчтән елый,
Эчтән сыза алар —
Дөрес аңлашылмас кемгәдер.
Тол хатынны тол хатыннар талый,
Хурлыклары үзәк өзәдер.

Бөек Акыл һәрбер җан иясен
Так итмәгән,
Парлы яраткан.
Бер Аллага сыгына ялгыз кеше,
Кыен килсә төрле тарафтан...

Толларның иң нечкә, иң җан әрнеткеч лирикасы — Аллага сыгыну. Бәндәләрдән өметен өзгән, җир йөзендә яклау таба алмаган бик күпләр дин юлына баса. Үткәненә китә...

Мин дә меңәр еллык тарихы булган халык авыз иҗатына, мәкаль-әйтемнәрнең төгәллегенә, тирәнлегенә кайтып-кайтып сокланам. Алардагы тапкырлык, нечкә тоем, камиллек, олпатлык гаҗәпләндерә. Яшәгән саен, җилкәңә килеп кагылган саен, тормыш үзе исбатлап күрсәткән саен ныграк аңлашыла алар.

Әйтик, «Тол хатынның тупсасы алтын булса да, хәер бирергә кирәк!» дигән мәкаль. Ишек тупсасына кадәр алтын түшәлгәч, нигә хәер тиеш соң аңа? Парлылар арасында мохтаҗлар күбрәктер дә, бәлки?.. Юк шул, биредәге «хәер» сүзе матди ярдәм булудан бигрәк рухи таяныч рәвешендә килә. Күңеле кителгән тол хатынга әйләнә-тирәдәгеләрнең мәрхәмәте, игътибары теләсә нинди матди ярдәмнән кыйммәт! Әмма... Күп нокта куям, чөнки «Кеше ышанмаслыкны чын булса да сөйләмә» ди халык.

Буыннан буынга күчеп, безнең көннәргә килеп җиткән кайбер гореф-гадәт, йолаларыбызның тылсым сере шактый тирәнгә яшеренгән. Тик күп очракта без аларга тиешенчә әһәмият итмибез.

Унбиш ел күрше булып яшәгән Зөһрә Сәхәбиева: «Тол хатынның сулышы да сихәтле, дип әйтәләр. Башыма массаж яса әле, малай», — дип керер, аннан: «Хәл булды бит, малай, рәхмәт, яме!» — дип, Хәйдәре янына ашыгыр иде. И гомерләр!.. Инде Зөһрәбез үзе җиләк кебек чагында тол калды.

Җан кыйналса, күңел уйлана. Уйланырга мәҗбүр иткән сүзләрнең берсе «Биеклекләр яулар өчен иҗат кешесе газап кичерергә тиеш...» дигән фикер. Минем үземә дә: «Тетрәнүләр кичермәсәң, болай күңелгә тиярлек итеп яза алмас идең», — дип әйтүчеләр бар. Мондый нәтиҗә белән шәхсән үзем һич кенә дә килешә алмыйм. Тетрәнүләрнең тәкъдиреңә язылганы — үзеңнеке, нишләмәк кирәк, түзәсең. Тик бит әле аның махсус оештырылып, план нигезендә эшләнгәннәре күп. Кеше ярасына тоз салып тукланучы ул тозсыз кешеләр үзләрен ничек аклыйлардыр, белмим, әмма кеше елату, яраларны ярдан төртеп төшерү юлларын эзләү һичбер вакытта акланмас һәм макталмас. Шунысы хак, язучы Нурихан Фәттах әйтмешли, кешедә тумыштан килгән талант юк икән, аны кайгы гына язучы итә алмый.

Тел сөяксез. Кайчагында ни сөйләгәнен, нәрсә өчен сөйләгәнен дә белми. Әнә бит, биш йөз ел үтеп, буыннардан буыннарга күчеп, якты образы бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән Сөембикәнең тетмәсен

тетүчеләр, күп иргә чыгуда гаепләүчеләр бүген дә бар. Татар хатын-кызының матур бер өлгесе, акыллы, зирәк, әмма михнәт эчендә кайнаган ханбикәсе белән биш гасырдан соң да булышып йөрү — һич кенә дә килешә торган эш түгел, минемчә.

Еш кына әдәбиятта да, мәкалә-язмаларда да ире үлгәч, беркемне якын җибәрмәгән хатыннарның тугрылыгы, ялгызлыгы мактала!

Шушыларга нисбәтле рәвештә безгә караганда күпкә әхлаклырак буын иҗатыннан бер мисал китерәсе килә. Ул Гаяз Исхакыйның «Мөгаллимә» драмасыннан өзек. «Олугъ башны тота торган, олугъ башны бора торган муен булу кечкенә баш булудан йөз мәртәбә артык... Ләкин татар хатыны муен да була белдеме?.. Сукыр Каюмны хәтерләңез!.. Кырык ел гомерен татар тормышында ялгыз үткәргәнен, үлгәндә янында йомшак сүзле бер кешесе булмаганын исеңезгә төшерегез. Кичә генә әле үлгән Габдулла Тукаевны... Гомерендә бер мәртәбә татар кызыннан сөйкемле сүз, сөйкемле бер хәрәкәт күрмәгән шул татар шагыйренең хәлен, трагедиясен уйлаңыз!.. Мин боларның икесендә дә татар хатыны бурычлы калды, вазифасын үти алмады, дия алам һәм дим».

Бурыч һәм вазифа. Менә бит, бер үк гамәлне әйбәт итеп аңлап та, гайбәт итеп сөйләп тә була. Кайсы кешелеклерәк? Кайсысы җәмгыятькә дә, бәндәнең үзенә дә файдалырак?..

Инде килеп, бу мәсьәләгә дин ничек карый икән?

Пәйгамбәребез Мөхәммәд әйткән: «Дөньяда өч нәрсәдә соңга калырга ярамый — вакыты җиткән намазны укуда, мәетне җирләүдә вә үзенә тиңен тапкан тол хатынны кияүгә бирүдә. Әгәр диндәш вә әхлакташ кеше табылган икән, озакка сузмыйча өйләнешегез... Җир йөзендә азгынлык вә фәхешлек кылмагыз... Өйләнмәгәннәрне өйләндерегез, кияүгә барасыларны кияүгә бирегез, үзегез арасыннан вә кол вә колиһәләрегездән дә...»

Читтән карап кеше хәләтен аңлау, кайгылы кешегә карата саф күңелле, эчкерсез булып кала алу — шактый кыен эш. Бу олы җанлылыкны таләп итә. Бер саплам илһам нурына сусап яшәгән тол хатынның яратасы, яңарасы килү теләген, сөеләсе, сөенәсе килү хәләтен чикләү хокукы беркемгә дә бирелмәгән. Адәм баласы кайчак үз биеклегеннән югары сикереп әллә ниләр эшләмәкче була. Кояш булса, җир йөзенә чыкмас, башкаларга көн күрсәтмәс дәрәҗәдә усалланып яшәүчеләр дә җитәрлек. Ләкин вакытлар үтү белән бу иптәшләрнең тормышы кискен үзгәрә. Табыннарда аларны элеккечә түргә утыртмыйлар. Әйткән сүзләреннән соң күтәрелеп кул чапмыйлар...

«Гайбәт — компас ул. Аңа карап, мин юлымны төзәтәм», — дигән Хәсән Сарьян.

«Компас» дип үзеңне юатсаң да, «Кеше сүзе кеше үтерә» дип ачыргалансаң да, тормыш дәвам итә. Диңгездә —
корбан сорап үкерүче упкын, җиһанда — җаныңны суырып алырга әзер гарасат... Өмет бары тик Кешеләрдә, яхшы Кешеләрдә!

Кошларның да пары бар,
Көннәрнең дә таңы бар.
Миһербансыз кыланмагыз,
Толларның да җаны бар!

Җаны бар шул толларның да! Күп кыллары өзелсә дә, өметләре өзелмәгән. Нечкә күңелләре бирчәйсә дә, бәхетле буласы килү теләге исән! Һәрбер тере җанга хас булганча, синсез яши алмаган җирдә тереклек күрү уе дәвам итә. Минем андый урыным — Шигърият! Рәхмәт аңа кайгымны да, шатлыгымны да сыйдырганы, язмышымны канатларында күтәргәне өчен! Ләкин шигърияткә мәхәббәтем никадәр генә зур булса да, аның кочагында никадәр генә онытылып юансам да, ул миңа газиз әнкәемнең ихлас сөю белән сөйгән, мәңге хәер-фатихада булган, бер генә гаебемне дә күрмичә ярата белгән җанын алмаштыра алмый. Уйларым белән мин тагын аның күңел шарламаларына барып кушылам. Һәм... Әнкәемнең актарылып аккан хисләрен шигырь итеп укыйм:

Тулып кына пешкән бу алмам,
Үземә бир, газиз бер Аллам,
Бөтен чирен, диеп, баламның —
Өзелүен күрдем анамның!..

*2002*

## ***Закирә тиргәге***

*Әнкәем—Шәйхетдин кызы Миңнезакирә*
*Сабированың якты рухына багышлыйм*

Йа Хода! Нинди Алла каргаган төн булды соң бу?

Сиринә ишегалдында әтисе белән тагын очрашты. Ул, күрәсең, яңа гына кайтып кергән, ындыр капкасы буенда басып тора иде. Әтисе аңа дөньядагы иң әшәке, иң намуссыз кеше булып күренде. Зөләйха чиннегендә мышный-мышный сөю сүзләре яудырып ятуы, хәзер исә берни булмагандай шат, кәефле тавыш белән: «Киноданмы, кызым?» — дип эндәшүе Сиринәне бөтенләй чыгарыннан чыгарды. Ул, бугазына таш булып утырган нәфрәт сүзләрен йотып, атылган ядрә кебек өйләренә томырылды. Мендәренә капланды. Әле генә булган вакыйга күз алдыннан йөгереп үтте.

Алар Айдар белән иде. Тыкрыкның икенче башыннан җырлап килеп чыккан Тәкыйнең күзенә чалынмас өчен, бәрәңге бакчасына сикерделәр, каралты ышыгына сыендылар. Шулчак Сиринә өчен «җир упты». Ул әтисенең тавышын ишетеп имәнеп китте.

— Кума, зинһар... яратам мин сине...

Кыз колакларына ышанмаска теләде, сәерсенеп, тавыш килгән якка сөзеп карады. Сөйләшү чиннек эчендә иде. Ярым пышылдап, ярым югалып өзек-өзек ишетелгән тавышлар аның бөтен көчен, хәлен алды.

— Балалар үсә бит... алардан оят... — диде хатын-кыз тавышы.

— Яратам... килмичә түзә алмыйм, Зөләйха!.. Синең белән очрашмасам... балалар өчен дә... кеше түгел мин...

Сиринә тәмам коелып төште. Аны кимсенү, әрнү, көнләшү, тагын әллә нинди хисләр биләде. Кочагына алып басып торган егете янында үзен гаепле сизде.

Айдар, бередән тизрәк китәргә кирәклеген аңлады, ашыгып ишарә ясады. Кыз, тере мәет кебек, аңа буйсынды. Аларның аяк асларында шартлап сынган корыган агач чиннек тәрәзәсен шакыды. Кулларын кычыткан өтте. Кайдадыр эт өрде. Коймадан ничек сикереп керсәләр, шулай тиз генә чыгып, тыкрык буйлап киттеләр.

Сиринәнең аяклары таш таккандай авыр, ә гәүдәсе әйтерсең үзенеке түгел. Ул Айдарның сүзләрен ишетми, аңа җавап та кайтармый, үзе дә һичбер нәрсә уйлый алмый бара да бара. Егет тә Сиринәне ничек итеп юатырга, сүзне кай тарафка борып җибәрергә белми аптырый.

Дөресен генә әйткәндә, бу тойгыларның, бу вакыйгаларның чын асылын Айдар үзе дә аңламый. Билгеле, авыл гайбәтчеләреннән төрлесен ишеткәне бар аның Сиринә әтисенең «чирттерүе» турында. Әмма Зөләйха ханымның һәркемгә кирәкле табибә булуы, Сиринә әнисе Солтания ханымның исә үзен бик тыныч, көләч тотуы гайбәтләргә үрчеп китәргә җирлек бирми иде.

Шулчак кыз тыела алмыйча, эчке бер сулкылдау белән такмаклый башлады:

— Ичмасам, үз колакларым белән ишетмәсәм... Каян гына килеп чыкты соң шул тәбәнәк Тәкый?..

— Кич җитте исә Зөләйха тыкрыгында бит инде ул, — диде Айдар. — Мулла бабай димләп тә караган үзләрен. Тегесе һаман ялындыра, имеш.

Айдар Сиринәне күкрәгенә кысты, тынычландырырга теләде. Әмма Сиринә һаман үксеп-үксеп елый, үзен кая куярга белми иде.

— Сиринә, — диде Айдар, кинәт кенә нидер исенә төшкәндәй, кызны җилкәсеннән кагып. — Мин сине бер җиргә алып барам.

— Кая?

— Изге урынга. Яңа гына кавышканнар да, мәхәббәттә ялгышканнар да элек гел шунда йөргән. Һәркайсы саф, тигез мәхәббәт сораган. Яхшы кешеләрнең теләге кабул булган...

— Теләк белән генә булса икән?! Әнием биш вакыт намазын калдырмыйча Аллага сыгына да бит...

— Әйткән иде диярсең, синең теләгең кабул булачак, Сиринә.

Алар кайту ягына борылдылар.

Шул көннән башлап Сиринә беркая чыкмады. Әтисе белән бер табынга утырып ашамады. Аның белән очрашмаска тырышты. Хәтта киләчәктә аңа «әти» дип эндәшә алуына шикләнде.

Сиринәнең эчке дөньясын актарып ташлаган сәбәпне әтисе дә, әнисе дә сизенде. Солтания ханым кызының ашаудан калуын күреп, чирләп китмәсен дип тә курыкты. Тик серне уртага салып сөйләшергә һаман җае табылмады. Тик торганда гына сүз башласа, ишекне шакымый килеп кергән сөмсез кеше кебек кызының күңелен кырырмын дип тыелды. Ә беркөнне сәбәп үзеннән-үзе килеп чыкты.

Баскыч башында гөрләшеп уйнап утырган балалар кинәт шаулаша башлады. Солтания ни булды икән дип ашыгып өйдән чыкканда, Сиринә Зөләйханың кызын куып капкадан чыгып бара, үзе:

— Әле син шулаймы? Безнең әти сезнең туганыгызмы? — дип сөрән сала. Кулындагы таягы белән кизәнә.

Солтания кызын куып җитмәкче, эндәшеп туктатмакчы булып карады. Тик кая ул?! Чыгымчылап чапкан тайдай ак-караны күрми йөгергән Сиринәне туктатырлык көч юк иде. Шул вакытта ул нәрсәгәдер абынып, шапылдап җиргә ауды. Йа Аллам, күрәчәгенә җилкенгән икән, бөтен йөзен җимергәндер дип уйлады ана, җирдән тормый яткан кызы янына килеп җитеп. Ләкин, ни хикмәт, сыдырылмаган да иде Сиринә. Әмма җаны «канга» баткан булып чыкты кызның. Ул чәбәләнә, әнисен мәсхәрәләүчеләрдән үч ала алмавына хурлана иде.

Башы иелеп, җилкәләре төшеп басып торган кызы канаты каерылган кошны хәтерләтте Солтаниягә. Ана үз ярасының баласы күңелендә бермә-бер тирәнрәк җәрәхәткә әйләнүен күреп өнсез калды. Ул бүген үк, менә хәзер үк кызын бу газаплардан арындырырга кирәклеген аңлады.

— Тынычлан, кызым, өйгә кайтып юын да утырып сөйләшик, — диде.

Сиринә кайтып җиткәнне көтмәде.

— Әни, нигә дип иярләндерәсең шул Зөләйха балаларын? — дип сорау бирде.

— Алар синең туганнарың янына килә бит, кызым. Бергә укыйлар, бергә уйныйлар, — диде Солтания.

— Башкалар белән уйнасыннар. Ә безнең ихатага аяк басмасыннар! — диде Сиринә, ачу белән.

— Алай ярамый, кызым. Ишегалды зур бит, уйнасыннар, — диде әнисе.

— Аларга әллә нинди «ярамыйлар» ярый...

Солтания кызының нәрсәнедер әйтеп бетермәгәнен аңлады, тик сорау бирмәде.

Сиринә үзе дәвам итте, ярсып:

— Икенче килсәләр, үзен дә, энесен дә кыйныйм, әйткән иде диярсең! — диде.

— Үксезләргә кул күтәрә күрмә. Болай да этисез үсәләр. Дөньялары китек.

— Бер дә китек түгел, безнең этине үзләренең туганнары дип саный башлаганнар хәзер. Эти дә, алар килсә, шатлыгыннан нишләргә белми, туктаусыз башларыннан сыйпап йөри. Алар этисез калганга без гаеплеме әллә?..

Солтания бер мәлгә сүзсез калды. Аннан:

— Без дә гаепле, — диде, тавышын әкренәйтеп. — Зөләйха иренең үлемендә этиеңнең абыйсы гаепле. Төрмәгә утыртса да була иде. Әмма этиең һаман барып, булышып йөргәч, судка бирмәде, — дип өстәде.

Сиринә Зөләйха иренең трактор арбасы авып, йөк астында калуын ишетте. Әмма бу фаҗигадә кем гаепле — нечкәләп белми иде. Әтисе күңелендәге мәхәббәт хисенең дә әнә шул «булышып» йөрүләр вакытында кабынуы аның өчен караңгы иде. Ләкин бер нәрсә ачык: «мәхәббәт геройлары» әнисенең сабырлыгыннан усалларча файдалана...

Шулай итеп, әтисенең «уҗымга чыгуын» әнисе никадәр генә яшерергә тырышса да — без капчыкта ятмады. Дөресен генә әйткәндә, Солтания бу хәл белән үзе дә озак кына килешә алмады. Иренең Зөләйхага ярдәмләшеп кенә йөрмәвен белгәч, күңелендә туган өермә әллә нинди каршылыклы фикерләр уятты. Үзен Зөләйха урынына куеп карады. Яшь, чибәр хатынның иң дәртле еллары ялгыз үтүен күреп кызганды. Шулай уйлаганда ул аны аклады. Икенче караганда, бүген өйләнергә әзер торган буйдак Тәкый сораткан чагында кеше иренә алданып, гомерен зая үткәрүе өчен гаепләде. Тәкый ярамаслык егет түгел. Эшчән, күндәм. Хуҗалыгын гөл итеп тотар, үзе дә ирле хатын булып яшәр иде, дип уйлады. Аннан тагын «Җаны теләгән елан ите ашаган» диләр шул, күңеле тартмыйдыр, дип, бу фаразларын да эченә йотты.

Айлар гына түгел, еллар үтте. Тора-бара Солтания ачы язмышы белән дә килеште. Ирен үз иркенә куйды. Бөтенләй үк юлдан язган бәндә түгел бит, балалар үсә башлагач оялыр, акылына килер, дип өметләнде.

Ире дә җәмәгатенең йөрәге урынында түгеллеген сизә, ләкин сер бирмәвен, алай гына да түгел, кеше алдында, киресенчә, күңеллерәк булырга, үзен бәхетле итеп күрсәтергә тырышуын күреп сөенә иде. Шуңа күрә дә ул хатынына тагын да мәрхәмәтлерәк, игътибарлырак була барды. Тик мондый «яхшылыклар»ның балалары күңелендә нинди гарасат кузгатасын, аларның керсез йөрәкләрен чәлпәрәмә китереп чәрдәклисен генә алдан күрә белмәде.

Ана белән кыз өйләренә якынлашып килгәндә, җир астыннан үсеп чыккандай, Айдар пәйда булды.

— Исәнмесез, — диде ул, атна буе күрешә алмаган кадерлесен очратуына шатланып. Аннан бер Сиринәгә, бер аның әнисенә карап тотлыгып калды. Солтания ханым, яшьләрне аңлап, алга атлады.

— Сиринә, теге изге тирәк турында әбиемнән тагын бер кат җентекләп сөйләттем, — диде ул, ашыгыч хәбәр җиткергәндәй. Айдарның күзләре очкынланып яна. Гүя ул аларны, аларның гаиләсен бу газаплардан бүген үк коткарырга тели иде.

— Мин ышанмыйм андый әкиятләргә, — диде Сиринә, салкын гына.

— Син нәрсә, Сиринә? Нинди әкият булсын. Кеше күңелендә иман беткәнгә күрә генә оныткannar ул тирәкләрне!

Кыз егетнең хәтерен калдырганын аңлады. Тизрәк сорап куйды:

— Кайда диден әле син аларны?

— Суның аргы ягында. Иске авыл урынында, — диде Айдар, җанланып китеп. — Әбием яхшы хәтерли ул турыда. Теләсәң, әбием янына үзеңне дә алып барам. Закир бабайга бишенче буын онык та тиеш әле без. Шәҗәрәбез дә бар...

Айдар әбисе сөйләгән истәлекләргә күчте.

...Әнием дә тумаган бер вакытта, авылларында пәһлевандай батыр егет белән сусылудай матур кыз яшәгән. Батыр егетнең исеме — Закир, сылу кызның исеме Закирә икән. Закир белән Закирә кавышып

бергә тора башлаганнар. Һәм беренче көнне үк, түр яктагы бакчаларына чыгып, пар тирәк утырткannar. Ир белән хатын картая барган саен, агачлар яшәрә, югарырак үрмәли, ныгый икән. Алай гына да түгел, егет утырткан тирәк кыз утырткан тирәкне бер ботагы белән әйләндереп алып, кочаклап үсә башлаган. Халык бу тамашага хәйран калган. Гомер буе тату, үрнәк булып чөкердәшеп яшәгән Закир белән Закирәнең чын мәхәббәтләре чагылышы дип бәяләгән. Үзләре исән чагында ук саф мәхәббәтләренә Табигать һәйкәл куйды, изге кешеләр икән, дип нәтиҗә ясаганнар.

Җилләр искән, еллар үткән. Авыл кечерәйгән. Закир белән Закирә яшәгән урам да беткән. Ә алар утырткан тирәкләр кочаклашып һаман яши. Кешеләр ул урынга олылап карый башлаган. Мәхәббәттә бәлагә юлыксалар, куш тирәк янына килеп хәсрәтләрен сөйлиләр, Ходайга ялваралар, ярдәм итүен үтенәләр икән.

Тагын еллар үткән. Вакыт елгасы авылда берничә генә булып калган өйләрне дә алып киткән. Закир-Закирә тирәген дә кыскартып, «Закирә тирәге», «Закирә аланы» дип кенә йөри башлаганнар. Тора-бара бөтенләй онытканнар.

— Ходайның хикмәте, ул тирәдәге үлән көз көне дә саргаймый иде, бер-бер сере бар инде аның! — дип йомгаклаган әбисе үзенең сүзен.

Сөйләп бетергәч, Айдар Сиринәгә сораулы караш ташлады. Кыз күңелендә сәер бер битарафлык хөкем сөрә иде.

— Әнигә әйтеп карыйк, рөхсәт итсә, барырбыз, — диде ул, бигүк сикереп төшмичә генә.

Алар, өйгә кереп, Солтания ханымга серләрен ачтылар. Үз кичерешләренә бирелгән ана бертын эндәшә алмый торды. Якты хыяллар белән башланган яшьлегенең сизелмичә дә узып китүе, кайчандыр дөрләп кабынган кайнар мәхәббәтенең бүгенге көндә пыскып утырган кисәү кебек берсенә дә җылы бирмәве бәгырен телгәләде. Инде менә балалары ярдәменә мохтаҗ булып, алар алдында мескенләнеп басып тору аны ничектер түбәнсетте. Эчендәге бөтен үкенечләрен чыгарып ташлар өчен иңрәп-иңрәп кычкырасы килде. Ирен вакытында кулга алмавы өчен үзен-үзе гаепләде. Шулай да текәлеп карап торган кызы белән Айдарга:

— Юынып, чистарынып барыгыз, — дип фатихасын бирде.

...Менә алар алдында Закирә аланы. Алан тирән йокыда. Бөтен тирә-юньгә таралган тәмле дә, татлы да бөтнек исенә чумып, изрәп ята. Кайдадыр кошмы, җәнлекме кычкыра. Елга аръягында беренче әтәчләр тавыш бирә.

Таң сызыла. Дымык та, тыныч та төнне ямьләп, яктылык нуры күтәрелә. Закирә тирәге янында ак намазлык өстенә чүккән пар гәүдә күренә. Ботакта ике такыя эленеп тора. Әйләнә-тирәнең иң матур чәчәкләрен җыеп үрелгән бу «пар балдаклар» Сиринә белән Айдарның теләк-үтенечен дәвам итә, аларның үзләренә кушылып, әти-әнисенә күркәм мәхәббәт сорап дога кылалар кебек иде!

*1999*

## *Юрау*

— Алтын бөртегем минем! Йомшак, ягымлы, шәфкатьле балам! Исәнлектә кавыштырганы өчен кодрәтләре чиксез Раббыбызга меңнән-мең рәхмәт! Сыгылыплар төшеп сагынган идем үзеңне! — дип пышылдады ана, кызын күкрәгенә кыскан хәлдә. Аның күзләренә яшь, теленә әйтеп бетерелмәгән сүзләр килеп төйнәлде. Картаям, ахры, дип уйлады ул эченнән. Юкса әле бер, әле икенче илдән кайтып төшкән шушы төпчек кызын ничәмә-ничә тапкырлар каршылап бу кадәр җебеп төшкәне юк иде бит.

— Мин дә сагындым, әнием, сине! — дип җаваплады язгы яфрактан да нәфисрәк, иң гүзәл чәчәктән дә гүзәлрәк кызы. — Бу юлы озаграк торылды шул! — диде ул, әнисенең артык йомшап китүенә аклану эзләгәндәй. — Үзеңнең сәламәтлегең ничек соң, әнием?

— Менә бит, шәм кебек, — диде ана, кызы каршында тыпырдап куеп. — Бирешмим әле мин, кызым. Бүген мәлҗерәп төшүемә карама син. Күрешү шатлыгына чыдап булмаганга гына ул. Яшь чагым булсамы?..

— Яшь чагың булса ни эшләр идең? — диде кыз, ягымлы көлемсерәп.

— Бик сагынганда тотар идем дә җәяүләп чыгып китәр идем яныгызга.

— И әнием, меңәр чакрымлы океан-диңгезләр аша җәяү үтәр юл-сукмаклар юк бит, — диде кыз, әнисен кабат кочагына алып.

Күз карашыннан мәрхәмәт тамып торган кызы да йомшый башлаган иде инде.

— Кайчагында мин дә шулкадәр нык юксынам сине! Шулкадәр күрәсем килә, тизрәк берәр эшкә тотынмасам — котылу юк. Яки берәр видеокассета куям. Шулар алдый.

— Замана алдый, — диде ана, кызының сүзенә төзәтмә керткәндәй.

— Сиңа яраткан артистларың: Ричард Гир һәм Джулия Ормандның иң яңа язмаларын алып кайтам, әнием.

— Онытмавың өчен рәхмәт, кызым.

Аэропортның шау-шулы залында әле берсенең, әле икенчесенең кочагына сыенып, шушы мизгелдә үк бер-берсенә бөтен эч серен түгеп бетерергә теләгәндәй гәпләшеп, очрашу бәхетеннән тәмам «исергән» ике җан иясе басып тора. Менә алар беркадәр тынычлана төштеләр. Сагыну ташкыны чигенде. Әмма ярату, якынлык хисе икесенең дә күзләрендә очкын булып кабынган. Һәм ул очкыннар, керфекләре аз гына тирбәлсә дә, энҗе-мәрҗән булып алларына тәгәрәргә әзер тора иде кебек. Ярый әле бераздан сүзләре дөньяви мәгънә алды.

— Юлың ничек булды, кызым? Йончытмадымы, бик интекмәдеңме?

— Синең теләк-догаларыңның хикмәтедер, әнием, гаҗәп уңайлы һәм тиз кайттым, — диде кыз.

— Ходайга шөкер! Киләчәктә дә имин йөрергә язсын! Аллакаем рәхмәтеннән ташламасын!

— Рәхмәт, әнием! — Кыз тагын иркәләнеп әнисенең җилкәсенә башын куйды.

Шул вакыт, кузгалыгыз инде дигәндәй, бармакларында ачкычларын бөтерелдереп йөргән таксистлар килеп җитте. Алар бер-бер артлы: «Шәһәргә кирәкме?», «Автобуслар юк хәзер», «Киттек минем белән, кыйбат алмыйм» кебек тәкъдимнәр ясарга керештеләр. Ана кешенең сөйләшенгән шоферы булганлыктан, бу төрле кыяфәттәге әрсез ир-атлардан ипле генә итеп баш тартты. Ул да түгел, сөйләшенгәне йөгереп килеп кулларындагы сумкаларны алды. Алар җиңел машинага кереп утырдылар. Ана, кызының йомшак, җылы иңенә иңен терәп утыру ләззәтеннән рәхәт бер сихәтләнү кичерә иде. Ул бәгырь кисәгенә каерылган башын кире борырга теләмичә сораулар бирүен дәвам итте:

— Гаиләгездә иминлекме, кызым?

— Барысы да әйбәт, әнием.

— Кияү исән-сау гына калдымы?

— Таза-сау, әнием. Күп итеп сәлам әйтте.

— Рәхмәт!

— Әбиләрдә кияүгә карата аерым мәхәббәт булса да, кияүләр кыз анасын яратмый инде, — дип сүзгә кушылды рульдәге өлкән кеше.

— Һәр очракта да димәс идем, — дип, үзенең ирен якларга ашыкты кыз.

— Безнең кияү бу килештән сөбханалла әле. Андый ямьсез тойгы сиздергәне юк. Киләчәктә дә тату яшәргә язсын! — диде ана.

— Әйттем исә кайттым. Сүз югында сүз булсын дип кенә әйтүем иде, авырга алмагыз тагын. Сөйләшә белмәсәң, эндәшмә инде, — диде чит кеше, үз-үзен шелтәләп.

— Бер-береңне аңлап, зурлап яшәүләргә ни җитә! Гомер болай да бик кыска бит, — диде ана, тагын йомшый башлап. — Санаулы көннәр аеруча тиз үтә. Озаткан саен кабат күрә алырмынмы дип җибәрәм менә бу бәгыремнән өзелеп төшкән алтын бөртегемне.

— Әнием! — диде кыз, беркадәр үтенүле тавыш белән. — Үзең мин бирешмим дигән буласың.

— Ходайга шөкер анисы, нәселебез нык безнең, кызым. Әбиең белән бабаң әнә туксанга җиттеләр. Сезгә дә шундый озын, сәламәт, хәерле гомер бирсен Ходай Тәгалә, амин!

Аның сүзен башкалар да җөпләде:

— Амин!

— Амин!

Ана кешенең «сезгә» дип басым ясавында да, нәсел ныклыгы турында кат-кат телгә алуында да тирән мәгънә бар. Буйга узып, карынындагы сабыен туган илендә табарга дип кайтып килүче кызы күңелендә күкләргә күтәрер изге өмет уяту да, аның тиздән туачак газизләрдән газиз нарасыена якты язмыш юрау да иде бу!

*2005*

## *Язмышыңа язылсамы?..*

Алмазия урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлады. Аның да башка кызлар һәм егетләр кебек университет баскычларыннан менеп йөрисе, кәрәп-кәрәп белем аласы килде. Аның да башка бик күпләр кебек әти-әни акчасына ваемсыз гына итеп яшисе, дөнья күреп йөрисе килде. Тик... язмышыңа язылмагач — булмый икән... Аяз көнне — бар, болытлы көнне — юк. Авыру әнисен ялгыз калдырып ерак шәһәргә китүдән, ләззәтле, заманча тормыш эзләүдән тыелып киңәште-сөйләште дә, кыяр-кыймас кына атлап, үзен укытып чыгарган мәктәбенә килде.

— Хәлеңне беләбез, Кыямова. Укырга чынлап та китмәсәң, үзебездә эшләрсең. Бездә быел пионерлар саны артты, үзләренә бер вожатый кирәк булачак, — диде директор, кызның тел төбен тиз аңлап. — Билгеле, синең кебекләрне алга таба да укытасы иде дә бит!.. Ә син акыллы хәл иткәнсең, — дип өстәде ул бераздан. — Ялгыз әниеңне ташлап китмәвең хуплауга лаек!

Алмазиягә дә, энисе Тутыя апага да авыл халкы әнә шулай бик мәрхәмәтле. Китек күңелле ятим гаилә булгангамы, әллә аналы-кызлы икесенең дә бик кешелекле булуларын искә алыпмы — иске яраларын кузгатып йөрәкләрен телгәләгәннәре юк. Тик кеше күзгә төртеп әйтмәсә дә, Тутыяның бәгыренә таш булып утырган ул яра туктаусыз әрни, туктаусыз эчтән ашый иде.

* * *

Сугыштан соңгы еллар.

Әтисе Ватанны сакларга киткән җиреннән кире әйләнеп кайтмады Тутыяның.

Әнисе, озак та тормый, авыр елларның корбаны булды. Шулай итеп, әти белән әнисенә бердәнбер бала булып яшәгән кыз нигезләрендә япа-ялгыз торып калды.

* * *

Көз.

Көн кичкә авышкан. Тутыя эштән кайтты да инешкә төшеп чиләкләренә су алды. Бер тамчысын да түкмичә йөгереп кенә кайтып килгәндә, капкалары янында көтеп торучы абыстайга күзе төште.

— И-и, кызым Тутыя, мөлдерәмә тулы чиләкләреңә тап булдым, юлым уңар, иншалла, — дип башлады ул үзенең сүзен. — Хәтерем ялгышмаса, төпчегем белән бергә туган идегез кебек. Быел сиңа да егерме җиде тула торгандыр, — диде ул, сүзне үзенә кирәк якка борырга тырышып.

— Дөрес, абыстай, хәтерегез ялгышмый. Олыгаябыз, — диде Тутыя, абыстайның йомышын аңламыйча гына.

Кунак, үзалдына сөйләнгән кебегрәк итеп, сүзен дәвам итте.

— Болай юньле бәндәгә охшап тора торуын. Туганнарымны сугышта югалттым, үзем Уралдан, ди. Синең дә гомерең ялгыз үтә, мин әйтәм. Уйлап-уйлап карадык та абзаң белән сине кулай күрдек. Әллә, Тутыя кызым, очрашып, сөйләшеп карыйсызмы?

— Кем белән очрашырга? — диде Тутыя, курка калып.

— Бәй, соң, сине яучылап килдем ләса, — диде абыстай.

— Алай олы эш белән йөргәч, әйдә, өйгә керик, — диде Тутыя. Чиләкләрен куеп, тиз генә самавыр тергезде.

Абыстай кызның югалып калуын тиз сизенде һәм:

— Курыккан эш хәерле була ул, кем, Тутыя. Барыбыз да шулай кыенсынып кергән инде егет куенына... Бер җирдә туктап оя корыр идем, ди. Болай хәлле генә күренә үзе. Чәй эчәрсез, абыстай, күчтәнәч, дип, йомшак конфетлар алган. Бер тартма бөртекле тәмле чәе белән яулыгы да бар. Ә кич белән йөзлекләр арасыннан көчкә бер егерме бишлек табып абзаңны кибеткә җибәрде.

— Миңа кешенең акчасы кирәкми, абыстай. Тормыш көтәрлек, дөньямны үзенеке кебек итеп тотарлык иптәш кирәк, — диде Тутыя, кистереп кенә.

— Мин дә акчасын санамыйм. Мул куллы булырга охшый дип әйтергә теләвем генә, — диде абыстай. Аннан, йонның уңаена сыпырырга тырышып: — Тормышның Аллага шөкер инде кадерен белгән кешегә, — дип өстәде.

— Кешесе кеше төсле булса, бер әйберем дә җәл түгел, — диде кыз, йомшый төшеп. Ул үзен кайгыртып килгән авылның мәртәбәле карчыгына төксерәк эндәштем, ахры, дип, бераз борчылып та куйган иде.

Сүзне чәй янында дәвам иттеләр.

— Кавын түгел, эчен ярып карап булмый. Әмма сугышта һәлак булган улым белән кайчандыр бергә поездда барганнар икән. Шуның буенча эзләп килгән. «Улыгыз мировой иде!» ди. — Абыстай күзләрен сөртеп алды. — «Адресын бирде, кунакка чакырды», — ди.

— Сезнең балаларның начар аты чыкканы юк инде, абыстай.

— Малайны искә алгач, үзебезгә дә якын булып китте шул. Абзаң белән киңәштек тә, еракка җибәрмик җиләк кебек Тутыя барында, дип, сиңа тукталдык.

— Маңгаенда, — дип пышылдауга күчте абыстай, уң кашы өстендә пәйгамбәр суккан мөһере дә бар. Андыйларны бик бәхетле, судан да коры чыгучан була, диләр бит.

Тутыя монысына артык әһәмият бирмәде. Әмма:

— Нәселе ниндирәк нәсел микән соң, абыстай? Бер туганы да калмый кырылып бетмәгәндер бит? — дип басым ясап сорады.

— Төпчендем инде мин дә, кат-кат сорадым. Тамырыбыз корыды, бер мин исән калдым, ди. Аллага тапшырып, үзең күреп, сөйләшеп карыйсыңмы әллә? Насыйбың шул булса, белмәссең...

— Сезгә килеп төшкәч, яман кеше түгелдер, шәт, — диде Тутыя, сүзне йомгаклагандай итеп.

Икенче көнне Тутыя белән Урал ягыннан килгән мөһерле Хәкимгә мулла никах укыды. Ә инде тагын бер айдан кияү кеше суд каршына басты. Абыстай күргән йөзлекләр барысы да урланган

чемоданнан табылган акчалар булып чыкты. Гомерендә андый эшләрне күз алдына да китерә алмаган Тутыя, хурлануыннан җир тишегенә кереп китәрдәй булды. Ничек тә бу яман эшне авылдашларына сиздермәскә тырышты. Җилен тутырган сыерын сатып, ире урлаган акчаларны түләде.

Атналар, айлар үтте. Тутыя көне-сәгате белән авырга узып, кыз бала тапты.

— Алмазия дип исемлибез, — диде ата кеше.

— Бик матур исем, мин риза, — диде Тутыя.

Ләкин чамадан тыш холыксыз Хәкимне бала мәхәббәте генә дә үзгәртә алмады. Ул, һаман тузынып, хатынын кыйнады, ташлап китү белән янады. Ниһаять, көннәрнең бер кичендә алар өендә ут кабынмады...

— Кичә көн буе фермадагы сыерларын кеше сауды. Сорамыйча китеп барганы юк иде, баласы авырыймы әллә? — диде бригадир, аларның капка төбендә атын туктатып.

— Ишекләрендә йозак. Маллары да кычкырып ята. Әйтми-сөйләми кая китәрләр?.. — дип элеп алды күршеләре.

— Үзебез генә ниятләргә куркып тора идек, ни булса — шул, дип, нәни тәрәзә өлгесен алып, өй эченә колак салдылар. Өйдә ниндидер быдырдаган тавыш ишетелде, тынды, тагын ишетелгәндәй булды. Нидер бар монда дип, ишекнең күгәнен җайлап кына суырып, эчкә уздылар һәм аһ иттеләр. Өйнең асты өскә килгән. Бөгәрләнеп идәндә ятучы Тутыя аңлаешсыз сүзләр белән нидер әйтә, саташа, тагын аңын югалта. Җәрәхәтләреннән күп кан аккан. Ә бала сандык өстендәге мендәр-ястыклар арасыннан табылды. Бәхетенә, сабыйның сулыш алырга авызы да, борыны да ачык калган иде. Ләкин ул бик нык курыккан булса кирәк. Елаудан, озак бастырылып торудан тәмам хәлсезләнгән...

Тутыя аңына килгәнче, төрле кеше төрлечә уйлады. Кайсылары: «Хәким үзе Тутыяны шушы хәлгә төшереп кыйнап чыгып качкандыр», — диделәр. Кайсылары: «Элек акчасын урлаган кешеләр килеп, оясын туздырып, Хәкимне алып китеп берәр җирдә ботарлап ыргытканнардыр», — дип фикер йөрттеләр. Тутыя исә хастаханәдә генә аңына килде. Ә ир әйтерсең эреп югалды. Аны эзләү дә, тикшертү турында да беркем эш кузгатмады.

* * *

Яңа килгән табиб белән Алмазия бөтенләй уйламаганча очраштылар. Алмазия укучыларын урманга экскурсиягә алып барган иде. Сары урман шундый гүзәл! Аяк баскан саен төрле исемдәге яфраклар пырхылдап көлгән, үзара нидер сөйләшкән кебек кыштырдап куялар. Сөйләшүнең балалар да кимен куймый анысы.

— Алмазия Хәкимовна, бу чаган яфрагы бит, әйеме?

— Монысы юкә агачыныкы?

— Дөрес таныдыгыз, балалар, — ди укытучы. — Әйдәгез, агачларын да табыгыз әле.

Укучылар, чәчелеп китеп, агач төпләренә басалар.

— Монда җиде чаган бар икән.

— Сигез диген, менә тагын берәү.

— Юкәләр өчәү генә.

— Әнә, әнә тагын бер юкә агачы.

— Булдырдыгыз! — дип мактый укытучылары. — Дөрес таптыгыз. Балалар тагын урман буйлап сибеләләр.

— Алмазия Хәкимовна, менә монда чебен гөмбәләре кук- раеп утыра.

— Карагыз әле нинди зур абага. Алмазия Хәкимовна, абага чынлап та чәчәк атамы ул?

— Ә син язучы Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» дигән әсәрен укымадыңмыни?

— Класс белән укыдык бит, апа.

— Рөстәм, өйләреннән чыгып китеп, җиде төн уртасында абага чәчәген ашый да күренмәс кешегә әйләнә...

— Ай-яй-яй, сез ничек күп беләсез икән! — дип бүлдерде аларны кулына таяк тотып урман эченнән килеп чыккан кеше. Аны шунда ук танып алдылар. «Табиб абый, табиб абый». «Исеме Алмаз», — дип пышылдашты алар бер-берсенә.

— Исәнмесез, — диде егет, килеп җитәр-җитмәс, Алмазиягә баш кагып.

— Исәнмесез!

— Алмаз Хәкимулла улы Хәкимов.

— Алмазия Хәкимовна Кыямова.

— Фамилиядә үзгәреш булмаса, туган балалары дияргә дә мөмкин буласы икән, — дип шаяртты табиб егет. Сүз шунда өзелде. Балалар да көтелмәгәндә пәйда булган кунакка карап тынып калдылар.

— Канлы үлән эзләп йөрим, — дип телгә килде Алмаз. Дөрес, дару үләннәренең күбесен җыю вакыты узды узуын. Тик табып булса, канлы үләнне бераз әзерләп куярга иде исәп. Авылыгыздагы авыруларны белешкәч, кемгәдер кирәк булачагын аңладым.

Соңгы җөмлә Алмазиянең телен ачты.

— Безнең авылның авыруларын сез каян белештегез?
— Шәфкать туташыгыз — аяклы справочник. Миңа кадәр «табиб» булып торган бит, тәҗрибәсе дә зур, — диде Алмаз, бераз шаяртып та, мактап та.
— Алмаз Хәкимуллович, безнең очрашуыбыз уйламаганчарак килеп чыкты. Әниебез белән без сезне өебезгә чакырып сөйләшербез дигән идек әле...
— Ә сез бередә күрешмәдек дип уйлагыз. Сезнең кебек матур кызлар чакырганда, җир читенә барырга да риза, — диде ул, кыю гына. — Әйтеп бетермәдегез шикелле, кемегез авырый?
— Әнием.
— Чире нәрсәдән гыйбарәт инде?
— Кан килә аның, — диде ул, балалар ишетмәсен тагын дигәндәй, як-ягына каранып.
— Кайдан? — Алмазиянең кыенсынганын күреп: — Авырудан оялырга кирәкми, туташ. «Чирен яшергән — үлгән» диләр, шулай бит? — дип өстәде.
— Олы йомышын үти торган җирдән.
— Димәк, канлы үләнне мин сезгә эзлим икән...
Табиб тагын да җанланып китеп, балаларга үзе «хуҗа» булды.
— Балалар, сезгә урман ныграк таныш. Берәрегез канлы үләнне таныймы? Бармы ул сезнең урманда?
Кайсылары «белмибез», кайсылары «минем күргәнем юк» диде.
Ә бер кыз:
— Бар, абый, бар. Мин таныйм аны, — дип кулын күтәрә-күтәрә алга чыкты. — Бәби тугач, әбием белән җыеп алып кайттык. Бәбиебезнең тәне бозылган иде. Канлы үләнне салып югач төзәлде. Тик сарысы бик чыга икән аның, әнинең өр-яңа ак ләгәнен сап-сары итте, — дип такмаклады кыз.
— Ә сез аны каян җыйдыгыз?
— Әнә теге урман авызыннан. Шунда күп ул.
— Әйдәгез барып карыйк.
Мәгълүмат биргән кыз алдан йөгерде һәм әллә каян:
— Менә, менә ул канлы үлән, — дип оран салды.

* * *

Икенче көнне Алмаз Алмазияләргә үзе килде. Авыруның үпкәсен, йөрәген тыңлап карады. Әле эченә, әле аркасына яткырып бавыр турысына басып, бөер турысына суккалап кайтавазын тыңлады. Күзен, телен тикшерде. Аннан соң Тутыяның кайчаннан бу чир белән интегә башлавын, нәрсәләр белән дәвалануын, канның кайчан тукталып торуын бәйнә-бәйнә сораштырды. Әмма Тутыяның теле берне сөйли, башы икенче нәрсә уйлый иде. Ул Алмаз өйләренә килеп керүгә үк имәнеп китте. Кул чукларын, ияк тирәләрен, хәтта кешегә бераз яны белән утыруын ук үзе белән ике ел чамасы яшәп, үлем хәленә төшереп кыйнап чыгып качкан Хәкимгә ошатты.
— Улым, син кайсы авылдан? — диде ул, кызы әзерләгән чәй янына түгәрәкләнеп утыргач.
— Ыкның теге ягыннан, апа.
— Башкорт егетемени?
— Башкортстан татары.
— Ниме соң, эти-әниең бармы?
— Әнием бар. Ә эти?.. Исән диләр аны да, әмма безнең белән тормый.
— Әтиеңне күреп беләсеңме соң, улым?
— Әнием, безгә анысы нигә кирәк инде? — диде Алмазия, әнисенең артык күп сораулар бирүен яхшысынмыйча.
— Юк, белмим, — дип әңгәмәне дәвам итте Алмаз, Алмазиягә бөтенләй дә илтифат итмичә.
— Үскәч тә эзләп тапмадыңмы?
— Әнием рөхсәт итмәде. Әниемне җәберләп яшәгән ул. Ахыр чиктә кыйнап, әйберләрен урлап чыгып качкан... Ләкин бу сүзләр авылда сөйләп йөрү өчен түгел, Тутыя апа. Ни дисәң дә, сезнең авылга дәвалаучы булып килдем бит мин. Кешеләрне гарипләндерүче кансыз Хәкимулла малае булып түгел, — диде. Аннан, артыгын сөйләп ташладым, ахры, дип, үкенгәндәй итеп өстәде. — Әнием әйбәт кеше минем! «Канатсыз фәрештә» дип кенә йөртәләр үзен. Бөтен тирә-юнь халкын дәвалап тора. Сөлек сала — Алмаз, бөтенләй икенче тавыш белән, көлемсерәп, балачак хатирәләре белән баетып сүзен дәвам итте: — Алар бит, сөлекләрне әйтәм, ике-өч елдан артык яшәми. Көлдә яки тозда тәгәрәтә-тәгәрәтә костырып җәфалагангадыр инде. Ә костырмас идең, алты айсыз карыннары ачмый, капмыйлар. Ярдәм өмет итеп килүче кеше күп. Нишләргә? Әнинең күзе бездә. Букчага тәмле әйберләр салып егерме чакрым ераклыгындагы сөлекле күлгә җибәрә. Ә ул күлнең матурлыгын күрсәң — өстенә көмеш тәңкәләр сипкәннәрмени? Болай гына да күрергә барырсың менә! Сөлекләр әнә шундый бик чиста суда гына яши икән. Кайрысын юнып, ап-ак сөян агачларын батырып куясың суга, кайчагында ике-өч сөлек

тә ябышмый. Ис яратмыйлар. Кулларны тагын бер кат комлап юып, таякларны тагын бер кат комлап ышкып суга батырасың да куна каласың. Иртән торуыңа ярый ла таягыңны сырып алсалар?.. Әй, зарлану түгел инде бу, сүз уңаенда искә төшерү генә, — ди Алмаз, елмаеп. — Медицина институтында укыганда, мин ул сылуларның серләрен тагын да күбрәк белдем. Җир йөзендә дүрт йөз төре бар икән аларның. Бездә шуларның кан суырырга яраклы ике генә төре яши. Хәзер алары да Кызыл китапка кертелгән. Шуңа күрә соңгы вакытта биофарикаларда үрчетелә башладылар...

— Алмаз, әллә син сөлек тә саласыңмы? Әллә сөлекләрең дә бармы? — диде аны кызыксынып тыңлап утырган Алмазия.

— Әлегә юк, әмма сала башларга уйлыйм. Су хәрәкәттә чагында — яз, җәй, көз айларында салырга кирәк аларны. Теләсәң, сине дә өйрәтермен,—диде Алмаз.

— Ә мин куркам.

— Нәрсәдән? Сөлекләрдәнме, кешеләрдәнме?

— Сөлекләрдән дә... Кешеләрнең авыртмаган җирен тешләтсәң?..

— Беренчедән, Алмазиякәй, алар авырткан җирне үзләре эзләп таба. Икенчедән, сөлекләр бик матур җан ияләре. Аркалары буйлы, дулкынлы, өстәвенә яшь кызларны бик яраталар. Ә менә тәмәке тарта, тирли торган ирләрне тешлиселәре килми. Ә бер тешләсәме, сәгатьләр буе җибәрми — китабыңны ал да укып тик утыр. Кагылганны-борчыганны да өнәмиләр, үзләре егылып төшкәнче сабыр гына көтәргә кирәк. Авыруны да урыныннан кузгатмау хәерле, — диде Алмаз, елмаеп, — бөтен сере менә шул! Сөлек салу — безнең буыннан буынга килгән һөнәребез ул, Алмазия. Кешеләрне бик күп чирләрдән дәвалаганнар. Менә мин дә алар ягына тартканмын, ахрысы.

— Бала ике якка да охшый шул. Ата каның да әллә кая куеп булмый, — дип көрсенде Тутыя, һаман үз уйларыннан арына алмыйча.

Алмазия әнисенең сүзләреннән тагын кыенсынды.

Алмаз исә:

— Шулай, Тутыя апа, туры эчәкне мин әйткәнчә канлы үлән төнәтмәсе белән юдырасыз, нәтиҗәсен миңа җиткереп торасыз. Ашыгыч кирәк булсам, чакырасыз. Китим. Бик озак утырдым, бик күп сөйләдем дә, — дип, саубуллашып чыгып китте.

Әлеге очрашуны Тутыя үзенчә анализлап, үзенчә нәтиҗә чыгарса да, Алмазиягә шикләрен белдерергә ашыкмады. Бары тик айлар, еллар үтеп, кызының Алмазга кияүгә чыгу ниятен ишеткәч кенә башын тотып уйга калды.

— Кызым, — диде ул, ипләп кенә, — Алмазның маңгаенда миң күргән шикелле булдым, әллә берәр чүп кенә ябышкан иде микән?

— Ничек күрдең икән, әнием? Ул аны чәче белән гел каплап йөртә бит.

Тутыя бу сорауны тагын бер кат тикшереп карамакчы булып, юри генә биргән иде. Алмазиянең җавабын ишеткәч, бөтен шикләренә нокта куйды. Эченнән генә: «Шул, шул Хәким малае бит бу!» — дип кабатлады. Кызының язмышы өчен үзеге өзелде. «Мәктәпне алтын медальгә тәмамлап та минем аркада укырга китә алмады. Инде хәзер тагын минем гаебем аркасында үз туганына кияүгә чыгарга җыена. Тәүбә, тәүбә — авызымнан җил алсын!» — дип хафалы уйларга чумды.

Шунда ул, икеләнергә урын калдырмыйча:

— Кызым, миңа Алмазның әнисе янына барып кайтырга кирәк. Шыпырт кына, хәтта Алмазга да белгертмичә, — диде.

— Нишләп инде, әнием? Йола буенча Алмазның әнисе үзе мине сорап килергә тиеш бит, — дип гаҗәпләнде Алмазия.

— Сәер сәфәр булса булыр, барыйм әле, ерак ара түгел бит. Сораучы булса, җиңги сырхаулап тора икән, хәлен белешергә китте, диярсең, — диде ул, катгый карарга килеп.

Киткәнче кызына сер чишүне иртәрәк дип санады. «Бик яратышалар шикелле, үземнең генә тешем үтмәс, ә көндәшем белән бергәләп үгетләсәк, шәт, иншалла, җиңәрбез» дип фикер йөртте.

Әмма... Язмышыңа язылсамы?..

Нәкъ шул кичтә, ике ана балаларының мөһерле Хәкимнән икәнлеген төгәл ачыклап, сөйләшеп утырган кичтә, бер ата балалары Алмаз белән Алмазия зөфаф кичәнә керделәр...

*1967*

## *Ашыгам, бик ашыгам*

Телеграмманы алгач, йөрәгем урыныннан купты. Барырга. Берсүзсез барырга кирәк! Әмма ничек? Алтмыш чакрым якын ара түгел. Бер төн эчендә юлсыз авылга барып җитү өчен тылсымчы булсаң гына инде?! Алтмыш чакрым якын ара түгел. Ул яшәгән төбәк белән Соколка пристанен тоташтыручы

бердәнбер ышанычлы транспорт — су трамвае. Ләкин аның иң соңгылары да китеп беткән булырга тиеш.

Бәлки, берәр моторлы көймә тотып булыр дигән өмет белән пристаньга юнәлдем. Мин ашыгып, кабаланып барып җиткәндә, пристаньга борыны гына тиеп торган баржадан ике кеше сикереп төште һәм, баржа чигенә башлап, арада күбекләнеп су кайнарга тотынды.

— Кая барасыз? — дип кычкырдым мин, сулышымны еш-еш алып.

— Сикер, сорап торма, — дип шаяртты баржадан төшкәннәрнең берсе.

— Тукта! Юләр кызый, нишлисең? — диде икенчесе.

— Төнгә каршы кемнәргә ышанып утырасың?..

Тик минем ярдагыларның әйткән сүзләренә колак салырга да, уйлап торырга да вакытым юк иде. Бердәнбер мөмкинлекне ычкындырасым килмичә, йөгереп килдем дә бөтен көчемне куеп еракка сикердем. Кемнеңдер көчле куллары, әллә су өстендә үк тотып алды тагы, шап итеп катыга бастырды.

— Ай-яй йөрәк үзегездә! — диде мине тотып алган кеше.

— Сез кая барасыз? — дип сорадым мин, башка нәрсәдә гамем юклыгын белдерергә теләгәндәй.

— Кая барганны да белмисез, ә үзегез сикердегез. Хәзер кая барсак шунда барасыз инде, — диде ул, бераз шелтәләгән кебек итеп.

— Соколка ягына бит?

— Ә сезгә кая кирәк?

— Соколкага.

— Без ул пристаньне үтеп китәбез. Рәхим итеп утырыгыз, — диде егет, зәңгәргә буялган агач диванга күрсәтеп. Әгәр туңасыз икән, эчкә кереп урнаша аласыз.

— Юк, рәхмәт. Мин монда гына, саф һавада барам. Ә без озак барачакбызмы?

— Ашыгасызмыни?

— Ашыгам, бик ашыгам!

— Бер-бер хәл булмагандыр ич?

— Бер-бер хәл?

— Әниегез авырып киткәнме әллә дип соравым.

— Әнием бөтенләй икенче якта яши минем.

— Биредә туганнарыгыз йә булмаса танышларыгыз торамы?

— Юк.

— Аңлашылды. Ничек кенә булмасын, сезгә тизрәк Соколкада булырга кирәк, шулаймы?

— Әйе, бик тиз барырга кирәк миңа...

Шулчак танышым йөгереп өскә менеп китте. Бераздан мин баржаның, чынлап та, тизлеген кызулата төшкәнен сиздем. Тукта әле, минем моңа кадәр зәңгәр күзле, кара чәчле кешеләрне күргәнем юк иде микәнни? Бик матур була икән ич кара бөдрә чәчләргә сыенган зур зәңгәр күзләр. Бик сөйкемле!..

Баржада егетләр байтак иде, күрәсең. Берсе керә, берсе чыга һәм һәркайсысы кырын күз белән генә миңа карап уза.

Берсе:

— Кичке салкын төште, җылыга кереп утырыгыз, — дип, үзләре янына кыстады.

Икенчесе, кулына ипи белән колбаса тотканы:

— Ашыйсыгыз килмиме, каракай? — дип үтеп китте.

Өченчесе, яныма ук килеп туктап:

— Әгәр безнең капитан тотып калмаса, сез хәзер кайда булыр идегез микән, ә, чибәркәй? Кем белә, баржа астына кереп китсәгез, үле гәүдәгезне генә табарлар иде, аны да бүген түгел. — Аннан, көлеп: — Егетләр күрдем дип, шулай кыланырга ярыймыни? Сез әле бик яшь! — дип өстәде.

— Мин бик ашыга идем, — дидем мин, урынымнан торып, һәм, хәлнең чынлап та бик хәтәр булганлыгын уйлап, калтыранып куйдым. Әмма башкалардан өлкәнрәк һәм дорфарак күренгән бу абзыйга сер бирәсем килмәде.

— Башыгызда гел юньсез уй, — дидем дә аңа аркам белән борылып яр буендагы өзек-өзек урманнарга карап бара башладым.

— Һе, юньсез, имеш. Беләм мин сезнең ише чибәр кызларны. Әнә шул арада безнең капитанны нишләттегез. Баржаны ни өчен соңгы тизлек белән куа башлады дип уйлыйсыз?!

Минем турыдагы хәбәр, күрәсең, барысына да ишетелгән иде. Ләкин миңа бу тизлек кенә дә җитми, миңа тагы да, тагы да кызурак кирәк иде. Чөнки минем бар курыкканым — кадерле очрашуга өлгерми калу иде.

Ниһаять, барып җитмәслек булып тоелган Соколка утлары җемелдәде. Биредә су тагы да киңәеп киткән. Кызгылт сулы Нократ нәкъ шушында кара-кучкыл сулы Чулман белән кушыла, диләр. Кызгылт дулкыннар — удмуртлыларның, кара-кучкыл дулкыннар башкорт дусларның кайнар сәламен

алып килеп кечкенә бер калкулыкка урнашкан Соколка янында кавыштыра да Татарстанның киң Иделенә озата. Хәерле юл, дулкыннар! Алдагы көннәрегездә дә бердәм һәм бергә булыгыз!

Мин, тукталу белән ярга сикерергә әзерләнеп, баржаның борынына бастым. Күп булса тагын биш минут чамасы барасы калгандыр. Яныма коткаручым килде. Үземнең дә игелекле бу егетне тагын бер күрәсем килгән иде. Ул янәшәмә басты да:

— Менә вакытны бермә-бер оттык. Хәзер, шәт, өлгерерсез, — диде.

— Рәхмәт сезгә! Чын күңелемнән, зур рәхмәт!

— Бәлки, исемегезне әйтерсез? Минеке — Баязит, — диде ул, кулын сузып.

— Диләрә.

— Диләрә! Бик матур исем. Диләрә, Соколка әллә сезнең туган җирегезме?

— Юк, мин бөтенләй Минзәлә ягыннан, — дидем мин.

— Кара, якташлар булып чыктык лабаса. Мин — Бикбаудан. Сез кайсы авылныкы?

— Калморзадан.

— Күрше авылларда туганбыз, ә кайда килеп очраштык. Кызык бу дөнья, — диде егет.

Без пристаньга якынлашканнан-якынлаша бардык.

— Диләрә, мин сезгә хат язармын, — диде ул, минем күзләремә карап.

Мин эндәшмәдем. Башкаларга әйткән кебек: «Сезнең халык гел шулай, бер күрә дә гашыйк була, имеш», — дип каты бәреләсем килмәде.

— Бөтенләй онытып торам. Хәзер өлгерә аласызмы соң инде, Диләрә?

— Белмим.

— Бернәрсә дә аңламыйм. Сез берәр кайгылы чакыру белән бармыйсыздыр бит? — диде ул, иңбашларыма кулын куеп.

— Юк, киресенчә.

— Алайса, нигә борчыласыз? Нигә ашыгасыз?

— Шатлык белән очрашырга ашыгам.

— Егетегез беләнме, дисәм, ул сезне чакырмас, үзе килер иде?

— Ул армиядә. Урып-җыю вакытында эшкә җибәргәннәр, ә менә бүген алар кире китәләр. Соколка аша үтәбез дип телеграмма суккан.

— Менә ничек? Бәхетле егет! — дип өстәде ул, бераз тын торганнан соң. — Бәхетле! Үзе өчен җан атып торган кызны эләктергән! Мин сезгә уңышлар телим, Диләрә! Очрашуыгыз күңелле булсын!

— Рәхмәт, Баязит!

Ул, зәңгәр күзләрен тутырып, моңсу гына елмаеп миңа карады. Баржабыз яр буенда туктаган башка баржаларга килеп бәрелде, чигенде, кабат якын килде.

Баязит кулларымнан тотты, йөземә туры карап:

— Диләрә, бик ашыксагыз да кабат алай кузгалып китә башлаган транспортка сикермәгез, ярыймы! — диде. — Ишеттегезме, Диләрә?

— Ишеттем, — дидем мин.

Баязит, бер аягы белән күрше баржага басып, миңа чыгарга булышты.

— Рәхмәт сезгә! Сау булыгыз! — дидем мин.

Юлын дәвам итүче баржага, минем якка карап торучы Баязитка бермәл кул изәп тордым да агымга каршы яктан пәйда булырга тиешле теплоходның кайчан килүен белешергә дип өскә таба йөгердем.

*1967*

## *Энҗе*

Күрше авылга кайтып төшүенә, Энҗегә көтмәгәндә Фәнил очрады. Җилдәй очып барганда, күзенә чалынган кызны күреп тормозына басты, ахры, мотоцикл тавышы кинәт тынып калды, аннары тузан эченнән ак тешләрен елтыратып үзе дә килеп чыкты.

— Исәнме, Энҗе, — диде ул, зур кулларын сузып.

Кыз әллә күрешергә теләмичә, әллә кулындагы әйберләрен җиргә куеп пычратудан куркып, күзләре белән генә елмайды да:

— Исәнмесез! — диюдән узмады.

Фәнил шунда ук:

— Ялга кайтып барышыңмы? Озаккамы? Кире тагын шәһәргә китәсеңме?.. —дип, бетмәс-төкәнмәс сораулар белән күмеп ташлады.

Бу сорауларны ул шундый ашыгып әйтте, күрәсең, аның шундый ук ашыгычлык белән барысын да берьюлы беләсе һәм Энҗесен башка беркая да, беркая да җибәрәсе килми иде. Әйе, кодрәтеннән килсә, ул һәммәсен дә хыялындагыча эшләр иде. Энҗесен кичекмәстән һәм гомерлеккә үзенеке итәр иде!..

Менә хәзер дә кочаклап алып чиядәй иреннәреннән шашып-шашып үбүдән һәм бөтен дөнья халкы ишетерлек итеп: «Мин яратам сине, Энҗе! Яратам, бик яратам!» — дип кычкырудан чак кына тыелып тора.

— Энҗе, кая, авылыгызга үзем илтеп куям, — диде ул, бермәл онытылып карап торганнан соң.

— Рәхмәт, Фәнил, район үзәге бит, машиналар булыр әле.

— Юк, юк, үзем илтәм, — диде Фәнил, ашыгып, һәм җавап та көтмичә мотоциклын борып алып та килде.

Менә авыл очы. Энҗеләрнең өе янында гына ботакларын киң җәеп мәһабәт ике өянке үсеп утыра. Ай, нинди зур, нинди күркәм ул өянкеләр! Җәй көннәрендә күләгәсенә утырып китап укый-укый бәбкә саклаган, качышлы уйнаган, күңелгә якын истәлекле урыннар...

Фәниләр күрше авылдан алар мәктәбенә йөреп укый. Иртә дә, кич тә аларның өе турысыннан үтәләр. Фәнилнең әле бишенчегә килә башлаган гына елы иде. Шулай бер тапкыр кайтып барган җиреннән мәктәп сумкаларын җиргә куйды да алар төркеменә уенга кушылды һәм Энҗене беренче булып ул куып җитте. Куып җитте дә ипләп кенә кулларыннан җитәкләде... Ул вакыйгага хәзер нәкъ дистә ел!..

Фәнил мотоциклын нәкъ шунда, беренче тапкыр очрашкан урыннарына, өянке янына китереп туктатты. Сумкаларын алып капка төпләренә кадәр илтеп куймакчы булды, әмма Энҗе кире какты.

— Рәхмәт, Фәнил, сау бул.

Фәнил ни дип әйтергә белмичә аптырап калды һәм үзеннән ераклаша барган Энҗегә гашыйк күзләре белән сокланып карап торганнан соң гына:

— Энҗе, мин бүген кичкә килеп җитәм, яме, — диде дә тузан туздырып китеп барды.

Ул Энҗенең, куркынып:

— Кирәкми, килмә. Берүк килә күрмә! — дип әйткәнен бөтенләй ишетмәде. Хәер, ишетсә дә барыбер киләчәк иде ул!

Энҗе шәһәрдән «Минем монда егетем бар, мине көтмә» дип хәбәр иткәч тә һаман хатлар язды бит Фәнил. Сеңлесеннән сорашып, йөрәгеен юатырлык сүзләр эзләде. Әтиләренең утын алып кайтырга йөргән вакытларына туры килгәч, абыйсының машинасын сорап торып, юк вакытын бар итеп утыннарын илтеп кайтты. Энҗенең әти-әнисе дә якын итәләр кебек Фәнилне. Кызларының әллә кая читкә китеп еракта кияүгә чыгып калуын бер дә теләмиләр.

*** * ***

Кичке авыл өстенә Энҗенең иң яраткан көе — «Фазыл чишмәсе» моңнары таралган. Адымнарын кызулаткан саен, аның йөрәгә ешрак тибә, сулышы тирәнәя. Әйтерсең ул бу көйне бервакытта да тыңлап туя алмас. Аның тизрәк көйнең чыганагын эзләп табасы, табасы да шушы гүзәллекне тудыручыга мөкиббән китеп карап торасы килә. Шушы кадәр сихри тәэсир тудырган кешегә баш иеп рәхмәт әйтәсе килә! Бер уйласаң, аның Фәниле дә моңардан ким уйнамый инде. Күңеленең нечкәргән чагына туры килсә, ул да шулай үзәкләрне өзеп сулкылдата иде. Бу уенчы башка булырга тиеш. Бу уенчының көендә моңа кадәр Энҗе ишетмәгән, нindидер өздереп ала торган яңа бер аһәң бар.

Энҗе сеңлесе Денҗү белән икәнлеген дә онытып, ашыгып, дулкынланып клубка барып керде. Ул килеп керүгә үк, көй кинәт туктады. Аны шау-гөр килеп авылдашлары, дус кызлары камап алды. Аннары кабат баян тартылды, кабат җыр яңгырады:

Челтерәп аккан чишмәгә
Суга дип төшкән идем,
Тиз генә әйләнеп өйгә
Кайтырмын дигән идем...

— Шушы Энҗе кайтса, үзе бер шатлык. Ичмасам, юньле вечерлар була, — диде кызларның берсе, баянчы ягына карап. — Юкса үзебезнең авыл егетләреннән ни чыш, ни пыш дигәндәй, юньләп гармун да тарта белмиләр.

Энҗе уйнаучының Фәнил икәнен абайлаган иде инде. Ул шул якка текәлде. Аларның күз карашлары очрашты. Фәнилнең шатлыгы йөзенә чыкты. Әйтерсең Энҗе башкаларга түгел, аңа, бары тик аңа гына елмайды. Һәм шул елмаю аның барлык борчуларын юып алгандай булды... Яңадан тугандай тагын да дәртләнеп, тагын да хисләнебрәк уйный башлады.

Фәнил ничектер олыгаеп киткән кебек тоелды Энҗегә. Җилкәсе тагы да киңәя төшкән, йөзе, таза беләкләре каралган. Кайчандыр Энҗе бик яраткан соры чалбары белән сөтле кофе төсендәге күлмәген кигән. Хәзер алар элекке шикелле килешми инде Фәнилгә. Хәзер бит тездән түбән өлеше киңәеп киткән, туфли үкчәсенә тияр-тимәс торган, лафсанлы материалдан тегелгән чалбарлар кияләр. Соңгы мода белән тегелгән мондый чалбарлар егетләрнең гәүдәләренә нindидер пәһлеванлык өсти. Һәрвакыт кәттә киенеп йөрүче шәһәр егете Ренат янында Фәнил бик гади, бик авылча шул.

Уен тәмамланды. Яшьләр таралыша башлады. Фәнил дә клубтан чыгуга Энҗеләр янына килеп басты. Әмма Энҗе аның авызын да ачырмады. Тик Фәнил, үзен кадерсезләп булса да, аларга тагылып кайтуын дәвам итте.

Энҗе, үз өйләре турысына кайтып җиткәч, әдәпле генә саубуллашты да кереп тә китте. Фәнилнең өтәләнеп яудырган бер генә соравына да җавап бирмәде. Калган көннәрдә исә клубка бөтенләй чыкмады.

Ниһаять, тәмам түземе бетте Энҗенең. Ялы иксез-чиксез озын булып тоелды. Ахыр чиктә, соңгы өч көнгә калгач, әллә нинди сәбәпләр табып авылдан китте. Аны юл буе Ренат белән кайда, ничек очрашу мәсьәләсе борчыды. Чөнки ул бит Энҗене тагын өч көннән соң гына каршы алырга тиеш. Бүген килгәнен аңа ничек белдерергә? Өйләренә барсаң? Юк, юк, уйларга да оят. Хат язсам? Алай да озак. Кинога барып карарга кирәк. Ул бит киноларны бер дә калдырмый.

Энҗе, самолеттан төшеп, әйберләрен фатирына илтеп куйды да, юеш асфальт төсендәге Ренат яраткан күлмәген киеп, чәчләрен рәтләп кинотеатр бинасы янына йөгерде. Юри ишек төбенә үк килеп басты. Энҗесен күрми калмасын тагы...

Ул дөрес сизенгән булып чыкты. Ренат килде. Тик... Күзләренә генә күренәме? Ренат кинога нindидер бер кыз белән үтеп бара лабаса. Энҗенең иреннәре «Ренат» дип пышылдады. «Ренат, Ренат...» Ләкин ул үз тавышын үзе дә ишетмәде. Күз яшьләренә буылып фатирына йөгерде.

Өч көн вакыт авылда үткәргән бер айдан да озын, ямьсез булып тоелды аңа. Өч көнгә ул бер генә мәртәбә дә елмаймады, өч төннең берсен дә күз яшьләрсез үткәрмәде. Ләкин өч көннән соң, әле таҗ яфраклары да ачылып бетмәгән лилия чәчәкләре күтәреп килгәч, Ренатны бик тиз гафу итте. Гафу итү генәме, хәтта чын асылын белмичә йөгерек күңеленең егете турында начар уйлавы өчен үзен бик нык битәрләде. Ренат исә кинога апасының кунакка килгән кызы белән барган булып чыкты...

* * *

Кич. Вокзал. Алар соңгы автобус белән ял йортыннан кайтырга тиешле дусларын каршы алырга килгәннәр. Шул вакыт Энҗе үзенә текәлеп карап торганнарын сизде. Йа Алла! Әгәр җир тишеге булса, кереп китәр дә юкка чыгар иде. Ләкин ерактан елмаючы күзләр аны тиз аңлады, якынаерга ашыкмады. Күр, ул да шәһәрчә киенгән. Тукта, Фәнил үзе генә түгел, аның әнисе белән бит. Бу ничек болай? Кинәт Энҗене катып калган җиреннән көчле сагыну куптарып алды. Ул йөгереп барып әнисенең муенына сарылды.

— Әнием!

— Кызым!.. Булыш, балам, — диде ана, бөтен йөкне үзенә җыйган Фәнилгә ымлап.

Фәнил карышып кына бер җиңел сумкасын бирде.

— Әнием, ничек болай?

— Менә Фәнил имтихан бирергә барам диде дә, аңа ияреп мин дә килдем әле. Бик тиз уйлаштык, шуңа күрә хәбәр итеп тә булмады. Тукта әле, кызым, ә син нишләп йөрисең? Ай-һай, сез безне шаяртып кына йөрмисез микән? — диде әни кеше, бер Энҗегә, бер Фәнилгә карап.

— Әни, син нәрсә сөйлисең?

Энҗене әйтерсең корт чакты. Ул ялт итеп бер кырыйда басып, аларның сүзләрен ишетү түгел, барлыкларын да оныткан кебек сагыз чәйнәп торучы Ренатка карады.

— Без менә Ренатның дусларын каршы алырга килгән идек.

— Ә-ә, Ренат шушы буламыни инде? — диде әнисе, аңа якынрак барып, кулын сузды. — Исәнмесез!

— Исәнмесез!

Арыган юлчылар Энҗеләрнең кайтасы кешеләрен бер сәгать чамасы көткәннән соң, Ренатны белешеп килергә җибәрделәр. Ул исә: «Бүген кайтмаячаклар, рейслары иртәгә күчерелгән», — дигән хәбәр алып килде.

Шуннан соң инде барысы берьюлы кайту ягына кузгалдылар.

Әмма баягы кебек үк уңайсыз тынлык дәвам итте. Тик кызының нинди хәлдә калуын аңлаган ана гына, ике якның да күңелен төшерүдән куркып, төрле яңа хәбәрләр сөйләде. Әмма Ренатның битарафлыгы Энҗене тәмам аптырашта калдырды. Бу битарафлык та түгел, бу — аның әнисен хөрмәт итмәү, кешегә санамау кебек иде. Трамвайга кереп утыргач, егет Энҗеләр яныннан читкәрәк китеп басты. Кулындагы сумкасын да кемнәндер яшергәндәй, бер кулыннан икенчесенә күчереп газапланды. Трамвайдан төшкәч, түзмәде, Энҗенең җиңеннән тартып:

— Фатирыңны өйрәт тә үзләре барырлар, ә без киттек, кинога соңга калабыз, — диде.

— Һичьюгы кайтарып куйыйк, Ренат.

— Син нәрсә, шәһәрнең үзәк урамыннан төрле төстәге төенчекләр күтәрепме?

Энҗе үз колакларына үзе ышанмады. «Ә» дип әйтергә дә, «җә» дип әйтергә дә теле әйләнмәде. Ул йончыган адымнар белән әкрен генә таш урамнан атлаучы әнисенә карады. Баласы өчен мең җәфалар

чигеп, җәһәннәм ераклыгындагы авылдан күтәренеп килгән әнисен ташлап кинога барсынмы? Йә булмаса Ренатын калдырып китсенме?.. Ул үзенә бер төрле булып әрнегән йөрәгеннән, ике якның кайсын сайларга дигән соравына җавап ала алмыйча атлавын дәвам итте.

Шулчак, сискәндереп, аларны чак кына үтеп китеп такси туктады. Машинадан теге вакытта Ренат белән киногa кергән кыз килеп чыкты. Чыкты да туп-туры Ренатка килеп сыланды.

— Танышыңмы? — диде ул Энҗегә.

— Әйе, танышым иде, — диде Ренат.

Энҗе бер минутка югалып калды да әбиләр кебек үзалдына сөйләнеп: «Вакытында күзләремне ачканың өчен рәхмәт, Ходаем-Аллам!» — диде. Һәм киң итәкле озын күлмәген җилфердәтеп урам кырыеннан атлаган әнисе, авыр сумкаларны чәнти бармагына гына элгәндәй җилләнеп атлаучы Фәниле артыннан йөгерде.

*1966*

## *Нурлы хатын*

Мин бер хатынны беләм. Ул шундый нурлы, назлы, күркәм ки, сөйләшкәндә сүзе сары май кебек йомшак, бәлзәм кебек сихәтле булып йөрәккә ята. Керфекләренең тирбәлүе бер күрүдә әсир итеп, иркә җил кебек җанга кагыла. Йөреше, хәрәкәте иң күрекле хан кызларыныкы кебек ыспай, нәзакәтле. Дөньяда шундый гүзәл хатын-кызлар яшәвенә, аларның соң минуткача садә кала алуына сокланасың.

Ул сөйли. Аның алсу йөзеннән, мөлаем карашыннан нәфислек бөркелә. Күкрәк моңы белән әйткән һәрбер сүзе йөрәгеңне илһам ләззәтенә күмә. Ул аһәңне һич кенә дә туктатасы килми. Мондый ләззәтле минутларны өзү, әлеге хатыннан аерылу — якты көннән мәхрүм калу белән бер булыр шикелле тоела. Гүя ул үзе дә күңелеңнең ни теләгәнен белә һәм дөньясын онытып шигырьләр сөйләвен дәвам итә. Һай ул тәмле дә, татлы да рухи азык!.. Аның көче, аның тәэсире!.. Үзең белән идарә итә, сүз белән әйтеп аңлата алмаслык халәт туа. Күзләрдән генә түгел, йөрәкләрдән дә көлтә-көлтә нур сибелә башлый. Шигърият очкынының кайнарлыгы бөтен тән буйлап, тамырлар буйлап тарала. Бит алмаларына ялкын булып үрли. Хатын исә салмаклый, тавышын киметә төшә. Үзендәге тылсым могҗизасының кешеләрне шулай «сихерли» алуын күреп елмая. Тыңлаучылар белән мин дә әкрен-әкрен үз хәлемә кайтам. Биеклеккә күтәрелгән җаным, янәдән дә тәнемә төшеп, бүленеп калган тынымны тигезли. Бөтен зиһенемне җыеп, шигъри җанлы хатын турында уйлануымны, аңа соклануымны дәвам итәм: бу нурлы хатынны табып үстергән Ана нинди кыяфәттә икән?! Асыл гәүдәсе кайсы бәхетле затның куенын җылыта? Ир дигәне кадерен беләме, үзенең никадәр сылу зат белән гомер итүен аңлап горурланамы?..

Миндә әлеге хатынны биләп торган, шушы кадәр байлыкка ия булган ирне күрәсе килү, аннан да бигрәк йөзеннән күземне ала алмыйча тыңлаган Нурлы хатынны үз өемдә кунак итү теләге үскәннән-үсә бара. Бу минем алар арасындагы яратышуны, ягъни дөньядагы иң илаһи, иң зур Мәхәббәтне күрәсем килү теләге дә иде...

Көннәрдән бер көнне табын көйләп аларны кунакка чакырдым. Ризыкларымны бик тә хасиятләп, Нурлы хатынга лаек итеп әзерләргә тырыштым. Билгеләнгән вакыт якынлашты. Ишек катындагы һәр кыштырдауга колак салып, Нурлы хатынның үзеннән дә мәһабәтрәк ирен култыклап, кунакка килүен көтә башладым. Ниһаять, кыңгырау җырлады. Мин, дулкынланып, кунакларымны каршы алырга йөгердем. Ишекне ачып... Нурлы хатыннан беркавым күземне ала алмый тордым да, янындагы кешене күреп, имәнеп киттем. Аның белән янәшә үзеннән бер баш чамасы тәбәнәк, ярым пеләш, лач су булып тирләгән мәхлук бер адәмчек басып тора иде. Ходаем-Аллам, ире әллә шушы микән?.. Үз-үземә биргән бу соравым урынсыз иде. Нурлы хатынның хәләл җефете тышкы кыяфәте белән тырнак очы кадәр генә дә үзенә тиң түгел. Мин, югалып калуымны яшерергә тырышып, аларны өйгә чакырдым. Тик никадәр генә тырышсам да, аптыравым чамадан ашкан, кайнар хисләрем яшен суккан кебек юкка чыккан иде. Гүя мин үзем булудан туктадым. Агардыммы, кызардыммы — гаҗәпләнүем йөземә ни кыяфәттә чыккандыр — белмим, бары тик Нурлы хатынның беләгемә кагылуы гына мине терелтеп җибәрде. Бары тик шунда гына тотлыга-тотлыга кунакларны түргә дәштем. Ир дә, хатын да минем каушавымны күреп сагая калды. Нурлы хатын «Әллә иртәрәк килдекме?», «Әллә авырыйсызмы?», «Әллә килүебез вакытлы булмадымы?» кебек сораулар биреп, сәерсенүемә җавап эзләде. Мин, ниһаять, үземне кулга алып, аларны әзерләгән өстәлем янына утырттым. Табыным, чынлап та, кунакларымның бик көтелгән кешеләр булуын раслап тора иде.

Хатын хәтта:

— Чакырылган кунакларыгыз соңара, ахры, — дип әйтеп куйды.

Мин:

— Юк, башка бер киләсе кешем дә юк. Бүген иң олы, иң кадерле кунакларым — сез, — дип җавапладым.

Сөйләшеп, ашап-эчеп утырырга куштым. Нурлы хатын, шул әмерне генә көткәндәй, мавыктыргыч итеп сөйләргә, очынып-очынып шигырь укырга кереште. Мөлаем итеп көлде, ягымлы итеп эндәште, сак кына иренә сырпаланды. Ә ир ник кенә бер күз сирпеп алсын да ник кенә бер мәртәбә хатынына кагылып куйсын?! Өстәвенә мин аның комагайланып ашавын, өстәлдәге нигъмәттән башка һичбер нәрсәгә илтифат итмәвен күреп хәйран калдым. Аптыравым шул дәрәҗәгә җитте ки, гүя мин күпмедер вакытка уйлау сәләтемне җуйдым. Гәүдәм — алар каршында, ә җаным? Җаным тәнемне ташлап китеп барды кебек. Бу юлы ул күккә күтәрелеп, Кояшка якынаеп, тәнемә дәрт-дәрман төяп кайтыр өчен түгел, ә бәлки, бәргәләнә-бәргәләнә елар, әченә-әченә үксер өчен караңгы бушлыкка, упкыннар арасына төшеп киткәндер кебек тоелды. Тәнемә кире кайтканда, ул тәмам көчсезләнгән, хәлсезләнгән, сулкылдаудан ярсып йончыган кебек иде. Шуңа күрәдерме вөҗүдемне ниндидер дерелдәү биләп алды. Тере мәетнеке кебек сүнгән һәм сүрелгән күзләрем белән текәлеп-текәлеп каршымда утырган парларга карадым. Бу кадәр дә салкын, бу кадәр дә җансыз кешене үз гомеремдә беренче күрүемме әллә? Әллә инде күз тияр дәрәҗәдә сылу, гүзәл хатын янында булганга шулай мәхәббәтсез күренәме бу бәндә? Нурлы хатын сөйләвен дәвам итте. Ләкин бу юлы аның тавышы мине рухландыра алмады. Көтелмәгән тәэсир, язмышның гаделсезлеге хис-тойгыларымны үтереп кенә калмыйча, үземне дә тораташ итеп катырды...

Нурлы хатын кызгану тулы яшьле карашымны абайлап алды. Әмма, иң үкенечлесе, бу юлы җаннарыбыз бер-берсенә тартылмады. Мин хәтта чын йөземне яшереп, елмая, артистланып булса да, аларны сыйлый алмый башладым. Нурлы хатынны жәлләүдән, табигатьнең шундый ялгышларга юл куюына ачуым килүдән әллә кая чыгып югаласым, җирне тырный-тырный сыктап, әрнүемне басасым килде.

Мәхәббәт! Мәхәббәт!! Мәхәббәт!!!

Менә нинди икән ул?! Матурлыгы белән күзләремне камаштырган, шигъри күңеле белән җанымны әсир иткән нурлы танышымның мәхәббәте!.. Менә кемне иш иткән дә менә кемне сөя икән ул минем алиһәм!

Ә беләсезме, ул аны чынлап та сөя, ярата икән бит! Ышанасызмы, сөя, ярата! Ярата, сөя икән!.. Мин бу нәтиҗәне, Нурлы хатынның кершәндәй кульяулыгын чыгарып, иренең иягеннән агып төшкән майны сөртеп-сөртеп алуыннан, тончыга башласа, сабый баланы сөйгәндәй, ипләп кенә җилкәсенә кагылуыннан, иркә сүзләр әйтеп, аңа сыенып-сыенып куюыннан аңладым.

— Моңа кадәр мин сезгә шагыйрьләр язган шигырьләрне укыган идем, ә бу юлларны, иремә багышлап, үзем иҗат иттем, — диде ул, хәләл җефетенә тулган айдай елмаеп карап.

Иңнәремне терәр ышанычым,
Аргамагым минем, тулпарым.
Син булганда гына бәхетле мин,
Күз алмама торыр җан ярым!

Аннан, миңа карап, гүяки күңелемдәген укып, җавап бирде:

— Сез аның кеше янында үзен артык тыйнак тотуына илтифат итмәгез. Ирем мине күтәреп кенә йөртә. Мин бит озак басып тора алмыйм, биеклеккә күтәрелү бөтенләй көчемнән килми...

Шулчак ирнең ишек ачкандагы тирләгән кыяфәте күз алдыма килде. Йа Алла, димәк, бишенче катка?..

Мин инде икенче төрле аптырау белән аптырый башладым. Бары тик «а-ла-ай» дигәнне аңлатып, башымны кактым. Соң чиккә җиткән гаҗәпләнүем чынлап та телсез иткән иде. Үземнең, ире юк җирдә генә нурлы булып күренә икән бу хатын дип фаразлавым, дөньядагы иң бәхетсез кеше икән дип гөманлавым өчен җир тишегенә кереп китәрдәй булып оялдым. Бактың исә, әнә нинди сирәк, әнә нинди олы Мәхәббәт белән яши икән бит ул. Шул Мәхәббәте бәхетле, шул Мәхәббәте нурлы итеп күрсәтә икән аны кешеләргә...

*1996*

## *Васыять*

«Миннән васыять, акыллы кеше, бала ияртеп, хатын аерган иргә кияүгә чыкмасын», — дип җан бирде Мөслиха түти. Бу сүзләрне ишеткән күршеләре башларын чайкап телләрен тешләде.

Күршеләренең һәммәсе Мөслиха түти күргән-кичергән хәлләргә тере шаһит иде. Балаларының үги ата белән ничек газап чиккәнен дә, ике якны да җайларга, бер-берсенә мәхәббәтле күрсәтергә тырышып Мөслиха түтинең ничек бәргәләнгәнен дә күреп, күрмәгәнен сизеп торды алар. Юк икән, бер булмагач булмый икән... Олы-кары белеп әйткән: «Үзегез тапкан балаларыгызны үзегез үстерегез!» — дигән.

Бәлки, кияүгә чыгуым белән үлгән иремнең рухын рәнҗеткәнмендер, хәзер шуның әҗерен алып яшимдер, дип тә өзгәләнде Мөслиха түти. Юкса ирен бөтен шартын китереп җирләде. Үлемнән соң тиешле булган барлык эшен йола буенча эшләде. Бик озак еллар аның җылысын тоеп яшәгәннән соң гына әлеге Сәйфигә кияүгә чыккан иде.

Тора башлаганда, барысы да ал да гөл кебек тоелды. Сәйфи сөйли, Мөслиха түти елый-елый тыңлый. Тыңлаган саен Сәйфигә мәхәббәт, аның ташлап калдырылган хатынына нәфрәт арта бара. Ничек инде көне-төне эшләп, пачкалап акча кайтарып биргән, хатынының күзенә генә карап яшәгән шушы ирне кадерләмәскә, керен юмаска, ашатмаска мөмкин? Ничек аны туктаусыз битәрләп торырга да вакытында өйгә кайтмаска, читләр белән чуалырга була? Бу ирнең аяк астында туфрак булып сибелергә, җәймә булып җәелергә кирәк. Үзе әйтмешли, гайрәтле кочагында бер сөелү бәрабәренә булса да кол булып яшәргә риза булырсың!..

«Тәүбә, әстәгъфирулла» — Мөслиха түти үз уйларыннан үзе куркып, сискәнеп китте. «Кол» «тол» сүзенең туганы микән әллә, бигрәк бертөрле яңгырыйлар... Толлыкны күрде, толлык яман. Ә коллык? Мәхәббәтнең колы булу алай начар эш түгелдер, бер булса...

Тик колның да билгеле бер максат куеп яшәгән колбиләүчесе булырга тиеш икән шул. Хатын кол булса да, Сәйфи колбиләүче була алмады. Аннан соң тагын бер нәрсәне уйлап бетерә алмады Мөслиха түти. Аңа килеп кергән көннән башлап гомер иткән хатынын, балаларының анасын туктаусыз хурлап, аны сүгү, мәсхәрәләү бәрабәренә үзен кызгандырып утырган ирнең күпмедер вакыттан соң яңа гаиләсенең дә нәкъ шулай итеп яманатын сатар бу дип уена китерә алмады. Ә ул нәкъ шулай булды да. Хәлләр, тасмасын кирегә әйләндереп караган кино кебек, кабатланды да торды.

Киң җилкәле, үзе әйтмешли, ирнең беренче сортына керә торган кешегә күз төшереп, сокланып йөрүчеләр тагын табылды. Кунакка йөрергә һич кенә дә иренмәгән Сәйфи, аларның тәмле чәйләрен мактап, онытылып-онытылып ял итте. Алай гына да түгел, Мөслиха түтинең йә песиен чакырып, йә иптәш кызлары килгәч көлешеп алган балаларын күрмәс өчен еш кына кайтмый кала яки, юктан да сәбәп табып, үзен ярсытып чыгып китә башлады. Менә шул вакытта Мөслиха түти тиз ышанучан күңеленең нык итеп алданганын төшенде. Гомере буе «гөнаһсызга рәнҗетелгән, бастырылып яшәгән» иренең бөтенләй дә ул сөйләп ышандырганча булмавын белде. Нәни генә кырын сүзнең дә кайсы елның кайсы вакытында әйтелүен күңеленә бикләп гомере буе ачу саклаучы, шуларны кешегә сөйләгән саен сүзен иҗади үстереп ул кешегә усаллыгын арттыра баручы, яхшылыкны тиз оныта торган бер адәм икәнен күрде. Әмма бу тамаша алдында Мөслиха түти көчсез иде. Буар елан авызына үз аяклары белән барып кергән куян хәлендә калуын тоеп, җаны газапланды. Ләкин эш узган. Аның инде хәзер бер генә максаты: Сәйфинең гаиләгә күңел бирмәвен, үксезләрнең ире күзенә көннән-көн сөйкемсез күренә баруын туганнары сизеп борчылмасын да, кияүгә чыгуын хупламаган кешеләр белеп сөенмәсен. Тик гомере буе аралашып, авыр кайгыларны, зур шатлыкларны бергә күтәреп яшәгән ут күршеләре Мөслиха түтинең эченә кара кан йотып көн итүен бик яхшы аңладылар. Аның көннән-көн сыза, ешрак авырый башлавы якыннары күңелендә борчу уятмый калмады. Җыелышып Сәйфи белән сөйләшеп карарга да уйладылар. Әмма «Бөкрене кабер генә төзәтә», «Кешене тыңлый белә торган түгел» дигән нәтиҗәгә килеп тукталып калдылар. Аннан соң, юк дисәң дә парлап кеше арасына чыкканда Мөслиха түтинең бәхетле минутлар кичерүен күреп, үзләрен тынычландыра килделәр. Әмма ире белән капма-каршы холыклы Мөслиха түти биреште. Башта кыйналган кебек бөтен тәне авыртып, авыраеп йөрде дә урынга ятты. Һәм шул ятуыннан тормады. Хәле көннән-көн начарланып, үзенең соңгы минутлары якынлашканын тоеп, иң якын туганнарын, гомере буе бер мәртәбә дә телгә килмичә тату итеп яшәгән күршеләрен чакырды. Һәр сүзеннән соң хәл ала-ала һәммәсенә рәхмәт әйтте, бәхиллеген бирде. Аннан: «Чирен яшергән — үлгән... Миннән васыять, акыллы кеше, бала ияртеп, хатын аерган иргә кияүгә чыкмасын. Хатынын яратмыйча яши-яши ул инде бозылган, кансызланган була, бала-чагага да миһербаны бетә икән. Балаларым ир кеше тәрбиясе алып үссеннәр дип мин бик ялгыштым», — диде.

Мөслиха түти нәтиҗәне шулай ясады. Балаларының дөм ятим калуларын күз алдына китереп, өзек-өзек сүзләр әйтеп елады да яшьле күзләрен йомып җан бирде.

«Урыны җәннәттә булсын!» — диделәр күршеләре, Мөслиха түтинең ярым ачык калган күзләрен йомдырып. Берсе, хатының фани дөнья белән хушлашты, дип әйтергә Сәйфи янына чыгып китте. Сәйфи исә, авызын колагына кадәр ерып, Мөслиха түтинең хәлен белергә килгән саңгырау Шәмсекамәр әбигә: «Үлми, минем белән яшәгән хатын үлә димени? Минем бер төнем ун еллык сихәт бирә аңа!» — дип шар яра иде.

*1996*

## *Нинди әләм, шундый сәлам*

Әти буласы кешене күрүдән озак кына куркып йөрдем. Куркып йөрүемнең сәбәбе — ул мине, мин аны кабул итә алмасак яки фикерләребез, фигыльләребез туры килмәсә, дигән шикләнүле уйлар сәбәпле иде.

Әнием үтә дә мәрхәмәтле, ягымлы, сылу бер хатын-кыз буларак, мин аны бик тә сагынам. Күрәсем, кайтып көлемсәр күзләренә карап гәпләшеп утырасым, ул пешергән берсеннән-берсе тәмле ризыклар белән сыйланасым килә. Әмма төрле сылтау, сәбәпләр табып, очрашуны һаман кичектерәм дә кичектерәм. Тик һәрнәрсәнең чиге булган кебек, минем дә түземем төкәнде. Үз-үземне «Әнием яраткан кешене мин нишләп яратмаска тиеш? Ялгыз башына иптәш табылгач бик әйбәт булган әле» дигән уйлар белән юлга чыктым. Күчтәнәчләремне дә мулдан алдым. Беренчедән, әниемне хәзер шәһәр кибетләрендә тулып торган тәм-томнар белән сыйлыйсым килсә, икенчедән, ят кеше алдында сынатмаска кирәк дип уйладым. Ә менә ничек итеп күрешергә, дигән сорауга соңгы минутка кадәр җавап таба алмый аптырадым. Әти урынына килгән кешегә кем дип эндәшергә? Үземне ничек тотарга? Әти кеше бер генә була бит... Башта ничек эндәшсәң, шулай китәчәген белгәнгә күрә дә «әти» сүзен ят кеше өчен күпсенеп йөдәдем. Күпсенүемне аклар сәбәпләр дә эзләдем. Әгәр тора-бара бу затлы сүзгә лаек булмаса? Әниемне рәнҗетсә? Безнең кайтып-китеп йөрүләрне килештерми башласа?..

Мин авылыбызга якынлашканнан-якынлаша барам. Йөрәгем тагын да ныграк тынгысызлана. Машинамны туктатып юл буендагы чирәмлеккә чыгып утырам. Күңелем белән әйтерсең вакытны сузарга телим. Ә күзләрем ирексездән табигатьнең гүзәллеге белән хозурлана.

Безнең авылыбыз сөйләп тә, язып та бетергесез дәрәҗәдә матур ул! Олы юлның ике ягына гаскәр кеби тезеп ак каеннар утыртылган. Агачлар белән юл арасындагы «хәтфә»дә нәфис таҗ яфракларын тибрәтеп аллы-гөлле чәчәкләр чайкала. Шушы урында уңга каерылып керсәң, төрле зурлыктагы таулар тезмәсе, сулга карасаң, әйләнеп чыккысыз сихри болын башлана.

Әйләнеп чыккысыз дип әйтүем дә сүз уңаеннан гына түгел. Болыныбыз, чынлап та, әйләнеп чыккысыз зур. Урыны-урыны белән чытырманлыклар, балан, карлыган, гөлҗимеш куаклары хакимлек итә. Аларга сарылып, уралып үрмә гөлләр, чәнечкеле бөрлегәннәр үскән. Аркылы-торкылы сузылган бу галәмәт ныклы «яшел баулар»ны аралап алга бару шактый авыр. Җитмәсә, күле дә әйләнмәле бит аның.

Әйләнмәле күл. Исеме җисеменә туры килеп тора тагын. Чөнки кай тараф, кайсы ягы икәнен аерып булмаслык әлеге күлне кырыкмаса-кырык әйләнеп тә юл таба алмыйча утырып елаган кешеләрне сөйлиләр. Хәтта адаштыра, башны әйләндерә торган сихри тәэсире дә бар, имеш. Булса да булыр. Чыккан сөякләрне, кул башларын, тайган аякларны әллә нинди кинәт килгән бер көч белән тартып, оясына утыртучы авылдашыбыз Миңнегөл апаны әнә шул Әйләнмәле күл янында адашып төн кунган, арып йокыга киткәч, җеннәр укыткан дип сөйлиләр.

Минем дә уйларым белән Әйләнмәле күл янында әйләнеп йөрүем тикмәгә түгел. Ул минем үз әтием белән үткән кыска бала чагыма бәйле.

Әниемнең сөйләвенә караганда, әтием туган авылыбызны, аның табигатен, урман-кырларын нык итеп ярата белә торган кеше булган. Һәр могҗизаны үз күзләре белән күреп, һәр җимешен тәмләп карарга яраткан. Әмма бер очрак аны Әйләнмәле күлдән биздергән.

Хәер, аңа кадәр ул инде Әйләнмәле күл буенда әллә ничә тапкыр сәяхәт иткән. Хәтта сынамак өчен төн дә кунып калган. Ә бу юлы безгә күрсәтәсе, бездә туган табигатькә карата мәхәббәт уятасы килеп, бер төркем бала-чага ияртеп, янына өч яшьлек улын, ягъни мине дә алып болынга киткән. Менә шунда инде әтием Әйләнмәле күлгә исемнең дөрес бирелүенә ныклап ышанган. Берсеннән-берсе вак, дистәләгән баланы кайсын арка кочтырып, кайсыларын өчәрен берьюлы кулына күтәреп, алга да, артка да сукмак ерып, үзе буе булып үскән кыргый «дәрья» белән көрәшкән. Кеше балаларын югалтудан йә бер-бер бәлагә очраудан куркып җаны табанына төшкән. Көнозын шулай изаланганнан соң, ниһаять, кояш баеп барганда күзенә юл күренеп, көч-хәл белән авылга кайтып егылган.

Күлне туктаусыз әйләнеп йөрүем — үземне чамадан тыш җаваплы тоюдан булды. Кинәт гашыйк булгандагы кебек, хисләрнең артык кайнар булуы күңел күзен сукырайта икән, дигән әтием. Ә икенче җәйдә ул инде якты дөньядан китеп тә барган.

Бу югарыда сөйләнгән вакыйганы мин бик томанлы гына хәтерлим. Нәни аякларым белән әтиемнең муенын кысып, егылмас өчен чәчләренә чытырдап ябышып җилкәсендә йөргәнемне күз алдыма китерүем дә балачак хатирәләремнең сүнүенә әнием ирек бирмәгәнгәдер дип уйлыйм. Әмма аңлы үсмер чагымның әтиемне юксынып үтүләрен исемнән бер дә чыгара алмыйм.

Әтиле кешеләр уена да китермәгән әрнүле газаплар белән яндым мин ул чакларда. Бергә уйнаган дусларымның киң кочакка сыенганнарын күргәндә дә; «Әти-и!» — дип кычкырып, каршыларына йөгергәннәрен карап торганда да; калын тавыш белән: «Улым!» — дип чакыруларын ишеткәндә дә йөрәкнең әллә кай төшләре өтелеп, өзелеп китә иде. Хәтта кайберәүләрне сыек чыбык белән кыздырулары да кызыктыра. Әтиле булсам, сыек чыбык түгел, билендәге каешын алып суктырса да бер җирем дә авыртмас, авыртса да шыңшымас шикелле идем. Беркемгә дә сиздермәскә тырышып, шыпырт кына елый-елый, Аллаһыдан әтиле булу бәхете бирүен сорадым. Әмма юк, иң кирәк, иң

теләгән минутларымда «Әти» дип әйтер кешем пәйда булмады. Әллә теләк тубалым тулып җитмәде, әллә әнием башка хатыннар кебек тәвәккәлләргә читенсенде... Ә менә бүген, күптән инде язмышым белән килешеп, этисез тормышка ияләшкәннән соң, шул вазифаны үтәргә дип килгән берәүне күрергә кайтам. Хәер, нигә аны? Әниемне күрергә дип, әниемне сагынганга юлга чыктым лабаса. Тик һаман да шул сорау тынгысызлый: әнием янәшәсендәге ир-атка кем дип эндәшергә соң?

Җиңел машинам белән җилкапкабыз янына килеп туктадым. Өйалдыннан сулышы белән тартып алырдай булып көткән әнием килеп чыкты. Йөгерә-атлый ашыгып:

— Улым, күз нурым минем, исән-имин генә кайттыңмы? — дип кочагыма сеңде.

Шулай бер-беребезне сөеп, ләззәтле минутлар кичергән мәлдә озын буйлы, какча гәүдәле ирнең яныбызга ук килеп җиткәнен сизми дә калганмын.

— Исәнме, улым, мин синең этиең булам, — дигән тавыш тәнемә сәер җылылык йөгертте.

Нинди әләм, шундый сәлам, ягъни үрнәге нинди — нәтиҗәсе шундый дигәндәй, мин дә, җавабыма аның кебек ныклы бер аһәң салырга тырышып:

— Исәнмесез, эти! — дигәнемне сизми дә калдым. — Әниемә тиң пар булыгыз! — дип, күрешү өчен кулларымны ул сузган кулларга бирдем.

*2006*

## ***Тормыш***

Уйлары спектакль белән бергә үрелеп акты аның. И-и, минем тормышымны язганнар, гелләрем дә минем тормышымны язганнар, дип кабатлады ул эченнән. Ялгызлар күп шул хәзер. Шуларның да яртысы кияүгә чыкмый, бала тапмый картайган.

Фәһимәгөл туңып, калтыранып куйды. Балаң да булмагач, бу зур дөньяда ялгызың да булгач, бигрәк кыендыр шул. Ходайның биргәненә шөкер, ул ялгыз түгел. Димәк, бәхетсез дә түгел...

Уйлары тамаша залы буйлап әле артка, әле алга йөгерде. Туктале, дип куйды ул үз-үзенә. Бу ирләр бит туганда күбрәк тә туа. Әнә аның да алты баладан дүртесе малай. Күрше Зөләйханың да малайлары күбрәк. Ә менә Фәриданең икесе дә кыз. Аның каравы Гөлиянең икесе дә егет. Тууын туа инде алар. Тик менә үлүен дә күбрәк үләләр шул.

Йә, ярар, кеше баласын санап утырмыйм әле. Рәхәтләнеп спектакль карыйм. И-и, гелләрем дә минем тормышымны язганнар бит. Гелләрем дә минем тормышымны...

Әнекәччем?.. Шулай шул, шулай, җыен этрәк-әләм менә дигән ир белән тора. Шундыйларга ирләрнең дә гомерлесе туры килә бит аның... Томрап торган, кулларыннан гөлләр тамызып яшәгән хатыннарның бәхете юк. Нигә тигезсез бу тормыш, нигә гадел түгел? Нигә шундый пешмәгән арыш боламыгы кебек хатыннарның алдында бал да май? Фәһимәгөл тирә-юньдәгеләргә күз салды. Һәммәсе шым гына спектакль карый иде. Әй, нигә теләсә ни уйлап баш катырам соң?.. Ходай Тәгалә белми яратмагандыр әле. Димәк, дөньяда андыйлар да кирәк. Әнә сөйлиләр бит. Имеш, бик борын заманда фәрештәләр күзгә күренеп йөргән. Бервакыт тирләп-пешеп урак уручы хатыннар яныннан узып бара икән бәхет өләшүче фәрештә.

— Ник безне әйләнеп үтәсең син, бәхет өләшүче фәрештә? Безгә бәхет калдырмыйсыңмыни? — дигән аңа эшчән хатыннар.

— Сезнең кулларыгыз ут уйната, күзләрегез нур сибә. Бәхетне миннән башка да табачаксыз. Мин булдыксыз хатыннар янына барыйм әле. Калган бәхетне аларга өләшеп бирим, — дигән бәхет өләшүче фәрештә. Һәм кул кушырып, күзләрен алартып, сагыз чәйнәп утырган хатыннар ягына юнәлгән...

Йә, менә бар диген инде дөньяда дөреслекне?! «Эш язганга — эш язган, аш язганга — аш язган» дип тикмәгә генә әйтмәгән шул халык. Әй, ярар, бу уйларның очына чыгып булмас. Рәхәтләнеп бер спектакль карыйм әле. И-и, гелләрем дә минем тормышымны язганнар бит, ә? Гелләрем дә минем тормышымны язганнар...

Шулай ир белән хатын яшәгәннәр, ди. Аларның бердәнбер уллары булган. Күп бала табып, бу дөньяда кем рәхәт күргән? Хәерчелек арттырасы килмәгән боларның. Бер булсын, берәгәйле булсын, шушы берне үстерсәк, дөньябызны да бүлгәләп йөрисе булмас, үзебез дә өебезнең түрендә утырырбыз дип уйлаганнар. Һәм бөтен тапкан-табынганнары белән бердәнбер улларын киендереп, тәмледән-тәмлене генә ашатып үстергәннәр. Кеше арасында аерылып торсын дип, еракка җибәреп укытканнар. Кирәк-ярагына акчаны да мулдан биреп торганнар. Бервакыт егет укып бетереп, солдат хезмәтен дә тутырып өенә әйләнеп кайткан. Авылның бер бик яхшы кеше баласына өйләнеп тә җибәргән. Әмма күз өстендә каш булып үскән егетнең үзсүзлелеге торган саен ямьсезрәк төс ала икән. Мәсәлән, үзенә каршы әйткән кешене өйдән куып чыгару, караңгы базда төн калдыру яки мунчага бикләп ач тоту аның гадәти бер

мин-минлегенә әйләнгән. Әйбәт вакытта әйтеп тә, сөйләшеп тә карыйлар, әмма һич кенә дә җиңә алмыйлар икән.

— Алты яшьтә үк аяк тибеп кычкыра иде. Алтмышта да кешене кеше дип белмәс инде бу. Без үлгәч ничек кенә яшәрсең микән моның белән? — ди икән каената килененә.

— Киленкәем, без бер бала белән калып ялгыштык. Үзе генә булганга артык ирәйде. Тапсаң, биш-алтыны тап, тапмасаң, берне дә тапма, — дип васыять әйтә икән каенанасы.

Көннәр, еллар үткән. Каената белән каенана киленнең олы терәге, киңәшчеләре икән. Яшь хатын каенанасын тыңлап, алты бала тапкан. Табуын тапкан, әмма иренең яман чире көчәйгәннән-көчәя генә бара икән. Шулай беркөнне бөтен өйне ду күчереп, бөтен оясын тузгытып каһәрләгән бу. Үз-үзен белештермичә дулаган, тавышланган да чыгып киткән. Һәм шул китүеннән әйләнеп кайтмаган. Төш үткән, кич җиткән, таң аткан. Өйдәгеләр бик сәерсенгәннәр. Безнең рәнҗеш төшеп машина астына кердеме әллә дип тә уйлаганнар. Ә бераздан хәл ачыкланган.

Өеннән чыгып киткәч, олы су буена барган бу. Кием салымын пөхтәләп төреп куйган да бер кәгазь битенә озын итеп хат язган. Хатында эти-әнисеннән, хатыныннан бәхиллек сораган һәм «...Олы мәхәббәтем хакына шушылай эшлим. Сезне чиксез яратам, әмма үземне тыя алмыйм. Дистәләгән кешенең җанын җәзалап, күңелен гарип иткәнче, бер әшәке адәмнең дөньядан китүе хәерлерәк булыр. Газизләремнең кан-яшен агызып җир йөзендә яшәргә хакым юк минем» дигән. Һәм хатны аяк киеме белән бастырып куйган да муенына зур таш бәйләп су төбенә төшеп яткан...

Менә шулай... Кич җитүгә, «Алты бала атасының олы мәхәббәте» хакында бәет чыгарды авыл халкы...

«Ж-ж, әллә нишләп туңып киткәндәй булдым, — дип үзалдына сөйләнеп куйды Фәһимәгөл. — Гелләрем генә минем тормышны язганнар бит. Уйлап чыгарып, шыттырып язалар, дисәм, бөтенләе белән тормыштан алып иҗат итә икән бит бу язучылар. Менә бит нинди спектакль булган безнең тормыш?! Елый-елый карый халык! Минем үземне дә елатты ул мәхәббәтем! Артык олы, артык дуамал, артык баш бирмәс мәхәббәт иде шул!..»

*2001*

## *Кояш баешы*

Ул, сәхнәгә менеп, чәчәкләр бирде. Ләкин таныдымы аны Йолдыз? Белми. Чөнки сәхнә күзне сукырайта, каушата, әллә кая чиксезлеккә чакырып башны әйләндерә икән. Кемгә ничек, әмма Әхмәтгали өчен бу шулай булды. Искиткеч авыр йөк күтәреп менгәндәй кара тиргә батып төште ул җырчы мөнбәреннән. Тирләсә тирләде, әмма үзеннән канәгать калды. Сәхнә йолдызына үз куллары белән чәчәк бүләк итте бит! Йолдыз үз куллары белән аның чәчәкләрен алды.

Ходай Тәгаләнең барлыгына бүген тагын бер кат ышанды Әхмәтгали. Аллаһы Тәгалә әйткән ди бит, сорагыз гына, ак сарык сорасагыз — акны, кара сарык сорасагыз — караны бирермен, дигән. Әхмәтгали дә сорады. И Ходаем, и бер Аллам, диде ул, бөтен татар кешесенең ушын алган шушы җырчыбыз минем тупсамны атлап кереп, түремә узып, мин салып биргән шәрабтан авыз итеп, мин ясап биргән чәй белән сусынын басып, күзләремә генә карап утырсын иде. Минем юка идән-түшәмле өемне яңгыратып бер җырласын иде дә тирә-күршеләрне аһ иттерсен иде. Белсеннәр иде Әхмәтгалинең кем белән аралашканын. Күрсеннәр иде аның табыны түрендә кемнәрнең ризык җыюын!.. Бәлки әле, кыюлыгы җитеп кулын сорар. Иреннән аерылган дип сөйлиләр бит. Ходай Тәгаләнең «Амин!» дигән чагына туры килеп... Ул, үз уйларыннан үзе ләззәтләнеп, тәне кымырҗып, тез башларын уып куйды.

Чынлап та, бирде бит Ходай. Ак сарык идеме Әхмәтгалинең сораганы, кара сарык идеме — Аллаһы Тәгалә аның үтенечен ишетте, очраштырды ул аларны. Хәер, Әхмәтгали кичергән уй-ләззәтне үз тәртибендә сөйлик әле.

Алар урамнан бара иде. Алар дигәнем Әхмәтгали белән Сәгыйдә. Сәгыйдә — никахлашмыйча гына Әхмәтгалинең өч ел буе хатыны булып яшәүче танышы. Өч ел эчендә ияләште дә шикелле инде ул аңа. Әмма бик тә начар бер гадәте бар танышының: иң кирәкмәгән җирдә ашка төшәргә җыенган ана кара таракан кебек күзен тасрайта да басып тик тора. Бу юлы да шулай итте. Юк бит, артына борылып карамыйча гына китеп барырга ярамый... Басты да тора.

Әйе, урамнан икәү барган чаклары иде. Шул вакыт Әхмәтгали ни күзе белән күрсен, каршысына җил-җил атлап кыйммәтле тун, аның өстенә туннан да кыйммәтлерәк шарф салган сәхнә йолдызы килә.

— Йөрәккәем, — диде Әхмәтгали, кулын күкрәгенә куеп, — гомерегез озын булыр, Сезне генә уйлап килә идем.

Ул Йолдызның кулына үрелде. Иелеп, җырчының бил турысыннан югары күтәрелмәгән кулын үпте.

— Мине? Нәрсә дип уйлап килә идегез? — дип шаркылдап көлде Йолдыз, башын чайкап. Йолдызның куе бөдрә чәчләре, сибелеп китеп, Әхмәтгалинең битен кытыклады. Битенә генә түгел, бөтен вөҗүденә сихри наз таралды. Ул, чак кына аңын җуймый калгандай, тотлыга-тотлыга җавап бирде.

— Концертыгыз хакында. Сезнең исемегезгә җисемегез туры килүе, сәхнә йолдызы, алай гына да түгел, татар халкының якты кояшы булуыгыз хакында, йөрәккәем! — диде Әхмәтгали. — Милләтебезнең горурлыгы Сез! Сезнең кебек асыл хатынны сәхнәдә генә түгел, тормышта да гөлгә күмеп яшәтергә кирәк! Ә болай җәяү йөртү?.. Оят, билләһи...

— Машинагыз нинди марка? — дип сорады Йолдыз, каршысында өзелергә җитеп басып торган ирдән.

— «Волга». Билгеле, Сезнең өчен... — Ир кыенсынып куйды, тик сүзне икенчегә борып: — Йолдыз ханым, әйдәгез, өйгә кереп сөйләшик. Мин менә монда гына яшим. Ихлас күңелемнән чакырам, — диде.

— Начар булмас иде дә, соңга калырмын шул, — дип сузды Йолдыз.

Йолдызның бигүк өметсез булмаган җавабы Әхмәтгалине җанландырып җибәрде.

— Чакырылган җирегезгә үзем илтеп куярмын. Әгәр инде «Волга» машинасы гына дип утырырга оялмасагыз?..

Йолдыз риза булды.

Әхмәтгали Сәгыйдәнең китеп баруын бик теләсә дә, өйгә ул да керде. Тик шунысына рәхмәт, Йолдызга: «Сез әфәнденең кеме буласыз?» — дип сорагач, «Тәрбия итүчесе», — дип җавап бирде. Төрлечә аңларга мөмкин булган бу җаваптан Әхмәтгали канәгать калды. Әмма күңеленә бер шик керде. Йолдыз аның исемен оныткан булырга тиеш. Юкса «әфәнде» дип сөйләшмәс иде. Ярар, бүгенге кичтән соң онытмас, Алла боерса, дип уйлады ул һәм, кая басканын да белмичә, кунагына хөрмәт күрсәтү хәстәренә кереште. Ялгыз кешенең шул инде, урыным да җыелмаган, дип, таралып яткан диванына җәймә каплады. Нәрсәләрнедер шалтыратып аудара-ега, иң кадерле кешем өчен саклаган бәлзәмем, дип, балчык савытка салынган эчемлек тартып чыгарды. Мондый игътибар Йолдызның күңеленә хуш килде, әлбәттә. Сихәтле бәлзәмнең беренче тәэсиреннән үк җырлый башлады:

Җилкенүне үз башыңа, диләр,
Син җилкенеп шашып яраттың.
Мин таш кыя,
Син абындың миңа,
Йөрәгеңне бәреп канаттың.
Йөз алданып, мең ялганып шулай
Утка-суга төшеп яраттың.
Мин сөймәдем сине,
Ә син, тиле,
Бер күрәсең килеп җан аттың...

Әхмәтгали катып калды. Кем турында, нәрсә хакында бу җыр? Сәхнә йолдызының буйдак иргә җыр белән төрттерүеме? Сәгыйдәнең үпкә сүзләрен җырга салган дисәң, очрашканнары юк. Ул уйлары белән упкынга убылгандай булды. Алай гына да түгел, аяз көнне яшен яшьнәгәндәй, Сәгыйдәсе дә, рюмкасын Йолдыз белән чәкештереп, җавап җыры сузды:

Җырла әле, җырла әле,
Уй юшкыны юылсын.
Кайгыдан каралган йөзем
Синең җырда юынсын!

«Хәзер генә уйлап чыгарды, моңарчы җыр җырлап яшәгән кеше түгел инде бу», — дип нәтиҗә чыгарды Әхмәтгали Сәгыйдә турында. Һәм үзе дә, булгач булсын инде дигәндәй, бик күптәннән хыялланып йөргән Йолдызны каршына утыртып җырлау нияте белән бер шагыйрьдән махсус яздырып алган җырын башлады:

Керфегеңә ай яктысы,
Ай яктысы уралган.
Бәгырькәем, синнән башка,
Синнән башка торалмам.

Йөзләреңә кояш нуры,
Кояш нуры буялган.
Бәгырькәем, сине күреп,
Сине күреп туялмам.

Синең сөю, минем сөю
Яз белән көз арасы —
...Гүя кышкы бураннарда,

Йолдыз Әхмәтгалине көчкә тыңлап бетерде. Кыбырсыды, йөзен чытты, боргаланды.

Бәлзәм салынган аракы да гайрәтле булып чыкты, күрәсең. Кунак, нидер әйтмәк булып кулын селтәп, Сәгыйдә ясап куйган чәйне аударды. Ватылган чынаякны бәхеткә юрадылар.

— Бәхеткә, бәхеткә! Сезне очратуым бәхеткә булырга тиеш. Шушы көннәрдә миңа машина кирәк иде, — диде Йолдыз.

Хуҗа тиз генә үзенең телефон номерын язып бирде.

— Көннең яки төннең кай вакытында йомышыгыз төшә, шылтыратыгыз. Әйткән минутта ишек төбегездә булырмын,— диде.

Телефон шылтыравы озак көттермәде. Йолдыз икенче көнне үк чакырды Әхмәтгалине. Егет, өр-яңа ак күлмәген, әйбәт костюм-чалбарын киеп, машинасына сәхнә йолдызының кассеталарын көйләп, чакырган җиргә китте. Әхмәтгали дүрт күз белән карап утырган ишектән көттереп кенә озын буйлы, кара күзлекле, чибәр ир чыкты.

— Әхмәтгали буласызмы? Мин — Йолдызның ире. Менә сезгә ул калдырган язу, — диде ир, кәгазь кисәген шоферга сузды һәм, аның укыганын көтеп тә тормыйча, машинага кереп утырды. Ишекне япканчы ук шалт кына кнопкага басып, хатынының тавышын туктатты. Үзе, сагыз чәйни-чәйни, авыз эченнәнниндидер колак ишетмәгән көй шыңшый башлады.

Әхмәтгалинең өстенә тәпәне белән салкын су сипкәндәй булды. Чатнама суык вакыттагыдай өшеп, калтырана башлады. Баш миен «Иреннән аерылган дип сөйләгәннәр иде бит?» дигән сорау бораулады. Ул кулының калтыраганын, үзенең тәмам аптырашта калганын сиздермәскә тырышып, ир биргән кәгазьне алып, язуын укыды. Анда: «Үзем гастрольләргә китәм. Иремне минем кебек якын күреп, йомышларын үтәгез!!!» — дип язылып, өч өндәү билгесе куелган иде. Менә сиңа, туймасаң, бәлеш аша...

Кыскасы, Әхмәтгалигә Йолдызның ирен бер ай буе килеп алырга, әйткән җиренә алып барырга, көтеп утырырга, кайтарып куярга кирәк булды. Әллә Йолдызның аяк астында туфрак булырга әзер торганга, иренә дә тугры хезмәт итте ул. Тик, алай-болай шикләнмәсен тагын дип, машинасына ара-тирә Сәгыйдәне дә утыртып баргалады.

— Хатыным. Мулла чакыртып никахлашмасак та өч ел буе бер түбә астында яшибез, — дип таныштырды арткы рәтнең бер почмагына посып утырган хатынны.

— Никахсыз яшәгәч — сөяркә инде. Зина белән шөгыльләнәсез, — диде ир, салкын гына.

— Зина?! — дип кычкырып җибәрде Әхмәтгали, нәкъ шушы минутта гөнаһ өстендә тотылган кешедәй.

Ир ике сөйләшә торганнардан түгел иде.

— Карусыз хезмәтегезне кайткач Йолдызга җиткерермен. Аның сезгә тагын йомышы булыр әле, — дип, башка көннәрдәгечә, рәхмәт әйтми генә төшеп калды.

— Бу артистларга читтән карап кына сокланырга ярый икән, — диде Әхмәтгали, көрсенеп. — Җырын тыңлаган барлык тамашачыны үзләренә бурычлы дип санныйлар, ахры.

— Һәр ялтыраган алтын булмый, иркәм, — диде Әхмәтгалинең хыял-өметләрен күптән аңлаган Сәгыйдә.

Әхмәтгали эндәшмәде.

Көннең кичне каршылаган мәле иде — кояш баешы. Алар кайтыр юлга борылдылар. Тынлыкны моңсу карашы белән офыкка төбәлгән Сәгыйдә бүлде:

— Кояш бүген дә болыт артына качып баер, ахры...

*1993*

## *Чиләгенә күрә капкачы*

— Сәгъдулла, тукта әле, тукта, дим. Әллә бик ашыгасың инде? Син дә ялгыз, мин дә ялгыз дигәндәй, бер утырып гәпләшеп алыйкмы әллә?

— Үземнең дә сине күптән күрәсем килеп йөри иде. Борчулы чакларың бугай. Кайгыңны уртаклашам, дисәм инде?..

— Нинди кайгы булсын ди ул, юләр? Киресенчә, шатлыгың белән котлыйм дияргә кирәк.

— И-и, малай, аерылышу шатлык түгел инде, үземнән беләм. Сер бирәсең генә килми. Хатының да начар кеше түгел иде юкса.

— Начар түгел? Каян беләсең син аның начар түгеллеген? Син аның белән торып карагынмыни? Беләсеңме синең турыда нәрсә дип әйтә иде ул?

— Белмим, сөйләшкән юк бит, — диде Сәгъдулла, кикриге шиңгән этәчтәй.

— Бервакыт юбилееңа бардыкмы? Алтмыш кеше чакырып алты кеше генә килгән иде ашыгызга, өстәлегез буп-буш булды?

— Шуннан, — диде Сәгъдулла, төксе генә.

— Менә шуннан минем хатын әйтә: Сәгъдулланың кем икәнен белер өчен ерак барасы юк, чакырган кунаклары да килмәгән иде, — ди.

— Шулай диме?

— Шулай ди. Әле халык мәкале белән раслап та куйды. «Чакырып кунагың килмәсә, авырып хатының үлмәсә, бик читен дип әйтәләр бит», — ди.

— Ник, дөрес инде, чирләп хатының үлмәсә, бик кыен, аерылышырга туры килә. Йә синең кебек ташлап чыгып китәсең дә яшьләр белән типтерә башлыйсың, — диде Мөнәвир, Сәгъдуллага төрттереп.

— Авызыңны ерып торма, — дип чыгырыннан чыкты Сәгъдулла, ярсып. — Минем хатын да синең гайбәтеңне аз сатмады. Кеше карарлык җире юк, бер өтек шунда, ди.

— Синең хатының үзе өтек. Кәкре сыйраклы, тоз күзле. Ачуым килмәсә әйтмәс тә идем, билләһи!..

— Ә синеке? Үзеңнекен бел, ичмасам, минем хатынны хурлаганчы, үз хатыныңа кара! Хәер, чиләгенә күрә капкачы инде, икегез дә бериш...

— Ничек бериш? — диде Мөнәвир, Сәгъдуллага җен ачулары чыгып. Аннан, юкәдә икән чикләвек дигәндәй, бик тиз сүрелде. Алда җибәргән хатасын аңлап, бөтен көченә хатынын якларга тотынды. — Минем хатынның бер җире дә кешедән ким түгел! Туганнарым килеп, мәсәлән, кайчан ишекне ачсалар да, йөзе кояш кебек. Өй ялт иткән — чиста. Тәмле пешерә!..

— Чисталыкка минем хатынга җитми инде анысы! Юган керләре — ак кершән! Үзләреннән ислемай исе аңкый!..

— Яшь хатының керләреңне юмыймы әллә? — диде Мөнәвир хисләнүеннән чайкалып торган Сәгъдуллага, мыскыллы тавыш белән.

— Нинди яшь хатын? Минем өйләнгәнем юк, — диде Сәгъдулла һәм, хатынын сыйпап иркәләгәндәй йомшак, назлы тавыш белән: — Алма кебек хатыным барында... — дип өстәде. — Туган көне генә җитсен, бер кочак чәчәкләр сатып алам да өемә кайтам. Чәчәк күргәч, кертми калмас әле, Алла боерса!

— Бәй, минем хатын да чәчәкләр ярата бит! — дип шатланып кычкырып җибәрде Мөнәвир. — Чәчәкләр күрсә, эри дә китә менә... Искә төшерүең өчен рәхмәт!..

Шулчак Мөнәвир, саубуллашырга да онытып, ашыгып китеп барды. Ун адымнар чамасы читтә Сәгъдулла аның, бу тирәдә кайда чәчәк кибете бар, дип сорап торганын ишетте.

*1994*

## *Мең дә бер кичә*

Тәмам аптырады Гайшәбикә. «Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас» дигәндәй, булырлык булса башта ук тыңлар иде аны Фәтхелбаяны. Әйбәтләп әйтеп карады, ачуланды, елап җәлләтергә тырышты, аерылам, дип куркытты. Юк, булмагач булмый икән. Һаман эчә, һаман соң кайта. Ул эчеп кайткан саен, Гайшәбикәнең күз төбенә бер җыерчык кереп кунаклый. Соң кайткан саен, йөрәк мускулларындагы бер капилляры шартлый. Ә Фәтхелбаянга ни? Өс бөтен, тамак тук. Гаилә бар, малай үсә. Кыскасы, әнә шулай юкка-барга борчылмый гына, көн саен сәламәтлеген саклап эштән соң «башын ял иттерә» Фәтхелбаян.

Ә беркөнне гадәттәгедән соң кайтты ул. Гайшәбикә яткан. Өй эче тып-тын. Хәтта тәлинкә ваткан тавышка да уянучы булмады.

— Ашыйсы килә, — диде Фәтхелбаян, хатынының колак төбенә килеп.

— Ә-ә, картым кайткан икән, — диде Гайшәбикә, елмаеп. — Пешердем, син ярата дип, яшелчә ашы пешердем. Менә, — диде ул, аш бүлеп. — Аша, аша, карының ачкандыр. Төнге унике җиткән икән инде!

Каршысына ук утырып кыстады ул ирен.

— Ашыңның кәбестәсе пешмәгән, — диде Фәтхелбаян, хатынының ачуы чыкмаганга үзенең ачуы килеп.

— Тукта алайса, картым, пешмәгән кәбестә эчеңә тимәсен, — диде Гайшәбикә һәм Фәтхелбаян алдындагы ашны алып ялт кәстрүлгә салды да утка утыртты. — Бер-ике сәгать кайнатып алыйк!

Ашны пешереп ашап, таң атканда урын җәеп, йокларга ятты алар.

Иртә белән Фәтхелбаян янына малае йөгереп килде.

— Әти, — диде ул, пышылдап, — бер сер әйтимме?

Фәтхелбаян баш какты, сер сакларга ризалыгын белдерде.

— Әни бер китап алып кайтты. Иртәгә кичке сәгать алтыда укый башлыйбыз. Көн саен бер хикәя. Беләсең булса, шундый кызык язучы икән!

— Кем? Исемен беләсеңме соң? — дигән булды ата, улының хәтерен калдырмас өчен генә әңгәмәгә кереп.

— Фаил Шәфигуллин!

Фәтхелбаянны очкылык тотып куйды. Кайчаннан бирле эзли бит инде ул аны. «Китап кибетендә танышларың бар, тап шуның җыентыгын», — дип, Гайшәбикәсенең колагына чикерткә булып кергән иде юкса.

— Гайшәбикә, кая, бир әле, карыйм, — диде Фәтхелбаян, хәбәрнең сер икәнен бөтенләй онытып.

— Нәрсәне? — диде хатыны, гаҗәпләнеп.

— Фаил Шәфигуллинны!

— Нинди Фаил Шәфигуллин булсын миндә?

— Соң, яшермәгез инде миннән! Мин дә шушы гаилә кешесе бит! — дип өзгәләнде Фәтхелбаян.

— Иртәгә кичке сәгать алтыда карарсың, — диде Гайшәбикә, коры гына. Үзе улына матур итеп күз кысып алды.

— Ничек алтыда? Нигә унда түгел?

— Унда башка кеше караячак. Безнең вакыт сәгать алтыдан җиденче яртыга кадәр, — диде Гайшәбикә, тыныч кына.

Ышанырга да, ышанмаска да белмәде Фәтхелбаян Гайшәбикәнең сүзенә. Шулай да иртәгесен бөтен чакыруларны, тәкъдимнәрне кире кагып, эш беткәч, туры өенә кайтты. Гайшәбикә белән малае коңгырт тышлы китапны укырга әзерләнеп кенә торалар иде. Фәтхелбаян да тавыш-тынсыз гына алар янына кереп чүгәләде. Беренче хикәяне ләззәт белән укып, рәхәтләнеп көлә генә башлаганнар иде, ишек кыңгыравы шылтырады. Фатыйма икән.

— Укып чыктык, ахирәт, гаҗәп тә кызык, — диде Гайшәбикә, китапны дус хатынына сузып.

Фәтхелбаян зал ишегеннән үрелеп карарга өлгермәде, Фатыймадан җилләр искән иде.

— Тотып та карый алмый калдым, — диде Фәтхелбаян, үзалдына турсаеп.

— Иртәгә, картым, иртәгә, алтыда, — диде Гайшәбикә.

— Ә соңрак булмыймы?

— Булмый, — диде Гайшәбикә. —Бөтен урамга бер китап, һәркемнең тизрәк укыйсы килә. Шуңа күрә чиратка салдык. Ә син кайгырма, иртәгә кайталмасаң, башка хикәяләрен тыңларсың, тотып та карарсың, мең хикәя әле ул, — диде хатын, хәйләкәр елмаеп.

— Әйе, шулай итәрсез! Миннән башка гына Фаил Шәфигуллинны укырсыз! — диде Фәтхелбаян, идәндә таптанып.

... Ә мең дә беренче көнне?.. Мең дә беренче көнне кичке сәгать алтыда улы белән хатынына үзенең хикәяләрен укый башлады Фәтхелбаян.

*1995*

## *Таш йөрәк*

Төн уртасында ишек шакыдылар.

— Бәрәкалла, вакытлы-вакытсыз кайсы хәерсезе булыр икән? — Нурикамал түти сөйләнә-сөйләнә ишек катына килде.

— Кем бар анда?

— Картың. Ач әле ишекне, — диде тавыш.

— Капкаңны ялгышкансың, акыллым. Минем ирем юк. Ташлап чыгып киткәненә бишбылтыр, — диде Нурикамал түти, кырт кына.

— Ялгышаммы соң? Кирәк чакта мин сине җиде төн уртасында табам. Үзеңнең Шәмсезыяның бу, карчык, — диде тавыш, өтәләнеп.

— Булмас, безнең Шәмсезыян борын белән сөйләшә иде. Синең сүзләр бөтенләй аермачык чыга!

— Соң, карчык, эчмәгәнгә өч көн ләбаса, акча бетте. Шуңа күрә сүзләр дә аермачык чыга. Йә, ач инде.

— Ә-ә, эчәргә акчаң бетте дә Нурикамалың исеңә төштемени? Юк инде, акыллым, кая дип чыгып киттең, шунда тор! Шунда барып сора акча!

— Кертмисеңмени?

— Юк, кертмим.

— Кертмәсәң, тотам да бил каешым белән!.. — дип зеңгелдәде теге тавыш. — Тотам да ишек тоткасына асылынам. Ояты сиңа булыр. Ирен куып чыгарган да кертмәгән, ә ире йөрәгенә чыдый алмыйча асылынган, диярләр.

Нурикамал түти каушап калды. Ай Аллам, тәмам әсәренде бит шул асылыну белән! Бернәрсә булса, тота да бауга ябыша, тота да асылынам дип куркыта. Алла сакласын, эченә коткы кергән кеше уйлаганын эшләми калмый, диләр. Күрәчәгең булса, асылынды куйды булыр.

Нурикамал түти ишек артындагы тавышка колак салды. Менә нәрсәдер чең итеп ишек тоткасына бәрелде. Мөгаен, каеш аелы. Әнә ишек тә тартылып куйды. Уеннан уймак чыкмасын тагын дип уйлады Нурикамал түти һәм, калтыравык тавыш белән:

— Шәмсезыян, нишлисең әле син? — дип сорады.

Җавап кайтаручы булмады.

— Шәмсезыян, нишләвең бу? Адәм рисвае итәсең, ахры, инде. Һай Алла, гөнаһ шомлыгы! — дип калтырана-калтырана ишекне ачты.

Аның каршында ике кулы белән үзен-үзе кочаклаган, ишек яңагына сөялгән Шәмсезыян басып тора иде.

— Ай шул гадәтеңне! — диде Нурикамал түти, әйтер сүз тапмыйча.

Ире әкрен генә атлап өйалдына керде.

«Әнә шулай була ул», — дип уйлады Шәмсезыян, эченнән генә. Өч көн эчендә ирсез торуның әчесен татыган түтәгез! Башка вакытта: «Пычак, бау күтәрмәссеңме? — дип, ишек артында сәгатьләр буе ант иттерә иде. Хәзер менә Шәмсезыян абзагыз нишләргә икәнен белер! Ул керә-керешкә өйалдындагы кадакларга, ыргакларга күз төшерде. Нурикамал карап торганда, берничәсен тартып та карады. Өстәл тартмасыннан ипи пычакларын алып бер-берсенә ышкып торды, күкрәгенә чәнчегән булып кыланды. Әмма ләкин карчыгы ник кенә бер күз сирпеп баксын. Башка вакытта Шәмсезыянның борылуы булыр иде, пычак-чәнечкене йә ястык астына, йә юылган кер арасына яшерер иде. Хатынының шулай кан калтырап куркып торуы Шәмсезыянның йөрәгенә сары май булып ятар иде. Ә бүген әллә нишләгән әле ул. Аркасы белән әйләнгән дә урын җәя.

— Эһе, — дип уйлады Шәмсезыян. — Болай булгач, мәсьәләне чынга якынлаштырырга кирәк. Иплəп кенә барып матчадагы бүрек элә торган кадакны тартып карады. Өйалдыннан бастырык кыса торган юан бауны алып керде дә шап итеп идәнгә ташлады.

— Асылынам бит, нәрсә карап торасың?!

Аның картын туктатырга теләп артыннан чабып йөрмәгән карчыгына ачуы чыкты.

— Ә-ә, алаймыни? — диде Нурикамал түти, тыныч кына. Туктап тор әле син. Ул бау бик юан булыр, үләлми интегерсең.

Нурикамал түти, аяк очына кадәр җиткән төнге күлмәген җилфердәтеп, шкаф янына китте:

— Менә монда нечкәсе бар. Ефәк бау! Асылынгач-асылынгач, асылына асылын инде бауның!

Шәмсезыян баскан җирендә катты да калды. «Таш йөрәк! — дип уйлады ул Нурикамал түти турында. — Үлсәң дә кызганмас!.. Кемгә өйләндем мин, ә?! Таш йөрәк!»

*1974*

## *Ис сизү*

Ясирә тагын телеграмма алды. Үзенең һәм әтисенең исеме, фамилиясе тутырып язылган бу телеграммада чәчең үрә торырлык мыскыллау сүзләре язылган иде. Икенче көнне нәкъ шундый эчтәлектәге ачык хат килеп төште, өченче көнне — открытка...

Шушы хәл Ходайның һәр бирмеш көнендә кабатлана башлады. Һич кенә дә кичекмичә, буталмыйча, төгәл бер тәртипкә салынып куелгандай: телеграмма, ачык хат, открытка; телеграмма, ачык хат, открытка... Әгәр дә ки телеграмма китергәндә өйдә булмасаң, ишеккә язу кыстыралар да почтага чакыралар. Ә анда: «Ә-ә, сезмени ул, менә сезнең исемгә җибәрелгән «котлау», — дип, музей экспонаты кебек итеп каршыларына куелган кәгазьне китереп бирәләр.

Котлау дигәч, Ясирә шатланып китә. Әмма телеграмманы кулга алуга, шатлыгы сабын куыгы кебек шартлый. Күзләре шул бер үк сүзләрне укый: «нәҗес», «күз көеге», «сөйрәлчек»... Кызлар аңа карап, ачыктан-ачык көлеп тора. Ясирә җир тишегенә кереп китәрдәй булып кызарып, уңайсызланып чыгып китә. «Болары чит кеше, алар белән көн дә очрашмыйм. Менә үз балаларым алдында ни йөз белән йөрергә?» — дип уйлый ул. Чөнки көн саен кабатланып торган бу хикмәтне алар күзеннән яшереп калу берничек тә мөмкин түгеллеген аңлый.

— Беркемнән дә сүз әйттермәм, дигән идең. Бер чарасын күрергә кирәк бит инде, — ди ул белеп тә, белмәмешкә салышып йөргән иренә, кичке табынны җыйгач.

— Ә син аларны ташлап бар. Укыма! — ди ир, исе китмичә генә.

— Соң, мин ташлармын да, тик миңа кадәр ничәмә-ничә кеше кулына керә алар... Ничәмә-ничә кеше укый, көлә, гайбәт тарата.

— Андый ваклыклардан өстен була белергә вакыт инде сиңа, — дип шелтәли аны ире һәм, күзләрен кыса төшеп: — Синең эндәшмәвең үзе туктатачак аны, түз, — дип өсти.

Ясирә өйләнешкәндә тау кочаклаткан иренең хәзер шулкадәр дә битараф булуына гаҗәпкә кала.

Түз! Әйтергә ансат. Ул түзүләрнең бер очы күренсә икән?.. Атналар, айлар үтә. Әмма телеграммалар авторының туктарга нияте күренми. Киресенчә, язу эшен тагын да киңрәк җәелдереп, Ясирәнең күршеләренә, эшләгән җиренә, газета-журнал редакцияләренә, җавап таләп итеп, хатлар яудыра.

— Кеше бәхетсезлеге өстендә бәхет төзеп булмый, — ди Кафия Кәбировна ашыгыч чакыртып китертелгән Ясирәгә, тигез ак тешләрен күрсәтер өчен төбенә кадәр ерган авызын җыя алмыйча. — Без — «Хатын-кыз хокукларын саклау җәмгыяте» — мондый эшләргә юл куя алмыйбыз.

— Үз тәҗрибәгездән чыгып әйтәсезме? — дип сорый Ясирә, Кафия Кәбировнаның үткәнен яхшы белгәнгә күрә, хәзер әллә кем булып утыруын өнәмичә.

Кафия Кәбировна, мондый эшләрдә елан аягын кискән белгеч буларак, тавышын да, сөйләшү алымын да шунда ук үзгәртә.

— Өстенә бастың. Мин этиләрен аертып алганда, ике-өч яшьлек кенә иде ул балалар. Вак бала — вак бәла, олы бала — олы бәла, ди халык. Ә син нәкъ мәшәкатьләре зурайгач, онычкларын карарга бабалары кирәк була башлагач аертып алгансың. Синең гаебең күпкә зур, туганкай, — ди.

— Тукта әле, тукта, ахириең Мәхмүзәне ничек итеп күккә чөйдең кияүгә чыккач? Имеш, Мәхмүзә намуслы. Имеш, Фәритне балалары балигъ булгач кына үзенә яр иткән. Ә инде Фәрит Мәхмүзәнең эчке мөмкинлекләрен, талантын ачып, халыкны бәхетле итәр өчен аңлы рәвештә бу адымга барган. Дан пар күгәрчендәй матур парларга! дип сайраган идең түгелме?

— Әйттем шул. Алар иске гаиләләре белән болай да аерылу чигенә килеп җиткән булганнар. Ә син, хат авторы әйтмешли, чөкердәшеп яшәгән ир белән хатынны аергансың!

— Мин аермадым аларны! — дип аяк тибеп җавап бирә Ясирә, Кафия Кәбировнаның үзеннән дә уздырып. — Миңа кадәр әллә ничә тапкыр киткән булган ул хатыныннан. Син очрамасаң да, аның белән яшәми идем, монда синең бер гаебең дә юк, диде ул миңа... Аннары, — дип дәвам итте Ясирә, хатирәләргә бирелеп, — торыр җире дә булмагач, җәлләү хисе, теге, ни, ир исе иснисе килү теләге дә булгандыр, бәлки?! Үземнекеннән бик яшьли калдым бит...

— Шул шул! — дип күтәреп алды аны Кафия Кәбировна, — ис сизү боза гаиләне. Минекеннән дә кәҗә тәкәсе исләре килә башлады. Киредән ничек карт хатынына җибәрергә белмим. Берәр киңәш бирә алмассың микән дип чакыруым иде әле үзеңне.

*2003*

## *Бишботлар юкка тавык суймас!*

Хатыннан аерылган көнне үк Басыйр үзенә фикердәшләр эзли башлады. Ә алар, алдан әзерләп куйган кебек, очрап кына тордылар. Авылны икегә аерып аккан елга турысына барып җиткәндә генә, каршысына күпербаш Сәхи карчык килеп чыкты.

— Әй-бәт тә иткәнсең, кем, Басыйр улым, Бишбот кызын аерып! Электән үк сөйми идем шуларның мин мин микән, мин кем микән дип йөрүләрен! Иллә дә әйбәт иткәнсең!..

Басыйр җавапка серле генә сөйләнеп куйды:

— И-е-е... Бишботлар юкка тавык суймас!..

Сәхи әби, хатынын аеру кайгысыннан ычкынганмы әллә бу дигәндәй, сәерсенеп карап торды да таягына таянып ары китте. Басыйр да атлавын дәвам итте. Тыкрыктан кинәт кенә калкып чыккан Хәлимәнең көянтә-чиләгенә чак кына бәрелмичә туктап калды.

— Тол хатынга хәл-әхвәл сорашып, озаклап сөйләшеп торырга ярамый, Басыйркаем, — диде Хәлимә, кояштай елмаеп. — Әмма тегеләрнең кикрикләрен шиңдерүең яхшы булды әле! Җиде кыз җидесе дә авылның иң асыл ирләрен билəп, безнең ише толларга өстән генә карап йөриләр иде, татысыннар әле бераз ялгызлыкның ни икәнен! — диде Хәлимә, шатлыгын яшереп тормыйча. Аннан, пышылдауга күчеп: — Куна кил, капканы ачык калдырам, — диде дә чиләкләрен чайпалдырып китеп тә барды.

Басыйр Хәлимәнең очкын чәчеп торган карашыннан айнып та җитмәде, дусты Фәүзи кочаклап алды.

— Котлыйм, туган! — диде ул, авызын колагына кадәр ерып. — Билгеле, моның ише эшләргә бик сөенмиләр, вә ләкин син молодец! Тәвәккәл кеше син! Үземнең гомергә шуңа йөрәк җитмәде. Гомер буе чиләнәм карт хатын белән! Үзеңнән унбиш яшькә кече диләр яңа хатыныңны. Ну, каймак эчендә йөзәсеңдер инде... Менә бит, атлауларың икенче, күзләрең ут янып тора! Булдыргансың, туган!..

Димәк, ялгышмаганмын. Якын дустым Фәүзи дә хуплый бит дип уйлады Басыйр.

— Сер булмаса, аерылышуыгызның сәбәбе нәрсә булды соң? — дип, икенче тонга күчте Фәүзи. — Беренче хатының да кеше арасында төшеп калганнардан түгел иде кебек?

Фәүзинең соңгы җөмләсе Басыйрның ачуын китерде.

— Мин үземнең нәрсә эшләгәнемне бик яхшы беләм! Мин өйләнгәндә кыз түгел иде ул! Менә шуны исәпләп чыгардым быел.

— Исәпләп чыгардым? — дип кабатлады Фәүзи, сорау катыш гаҗәпләнү белән. — Андый нәрсәне исәпләп буламыни? Аннан, батыраеп: — Әле генә өйләнешүебезгә кырык ел тулды! дип, бик олылап бәйрәм итеп йөргән идегез түгелме соң?

— Хәтерең яхшы синең, — диде Басыйр, йомгак ясап. — Дөрес әйтәсең, бәйрәм иттек тә бит, әмма кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә! Менә мин быел шуны исәпләп чыгардым! — дип ярды Басыйр. Аннан аңлату тонына күчте: — Үзең беләсең, бик зәһәр сеңлесе бар бит аның. Кияү булып керәсе кичтә шул сеңлесе белән тавык суеп маташты болар. Теге зәһәр сеңлесе без ятасы җәймәгә шул тавык канын агызган булырга тиеш...

— Ә-ә?! — дип сузды Фәүзи, Басыйрга сәерсенеп карап. — Кара син аны! Синдәй егетне тавык каны белән алдаганнар диген, ә?..

Ул Басыйрга тагын бер текәлеп карады.

— Саубуллашыйк, Басыйр дус. Минем дә үзем белән бергә картайган хатыным бар бит. Чәй куеп, күзен тәрәзәдән алмый көтәдер.

Фәүзинең салмак, тигез адымнар белән өенә таба китеп баруын Басыйр сүзсез генә карап калды. Тик нигәдер күзләренә яшь бәреп чыкты, бугазына төер тыгылды. Нәрсә галәмәте булыр бу? Шатлык дисәң, шатлык түгел, кайгы дисәң, кайгы түгел... Ну бу Фәүзине! Каян таба диген сүзләрнең шундый шомлыларын?! Шундый күңелле көннең ямен җибәрде, котсыз!

*2004*

## *Баш чүмечендәге өч бөртек чәч*

Юмор яз әле, дисең син. Язарсың юмор!

Утырабыз ирем белән икәүләшеп телевизор карап, Кашпировскийның «Кояшкаем» дип эндәшкәнен тыңлап. Мин, гадәтем буенча, җайлап кына, ипләп кенә иремнең башыннан сыйпап утырам. Кашпировский пычаксыз операциясен төгәлләп, әкрен генә саный... Ике... өч... Шул вакыт иремнең башын сыйпаган бармакларыма дымсу нәрсә тия башлады бит. Әһә, мин әйтәм, килеште моңа Кашпировский дәвасы — кара тир чыга башлады, димен. Кара тир белән бөтен авырулары чыгар, боерган булса, мин әйтәм. Берзаман күтәрелеп карыйсы иттем бит мин моңа. Илаһым Кәрим! Иремнең башында ямь-яшел булып суган үсеп утыра! Күзләремә күренәме әллә дип, бер кыягын өзеп ашап карадым. Суган. Әйе, нәкъ менә кыш көне парникларда үстереп сатыла торган чын суган! Өзеп иремә дә бирдем, мәле, мәйтәм, ашап кара әле, башыңда суган үсә башлады бит, димен. Ашап карады. Суган, ди. Туктале, мәйтәм, суганын суган да, йолыкканда авыртмыймы соң башың, димен. Тартып чыгардым берсен тамырлары белән. Юк, ди, авыртмый, ди. Соң, алай булгач нәрсә карап торабыз, файдаланып калырга кирәк, мин әйтәм. Йолка башладым мин моның суганнарын. Йолка торам, йолыккан бер җиренә яшел суган үсеп чыга тора. Йолка торам, яшел суган үсеп чыга тора. Сатарбыз, мин әйтәм, иш янына куш булыр. Менә бит, ирнең дә кирәге чыга икән аның. Кухнядан йөгереп кенә зур табак алып килдем. Үзең дә йолкы, мәйтәм, хәзерге заманда хәләл көч белән генә баеп булмый, анда-санда Кашпировскийлар булышмаса, димен. Йолкабыз суганны: кәрҗин тулды, табак тулды, өстәл тулды, идән тулды. Әйбәт булды. Машина алырга акчабыз җитеп бетми иде. Әллә, мәйтәм, баш чүмечендәге өч бөртек чәчне йолкып ыргытып, анда да суган үстерәбезме, димен? Шулай дип әйтүем булды, иремнең акаеп каравы булды — әйдә, синекен йолкыйк, ди бу, минем башка үрелә. Шул мәлдә үк әллә ни булды үзенә. Тукта әле, тукта, дип, әсәренгән күзләре белән миңа таба килә башлады. Башыңны суган корты баскан лабаса. Их бу комсызлыкны! Иремнең баш чүмечендәге соңгы бер-ике чәчне йолкырга үрелүем булган, мине суган корты баскан икән! Минем өстән төшә торалар, суган өстенә каплана торалар. Үзләре эреләр, үзләре җәһәтләр. Ул комсызланып ашыйлар инде суганны! Колорадо коңгызларыннан да уздыра, ахры, болар дип уйлавым булды, Кашпировский утыз өч дип, чыгышына нокта куйды. Шул вакыт әлеге фетнә дә күз алдыннан юкка чыкты! Менә шулай, тау булып өелгән яшел суганнарны да, суганны төбе-тамыры белән ашаучы кортларыбызны да үзе бирде, үзе алды Кашпировский!

Моны ничек юмор итеп сөйләмәк кирәк инде?!

Трагедия бит бу! Шекспирлар язарлык!

*1989*

## *Эльмира Шәрифуллинаның басылып чыккан китаплары*

Безнең зоопарк: балалар өчен шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. — 32 б. — 200000 данә.
Яңгыр җиле: шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. — 78 б. — 1600 данә.
Мизгел: повестьлар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 96 б. — 6500 данә.
Гөлләр елы: шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 104 б. — 5000 данә.
Җитәкләшеп җил белән: балалар өчен шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. — 47 б. — 25000 данә.
Безнең зоопарк: балалар өчен шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. — 32 б. — 200000 данә.
Зәңгәр эңгер: шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — 112 б. — 3000 данә.
Асрамага бала бирәм: педагогик язмалар. — Чаллы: «КамАЗ» нәшр., 1994. — 80 б. — 2500 данә.
Зәңгәр каурый (Безнең зоопарк): балалар өчен шигырьләр. — Казан: «Мәгариф» нәшр., 1995. — 32 б. — 5000 данә.
Таң чыгы: шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. — 96 б. — 2000 данә.
Иң матур әни: шигырьләр, әкият-хикәятләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. — 40 б. — 5000 данә.
Безнең зоопарк: балалар өчен шигырьләр. — Казан: «Раннур» нәшр., 1999. — 34 б. — 100000 данә.
Алтын балык: әкият-хикәятләр. — Казан: «Мәгариф» нәшр., 2000. — 24 б. — 2000 данә.
Нәниләргә әлифба: балалар өчен шигырьләр. — Казан: «Хәтер» нәшр., 2000. — 20 б. — 10000 данә.
Ничек, нинди, ни төсле?: балалар өчен шигырьләр. — Казан: «Хәтер» нәшр., 2000. — 96 б. — 3000 данә.
Уйлы еллар: шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 287 б. — 2000 данә.
Алтын балык: әкият-хикәятләр. — Казан: «Мәгариф» нәшр., 2004. — 24 б. — 3000 данә.
Сөюемнән мин бер чибәр идем...: шигырьләр. — Казан: «Рухият» нәшр., 2005. — 528 б. — 2000 данә.
Кемнең уе кемдә: әкият-хикәятләр. — Казан: «Раннур» нәшр., 2005. — 64 б. — 50000 данә.
Казаныңа ни салсаң: укытучылар, педагогия көллиятләре һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. — Казан: «Мәгариф» нәшр., 2005. — 256 б. — 3000 данә.
Игезәк йолдыз: тарихи әкият. — Казан: «Мәгариф» нәшр., 2006. — 16 б. — 2000 данә.

## *Эчтәлек*

**Повестьлар**

Әтием
Җанлыдан җан яралгач
Алма апа
Мизгел

**Эсселар**

Мәхәббәтнең җиде төсе
Миһербан чишмәсе
Толларның да җаны бар

**Хикәяләр**

Закирә тирәге
Юрау
Язмышыңа язылсамы?..
Ашыгам, бик ашыгам
Энҗе
Нурлы хатын
Васыять
Нинди сәлам, шундый сәлам
Тормыш
Кояш баешы
Чиләгенә күрә капкачы
Мең дә бер кичә
Таш йөрәк
Ис сизү
Бишботлар юкка тавык суймас!
Баш чүмечендәге өч бөртек чәч

Эльмира Шәрифуллинаның басылып чыккан китаплары

Литературно-художественное издание

**Шарифуллина** Эльмира Мухамметовна

**Семь цветов любви**

Казань. Татарское книжное издательство. 2007
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Шәрифуллина** Эльмира Мөхәммәт кызы

**Мәхәббәтнең җиде төсе**

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Г.В.Панкратова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 07.06.2007. Форматы 84x108$^{1}/_{32}$.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 13,44. Шартлы буяу-оттиск 14,44. Нәшер-хисап табагы 14,34. Тиражы 3000 д.
Заказ С-644.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.